ISSN 0206-4189
Индекс 73210

12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

10.2015



№10 (1116) 2015



**Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның инаугурация тантанасында биргән анты:**

«Татарстан Республикасы халкына тугры хезмәт итәргә, гражданнар хокукларын һәм ирекләрен, ТР Дәүләт суверенитетын тәэмин итәргә, Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәргә, миңа йөкләнгән Татарстан Республикасы Президенты югары вазифаларын намуслы башкарырга тантаналы төстә ант итәм».

*18 сентябрь, 2015 ел.*

www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Хәтер көне. *Шигырь.* ....3
Вахит ИМАМОВ. Сөләйман солтан. *Тарихи роман.* ....4
Айрат СУФИЯНОВ. Чагылдырып чорның сурәтен. *Шигырьләр.* ....24
Рәфкать КӘРАМИ. Кая чабасың, гомер юртагы? *Роман.* ....28
Рифат ҖАМАЛ. Агымнарга ятып акмадым. *Шигырьләр.* ....83
Фарсель ЗЫЯТДИНОВ. Әремнәрне мактап җырлармын. *Шигырьләр.* ....102
Асия ЮНЫСОВА. *Хикәяләр.* ....105

**КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ**

Гүзәл ӘДҺӘМ. Меңнәрнең берсе. *Бәян.* ....86
*100нче бит:* Рабит БАТУЛЛА. Халыклар арасында оятка калмыйк инде! ....100

**ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ**

Ренат ХАРИС. «Җир шары рәисе» Велимир Хлебников. ....119
Велимир ХЛЕБНИКОВ. *Шигырьләр.* ....121

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЯҢА ДӘҮЛӘТЧЕЛЕГЕНӘ — 25 ЕЛ**

Чигенүме, җиңелүме? *( Р.Хәким, Р.Вәлиев, Ф.Сафиуллин, Д.Исхаков катнашында «түгәрәк өстәл»).* Р.Юныс әзерләде. ....126

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Ләйлә МИНҺАҖЕВА. Гашыйк күңел тибрәнеше... *(Җәүдәт Дәрзаманга 70 яшь).* ....143
Мәдинә МАЛИКОВА. Аның җырлары озын гомерле *(Мансур Шиһаповка 75 яшь).* ....147
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Милли китапханә: үткәне, бүгенгесе, киләчәге. ....150
Мөдәррис ВӘЛИЕВ. Баязитов «Нур» гәзитен ничек язып өлгертә? *(«Нур» газетасы чыга башлауга 110 ел).* ....153
*Шигъри хәтер:* Фирая ЗЫЯТДИНОВА. Тик яратып китик дөньядан. *Шигырьләр.* ....157

**ТАРИХ**

Нурулла ГАРИФ. Яр Чаллы түгел, Чаллы! ....160
*Тормыш язган хикәяләр:* Миңнеруй ГАЙФУЛЛИНА. Йөрәгем яна. *Хикәя.* ....164
*Укучыларыбыз иҗаты:* Зөйфә САЛИХОВА. Соңгы балкыш. *Хикәя.* ....166
*Мөгаллим мөнбәре:* Зөлфия ГЫЙБАДУЛЛИНА. Әхлак сагындагы шагыйрә. ....172

**ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ**

Рәис КӘЛИМУЛЛИН. Илгә тарих язганда. ....174
Б.ӘЮПОВ, Р.ГЫЙЛЬФАНОВА, Ф.ГРИГОРЬЕВА, Л.ГОЛЕМОВА, Э.ИХСАНОВА, Р.КӘЛИМУЛЛИН, Ә.МИНҺАҖЕВА, Ә.НОГМАНОВА, Г.ӘКСӘНОВА *шигырьләре.* ....175
*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....178

**АК ҖИЛКӘН**

Гадел КУТУЙ. Рөстәм маҗаралары. ....181
*Хикәя яза аласызмы?* Х.ИСМӘГЫЙЛЕВ, Э.РАЗОВА, Н.ВӘЛИЕВА *хикәяләре.* ....186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (әст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (әст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (әст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (әст.1268).*
**Факс** — *(843) 222-09-83 (әст.1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.09.2015, график буенча 30.09.2015.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-2766. Тираж 4010.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2015 ел



Ркаил
Зәйдулла

# ХӘТЕР КӨНЕ

*– Бүген Хәтер көне... Онытмадыңмы?*
*– Юк. Хәтерлим.*
*– Мәйданга чыгабызмы?*
*– Юк. Тышта карлы яңгыр.*
(Телефоннан сөйләшү)

Каракошның канат очы
Кагылганда болытка,
Яшен уйный мине кочып,
Һәм пышылдый: «Онытма!»
Давыл узган иде монда,
Ерак-ерак заманда.
Офыкларны каплап алган
Күләгәсе һаман да.

Хәтерлибез!
Әнә мин ул —
Ерып карлы яңгырны,
Сулышын тыңлыйм давылның,
Бәгыремдә тамыры.
Сөйгән ярның толымыннан
Кереш тартам җәягә —
Ук очкан аралык кадәр
Бүген минем бәя дә...

Хәтерлибез!
Хәтер көне
Гасырларга сузыла.
Тузгып калган учакларның
Җем-җем, җем-җем кузыдай
Төнне чәнчеп, ни ул?
Өнме?
Әллә соң бер вәсвәсә?

Карлы яңгыр ява тышта...
Һәм чапрәмә касә...



Вахит
Имамов

# СӨЛӘЙМАН СОЛТАН

ТАРИХИ РОМАН

## 1

Роксолананы таң атканда килеп урладылар.

Әүвәл яр өстендә кешнәгән атлар, урамда сүгенеп кычкырган ирләр, ачыргаланып елаган хатыннар һәм бала-чага тавышыннан сискәнеп уянды ул. Тәрәзәгә капланса, инде үзләренең ихатасына да җиде-сигез җайдак якынаеп килә. Кулларында сөңге, билдә ятаганнар. Кеш тиресе белән каймаланган чалма төсле бүрекләренә, көмеш җепләр өстәп чиккән якалы җиләннәренә карап та чамалавы җиңел — Кара диңгез буеннан күтәрелеп килгән татарлар бу!

Ишек янындагы ятагыннан әнисе дә сикереп купкан икән. Күрше тәрәзәдән тышка күз ташлауга, Роксолананы пәрдәләр яныннан эчкә сөйрәп алды да мич буендагы баз капкачына барып ябышты.

— Татарлардан исән-имин котылырмын димә, базга сикер, балам!

Өлгерә алмадылар. Имән ишекне албастыдай тибеп, бусагадан берсе — колга сыман озын, икенчесе карсак буйлы ике татар керде. Колга буйлысы әле ишектән үк көянтәдәй бөгелеп узган иде, өй эчендә дә тураеп баса алмый, баш түбәсе түшәмгә тия. Хәер, ана аягүрә тору кирәкмәде сыман, тупсаны атлауга, юлбарыстай ыргылып, ул түр почмакта торган лампада өстенә капланды.

— Алтын! Алтын!

Колга татар лампаданы юлдашына сузып ыржайса да, тегесе аңа таба борылып та карамый, аның бар дикъкате күкрәкләре түгәрәкләнеп килгән, озын буйлы, саргылт чәчле кызда.

— Хатынлыкка әле яшь булса да, җәйрән шикелле гүзәл бүләк бит бу! Ясир, ясир!

Татарларны моңа чаклы базарлардан башка җирдә күргәннәре дә юк, әмма «алтын, ясир» дигән сүзләрне генә икесе тин чамалыйлар иде. Житкән кызын сыны белән каплап, әнисе шундук Роксолананың алдына чыгып басты.

— Юк, юк, балакаем чирле! Аның кешеләргә йога торган яман зәхмәте бар!..

Колак салмадылар. Колга татар әни кешене читкә этәрде. Карсак буйлысы, Роксолананы кулыннан эләктереп, тышка томырылды. Әнисе, ялгыз калган

---

Вахит ИМАМОВ (1954) – *язучы; «Татарларның Ватан сугышы», «Сәет батыр», «Утлы дала» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

аккош тавышлары белән ачыргаланып, ихатага тикле сөйрәлеп чыккан иде дә, колга татар анын җиләнгә ябышкан кулына чапты.

— Ән-ни, әникәем! — дип өзгәләнеп, Роксолана анын баскыч төбенә ауган гәүдәсенә таба ыргылып карады, тик карсак буйлынын кысла шикелле ябышкан кулларыннан ычкына алмады. Аннары инде тау өстендә куначадагы күркә шикелле кукраеп утырган чиркәү тарафына текәлде дә, чүл бүреседәй улап, шунын өстенә нәгърә-ләгънәт орды.

— Әткәй, әтекәем! Бу чиркәүне кирмән шикелле корып куйган чакта «монда ярты шәһәребез сыя, айлар буе камап тотса да, дошман аңа керә алмаячак», дип шапырган иден лә син. Нигә пономарьларын белән генә кереп бикләнден дә нишләп безне яклаучысыз көе ташлап калдырдын соң?!.

Роксолананы яр буена тезелешкән зур баркаслар янына сөйрәп төшерделәр. Монда инде ясирләрнен саны илле генә бардыр. Араларында юлда җәфа булырдай сабыйлар да, чәчләренә чал кунган карт-корылар да юк. Тоткыннарнын күпчелеге җиде-сигез, унөч-унбиш яшьләрдәге кыз-кыркын һәм ташбаш малай-шалай. Роксолана белән бер урамда яшәп, әле бер ай элек кенә туй үткәргән Давид белән Ярослава да ятьмәгә эләккән, димәк, йә аларнын ирле-хатынлы икәнен белмәгәннәр, йә аерым-аерым сатып җибәрергә уйлаганнар инде...

— Рокса, Роксакаем! — дип пышылдаган тавышны ишетүгә, Роксолана баркаслар тарафына йөзен борган иде, анда юан колгага куллары каерып бәйләнгән Николаңы шәйләп, салкын тиргә батты.

— Сине... сине дә эләктерделәрмени, җаныкаем?

Роксолананын: «Тагын бер-ике ел узса, кавышырга, туйлар уздырырга сүз куешкан идек бит, Никола, оһ, Николка!» — дип кычкырасы килде, ачы төер бугазыннан алды.

— Син холкымны беләсен, мин беренче җай чыгуга ук болардан качачакмын, — дип җилкендергән булды Никола үз-үзен, дошманнары белән сугышырга җыенган ярсу әтәч сыман. — Утлы казанга салып кайнатсалар да, мин татарларга буйсынначак түгел!

«Бөтен әсир дә шулай үз-үзен юатып китә була инде, тик берсенен дә татар элмәгеннән котылып кайтканы юк әле», — дип Роксолананын күнелендә мен төрле уй бөтерелде, моны сөйгәненә генә житкермәде.

Ә ул арада ясирләрне баркасларга аерып утырта башладылар. Роксолана Ярослава белән бер баркаска эләкте. Ярослава өзгәләнә, көенә, әлбәттә. Кайчан гына авыз ачмасын, телендә бертөрле сүз:

— Булачак балам бар дип күнел юатыр идем, их, авырга да узып куя алмадым шул!..

Ярослава көтүдән аерылып калган колын сыман як-ягына карана, гел Давидын эзли. Роксолана да шәйләп өлгерде, татарлар — әсирләр белән эш итәргә нык өйрәнгән халык. Әнә, Днестрга таба борып куелган ин беренче баркаска Давид шикелләрәк яшь ирләрне, Никола чамасындагы унҗиде-унсигез яшьлек егетләрне җыеп утыртканнар. Әле яр өстендә чакта ук күбесенен кулларын йә сыртларына каерып, йә колгаларга бәйләгәннәр иде. Баркаска керүгә, муеннарына элмәк ташлый-ташлый, әсирләрне бер арканга беркетә башладылар. Янәшә бәйләнгән ике ир арасы кул сузымыннан артмый, берсе саксыз читкә ыргылдымы, яндагылар буылып гырылдаша. Ул да түгел, яннарына, эт сыман сикереп, татар сакчылары килеп җитә, сөлгегә уралган «бияләйле» камчы белән котырып яра башлый. Татарлар өчен коллар — туган-тумача түгел, алар өчен һәрбер ясир — сатасы мал, керәсе акча бит. Николакай юкка әтәчләнә, болар кулыннан, бар, ычкынып кара...

Икенче баркас борынындагы мәйданчыкка менеп баскан бер ир баш атаман,

ахры. Көтүдәге ана бүре булгач, ана кәрван мангаенда барган караб борынына атланып алса да ярап куяр иде. Юк, беренче карабка талаудан кайтышлый йә дошманнар, йә үзләрендәге чит ырулар ябырылу мөмкин. Жаны бик кадерле, ахры, шуна күрә атаман чит-ят ышыгында, күләгәдә кайта. Ә күзләре тавык кетәклегенә менгән сасы көзәннекедәй елгыр. Анын куе кашлар астыннан сузылган карашы, яшен уйнагандай ялт-йолт итеп, әле баркас идәненә тезелешеп утырган әсирләрне, әле елга буйлап буар елан сыман сузылган кәрвандагы каекларны, карабларны барлый.

Менә, бер мизгелдә анын яшен угыдай очлы күз карашы Роксолана тәнен көйдереп-капшап үтте, кызый утлы күмергә яланаяк баскан шикелле куырылып калды. Каек-баркасларда Роксоланадан да тулырак ботлы, мул күкрәкле, күзләре кар базына эләккән мәченеке сыман уйнаклаган кызлар йөзәрләгән бит, ник шуларны күзләми, авызына төкерим?!. Нигә дип кипкән такта төсле ябык тәнле, нечкә сыйраклы, елый-елый инде күз төпләре эренләнеп беткән ятимне бораулый ул, әй, пычагым кергере!..

Кыз үзен кимсетеп ялгыша, ә кәрван атаманы житкән орлыкны солычадан гына аера белә иде. Рогатин кирмәнендә ятьмәгә эләккән Роксолана ундүрт-унбиш яшьләр тирәсендә генә, хатынлыкка бирергә дә иртә. Иллә мәгәр ияртезгеннәрне татымаган тай яисә капкын-тозакларнын ни икәнен дә белмәүче дала жәйрәне, кыргый болан бит бу! Дала малы, кыя-тау асылкошлары симез буламыни? Әнә, инбашларын аз гына төзәтсә дә, тулган алма, нәни карбыз кебек кабарып уйнаклаган күкрәкләрдә бит бөтен дөнья тәме, дәрт һәм гайрәт! Ә ертык итәк астыннан чыгып идән буенча сузылган озын, төз ботлары! Уч төбенә сыеп бетәрдәй бил астында — түгәрәкләнгән ике йомшак мендәр. Аккошныкы төсле озын, чиста муен. Иңнәрендә елан сыман боргаланган ике саргылт толым. Пешкән чия кебек мул иреннәр. Зәмзәм суы белән юылган шикелле керсез, зәңгәр күзләр. Каз канаты, тал бөресе сыман йомшак, ап-ак куллар. И-и, мондый хур кызыен йомшак түшәкләрдә, шәрә көе генә сөеп торсаң икән!..

Роксолана төнлә инбашына чит бармаклар кагылудан сискәнеп күзен ачты да, каршысында чеби алырга төшкән тилгән төсле канатларын жәеп баскан атаманны шәйләгәч, шәрран ярып кычкырмакчы булды. Тик ул авыз ачарга да өлгермәде, икенче мизгелдә усал куллар анын йөзен, иреннәрен япты. «Дәшмә, жаный, дәшмә», — дигән пышылдау авазы елан ысылдаган сыман ишетелде. Аннары атаман аны песи баласыдай бөтереп эләктерде дә, күкрәгенә соскан көе, баркас мөгезендә ясалган мөнбәр астындагы базга күтәреп төште. Монда барысы да алдан хәстәрләнгән: түрдә балавыздан ясалган шәм яна, идәндә — ястык-түшәк, аяк очында шәраб шешәләре, касә белән хөрмә-йөземнәргә чаклы әзер иде.

— Жаный, жаный! — дип янып кабатлады да атаман Роксолананы әүвәл түшәк өстенә ташлады, аннары сугым малын чалырга жыенгандай, әзмәвердәй гәүдәсе белән аны изеп ятты. Үзе ике казык арасына кысылып буылган малдай калтырана-гыжлый, ә уң кул бармаклары, итәк астына чумгач, адашкан сукбай төсле, эләктереп алырдай тотка-яр эзләп йөзә башлады. Әмма итәкләр күп катлы, атаман хыялланган жәннәт бакчасына хәтле ерак иде әле. Роксолана ул арада әүвәл тешләрен атаманнын муенына батырды, тегесе утта куырылган каен тузы шикелле читкә бөгәрләнеп төшүгә, әллә кайдан гына пәйда булган нәни хәнжәр асбастыдай ирнең беләк-инбашларын телеп-тырнап узды. Ләкин тәүлек буена коллык газабын кичкән кызнын айгыр кебек гаярь ирне жиңә алырдай көч-куәте калмаган иде инде. Бер арада атаман Роксолананын хәнжәрен кулларыннан каерып алды да чүлмәк чаклы дәү йодрыгы белән кызыкайнын йөзенә китереп бәрде.

— Аh, син, кара елан! Мин бит сине суга тотып атам!

Атаман түшәк астыннан сөлгеләргә уралган камчысын суырып чыгарды һәм Роксолананы утын пүләне урынына тотып бәргәләргә, ярырга тотынды. «Һе, каеш камчы белән кыйнаудан тыела бу, димәк, сатып җибәргәнче мине яраҗәрәхәтсез көе сакламакчы була», — дип уйлап юанырга өлгерде Роксолана, ә бераздан, барыбер дә, туктаусыз тукмаклардан бөтенләй онытылды...

## 2

Корабларны, Кырым тирәли урый-урый баргач, көнчыгыш ярдагы Акмәчет портына китереп туктаттылар. Бу юлы корабларның кайнар чүлләр үтеп җилгә суырылган карт сәйяхләр төсле ярга борын төртеп тынуы да, палуба өстендәге татарларның шайтан туена эләккәндәй кул чәбәкли, акыра-акыра биеп йөрүе дә һәммәсен сискәндерде. Днестр елгасы буйлап төшкән чакта Дубоссары, Тирасполь атлы калалар янында да тукталганнар иде бит, югыйсә. Тик ул чакта татарлар баркас-корабларны яр буена якын китермәде. Елга уртасында гына су төбенә тимер тырнак ташлап, кәрван үзе җиде-сигез дилбегә арасы читтә торып калды. Су белән азык-төлекне көймәләргә тутырып ташыдылар. Әсирләрнең зынҗыр тарта-тарта аяк-кулы шешеп, сусыз интегүдән тамак һәм тәннәре кибеп беткән иде, кул сузымында зур-зур портлар күргәч, сөенделәр хәтта.

— Безне барыбер коллыкка сатачаклар. Җәһәннәмгә китеп югалганчы, бу тирәгә эләгеп калу күпкә отышлырак. Монда, ичмасам, безнең диндәгеләр. Өстәвенә йә качып китүең, йә, хәбәр юлласаң, Подолиядәге туганнарың килеп алуы бар, — дип юандылар да әле.

Боларны ишеткәндәй, ике кала янында да ике-өч ир белән дүрт-биш кызны, арканнардан чишеп, көймәгә төшерделәр. Яр өстендә боларны җайдакларга тагып җибәрүләрен күрүгә үк, һәммәсе дә бүтәнчә төкеренде.

— Юк, түгелеп-чәчелеп бетү бер дә әйбәт түгел. Коллыкка сатсалар да, бергә-бергә китү хәерлерәк.

Роксолана гына бер дә сөенмәде. Күңеленнән ул инде меңенче мәртәбә аны якламаган, аны коллыкка озаткан әтисен һәм илен сүгә иде.

Гомер буе чиркәү побы булып йөрде аның әтисе. Ата да, атакай да. Көннәр буе чиркәүдән кайтып керүне белмәде, куна-төнә шунда малай-шалайларны укытып ятты. Ихатага яңа капка кую, өй түбәсен ямау, абзар-келәт, койма төзәтү кебек дөнья мәшәкатен йә чиркәүдән ул юллаган пономарьлар, йә көмешкә хакына ялланган күрше-күлән башкарып килде. Әнисе күндәм, нык басынкы иде. Роксолана бәләкәйрәк чакта, әтисе өйгә кайтмый калган һәр кич саен «Гаврила-атакай яшь кызыйлар култык астына иләнгән җеннәрне куарга өйрәнгән, шуңа Серет станицасындагы яшь киленнәр аңа тигәнәк шикелле ябышалар, имеш», шикеллерәк сәер сүзләр ишетелде. Соңга таба алар яшәгән Рогатин шәһәрчегендә «Гаврила-атакай чиркәү мәктәбендә гел бер малай белән йоклап кала икән», дигән гайбәт бураны да купты, ә әнисе күтәрелеп барыбер бәрелмәде. Шунадыр, ахрысы, Роксоланага энекәш-сеңелкәшләр дә алып кайтмадылар.

Соңгы елларда аларның ләһләр[1] — «Подолия», хохоллар «Галитчина» дип атаган өлкәсен юлбасарлар килеп таларга күнекте. Төн уртасында йә таң атканда эт өере сыман һаулый-һаулый бәреп керәләр дә, ярты шәһәрчекне ялкын-утка урап, тоташ талап чыгалар. Шул афәттән качып калмакчы булып, барча ирләр, җыелышып, чиркәү тирәли дивар төзеделәр. Рогатин тирәсе кыя ташларына гаҗәеп бай, янәшәдә — Карпат тавы астындагы озын мәгарәләр. Шуннан ташыган ташлар белән чиркәү коймасыннан чып-чын кирмән ясап бетерделәр, идән астына йөзәрләгән кеше сыярлык мәгарәләр казыдылар хәтта.

[1] Ләһ — поляк халкының элекке атамасы.

тик ни файда? Гаврила-атакай үзе качып калды, ә хатыны белән бердәнбер кызыкаен юлбасарлар кулыннан коткара алмады бит. Ходай Тәгалә алдында, мөгаен, гөнаһтыр да, әмма шул кешегә ләгънәт укымыйча ничек юанасың?!.

Роксолананы әле Акмәчет портына килеп туктагач та менә шундый уйлар талый иде. Татар сакчыларының тыз-быз килеп йөгерешә башлавын күргәч кенә йокысыннан уянгандай булды. Юлбасарлар кузгаткан ыгы-зыгы юкка түгел икән. Караб буйлап янгыраган хәбәрләр, сәмум җиле сыман, һәммәсен дә бердәм көйдереп узды.

— Ясирләрне карарга Хаҗиәхмәт вәзир үзе килә.

— Ясирләрнең киемнәрен алыштырырга, кыяфәтен ипкә-сапка китерергә кирәк.

— Юлда тотып ярганнан соң, кул йә кабыргалары сынган алабайларны караб трюмына яшермичә булмас...

Әсирләрнең күпчелеге ләһ яисә хохол булса да, арада татар телен чамалаучылар да байтак икән. Сакчылар камчы күтәреп килә башлауга ук, әсирләрнең күпчелеге өс-башларын барларга тотынды. Кемдер алмаш киемнәрен өеннән үк эләктереп чыгарга өлгергән, икенчесе сакчылар эткә ыргыткан сөяк урынына китереп ташлаган күлмәкләргә төренергә дә риза. Роксолана гына һич селкенми, черек бүкән шикелле тик утыра. Хаҗиәхмәт вәзир дигәннәрен дә ул кылкаланып беткән киемдәге килеш каршылады. Ә вәзирнең күзе атаманныкыннан да зәһәррәк һәм үткен булып чыкты. Роксолана турына килеп җитүгә үк, болай да дугаланып торган кашларын бөтергәләп, күз карашын уйнаклата-уйнаклата, атаманга дәште.

— Бу пәрине базарга алып чыгарсың. Биш-алты йөз динарга сатып алучы табылса, озатсаң да була, чукынып китмәгәе. Хатынлыкка бирергә иртәрәк бит моны, хәтта җария ясар өчен дә айлар-еллар буе тәрбияләп, өйрәтеп чиләнергә кирәк. Мәгәр инде тулысы белән берәр мең динар чыгарып салучы ахмак пәйда булса, бии-бии биреп җибәрерсең моның ише чеп-чи йомырканы. Монда хуҗа табылмаса да, терсәкләрне тотып тешлисе юк. Истанбулдагы бер яшь паша тау кәҗәседәй кыргый кызлар сорап тинтерәтә, ахыр чиктә шуңа озатырбыз. Җәфа, чыгым өстәләчәк инде өстәлүен, тик төрек пашаларының табаннарын яламыйча да булмый...

Әсирләрне кала читендәге зур базарга куып китерделәр. Рәтләр арасыннан үтеп барган чакта Роксолана шаккатудан тәмам телсез калды. Яр буендагы мәйдан чаптар атлар, яшь дөяләр белән шыплап тулган. Базарны түгәрәкләп алтын-көмеш, фарфор-керәч, күн итек вә читек, түбәтәй һәм чапан, чүлмәк-казан, савыт-саба тезелгән кибет йә чатырлар урап алган. Ә уртада — санап бетергесез егетләр һәм кызлар белән тулы коллар базары. Арада кем генә юк! Җиргә җиткән киндер күлмәк киеп, сап-сары толымнарын иңбашына салган кызларның килеш-килбәтләре, карашлары күндәм. Болар йә үз тәкъдирләре белән күптән ризалашкан, йә аларга кем алдында итәк күтәрсә дә аерма юктыр инде. Әтисенә ияреп барган чакта Роксолананың мондыйларны Подольски базарларында да күреп кайтканы бар. Урыс кенәзлекләреннән җыеп китерелгән маржа инде болар. Ләһ алпавытларының аларны түбәнсетеп көлгәне дә истә. Болар асларына балаклы ыштан киюне белмиләр дә, имеш. Кызык, итәкләрен күтәреп карасаң, чынында да бар зиннәте ачык тора микән?..

Сагыз төсле куе кара чәчле, ятагандай кәкре борынлы егет-кызлар Каф таулары арасыннан тотып китерелгән чиркәс, гөрҗи, әрмән булулары мөмкин. Аларны бик кыю, башбирмәс халык, дип сөйлиләр сөйләвен дә, әмма кул-аякларын зынҗырга урагач, чебен дулап тәрәзәне вата аламыни?..

Итәк сымак киң балаклы ыштаннарга төренгән егетләрне ләһ авылларыннан куып китергәннәр, монысында шик юк. Каш-керфекләренә чаклы житендәй

аксыл-саргылт төсле колларның алман, латыш яки норман булулары мөмкин. Роксоланалар килеп туктаган порт бугазында әләмнәренә баш сөяге сурәте ясалган караблар да басып тора иде. Әнә теге, ут өстендә ыслап киптерелгән балык шикелле арык сынлы, бакыр тәнле колларны шул караблар Сүрия, Мисыр якларыннан ук китермәде микән?..

Подолиядән китереп бушатылган кыз-кыркынны мәйдандагы зур чатырлар күләгәсенә тезеп бастырдылар. Учакка аскан казан төбендә бер чүмеч су кайнарлык ара да үтмәгәндер, балтасын суга төшергән шикелле кара көеп торган Ярослава янына зур корсаклы татар килеп житте. Базарда тылмачлар санап бетергесез булса да, бу үзенә кипкән яңаклы, ике яклап иякләренә асылынган чал мыеклы, каешланып беткән түбәтәйле бер картны да иярткән. Зур корсаклы агай тирә-юньдәгеләрдән һич тарсынып тормыйча Ярославаның күкрәкләрен, билен капшый башлады, күз ачып йомганчы итәген дә биленә кадәр күтәреп, яшь хатынның ботларына кул учлары белән шапылдатты. Инде синен чират, дигәндәй ым кагуга, каеш түбәтәйле карт төпченергә тотынды.

— Сезне Галитчина ягыннан китерелгән, диделәр, гуцул яисә хохлушкадыр инде. Атан-анан, туганнарын бармы? Тегеләр белеп алса, качарга да жыенуын мөмкин.

— Мин кияүдә! Теге якта, әнә, минем ирем! — дип Ярослава каршы якка бармак төртә-төртә кычкыруга тылмач картның мыегы да селкенмәде хәтта.

— Бәрәкалла, кияүгә дә чыгып куйдыңмыни? Бала табарга да өлгердеңме әллә? Ә-ә, юк икән, алайса, менә монысы шәп.

— Мин кияү төшәгендә ике атна гына йоклап калдым, — дип Ярославаның тагын шашып кабынуына каршы чал мыеклы картлач кеткелдәде генә.

— Бик хуп, бик хуп. Женен иләтеп өлгермәгән, димәк, бозылмаган. Минем хужага тач шундыйлар кирәк...

Зур корсаклы татар атаманны дәште, озак даулаштылар, «өч йөз, дүрт йөз», дигән сүзләр янгырап ишетелде. Зур корсакның тәкате корыды, ахрысы, янчыгыннан биш алтын динарны чыгарып, атаманның учларына атты. Икенче мизгелдә ул Ярославаның кулын әләктереп алды да мәйданнан читкә сөйри башлады. Ике якта ике өзгәләнгән тавыш яңгырады.

— Давид, мине синнән көчләп аералар, хуш, бәхил бул, жаным!

— Мин эзләп табармын, коткармыйча калмам, Ярослава!..

Үтеп-сүтеп йөрүчеләр Роксолана янына да еш тукталды, иярләреннән төшми генә барган хәрбиләр дә күз уйнатып узды. Атаманга килеп сүз кушсалар да, тегесе кул селтәгән шикелле жавап тотты.

— Әй, яшь бит әле ул, пешеп өлгермәгән. Пешекче итеп сатсан, аш-су рәтен белми, ни әйтсән дә, чиркәүдәге каратун баласы бит. Жариялеккә тотарга да иртә, хезмәтче итеп жигәргә дә кызганычрак инде.

Үзенә игътибар бирмәүләренә Роксолана әүвәл сөенгән иде дә, тора-бара мин-минлеге бүселеп-бүртеп чыкты. «Минем хакта сорашып, тәннәремне капшап караучы да юк, әйтерсең лә эштән чыгарылган, бозык, үтмәс тауар. Кул-аягым — гарип, кыяфәтем төкерерлек түгел, нишләп сайлаучы юк, вәт әкәмәт?!»

Тора-бара мин-минлек яки аптыраулар да томан сыман тарала гына барды. Татарлар бик саран, болар илле йә йөз тәнкә өчен дә бугазга-бугаз килергә торалар икән ләбаса. Ике агайлы-энеле татар шаккатырды. Алар Рогатинның чишмә ягындагы бистәсеннән куып китерелгән гаиләгә күз салган. Теге бичараларның ире дә, хатыны да яшь-яшь, ләкин яннарында күкрәк баласы бар. Базарга янчык күтәреп чыккан татарлар атаманнан йә хатынның япа-ялгызын, йә ире белән икесен генә сатып жибәрүне таләп итә, болар күкрәк баласын күз уңына да элми. Атаман күнмәгәч, яңгындагы сыман жәнжал куптаралар.

— Үләт чирен кичергәндәй ябык шушы ике карачкы өчен өчәр йөз дә, бу имгәге

өчен янә ике йөз динармы? Кит, шайтан алгыры! Моның ише җәфаны фәлән еллар буе ризык түгә-түгә асраганчы, Солхатныкыларга ияреп китәбез дә валах[2] белән болгар ярыннан үзебез үк йөзәр-йөзәр ясир җыеп кайтабыз бит. Синдә генә караблар бар да, син генә ди Алланың кашка тәкәсе, кит, имансыз!..

Кояш яр өстеннән дингезгә таба авыша башлаганда, Роксолана каршында да көмеш җепләр белән чигелгән киң җиләнле, үзе чегән шикелле чутыр-кара бер ир пәйда булды. Кырык-илле яшьләр тирәсендә, буйга озын, чандыр. Гөманлап торасы юк: житкелекле, милекле татар инде. Тик Роксолана аңа тәүге тапкыр күтәрелеп карауга ук кактай куырылды. Көмешләп чигелгән җиләнле татарның бер күзенә тоташтан ак сауган, аңа тетрәнмичә карап булмый икән. Кызганыч кеше, әлбәттә, ләкин шушы албастының да аңа хуҗа булып куюы бар бит!

Ә сыңар күзле ир, асылда да, хуҗа була икән. Менә ул атаман белән ике-өч кенә сүз алышты да янчыгындагы йөз алтын тәнкәне аңа бирде. Роксолананың күкрәкләрен дә, ботларын да капшап маташмады, сыңар кулы белән алга, пар ат җигелгән көймәле арбага таба юл күрсәтте.

— Әнә, теге паланкин минеке, шуңа кереп утыр.

Бәрәкалла, бу кызганыч булып күренгән татар хохолча да оста белә икән. Кыз-зык. Хохол телен нигә өйрәнгән дә сыңар күзе ничек гарипләнгән? Әллә, әллә чутыр-кара бу ир элек аның Подолиясен, шундагы Бережаны яки Збруч тирәләрен талап баеганмы?

Көймәле арбага җайлап урнашкач, яңа хуҗа ачыклык кертүне кирәксенде бугай.

— Син күрмәдең, ә мин сезнең барчагызны да базар читендәге бер чатыр төбәсеннән озак шәйләп тордым. Синең хакта «кыргый, беркемне дә үзенә якын җибәрми», дигән сүзләрне дә ишетеп калган идем. Ә миңа һәрбер ир-атка итәк ача торган кәнтәй хаҗәт түгел. Миңа тугры, гадел була белгән сердәш кирәк. Шул өметтән сине сайладым да.

Яңа хуҗа башкача бер сүз дә өстәмәде. Акмәчет читендә, зирек, кипарис, пальма агачлары белән уратылган киң ихата эченә кайтып туктадылар. Тышы акшарланган зур гына йорт баскычлары буйлап күтәрелгәч, хуҗа түрдәге бер бүлмәнең ишекләрен ачты.

— Монысы — синең бүлмәң. Өс киемнәреңне барлап азапланма. Мин мунча ягарга да, күлмәкләр алырга да кушып киткән идем, юынып чыккач, сайлап киенерсең.

«Коры тотмакчы бу, — дип уйлап куйды кызый. — Ашыккан — ашка пешкән. Дилбегә-тезгеннәреңне бик үк уйнаклатма».

Санаулы минутлар узуга ук, яшел җиләнгә төренгән хезмәтче кереп житте.

— Хуҗа сине мунчага алып барырга кушты, әйдә, киттек.

«Бүген үк кулга ияләндерергә, йөгән кидерергә җыена бит бу миңа, бармыйм, бармыйм», — дип үз эченнән генә ярсып утырса да, хезмәтченең атлы казак сыман басып торуына түзмичә, барыбер дә купты. Мунча дигәннәре ихатада гына, түрбакчада яшел сәрби куаклары артына яшеренгән икән. Тыштан тәбәнәк һәм кечкенәрәк булып күренсә дә, эче кояш нурлары сибеп чыккан шикелле якты һәм чиста. Иданнәрдә келәм, түрдә өстәл, аны чынаяклар һәм пар бөркегән кувшин бизәп тора. Диварларына күп-күп төрле көмеш яисә кереч тәлинкәләр эленгән, түр почмакны хәтта дүрт-бишләгән ятаган да бизи. Бик килешле, иплe, тик моның юына торган урыны, ләгән-комган ише әйберләре кайда?

Көтмәгәндә ян диварда ишек ачылды да анда анадан тума баскан хуҗа пәйда булды.

[2] Валах — румын халкын XIX гасыр уртасына чаклы шулай дип атаганнар.

— Нишләп көттерәсең? Чишен дә кер.

Жилкенчәк кызның тораташтай калуы аптыратты бугай, янә өстәп куйды.

— Ходай Тәгалә язган тәкъдирдән барыбер качып булмый, кер, дидем бит.

Роксолана һаман селкенмәде, ә хужаның түземлеге бетте. Ул аның өстендәге кылкаларны ертып төшерде дә, кызый бер кат эчке күлмәк белән торып калгач, кулларыннан сөйрәп, эчкә алып керде. Мунча һавасы кайнар, монда бер як түрдә агач ләүкә, ләгән-комганнар да тезелешеп киткән. Бер почмакта чумып чыгу өчен бик зур мичкә дә бар. Тышкы яктан бер дә болай иркен булып күренмәгән иде, ә эчендә кергәч алашырлык икән. Ярар, Ходам, инде тагын ниләр күрсәтерсең?

Хужа Роксолананы ләүкәләрнең берсенә илтеп утыртты, каршысына берсе кайнар, берсе салкын сулы ләгән тезеп куйды. Үзе әүвәл читтәге бер урындыкка барып чөмәшкән иде дә, аның ягына күтәрелеп тә карарга базмаган Роксоланага текәлеп утыра-утыра мин-минлек жене котырынды бугай. Ул урыныннан кисәк купты да, юлбарыстай сикереп, кызның иягеннән эләктереп алды, йөзен үзенә караткач, усал итеп дәште.

— Сынар күзле булсам да, бер генә иргә дә бирешмим. Синең кызганулы карашларыңа да мохтаж түгел, түгел! Мине ничек бар, шул көенчә ярат!

Роксолана авызына су капкандай берни эндәшмәгәч, хужа аның соңгы күлмәген изүеннән кендегенә чаклы умырып төшерде, кипкән ireннәре белән кызның күкрәкләренә капланды. Иреннәре шаша-шаша күкрәк очындагы нәни чияләрне суыра, ә куллары ике тез арасына кереп чумган иде. Роксолана әүвәл аны бар куәте белән читкә тибеп жибәрде, ә аннары янда торган кайнар сулы ләгәнне эләктереп, шәрә ирнең чыраена сипте. Мунча эчен шырыйлап акырган тавыш күмеп китте. Икенче мизгелдә Роксолана, капка-ярык эзләп, ихата түренә таба болан шикелле сикергәләп, дулап чаба иде инде...

3

— Әйттем бит мин сиңа, берзаманны барыбер үзең йөгереп киләчәксең, дидем. Барыбер итәгеңне ачып ятачаксың, дидем. Шулай булачакны аллан белгән идем, көтеп йөргән идем.

Атаман аны баркаста авызын колагына хәтле жәеп, шундый сүзләр белән каршылады. Роксоланага исә озын ай буена караб трюмына качып яшәргә туры килде. Сынар күзле «хужа», колын эзләп, порт ярына ике-өч мәртәбә килеп китте бугай. Соңгысында атаман күн янчыгын күтәреп чыккан иде, «хужа» бәндә шуннан ары бүтән күренмәде.

Озын айны түгел, ялгызлыкта бер тәүлекне үткәрү дә газап. Аның каравы, көтмәгәндә, Роксолана Мөхәммәтгәрәй ханның Хажиәхмәт атлы бер вәзире белән танышты бит. Хажиәхмәт вәзир дә, качак кыз сыман ук, яр буена төн кергәндә үзе килеп житкән. Трюм капкачы ачык калган иде, Роксолана атаман белән вәзир әңгәмәсен озак тыңлап ятты.

— Хан хәзрәтләре мине Венага юллады, шунда китеп барыш. Андагы каһанлык эчендә олы буза купкан. Бер якта — австрияилеләр белән хорватлар, ә боларга каршы чех белән мадьярлар, ди. Австрияинеке дигәннәре Каф тау итәгеннән Паннониягә күчкәч көчләп чукындырылган аварлардыр инде ул, мин шулай гөманлыйм. Ул аварларны тәре явы белән килгән баварлар йә саксоннар чукындырган булырга тиеш. Трансильвания атлы вилаятьләрендә чех-мадьярлар Янош атлы байгураны корольләре итеп сайлап куйган. Ә рум белән алман кубызына биюче австрияилеләр Буда каласына жыелганнар да ләһләр шаһзадәсе Лайош-Людвикны тәхеткә күтәргәннәр. Лайош дигәннәрен алман илә рум каһанлыгының короле Карл яклый, мәгәр тегенә падишаһ дәрәжәсен йөртүне каттый тыя икән. Имеш, күктә ике кояш булмаган шикелле, жир йөзендә дә ике король идарә итә алмый. Ул

Карл Лайошка эрцгерцог атлы исем йөртергә рөхсәт иткән. Янош белән Лайош хәзер үзара яу чаба, һәркайсы да үзен иң хокуклы хаким итеп саный, кан коя ди. Ә көтүдәге ике тәкә сөзешә башладымы, бүреләргә бәйрәм, чөнки икесе дә алар тәгамына барып керәчәк бит. Аннары ике айгыр тибешкән җирдә төк коелмый калмый. Менә шуңа күрә Мөхәммәтгәрәй хан мине мадьярлар короле Янош эргәсенә юллады да инде. Аңлавымча, үз ихтыяры түгел, Истанбулдагы Сәлим солтан боерыгы бугай. Аурупаныкылар солтан галиҗәнапләренә тиктомалдан гына «Явыз» кушаматын китереп такмады бит. Сәлим солтан яшь бәрәннәр абзарына кергән бүре төсле. Бер бәрән бугазыннан тешләрен чыгарып өлгерми, инде икенчесен ботарларга тора. Әйдә, ярар, минем эшем түгел. Мин боларны нигә сиңа бәйнә-бәйнә сөйлим? Чөнки җай табылса, ул яклардан да әсирләрне туплап кайту мөмкин. Буза вакытыннан файдаланып, безгә дә үзебезнең хәзинәне ишәйтү отышлырак. Йә, син инде Истанбулга кәрван тупладыңмы?

— Биш йөз әсир әзер. Шуларның берсен чакырып, синдәй олуг вәзир галиҗәнапләрен дә шаккатыра алам.

— Йә-йә, анысы кем тагын?

— Әлегә серне ачмыйм, үзен чакырыйк соң. Чамалап карыйм әле, тиз танырсың микән?..

Шул минутта ук яр өстендә атаманның тамак төбе белән кычкырган тавышы ишетелде.

— Рокса, Роксолана! Ярга чыгып күрен!

Качак кызый хан вәзирен әүвәл танымады. Хәер, вәзир үзе дә йөзәрләгән әсир арасындагы чандыр гәүдәле, йомыкый кызны ятламаган иде. Әмма Роксолана яр өстенә чыгып басуга ук күзләрендә шайтан уты бии башлады, сулышлары капты.

— Бәрәч-бәрәч, ошбу чәчби син Подолиядән алып кайткан әсир түгелме соң? Син бит аны Акмәчеттәге Камбала Хәттаб атлы элеккеге меңбашына сатып җибәрдем, дип акча биргән идең. Ничек итеп ул кабат синең кулга эләкте дә Хәттаб мескен хәзер нишли инде?

— Меңбаш Хәттаб читлегенә очып кергән тутый кошны да саклый белми икән, үзенә үпкәләсен. Ә мин аның белән алыш-бирешне өзеп куйдым инде. Хәзер бу тутый кошны Истанбулга алып китәм дә син вәгъдәләгән яшь пашага сатам...

Хаҗиәхмәт вәзир сылу Роксолананың билен, беләкләрен капшаштырып узды, ботларын тоткалады. Ни галәмәт, Роксолана беренче мәртәбә мал бәяләгәндәй мондый сынауларга каршы котырмады. Кызый зиһенендә яңа өмет учагы кабынгандай булды һәм, Хаҗиәхмәт вәзир китеп югалуга ук, Роксолана атаманнан төпченергә дә тотынды.

— Сезнең Кырымда иң баш кеше хан бугай бит инде, исеме кем әле?

— Мөхәммәтгәрәй хәзрәтләре.

— Ничә яшьләр ана?

— Иллене узды инде.

— Хатыннары күпме?

— Аны кем санаган. Хәрәм сарае тулы җарияләр. Бүген кайсын сайлый, шуны төнлә үзенеке итә. Тегеләр малай тапса, хатыны итеп калдыруы да мөмкин.

— Ә тапмаса?

— Андыйларын, капчык кидереп, Кара диңгезгә ташлаганнарын беләм. Ни өчен сораштыра башлавыңны да аңлыйм. Ләкин хәрәм сараенда ханның кулын тотып карамыйча картайган җарияләр дә байтак. Алар барысы да Ходай кулында бит.

— Ә-ә ю-ю-ук, алар язмышына Ходай түгел, Мөхәммәтгәрәй хуҗа. Син алдашма...

Икенче-өченче көннәрдә янына кергәндә дә, көзге чебен шикелле каныга-каныга, Роксолана атаманнын желегенә үтте.

— Ә ханнын харәм сараеннан берәр байгурага кияүгә чыгып киткән кызлар юк микән ул?

— Андыйлар турында бер дә ишетмәдем, — дип акланып карады атаман, ни әйтергә белмичә аптыраганнан гына.

— Сон, анда кызлар гел алышынып тора, дисен лә син үзен. Хан аларнын барысын да үз янында йоклатырга өлгерми бит инде, — дип Роксолана һаман үзенекен тезде. — Ә анын яраннарын, куштаннарын санап бетергесез. Әле чит илдәге король вә солтаннар белән дә килешеп яшәү кирәк. Анын үз жарияләрен читтәге король йә шаһларга кияүгә биреп куюы, алардагы харәм сарайларына яна сөяркәләр итеп озатуы да мөмкин. Юкка баш кагасын, кул-кулны юа, дип сөйли бит өлкәннәр. Сынар жарияне бүләк итү — хан-солтаннар өчен зур югалту түгел...

Шундый кысыр уйлар байтак төннәр буе анын йокысын алды. Әлегә, күсе шикелле, караб базына качып ята да бит. Ә иртәгә аны янә коллар базарына чыгарып бастырсалар? Янә сынар күзле Хәттаб яисә йөз динар өчен дә чәр ярып талашкан ике агай-эне кулына барып керсә? Ярар, Хәттаб куеныннан качып котылды, тик тәкъдир-язмыш дигәннәре бер мәртәбә алдын күрсәтсә, йөз мәртәбә артын үптерә ди. Анын да Ярославаны сатып алган юан корсак шикелле шыксыз бер татар кулына барып керүе бар. Шул татарнын аны шашкан үгез сыман тапалавы мөмкин. Анын ише шыксыз һәм кыргый кара-чура түшәгендә изелеп хур калганчы, лаеклырак, дәрәжәлерәк байгуралар жариясе булу күпкә отышлырак. Андыйлар да байтак. Сыбай[3], төмәнбашы, сәрдәр-паша ише хәрбиләр менәрләгән. Карабларга, тимер, көмеш, алтын, тире остаханәләренә хужа бай-бай сәүдәгәрләр бар. Хан һәм вәзирләргә сарайлар төзүче мигъмарлар да ярлы яшәмидер. Тик болар асылкош түгел, ата каз, күркә яисә әтәч шикелле, болар коймадан да югары күтәрелми. Ә гомеренне әрәм итәсен икән, падишаһ йә анын вәзирләре кебек лачын-бөркетләрнен юлдашы булу хәерлерәк. Әмма ничек итеп, нинди юллар белән алар хозурына барып эләгергә сон?..

Бер танда атаман төрткәләүгә сискәнеп уянды ул.

— Үз-үзенне тәртипкә китер, жыен, озакламый дингез карабына күченәбез.

— Без болай да карабта бит инде, монысы ник ярамый? — дип Роксолананын кәжәләнеп торуы ошамады, ахры, тамак төбе белән жикеребрәк дәште.

— Бу караб түгел, бу — черегән ләгән. Мондый ләгән Кара дингездә беренче давыл кубуга ук чәлпәрәмә килеп бетәчәк бит. Бер отыш та алырлык булмагач, мин сине нигә айлар буе качырып яткырдым сон?

Роксолананын янаклары тартышып куйды, әмма ярсуын сиздермәде.

— Кара дингез аша булгач, төрек каһанлыгына барабызмы әллә?

— Әйе, төрек солтанатына, ләкин моны юлда барган чакта чит колакларга гына ычкындырма. Әйдә, жыен.

Дингез карабы дигәннәре ярдан шактый читтә, бер култыкта тора булып чыкты. Әле баркаслар белән якынайган чакта ук Роксолана хәйран калды ана. Озынлыгы урам чаклы, биеклеккә ике-өч катлы икән. Һәрбер катта эреле-ваклы бүлмәләр, су мичкәләре, ашамлык чоланнары тезелешеп киткән. Өске палубага жилкән тартсалар да, аскы кат тәрәзәләреннән тышкы яктагы су өстенә тәртә юанлыгы ишкәкләр төшергәннәр. Шул ук ишкәкләр янәшәсендә таза-таза дистәләгән ирләр. Араларында учак өстендә янып корымланган казан шикелле чем-кара тәнле зәнжиләрне[4] күргәч, гел шаккатты. Зәнжи кавемен

[3] Сыбай — офицер. Төрекләрдә алар хәзер дә шулай атала.
[4] Зәнжи — негр.

үз гомерендә беренче мәртәбә очратуы иде, йә Ходаем, дөньяда дегет сыман чутыр-кара мондый бәндәләр дә була икән!

Ясирләрне күбесенчә икенче-өченче катларга бүлеп утырттылар. Кул-аякларына зынжыр салмадылар, әмма һәрбер ишек төбе саен дәү-дәү ирләр. Билләрендә ятаган йә хәнҗәр, кулларында камчы. Бүлмәләрнең тәрәзәчекләре кеп-кечкенә, житмәсә түм-түгәрәк, моннан качу турында хыялланырлык түгел. Аннары карабтан сикереп тә, диңгез уртасыннан кай якка йөзәсен ди?..

Беренче-икенче көннәрдә Роксолана диңгез өстен күзәтеп рәхәтләнде. Йа Ходаем, табигатьнең шундый искитмәле гүзәл, мавыктыргыч, сокланып туймастай матур почмаклары да бар икән бит! Әнә, кай тарафка гына күз ташлама, һәрбер якта дала кылганнары шикелле дулкыннар йөгерешә. Диңгезнең очы-кырые күренми, анын офык белән тоташкан сызыгын чамалау да читен. Дулкыннар иртән яшькелт, хәтта соры төскә кереп узышалар. Ә көндез, диңгез өстендә кояш йөзгән чакта, алар зәп-зәңгәрләр. Кояш чаткыларын һәр тамчыда бөртек-бөртек итеп чәчә-чәчә чапкан дулкыннар шултикле дә матур, шулчаклы чиста ки, ирексездән, бер дә шикләнмичә алар кочагына ташланасы, хәтфә үлән арасына чумган шикелле онытылып уйнаклыйсы килә.

Икенче көн ахырында караб борыны ягыннан жил көчәйде, диңгез төбендә учак кабызган шикелле дулкыннар күбекләнде. Төн уртасында диңгез инде карабны йомычка урынына унга-сулга йолыккалый, болгый башлады, кешеләр укшырга, ыңгырашырга, хәтта идәнгә ятып тәгәрәргә дә тотынды. Роксолана беренче сәгатьләрдә бирешмәскә, үзен бик вәсвәсә тотарга тырышып маташкан иде дә, чигәләре кысуга, эче борып авырта башлауга түзмичә, ул да идәнгә сузылды һәм газап-михнәт диңгезенә чумды...

## 4

Кырым карабын ерактан ук таныдылар, ахры. Босфор бугазын үтеп, Алтын Мөгез култыгына якыная башлауга ук, Сераль борынының ярында әүвәл зәңгәр төтен болыты пәйда булды, тик бераздан гына бик куәтле туп тавышы килеп ишетелде. Шулай да, Алтын Мөгез култыгына кереп туктагач, Сераль борынына олы гына баркас озаттылар. Әлбәттә, баркаска төшкән арадашчылар сандыгында алтын дукат һәм динар тәнкәләр дә, ефәк яки парча тукымалар, көмеш комган-касәләр, кыннары асылташ белән бизәлгән ятаган-хәнҗәрләр дә чиктән ашкан иде. Майлы кашык — һәр кешегә тансык, баркас бик тиз кайтты. Хуплау сүзен карабка менгәнче үк кычкырып житкерделәр.

— Баязит бакчасына барып бушанырга рөхсәт алып кайттык!..

Роксолана шушы Алтын Мөгез култыгында торган чагында ук ис-акылын җуйды. Култыкның ике як ярында да яшеллек диңгезенә төренгән, хәйран калырлык шәһәр. Бу — Истанбул, мөселман халкының башкаласы, диләр, мөгаен дә, хактыр. Ул бер аягы белән Аурупага чыккан, икенчесе белән Азия атлы кыйтга ярына басып тора икән. Бер як яр өстендәге сарай һәм анын тирәли үскән яшеллекне Сераль бакчасы дип сокланганнар иде, икенче як ярда солтаннарның Топкапе атлы кирмәннәре урнашкан булып чыкты. Бу кирмәнгә бик тә биек һәм гаҗәеп тә затлы зур таш капка аша үтеп керәсе бар, анын өстенә туплар урнаштырылган, солтан калага яки сәфәргә чыккан чагында шул туплардан атып хәбәр итәләр, ди. Кирмән эченә кара гавам, әлбәттә, эләкми инде, әмма Истанбулның бистә дигәннәре дә аерым шәһәрләр бит. Әнә, тау башында да, итәкләрендә яки инкүлекләрдә дә йөзәрләгән мәчет, дошманнарын сөзәргә әзерләнгән кәҗә тәкәсе яисә үгез шикелле, зәңгәр күк йөзенә манаралар сузган. Алар тирәсендә кызлар күкрәгедәй түп-түгәрәк, очлы гөмбәзләргә төренгән никадәрле сарай! Шулардан кояш нурлары сыман

як-якка таралган йөзәрләгән урам һәм тыкрыклар, меңәрләгән капка. Гаҗәеп зур даганы хәтерләтеп яткан Истанбулга дошман үтеп керерлек, аны яулап алырлык та түгел. Подольски яки Збручка барсаң, андагы тәкәббер хохол йә мадьяр сәүдәгәрләре төрекләрне кыргый халык, чи ит ашаучылар, дигән булып мыскыл итә иде. И-и, Истанбул биеклегенә менеп житәр өчен сезгә ничә еллар буе, ничә дистә олау тоз ашарга кирәк икән ләбаса!..

Баязит бакчасы дигән бистәләре сәүдә кибетләре һәм хисапсыз базарлар урнашкан үзәк булып чыкты. Тау өстендәге яссылыкка урнашкан зур мәйдан бу. Алачык-кибетләр түбәсе тоташ чатырны хасил итә, ә коллар базары читтә. Ана кертә торган урынга мәрмәр таштан бик тә матур капка корылган. Роксолана монысын атаман тирәсендә бөтерелгән унбашлардан сораштырып белде: дугалы бу капканы йөз ел элек Баязит Елдырым атлы бик данлыклы солтаннары төзеткән. Чит җиргә ясаган һәрбер яудан шул дугалы капка аша кайтып керә торган булган. Һавалану, көрпәләнү сыман гадәтләрне юлдаш иткән инде, мона шик юк. «Елдырым» дигәннәре дә «яшен» мәгънәсен аңлата, солтан үзе, имеш, дошман өстенә һәрвакытта сиздермәстән, үтә житез һөҗүм ясауны мәхкуль күргән икән. Кушаматлар таккан-тагуын да, тик исемен генә бик үк акламаган. Аксак Тимер атлы үзбәк әмире иленә бәреп кергәч, Баязит Елдырым Әнкара каласына тикле чигенгән һәм шунын янындагы яуда аксак әмир төрек гаскәрләрен пыран-заран китереп бетергән, ди. Баязит солтанның үзен кылдан үргән аркан ташлап кулга төшергәннәр, Аксак Тимер җинелгән гаскәре каршында аның башын чаптырып харап иткән. Баксаң, солтан хәтле солтаннарны да оҗмах капкалары гына көтеп тормый икән...

Коллар базары урнашкан мәйдан бик зур, монда да әллә ничаклы чатыр һәм кайсы таштан салынган, кайсы такталардан гына суккаланган эреле-ваклы сарай-алачыклар. Сәүдә рәтләре дистәләгән урамны хәтерләтә, ә таш яисә такта сарайларның нигә хаҗәт икәнлеген чамалавы читен. Рәт-урамнар буйлап бара торгач кына аңлашылды: әсирләрнең кул-аякларындагы зынҗырларны шушында салдыралар, алар су-ризык ише нигъмәт саклау чоланнары булып та хезмәт итә икән. Кырымнан китерелгән әсирләрне дә шул сарайлар аша үткәрделәр, кемдер күлмәк-яулыкларын алыштырды, кемдер күгәргән-янган күз төбен иннекләде.

— Синең киләчәк шушында хәл ителә, — дип сүз кушты Роксоланага аны юл буе күз уңыннан җибәрмичә килгән атаман. — Әгәр монда да кәҗәләнеп торсаң, мин сине кире алып кайтып җәфа чикмим. Йә күн капчыкны кәфен итәбез дә, әллүр су төбенә. Йә гомер буе бер янычарның аягын юачаксың.

Атналар үтә-үтә, Роксолана татарчаны да хәтәр шома сукалый башлаган иде башлавын, тик тозсыз җавап кайтарып вакланмады. Хәтта сукырлар да «ярар, күз күрер», дип үз-үзен юата, ди, тормыш тәгәрмәче эзен алмый калмас. Ә «янычар» сүзен Кырымда чагында ук кат-кат ишетте ул. Янычар — «яна чиру», «янача чиру», дигән сүзләрне кушканнан туган яна атама, ди. Төрек солтаннары яу сәфәре вакытында чит илдәге бәп-бәләкәй малайларны да әсирлеккә җыя, Төркиягә алып кайткач, аларны сөннәтләп ислам диненә иңдерә, шулар өчен төзелгән махсус мәктәпләрдә чыбык ашата-ашата зиһенен алыштыра һәм соңыннан, иң-иң гаярь егетләрне сайлап, шәхси гвардия ясап куя икән. Византия башкаласы булган Кайсаркаланы[1] яулап, ана Истанбул дигән ат кушканнан һәм төрек каһанлыгы төзеп куйганнан бирле, инде җитмеш ел буена дәвам итә ди мондый сәер зиһен алыштыру. Сәерен бик сәер, әмма кечә генә тәре тагып йөргән малайлардан да тугрырак җансакчылар юк, ди. Солтаннарның күз сирпүе дә җитә, янычарлар шундук арысланнар шикелле

[1] Кайсаркала — Константинополь.

сикереп яуга ташланалар, алар орышларда җиңелү-чигенүне, хаким чатырын ташлап качуларны, куркаклыкны, гомумән, белми, имеш...

Чатыр түбәле агач мәйданчыкка чыгарып бастыргач, Роксолана йомыркалар өстенә менеп утырган ана каздагы бер уяулык белән коллар базарын күзәтүен белде. Базар урамнары кырмыска йә бал кортлары оясыдай кайный. Хатын-кызлар итәгедәй киң балаклы юка чалбар кигән ирләр чиркәүдәге чаң телләре сыман әрле-бирле йөри, билләрендә — ятаган, баш түбәсендә — фәс. Асыл төрекләр, мөгаен, нәкъ шулардыр. Сәер, гаҗәп: аларның күпчелеге тимерче алачыгыннан чыккандай каратут, ябык тәнле, хәтта чәчләренә, күзләренә тикле шомырттай чем-кара булып, янып тора. Һәркайсы диярлек чылгыйлары аяк астына төшкән мыек йөртә, сакаллылар сирәк. Аннары боларның сакаллары да түгәрәк, пөхтә, җыйнак, чиркәү капкасын саклаучы алабайларныкы шикелле майга буялып, токмачка батып беткән себеркеләр түгел. Мөселман ирләре хәтта тышка да комган тотып чыга, барысы да, мөгаен, шуның галәмәтедер...

Сәүдә мәйданчыкларында корым сөрткән сыман чутыр-кара тәнле зәнҗиләрне санап бетергесез. Солтан Сүрия йә Мисыр якларына яу йөридер, болар — шуннан кайткан коллар инде, шаять. Арада ялгызлар, парлылар бар, ә бер гаиләне алты-җиде балалары белән әләктергәннәр бугай. Мондый күчкә сыңар хуҗа табылуы шикле, мескеннәр берәм-берәм төрле якка таралачак, димәк...

Роксолана янында торган ике хатын иреннәрен кул очлары белән каплап пышылдаша.

— Әнә, өсләренә буйлы-чуклы чикмән кигән өч ир якынлаша. Кайсы, диеп, башларына дүрт почмаклы түбәтәй кигәннәре. Берүк, безнең янга туктый күрмәсеннәр.

— Нигә? Без куркырдай кемнәр инде алар?

— Үзбәкләр бу, Каф тау белән Хәзәр диңгезе аръягыннан. Аларга чаклы дөя өркәчләре арасында өч-дүрт ай буена чиләнеп барасы бар. Ә бардыңмы — сәхрә, оч-кырыен мәңге күреп булмас ком даласы йә таш-таулар. Ул як учак өстендәге кайнар таба төсле, җәһәннәмнең үзе шунда инде, Ходай саклый күрсен...

Тынлык. Аннан янә чыш-пыш.

— Әнә теге, олы чалма урап йөргәннәре кемнәр?

— Алары йә фарсылар иленнән, йә Гыйрактан. Болар кулына әләктеңме, беттең. Гомер буе чаршау артыннан чыкмый, көн яктысын күрми ятачаксың, шул ирләрнең аягын юачаксың.

— Абау-абау, Ходай безне берүк ярлыкасын...

Роксоланага агач мәйданчык өстендә озак чиләнергә туры килмәде, сәүдә рәтләре арасында атаман пәйда булды. Ялгыз түгел, үз артыннан бик тә төз гәүдәле ир-атны иярткән бу. Аның килеш-килбәтенә күз йөгертеп алуга ук, Роксолананың йөрәге чеметеп-чеметеп куйды. Бастырыктай озын, зифа буй-сын, көчле, гаярь иннәр. Тезгә житкән бик кыйбатлы җилән итәкләре, җиң-якалар көмеш җепләр белән нәкышләнгән. Аякларына шундый ук чигүле күн читекләр кигән, билендә асылташлы, озын, шәп ятаган. Баш түбәсенә түбәтәй, фәс элсәләр, кыяфәте төсен жуяр иде, ә бу челтәрләре иннәренә төшкән очлым киеп алган, анысы гына көмеш. Сүз дә юк, бу затлы зат — бик тә югарыда оча торган бер асылкош инде. Үзе яшь бит әле, егерме дә юктыр. Базарларда йөргәч, хан-солтаннар нәселеннән түгел, ә шулай да кем соң?

— Хаҗиәхмәт вәзир хәзрәтләре сиңа атап юллаган иң олы бүләк менә шушы булыр, күз салып бага күрсәң иде, Рөстәм бәй, — дип сүз башлады атаман, Роксолана ягына баш кагуны һич тә онытмыйча. — Бер генә сатып алучыны да якын китермәдем, аның тәненә чит-ятларның бармак очлары да тиеп киткәне юк. Син сораган кыргый тау кәҗәсе, валлаһидыр, паша.

«Паша, паша, — дип кабатлады әсәренгән, сискәнгән Роксолана. — Солтан гаскәрендә бик зур башлык булып йөрүче бу, димәк. Әмма монысы Акмәчеттә калган мескен Хәттаб сыман менбаш кына түгел, шундук аерыла. Бу асылкошның төмәнбаш, хәтта кайсыдыр тарафта ябубаш, гаскәрбаш булып торуы да мөмкин».

Рөстәм паша бүләк ясирнең каршына килеп басты, карашы утлы кисәү белән кагылгандай яндырып һәм чеметтереп узды. Көчек шикелле йөгергәләп йөргән атаман Роксолананың итәк очын күтәрергә ымсынган иде дә, кырыс кунак елан төсле ысылдап шып туктатты.

— Кагыласы булма!

Кай арада ишетеп өлгергәннәр, кызлар мәйданчыгын эреле-ваклы сәүдәгәрләр, зәркән осталары, ятаганнарын билләренә кыскан хәрбиләр уратып алды. Һәрберсе, сузыла-сузыла, Роксоланадан бигрәк бәйне күзәтәләр, вакыт табып, чыш-пыш сөйләшәләр.

— Рөстәм паша — Сәлим солтанның малае Сөләйман шаһзадә гвардиясендә төп йөзбашы. Ул — Сөләйманның иң ышанычлы яраннарыннан берсе, ди. Шаһзадәнең аны иртәгә Ибраһим паша урынына гвардия башлыгы итеп куюы да мөмкин.

— Ул — серб сәрдәренең сабый көе әсирлеккә төшкән малае бит. Солтан ана Рөстәм атын соныннан гына, сөннәтләгәч кушты. Сөләйман шаһзадә белән алар икесе балачактан бирле бергә үсте. Аларны түшәктә дә бергә йоклый, диләр. Солтан Рөстәмне янычарлар мәктәбенә биргәч, Сөләйман шаһзадә дә, атасының ай-ваена карамыйча, шуның янына кереп укыды бит. Икесе дә яу гыйлемен бик шәп үзләштергән, кала артыннан калаларны тез астына салып, Сәлим солтанның данын арттыралар.

— Рөстәм пашаның алтын-көмеш коесы төпсез, күзе төшсә, ун кызны да сатып алала ул...

Рөстәм Роксолананың күзләренә бакты, ә карашы кызның гүя аяк табаннарын өтеп алды. Роксолана аның кылычтай тар борынлы, дугаланып торган куе кашлы булуын гына шәйләп өлгерде. Рөстәм исә кара гавам каршында сатулашып торуны нык ваксынды бугай, бил каешы астыннан калын янчыкны чыгарды да сузды.

— Ялгыз калгач, иркенләп санарсың, ә без киттек.

Рөстәм Роксолананың сынар кулыннан эләктерде, иреннәре белән генә елмайгандай итте.

— Булды, син ясир түгел, моннан ары мина үз тиңеңдәй эндәш, — дип сүз катты да үз артыннан тартты. — Хәзер бергәләп ычкынсак та була.

Такта мәйдан тирәсендә ыгы-зыгы купты, һәммәсенең телендә тик бер генә сорау:

— Рөстәм бәй никадәрле алтын биреп китте? Ясир кызны син күпмегә саттың?

Җавап сүзе генә һич янгырамады, хәер, яшьләр аны болай да ишетерлек дәрәҗәдә түгел иде инде.

## 5

Роксолана Рөстәмне бик ошаткан, хәтта, дәрәҗәлерәк түрә насыйп булмаса, сөйгән яры итәргә дә әзер иде, егет хаталанды. Ир-ат сәер һәм беркатлы шул: яхшы аргамак яисә күз явын алырдай кыз-кыркын таптымы, аны дус-ишләренә күрсәтеп масаймыйча калмый. Рөстәм дә әүвәл җария урынына сатып алынган кызны солтан кирмәне янындагы нииндилер таш йортка илтеп япкан иде, кечкә эңгер-меңгер төшкәнне дә көтеп житкерә алмыйча, үзенең «оясы»на гаскәрбашы Ибраһимны иярте кайткан.

— Менә, паша, үземә яр таптым. Сөләйман рөхсәт итсә, никах укытам да

шушы жирән сылуны үземә хатынлыкка алып куям әле, — дип күңелен ярып салды ул, тупса аша атлап керешли үк.

Роксолана күрде: йөзбаш Рөстәм аңа чынында да гашыйк, ике күзе уттай яна иде. Ләкин аңа ияреп кергән Ибраһим да сукыр йә талымсыз бәндә түгел, ясир кызны күреп алуга ук, аның күзләре дә янган күмер сыман очкынланды. Әмма Ибраһим хисләрен йөгәндә тота белә, аның жаны сандалга салып чүкелгән айбалта йә кылыч урынына нык чыныккан икән.

— Юк, бу жария синең куенына эләкмәстер кебек, — диде ул, кырт кистереп. — Син гел үз мәнфәгатеңне генә кайгыртасың һаман. Шаһзадә гаскәрендә кайсы баскычта торуыңны онытма. Син — бар гомереңне Сөләйман шаһзадәгә бүләк итү өчен антлар эчкән инсан. Нинди нигъмәткә юлыксаң, нинди жария тапсаң да, иң беренче — аңа! Инде ул баш тарта йә ошатмый икән, ахыр чиктә, синнән алда тагын мин дә бар бит әле!

— Соң, жарияне дә бүлешергәмени хәзер? — дип Рөстәм сүз кыстырган иде, Ибраһим паша, ярсыган эт шикелле, яманрак котырынды.

— Син Диярбакыр ягында яуда йөргәндә дә көмеш ганимәт хәнҗәрне кысып калган идең, угрылыгың хакында шаһзадәгә житкермичә түздем. Бармакларың гел үз ягыңа гына кәкре булса, синең ул азгын кулларыңны чабып ташларга да күп сорамам!..

Ибраһим паша Роксолананы кулыннан сөйрәп диярлек алып чыгып китте, йөзбаш Рөстәм кулыннан ялтыравык уенчыгы тартып алынгандай нәүмизләнеп калды. Роксолана солтанның иске сараендагы олы бер бүлмәгә кайтып кергәч, усал гаскәрбашы инде аны ятагына сузып салыр, дип шөбһәләнеп-куркып йөргән иде. Тик Ибраһим күңелендә башка ният яшь үләндәй шытып йөргән икән...

Роксолананы яңа төр коллыкка — харәм сараена илтеп бикләделәр. Эчендә — гарьләнү, йөрәк-бәгырьләре — тоташтан ут. Ибраһим аның белән бер генә төнне ишек төбендә йоклап үткәрде дә, икенче таңда ук шушында китереп атты.

— Мәңгелеккә ятла, син — хатын-кыз, фәкать ир күңелен күрү өчен яратылган бәндә. Үзеңнең жанын, тәнең, рәхәтлегең турындагы хыялларны оныт. Жир йөзендә син — тузан бөртеге генә, ә үзеңне яр итеп сайлаган теләсә кайсы ир-ат — синең өчен шаһлар шаһы һәм пәйгамбәр! Гел шуларны истә тотып яшә, ир тәненә сөлек булыпябыш, ул мунча ташы кебек кызып ярылганчы, нәсел үгезедәй ярсыганчы иркәли бел. Пар табасы һәм дә инде нәсел калдырасы килгәч, керпе булып керпеләр дә энәләрен жыеп, назын туплап ике ботын ача. Син дә ир кешегә ул үзен дөньядагы иң гайрәтле, иң кадерле зат дип саный башлаганчы рәхәтлек китерү өчен яратылган бәндә. Солтан яисә шаһзадә, һич югында минем ише зур пашалар күңелен яулыйм дисәң, иң әүвәле, иркәләргә өйрән. Әгәр шуннан чирканасың икән, сине теләсә кайсы хужаң көчек урынына урамга куып чыгара йә, әнә, зәнжи коллар астына сузып сала!..

Харәм сарае Баязит бакчасында, коллар базары белән янәшәдә генә урнашкан булып чыкты. Күршедә генә Мисыр бистәсе, Мисыр базары бар, тәрәзәдән караганда, шулар артындагы Мәрмәр дингезне дә күзәтергә мөмкин. Ләкин Роксолананың күңел ачардай, гөл-бакчалар белән хозурланырдай һичбер кәефе юк. Ул — иске кәвеш урынына читкә атылган корбан, аңа чоңгыллардан котылу, юкка чыкмау турында баш ватарга кирәк...

Харәм сарае — аерым бер мәмләкәт, кабатланмас дөнья. Роксолананы юнан-грек кызы Соломия белән бер бүлмәгә кертеп бикләделәр. Монда бүлмәкишәрлекләр санап бетергесез, таш сарайның ике каты да кызлар белән тулган. Сарай үзе зур бакча эчендә, тышта таш коймалар. Шунысы бик гажәп: бакча түрендә тагын дүрт-биш зур сарай бар, аларның берсендә Сәлим солтанның хатыннары, балалары гомер итә икән. Солтан үзе Сераль бакчасы каршындагы

Топкапеда яши, анын сараендагы бүлмәләрнен саны өч йөздән дә артып китә, ә гаиләсенә анда күченергә, күз унында булырга рөхсәт юк, ди. Имеш, солтанга каһанлык белән идарә итәргә комачау итмәсеннәр, дәүләт эшләренә борын тыкмасыннар. Зур башваткыч түгел, хәйләдер бу. Йә житкән угыллары суеп үтермәсен, йә жарияләр белән күнел ачкан чакта таяк тыкмасыннар, ди торгандыр инде. Солтан Сераль бакчасында йөрергә бик ярата, ә «Сераль» атын «сәр алып», дигән ике сүздән ясаганнар, имеш. «Сәр» сүзенен «баш» булуын Роксолана бик күптәннән белә. «Сераль» дигәне «баш алып»ны анлата инде, димәк. Роксолана үскән якларда да мөселманнар биек тауга кушкан «Алып» сүзен ләһ-хохоллар «Альп тавы», дип йөриләр бит әле...

Ә монданы жарияләргә харәм бакчасында йөреп, чишмә буена төшеп хозурланырга да бер рөхсәт юк. Дүрт якта да дивар, тышта кораллы сакчылар, эчтә — күпчелеге зәнжиләрдән тупланган хадим[6] даирәсе. Алар бик күп түгел, бер дистәдән артмый. Бер ишләре тышкы ишекне саклый, икенчеләр коридорда йөрештереп тора. Үзләре синен күзенә дә чәчрәп керми сыман, әмма тәһарәт бүлмәсенә йә бакчага чыга башладынмы, шәүлә урынына гел ияреп йөри.

— Нишләп безнен янга гел зәнжиләрне генә тагып куйганнар сон? — дип, түзмәгәч, Роксолана бүлмәдәше Соломиягә авыз ачкан иде, тегесе сәер жавап белән шаккатырды.

— Хадимнәр элек тулысы белән диярлек фарсылардан, гарәпләрдән торган. Ишеткәнен бардыр, Адәм белән Һаваны да ожмахтан тыелган алманы агач ботагыннан өзеп алган өчен куганнар бит. Жарияләр дә шулай, гарәп-фарсы хадимнәре белән типтерә башлаганнар, балалары туса, яшергәннәр. Шуннан ары Мәхмүт Фатыйх солтан, фарсыларны куып, зәнжиләрне китереп тутырган, ди. Алар белән бәйләнешкә керсән, кара бала туа. Уйнаш ачыкланса, солтан икесенен дә бот араларына кайнап торган көмеш салачак бит.

Ә уйнашлар булган. Мунча кергән чакта Каф тавыннан килгән чәчән кызы Гәүһәр бәян итте.

— Өч ел чамасы элегрәк мөгаллимнәр арасында Шампань каласыннан килеп ялланган Пьер исемле арфачы француз бар иде. Кубызда да, лирада да уйный, искитәрлек. Испан ярыннан тотып китерелгән Әндәлуз жариясе гашыйк булган мона. Арфада уйнарга өйрәнәбез, дигән сылтау белән мәктәпнен бер бүлмәсенә бикләнеп кала башлаганнар. Жария әчегән камыр шикелле жәелергә тотынды берзаман, шуннан ары, билгеле, яман гауга купты. Явыз Сәлим арфачыны төбе-тамыры белән сөннәтләргә кушкан. Ә бичара Пьер жариясе Ләйләгөлне яклап калу өчен үзенә ут төрткән. Зәйтүн мае ягынганмы инде, кара жир маемы — анысын шайтан белсен. Харәм бакчасында житен көлтәсе шикелле дөрт итеп кабынды да янды. Ахырдан Ләйләгөле, камыр кисәгенә төреп, энә йотты. Коткара алмадылар...

Роксолана, аптыраганнан, һаман кызыксынды.

— Син бирелә бик күптәннән интегәсен икән, уйнаш кылмый ничек түзәсен сон?

— Һе, мин дә көтүдәге ала карга түгел, — дип каш сикертте Гәүһәр. — Үткән кышта сарай диварларын бизәргә бер нәккаш килгән иде. Төскә-биткә ару гына үзе, мәгәр бик яшь, мыеклары төртеп кенә килә. Күз төште бит шуна, йоклый алмас булдым. Үткән-сүткән чакта каш сикертәм тегенә, елмайган да булам, ә теге ужым бозавы сынар сүз дә кушмый. Бу бер кичтә тоткарланып калды. Сонгы киче, нәккашкаем танга чаклы бизәү эшен инде тәмамларга тиеш икән. Иртән-иртүк вәзир киләчәк, ди, ә мин нишлим? Егетемнен монда калганын

---

[6] Хадим — евнух, харәм йортындагы хезмәтче.

белеп торам бит, йокы искә дә килми. Түземлегем корыды, угрылар шикелле шыпан-шыпан басып, янына кереп киттем. Нәккашкаем гел коелып төште, өтергеләрен куярга да онытып, баганадай тора. Шуннан үзем күлмәкләрне күтәрдем дә яттым. «Синең вакыткаең бик санаулы, әйдә, үз эшеңне эшлә», дип әмер бирдем моңа. Күз тимәсен, абау, сынатмады...

Роксолананың баш чайкавын күргәч, Гәүһәр кул селтәде.

— Ялгыш кына берәр янычар йә пешекче хатынлыкка алып куймаса, безгә тугыз ел буе монда чиләнәсе. Минем дүрт елым үтеп китте инде, ә синеке бөтенләй башланмаган. Каурыйларыңны гел-гел тәвис кошыдай кабартып кына озак түзә алмассың. Безнең монда бөтен күргән-белгән ир-ат — янычар да пешекче, йә аннары хадим. Ничарадан бичара булып, һич югы шуларга күз атасың инде.

— Бәй, хадимнәрне печелгән, диләр ләса.

Гәүһәр, түзми, кычкыра-кычкыра көлде.

— Монда барча ир дә сөннәткә утыртылган, тик аларның һәммәсе дә эштән чыгарылган, корыган кусәк түгел. Менә, берәр хадимгә күзең уйнат әле, аннан ышанырсың.

— Ю-у-ук, үз-үземә кул салсам салам, мәгәр зәнҗи хадим белән йоклау кебек түбәнлеккә төшмим.

Беркадәр тынлыктан соң Роксолана янә сорау бирде.

— Ә тугыз елдан соң безне урамга чыгарып аталармы?

— Юк, урамга түгел. Хакимнәр кайчакларда бик изге, миһербанлы булып та кыйлана беләләр ул. Җарияләрне харәм сараеннан чыгарып җибәргәндә, солтан алтын тәңкәләрне дә, затлы асылташларны да бик мул өләшә, ди. Кайчан да булса бер түшәк бүлешкән кешеләр бит, җарияләр соңыннан солтаннар турында яман сүзләр сөйләмәсен, дип майлыйлардыр инде. Җарияләрнең бик күбесе йортлар алып Истанбулда кала, бик сирәге туган ягына да кайтып китә, имеш. Кайтмыйлардыр, моңа бик ышанмыйм. Алтын-көмешкә төренгән ялгыз хатын сират күперен үтә аламыни? Юкка чыкканлыгын аклау өчен генә кайтып китте, дигән гайбәт тараладыр...

Ибраһим паша Роксолананы күз уңыннан һич тә җибәрмәгән икән, бер кичтә чакыртып, җария кызны солтан малаеның тәрбиячесе урынына билгеләтеп куйды.

— Мостафага әле дүрт кенә яшь, чит-ят итә белми. Аннары сиңа солтан даирәсенә якынлашу да комачауламас сыман. Кем белә, солтан күңеленә, бәлки, бала кулы аша юл кыскадыр?

Роксолана тиз белешеп куйды: Мостафа — Сөләйман шаһзадәнең өченче хатыны Маһидәүраннан туган бала икән. Маһидәүранне ялгыш кына да күргәне юк иде, аның каравы, шаһзадәнең үзе белән күзгә-күз очрашты бит. Тегесе нindидер, Мисыр юлындагы яудан әйләнеп кайткан да улы белән күрешергә кергән. Мостафаны кочаклап туйганнан соң, кулыннан төшергәч, бер почмакта яулык очын иреннәренә кабып торган җария кызга да күз йөгертте ул.

— Син сарайга ничек килеп эләктең? Кайсы яктан?

— Мин Подолиядән. Кырымлылар Мисыр базарына китереп сатты, — диде Роксолана, ялкын өстенә эләккән күбәләктәй янып.

— Һе, җария алайса, — дип иреннәрен бүлтәйтте төп шаһзадә хуҗа. — Атың нинди? Белеп калыйм әле.

— Роксолана.

— Анысы начар, — диде Сөләйман шаһзадә, һич тә көтелмәгән бер нәтиҗә ясап. — Андый кяфер аты белән ерак бара алмассыңдыр сыман.

Сөләйман артык сүз катып та тормыйча, шундук чыгып китте. Роксолана-бичаракай күңелендә ачы төер калды...

Роксолана төннәр буе йоклый алмый ята, мең төрле уйлардан гүя мие кайный. Ул түтәлдән йолкып алынган сынар гөл хәлендә. Күперләр яндырылган, кайтыр юллар бикле. Аны хәзер инде беркем дә Подолиясенә кайтарып куя алмый. Хәтта могҗизалар аша әйләнеп кайту бәхетенә ирешсә дә, анда кемгә хаҗәт? Әнисе, аны коткармакчы булып, җанын тәслим кылды. Роксолананы хыяллар дингезендә йөздерүче Никола бар иде, хәзер аның кай тарафта, кем кулында кол икәнлеген дә белеп булмый. Әтисе, гомумән, хыянәтче, куркак. Төптәнрәк уйласаң, хатыны белән кызын гына түгел, динен дә сатты бит ул. Ә әтисе һәм аның белән бергә чиркәү базына качкан пономарьларга да кадере калмагач, кол хәленә төшкән мескен кызга христиан дине нигә кирәк соң ул? Иисус Христос хәзер аны туйдыра йә яклый аламыни? Роксолана бүген, менә, сазлык эчендә, упкын төбендә бит. Ана сазлыкка батып юкка чыкмау өчен, агач башына үрмәләү, хәтта сынар чыбыкка тотынып булса да җанын саклап калу отышлырак. Нишләп Христос ана кулын сузмый? Әһә, коллар, мескен җаннар Христосның үзенә дә кадерсез һәм кирәкмәс бер йөкме? Алай икән, Христос атлы Аллаһ Роксоланага да кирәк түгел!..

Аннары туган җире аны, икенче бизмәнгә салып карасаң да, бер дә тартып, үсендереп тормый. Чит-ят табаны астында газап чиккән, кол хәленә төшкән халыктан да бәхетсезрәк, кызганычрак бер кавем дә юк бит. Үз-үзен яклый, дошманнарга каршы тора алмаган һәрбер милләт — йә печелгән тәкә, йә мүкләк сыер хәлендәге мескен инде. Ул сугым малы урынына егып салсаң да, юаш сыер сымак көне-төне савып яшәсәң дә дәшми. Азат булсак, безнең үз дәүләтебез, үз ханыбыз калкып чыгар иде. Ә Подолия-Галитчина дигән тәкъдир-ватан гомер буе йә мадьяр, йә ләһ короле астында золым күрде. Атай дигән сатлык сөйләвенчә, безнең җирне элек-электән үк Киев кенәзләре дә, Батый хан татарлары да изеп-талап, коргаксытып үткән. Үзе киткән чакта Батый безнең җиргә Бурундай атлы төмәнбашны баскак итеп утыртып калдырган, ди. Еллар үткәч, аны Янгеллон дигән ләһ сәрдәре килеп куган икән. Аның артыннан валахы да, мадьяры килгән, тагын әллә кемнәр. Ә азат ил, азат халык булып, бәхет күреп яши алмадык бит. Үз иреген яулый алмаган мескен милләт вәкиле булып саналу — зур дәрәҗә түгел. Чит-ят җирдә азат булу, коллык богауларын салу өчен, миңа үз илемнән һәм динемнән баш тартырга кирәк.

## 6

— Христианлыктан баш тартам, мине ислам диненә күчерегез тизрәк!

Баш хадим, бал кортларын гел-гел барлап торучы умартачы сыман, җарияләрне олы залга чыгарып тезгән иде, сарайда күптән түгел генә пәйда булган Роксолана авызыннан шундый сүз ишетеп, тораташтай калды. Ул аптыраудан күзен акайтты, ә кызыкай керфекләрен бер дә йоммас утлы караш белән, без шикелле бораулавын белә. Күзләрендә тәвәккәллек уты дөрләп яна, йөзендә исә һичбер икеләнү йә курку юк. Мә, үтәли тикшер һәм ятлап кал, дигән шикелле, башын беркадәр артка ташлаган, ияк очын югарыга чөйгән. Ул хәтта буйга да калкынып һәм үсеп киткән төсле.

— Сине кем котыртты? — дип сорады, ниһаять, баш хадим, озак вакыт буе күз карашларын сынаштырып, дәшми торганнан соң.

— Үзем, тик бер үзем! Мондый зур адымны чит-ят котыртуы буенча эшләмиләр!

Роксолана һәрбер сүзен алдан ятлап куйган, сөйләшүгә инде күптән әзерләнгән иде. Бу көн җиткәнчегә чаклы ныклап сораштырды. Сәлим солтанның диваны да, вәзирләре дә бар ул барын. Ләкин солтанга сүзе үтә торганнар фәкать өчәү-дүртәү: аның баш хатыны йә анасы, баш вәзир, шәйхелислам һәм ... менә шушы хадим. Ил-мәмләкәт белән дә диванда утыручы

буш вәзирләр түгел, шушы дүрт бармак, шул дүрт җеп кенә идарә итә икән. Әлбәттә, солтан галиҗәнапләреннән башка җил дә исми, яфрак та селкенми. Әмма шушы дүрт түрәнең берсен үз ягыңа аудара алсаң да, исемеңнең солтан колагына ирешүе мөмкин. Баш хадим булып йөргәне — төрек милләтеннән, үзе мөселман да. Роксолана кузгаткан шундый зур теләкне колак яныннан гына уздырып җибәрергә һичбер хокукы юк. Шайтан кытыклаган чакка туры килсә, баш хадимнең мондый яңалыкны солтан җәнапләренә әйтүе дә бар бит.

— Солтан яуда, — дип кисте баш хадим аның өметләрен, һәрбер уен укып барган сыман. — Шыгыйлардагы Исмәгыйль шаһ белән Бәһдад каласын тезләндерми торып, бирегә кайтмаячак. Теләгеңне шәйхелислам хәзрәтләренә җиткерермен, ул хәл итәр.

Роксолананың йөзе көл сипкәндәй сорыланып чыкты, әмма үзен бик тиз кулга алды, ирен читләре белән генә елмайгандай итте.

— Баш өсте, хадим хәзрәтләре, мин саргаеп көтәм...

Роксолана өметләнгән шәйхелислам урынына Истанбулның баш имамы килде. Солтан җарияләре күп меңнәрчә түгел, ә ислам динен кабул итәргә теләк белдерүче — бик санаулы гына. «Син безнең дингә үз ихтыярың белән инәсеңме, көчләп мәҗбүр итүче йә алдаучы юкмы?» кебек беркатлы сораулардан соң гына имам хәзрәт, Коръән китабын ачып, догаларга күчте. Бер тукталганында кызга күз йөгертте.

— Исемеңне кем дип куячакбыз, алдан уйладыңмы?

Роксолана әүвәл күзләрен акайтты, аннары гаебен йолып калу өчен, елмая-елмая җавап тотты.

— Мин белмим, бер дә уйламадым. Сез үзегез яхшырак беләсездер.

— Сөләйман шаһзадәнең чиркәс хатыны Маһидәүрән булып йөри иде, без аңа Гөлбаһар дигән яңа исем куштык, ул канәгать калды. Сиңа елмаю бик килешә икән, Хүррәм дигән атка ризасыңмы?

Роксолананың иңбашларын сикертеп җавапсыз калуын күргәч, аңлатуга күчте.

— Хүррәм — көләч, ачык йөзле, шаян, дигән сүз безнеңчә. Фарсыларда шул ук сүзне камәр, диләр. Аларча, тулган ай ул. Шул ат килешәме?

— Мин риза, риза, имам хәзрәтләре, — дип тиз-тиз кабатлады Роксолана. Ә имам бераздан гел йомгаклап куйды.

— Моннан ары син Хүррәм инде, әйе, кем, сеңелкәш. Элек күтәреп йөрткән исемеңне оныт. Җаның-тәнең белән безнең дингә бирел. Хак Тәгалә каршында...

— Ислам диненә тизрәк басу өчен мөгаллимнәр кирәк, — дип бүлдерде имамны Роксолана-Хүррәм. — Мине үзегезнең ислам мәктәпләренә алдырсагыз иде.

— Анысы гына булыр. Солтан балаларын укыту өчен болай да бу бакчага әллә ничә мөгаллим килеп йөри. Җарияләр арасында да талибләр күп, шуларга кушылырсын...

Шулай хушлаштылар. Ә бер атнадан соң Хүррәм атлы җилкенчәк кыз, Баязит бакчасындагы мәчет идәненә тезләнеп, сабак ала иде инде. Дога ятлатулар белән генә килешмәде, бер-ике айдан соң ук таләп куйды.

— Суга чуммый торып, йөзәргә өйрәнеп булмый. Коръән-Шәрифне дә ятлап түгел, аңлап уку һәм инану өчен, гарәп телен, гарәп хәрефләрен өйрәнергә кирәк. Мин Ходай Тәгаләгә ул үзе көйләп яздырган һәрбер дога, һәр сүрәне күңелем белән аңлап, йөрәгем аша үткәреп табынырга тиеш. Мине укытыгыз.

Гарәп хәрефләрен ятлауны гына да азсынды, берзаманны ак сакаллы бер мулладан тарих турында төпченүгә күчте.

— Кайсаркаланы Мәхмүт солтан яулап алган, Истанбул атлы яңа исемне

нәкъ шул кушкан, үзенә дә исән чагында ук Фатыйх дигән ләкаб такканнар, дип күп ишеттем, ә төгәлен белмим. Ислам дине наданлыкны сөйми, мин фәкыйренә дә шул хакта бәян итсәң иде, дамелла хәзрәтләре...

Ак сакаллы мулла аңлатып бетерүгә, яна сорау:

— Сәлим солтан турында «ул тәхеткә әтисен үтереп менгән», дип сөйлиләр, көфер сүздер инде?..

Мулла як-ягына карана, еландай боргалана, Хүррәм һаман чигенүне белми.

— Мин син сөйләгән турында бер кешегә дә әйтмим. Алдыйм икән, үземне яшен суксын.

Мулла тагын гыйбарәләр тезә, сабак дәресләре ахшам намазына тикле дәвам итә...

Менә берзаманны харәм мәктәбенә яңа гувернантлар килеп төште. Жарияләрне кием тегәргә, кубызда уйнарга, хушбуй майлары белән сөртенергә, шәрык биюенә өйрәтүче остабикәләр болай да күп иде. Боларга өстәп, Бавариядән килгән алман Гюнтер кызларга чисталык, пөхтәлек турында да сабаклар бирергә тотынды. Әмма моның пөхтәлек дигәне тәвис кошының койрыгыдай гаҗәеп күп каурыйлы, хәтта сын тоту, бил ясау, күкрәк мендәрләренне уйнарга өйрәтү дә шул ук сабакларга кереп китә икән. Ә француз Жан сабаклары турында инде әйткән дә юк. Шотланд биюен башкарасың икән, тезләренне билдән югары күтәреп сикерү генә житми, итәкләренне дә кендегең ялтырап күренгәнче уйната бел. Алман биюе дигәннәре тагын да кәттәрәк икән лә, каһәр. Жан Хүррәмне биленнән кысып тота, бер-берсенә кушылган пар куллары һавада бөтерелә. Шул чагында син әле тагын кендегенне дә алга таба этәр, бер аягыңны тегенең ике бот арасына кертеп уйнатырга да онытма. Аягыңны алсаң, түшенә ят, күкрәкләрең читләшсә, янадан алдын тер. Хүррәм шул хәрәкәтләргә күнегә алмыйча интегеп беткән иде, Жан янача газапларга тотынды бит тагын. Бер биюендә иелү-бөгелүләр бигрәк тә еш, син артың белән борылсаң, йомшак мендәрләреңне тегенең жан жиреннән аермыйча хәрәкәтләп һәм ләззәтләп икән. Хүррәм монысын бер дә жиренә житкереп кабатлый белмәгәч, Жан кызыйны өстәмә сабакларга алып калды. Үзе билдән аска бар зиннәтен тырпайтып күрсәтә торган ап-ак ыштан кигән, тәне белән кыса, ә үзе һаман вата-сындыра тәрекчә пышылдый бит.

— Корыган агач кебек хәрәкәтсез торма, булган байлыгыңны уйната бел. Ир кеше иренчәк, ул бер тапкыр канәгатьләнсә, икенче мәртәбәсенә селкенмәскә мөмкин. Син алжуны белмә. Ир кешене гайрәтле һәм яшь көенчә тоту — хатын-кыз кулында. Ике-өч төн буена ялгыш кына да бер үк төрле булма, иркә-назларыңны янартып тор. Син назлырак булган саен, ирләр сөяр, син көч биргән саен, алар һаман-һаман сиңа тартылырлар. Ирен түшәктә бәхетле иткән хатын — дәүләт вәзиреннән һич тә ким түгелдер, син гел шуңа омтыл...

Жан Хүррәмнең йөрәген ачып караган кеше шикелле ачыктан-ачык тезә. Ул хәтта кулларын уйнаткан чагында да Хүррәм теләге белән санлашуны белми. Ләкин ул бит — мөгаллим, син — талибә, остазыңны уздырганчы түзә белүдә сер...

*Дәвамы киләсе санда*



Айрат
Суфиянов

# ЧАГЫЛДЫРЫП ЧОРНЫҢ СУРӘТЕН

## Ватан

Туган нигезем ташына
Башымны терим... Эссе.
Базда яткан бәрәңгедән
Аңкыла хәтер исе.

Йөрәктә әнкәм сөтеннән
Күчкән игелек хисе.
Урман, кырлар, тау, тугайлар,
Күл, чишмәләр, күк, тургайлар —
Мөкатдәс бөтенесе.

Соң чиккәчә күзләремдә
Уңмас туган як төсе.
Ничек дөрләп кабынмаска?
Жанымда — ут яктысы...

Әйтерсең, туган нигезгә
Эрим дә кайнап тамам.
Кабатланмас моң сазымның,
Назлы, кырыс остазымның
Самими кылын табам.

Йорттагы яшь үләннәрдән
Наз сулый минем табан.
...Ватып вакыт киртәләрен,
Саф балачак иртәләре
Йөгерә миңа табан.

...Иреннән суты кипмәгән,
Үпкәләп ташлап китмәгән
Туган як — олуг Ватан!..

---

Айрат СУФИЯНОВ (1958) — *шагыйрь; «Кылычлы җил» исемле китап авторы. Чаллы шәһәрендә яши.*

## Шагыйрь

Бөкресе дә матурлыкка — һәйкәл!
Ямьсезләнер куйсаң төзәйтеп.
Чын шагыйрь ул күк язганны укый,
Чын шагыйрьне булмый төзәтеп.

Чынбарлыкка тугры калган килеш
Чагылдырып чорның сурәтен,
Калкан итеп хаксызлыкка каршы
Күтәрә ул сүзләр кодрәтен.

Гомер буе дөреслекне яклап,
Тоташтырып төнен таңнарга.
Кайгы, шатлыктан да чәчәк чигә:
«Жан өрче, — дип, — Раббым, аңарга».

Чын шагыйрьгә вакыт киртә түгел.
Ул — бердәмлек язы жаннарда.
Теләге юк, тезләнеп тә жирдә
Яшәү мөмкинлеген аңларга...

Чын шагыйрь ул меңнәр уйлаганны,
Изүчегә тәгъриз[1] уянганны,
Тапшыручы хөкем катына...
Аллаһ кушкан вазифасын үтәп,
Ялланмыйча тамак хакына,
Риясызлык йорткән иман белән
Хезмәт итүче ул халкына.

Үткәннәрнең тирән тамырына
Кан хәтере белән ялганып,
Бүгенгедә ачып көрәш күзен
Яши шагыйрь, ышандырып үзен,
«Киләчәк, — дип, — туар алланып».

Тоядырмы вакытыннан алда
Шәһит китәчәген алданып?
Жир йөрәге, чор йөрәге кебек,
Жыр йөрәге кебек таланып...

## Моңнан туып

Тыным кыса... Аңкый көек исе.
Жәберләнгән жирдә сөю хисе.
Баскан жирем күксел күл генә.
Караңгылык белмәсе аша
Шигырь юллыйм таңның гөленә.

Юл табармы, белмим, алашмасмы,
Юлыкмасмы елан иленә?
...Тамырларда каным катып кала,
Шикләнүдән бәгърем теленә.

[1] Тәгъриз — ризасызлык (протест) белдерү.

Жилдән сорыйм: «Ирештеме гөлгә
Шигыремнең моңлы дулкыны?»
Җавап кылә: «Тотты аны, йотты
Салкын битарафлык упкыны».

...Көлгә өрәм, бәлки, ут терелер,
Таралыр, дип, карангылык та.
Рухы уянмаган гавәм йоклый
Гафләт баскан гамьсез тынлыкта.

Хәлем беткән... Карашымда заман
Балкый-сүнә үзе чагыла.
Моңнан туып, ялгыз кайтып барам
Дөньялыкның бала чагына.

## Кояш төшә

**1**

Язар сүзләр — ярсыз галәм,
Ә язмышым — каурый каләм.
Бер сүз яздым, бетте карасы.
Күргәннәрен сыйдырырга теләп,
Талды күзләремнең карасы.
Тетрәнүле, әрнүле дә карыйм
Дөньяга, мин — адәм баласы.
Нәсыйхәтең бирче, Хак Тәгаләм,
Шул бер сүздә ничек каласы?

**2**

Ачмасам да, башка үлчәнешкә
Күчеп, яшәешнең яңасын,
Тирәнәя, киңәя дә барган
Чарасызлыгымның ярасын
Җилемләсен сүзем... ахирәттә
Дога булып инсен рухыма.
Үз-үземә көн-төн тукып торам:
«Чикләнгәнлек — черек тукыма.
Тукымага язган фанилыкның
Хата фаразларын укыма.
...Сират күпереннән уза алсам,
Кушылырмын яратучыма».
...Уйга талып, йоклап киткән саен,
Кояш төшә төшем учына!

## Әсир

Яшәешнең асылында
Мәңгелек көрәш... һәм... кан.
Кылыч уйлап табылмаса,
Дәһшәт чәчеп танылмаса,
Кирәкмәс иде калкан...

Һәр кузәнәк, һәр тере зат
Куркынычтан саклана.
Дөнья алдында көчленең
Фәлсәфәсе аклана.

Җиңгәннәр юк... Шатланганнар
Вакытлыча шатлана.
Егылачак тантананың
Байталына атлана.

Өзелгәннәр тузан эчеп,
Изелеп кала аста.
Яулап күнеккән кешелек
Нәфес сазында — хаста.

Чарасызмын... мидә кайный
Аяусыз чор тәэсире.
Кеше — мәңгелек алышның
Богауласын әсире.

Чордан чорга микроб булып,
Шулмы күчкән тәкъдире?..
Кайчан соң төшәр исенә
Хак Тәгалә исеменә
Юнәлтелгән тәгъбире?..

## Алтын пәрәвезләр

Жил кагылып, чыңлап өзелгәндә
Жан кылларым — күзгә пәрәвезләр,
Хөрмәт, ихтирамга лаек килеш
Бәһаләнми тузан күмгән эзләр,
Чагылганын хаят көзгесендә
Күргән саен тынычлыгым жуеп,
Чәбәләнәм, хәтер туфрагына
Чәчәк кадап, чал башымны куеп.
Сорау туа, күз яшьләрен коеп:
«Гаделләрнең нигә дөньялыкта
Яшәгәндә юк соң кадерләре?»
Вакыт узгач, басып аягүрә,
Кайсы чорны алма, соңлап күрә
Күк балкышы төшкән каберләрне...
Тормыш зарын сулап, ямансулап,
Өзелгәндә зыңлап пәрәвезләр,
Үкенермен кебек, калды диеп,
Әйтелмәгән күпме парвәз сүзләр.
Бүген мине иш итмәгән заман,
Бүген сине ишетмәгән заман,
Ә иртәгә, бәлки,
Юксыныр да күләгәнне эзләр.
...Киләчәккә самими моң чәчеп,
Бәхилләшеп... юк ла, исәнләшеп,
Өзеләләр алтын пәрәвезләр...

## Болыннарга чыксам

Болыннарга чыксам, күкрәгемә
Ярсыз шатлык керә ургылып.
Йоклап яткан уйлар уяналар,
Тышауларын өзеп куаналар,
Тулпар кебек күккә ыргылып.

Юкка чыга бөтен сызланулар,
Сыкранулар юган шикелле.
Рәхәт кенә татып бу дөньяга
Мин яшәргә туган шикелле.

Хуш ис кергән чакта үпкәләргә,
Эреп ага рәнжү, үпкәләр дә.
Онытыла әре-хуры да.
Табигатькә кушылганда гына
Кеше булам лаек урында.

Сөям дә мин, гүя сөеләм дә,
Хозурланам, яшьнәп яшәрәм.
Шул мизгелдә әллә өлгерәмме
Тулы гомер жирдә яшәргә?

Чикерткәләр черли... баш очымнан
Бал кортлары уза безелдәп.
Моңнан үргән шигырь-кәрәземә
Баллы сүзләр тама жемелдәп.

...Болыннарга чыксам, күкрәгемә
Мөстәкыйльлек керә ургылып.
Әйтерсең лә жирдән жиһангача
Күтәреләм тоташ нур булып.

Рәфкать
Кәрами

# КАЯ ЧАБАСЫҢ, ГОМЕР ЮРТАГЫ?

РОМАН

## 13

Егетләр үз бүлмәләрен үзләре җыештыралар иде. Дөрес, кайчагында алар бүлмәсен коридор җыештыручы апа юып чыгаргалый. Чөнки Габделнур ул карчыкка квартплата кәгазен тутырып бирә, вак-төяк электр әйберләрен төзәткәли. Күпчелек вакыт карчык идән юарга оныгын ияртеп килә. Ә ул алты-җиде яшьлек кыз бала авыру — тулы гәүдәле, шешенке күзле, калын иренле, теле, эре һәм сирәк тешле авызына сыймаган кебек, еш кына күренеп тә тора. Егет аны кызгана, ләкин җәлләвен сиздермәскә тырыша: шаярта, сөйләштерә, печенье яки конфет биргәли.

Бүген, Габделнур үзе идән себереп маташканда, ишек шакып, бүлмәгә тулай торак тәрбиячесе килеп керде. Зифа буйлы, җыйнак гәүдәле яшь хатын тыйнак кына исәнләште һәм гозерен әйтте:

– Габделнур абый, сезне культбытсоветка чакырырга куштылар.

– Нигә?

– Сез бит анда әгъза һәм әле «Яшьлек» газетасы редакторы да.

– Минме? — дип, сул кулы белән күкрәгенә төртеп күрсәтте егет, чөнки уң кулы әле һаман себерке тоткан килеш иде.

– Әйе, — диде аның бу соравыннан бераз каушап калган тәрбияче.

Габделнур иңнәрен сикертте.

– Беренче тапкыр ишетәм, — диде һәм, бераз тын торганнан соң, кисәк кенә әйтте: — Бармыйм да, йөрмим дә.

Тәрбиячегә тулай торак коменданты үз-үзенә бик ышанып әйткән һәм исемлек тә күрсәткән иде бит. Ничек алай килеп чыкты соң? Тәрбияче еларга җитешеп ялына башлады.

– Габделнур абый, төшегез инде, зинһарлап сорыйм. Анда ЖКО начальнигының урынбасары да бар. Алар мине ачуланачак бит. Кабат менгереп җибәрерләр.

Егет себеркесен шифоньер артына тотып атты да:

– Ярар, — диде.

Тәрбияче рәхмәт әйтеп чыгып китте. Болай тиз ризалашуының сәбәпләре бар иде. Бердән, бу яшь хатынның гаебе юк, аңардан башка гына исемлек төзеп куйган булулары ихтимал, икенчедән, Габделнур тәрбиячене — яшь балалы тол хатынны җәлләде. Эш шунда ки, узган ел көз көне аның мастер булып эшләгән ире суга батып үлде. Эштән соң салып утырганнар да, гайрәтләнеп, су коенырга киткәннәр. Эчкән кешегә диңгез тубыктан диләр бит. Ә анда, водозабор тирәсендә, чоңгыл булган, аягын көзән җыерган бахырның. Иптәшләре дә чак чыгып өлгергәннәр.

*Ахыры. Башы узган санда.*

Өстенә аксыл пиджагын, аягына тапочкасын киеп, егет аска төшеп китте.
Иң яхшы саклану чарасы — үзен башлап һөҗүм итү, дигән кагыйдәдән чыгып, ул кызыл почмакка керә-керешкә үк ризасызлык белдерде:
— Бәлки, мине үземә әйтмичә генә өйләндереп тә куярсыз? Миннән башка нигә сайлыйсыз? Болай да вакыт юк.
ЖКО башлыгы урынбасары — уртача буйлы, тулы гәүдәле ир уртасы кеше дә жебеп төшмәде: бу бүлмәдә кем хужа икәнен беренче сүздән үк төшендереп бирүне кирәк тапты:
— Син җыелышта булырга тиеш идең.
Егетнең дә тавышы әлегә көр чыкты:
— Бәлки, мин авырыймдыр? Минем бер минут та вакытым юк.
— Монда беребез дә тунеядец түгел. Утыр.
Бераз бәхәсләшкәннән соң, Габделнур каласы итте. Комендант битарафлык күрсәтте — сүзгә кысылмады, чәкәләшүне генә күзәтеп утырды.
Вазифаларны бүлү башланды. Газета чыгаруга килеп җиткәч, егет тагын теш-тырнакларын күрсәтте — һичничек тә мөхәррир булырга теләмәде.
— Ярар, член гына булырсың, — диде ЖКО башлыгы урынбасары, йомшап. — Егетләргә булышырсың.
Габделнур, сүзне беткәнгә санап, урыныннан торды һәм ишеккә таба юнәлде. Ә бүтәннәр — егермеләп кеше әле кузгалмаган иде.
Сөйләшүне алып баручы ачу белән, әмма үзенең хуҗа икәнен сиздереп, рөхсәт биргәндәй:
— Ярар, бар, бар, чык, — диде. — Син коллективтан аерыласың.
Дөресен генә әйткәндә, Габделнур монарчы, тәзү идарәсендә булсын, тулай торакта булсын, җәмәгать эшләреннән йөз чөермәде. Ләкин хәзер диплом язасы һәм дәүләт имтиханнарына хәзерләнәсе бар — баш тартмый хәле юк. Кем әйтмешли, ачка койрык чәнчеп йөгерәсе килми иде. Яшьләр күп: төрле югары һәм урта махсус уку йортларында кич яки читтән торып белем алучылар бар, кичәле-бүгенле төзүче-инженерлар институтын тәмамлап килгән мастерлар да байтак — алар эшләсен, аларга юл ачарга кирәк, аларны да җәмәгать эшләренә тартырга кирәк.
...Миргаязның дусты Әлфәс килде. Ул өйләнгән кеше. Шулай да иптәше янында тулай торакта еш була. Килгән саен, кесәсендә — ярты. Алар сөйләшеп утырганда, Габделнур су җылытырга куйган иде, чыгып юынып керде. Миргаяз өстәл тирәсендә булаша башлады. Ул арада Фәүҗәт тә кайтып керде. Өс киемен — мех курткасын, йонлач кара бүреген, кызыл шарфын һәм пиджагын салып, шакмаклы күлмәктән генә калды, аның өстеннән зәңгәр төстәге чаңгы костюмын киеп куйды.
Кайтканда, аның кулында төргәк бар иде. Сүткәч, аннан пөхтәләп төрелгән күлмәк белән майка чыкты. Эш шунда ки: аның киемнәрен йөргән кызы үзе сорап ала икән. Габделнур исә кер юу пунктына бирә. Шуңа күрә аның һәр күлмәк итәгендә ГГ тамгасы бар. Мәскәү кызы Аля янына йөргәндә, ул сынар өчен генә: «Күлмәк якасы каралган», — дигән иде. Туташның төксе чырае кара янды, кызарып чыкты һәм ул: «Мин сиңа прачка түгел!» — дип кырт кисте. Шуннан бирле егетнең берәүгә дә ялынганы юк. Чын күңелдән яратып йөргән Гөлзәриягә үзе сораса да бирмәс иде.
Өстәлгә кабымлык куелды, чәй кайнап чыкты. Кем әйтмешли, «тавык» янына «кунача»га савыт та менеп кунаклады.
Дусты Әлфәс килгән саен, Миргаяз аңардан бер хатын янына ничек итеп йөргәнен сөйләтә. Бу юлы да шуны исенә төшерде, тегесе кыстатып тормады. Байларча тамак кырып алды, мыегын сыпырып куйды:
— Армиядән кайткан гына чак, өс-башны да карыйсы бар, общагада ашау ягы да

тапкы-токы гына — һаман сталавай. Иялəндем, малай, бер бай хатынга — завмагка. Бер атна, ике атна йөрим, шуннан бу әйтмәсенме: «Әйдә, бөтенләй миңа күч». Мин өнсез калдым, ни әйтергә дә белмим, мин — яшь егет, ул — ике балалы хатын, яшь кызга өйләнәсе килә бит. Ну, тәрбиягә бер иялəнгәч, аннан да колак кагасы килми. Ярар, өйләнәм, дидем дә, для пущей убедительности, иске чемоданны илтеп куйдым, иске-москы тутырып... Янәсе моны карама көленә утырттым...

— Шуннан, шуннан, — дип, аны юри котырта Миргаяз.

— Ярар инде, беләсең бит инде, — диде Әлфәс, шулай да сүзен болай дип төгәлләде: — Мин юкта чемоданны каерып ачкан да чүплеккә чыгарып аткан; ушлый нәрсә иде шул, имансыз. Мин, тол хатынның бусагасы алтын булса да, сәдака тиеш, дип, үземә калса, саваплы эш эшләп йөрим, ә ул, имансыз, чемоданымны чыгарып аткан, үземне дә кабат кертмәде...

Әлфәснең бик сакланып кына эчкәнен күреп, Миргаяз:

— Син нәрсә кызлар кебек назландырып утырасың? — диде. — Чем добру пропадать, пусть пуза лопнет, диләрме әле.

— Бу арада ашказаны борчый.

— Кит әле, булмаганны, кеше ышанмастай сүзне хак булса да сөйләмә, — ак күлмәгенең җиңнәрен сызганып куйган дусты, чалбар кесәсеннән кулъяулык алып, тирләгән маңгаен, борын тирәсен сөртте. — Файдага гына ул, әйдә, тот әле, шнапс тринкен, немецлар әйтмешли... Әнә Эфиопиядә бер адәм кадак, пыяла ашый икән.

— Чираттагы ялган, — диде Фәүжәт, консерва банкасына чәнечке белән үрелеп.

— Чын әгәр, үзем укыдым.

Фәүжәтнең бирешәсе килмәде.

— Газетада элегрәк тә шундыйрак хәбәрләр булган иде: имеш, бер агач, кешене кочып алып, су урынына суыра икән; имеш, Африкада бер күл бар икән, анда радиация нормадан йөз тапкыр артык ди, ә барыбер шул күл янындагы авылда кешеләр яши икән, үзләре тап-таза ди.

Әлфәс бик җәелеп китмәде, шулай да әйтеп узды:

— Мин Чиләбе якларында хезмәт иттем. Анда булган икән хәлләр. Радиация дип бик исләре китмәгән, кайбер авылларны күчерми калдырганнар.

— Кешеләр яшиме? — дип сорады һәр яңалык белән кызыксынучы Фәүжәт.

— Кая барсыннар...

Габделнур андагы вакыйганы күптән ишеткән иде инде, чөнки туганнан туган абыйсы шунда солдатта булды, салып алса, кайбер нәрсәләрне сөйли иде...

Бүген Габделнур да егетләр табынына кушылды: тумбочкасында «НЗ» бар иде, шуны чыгарды, чөнки Гөлзәрия авылына, әнисе янына кайтып киткән иде. Ул Казанда булса, аның янына барасы — болай иркенләп утыра алмас иде. Дөресрәге, үзе үк теләмәс, хөрмәт иткән кадерле кешесе янына хәмер капкан килеш бармас, бу кыланышын кызы да ошатмас иде.

Алар бүлмәсендәге дүртенче кеше — республиканың төньяк районнарының берсеннән килгән егет авылына кайтып киткән иде; ике көнгә эштән дә сораган, әнисе хастаханәдә ята икән.

Миргаяз теманы үзгәртте, хыялга бирелеп алды:

— Их, егетләр, кешенең иң матур, иң яшь, иң гайрәтле чагы эштә уза.

— Эшләмичә нишләр иден? — дип сорады Габделнур, тегенең тел төбен аңышмыйча.

— Кырыкка хәтле уч тутырып пенсия бирсеннәр иде. Өйләнер идем...

Әлфәс, аны бүлдереп, төрттереп алды:

— Кәләшеннен ...парында җылынып кына ятар иденме?

Миргаяз һаман хыял дингезендә йөзә.

— ...Фатирга торбадан сыра кертсеннәр иде, краннан гына агызып алыр идем...

— Кем эшләми, шул ашамый, — дип мәгълүм мәкальне искә төшерде комсомол Фәүҗәт.

Миргаязнын үз туксаны туксан.

— Кырыктан соң үлгәнче эшләргә дә риза, — дип, сүзен йомгаклады ул.

Ләкин хәмер тәэсире башларына киткән зимагурларнын әле «даһиларча» фикер сөреше бетмәгән икән, әле берсе, әле икенчесе сүз кыстыра:

— Хатын иренә караганда күп акча алса, ул аны санламый башлый...

— Ир-егетнең үз кесәсендә ничә сум акчасы булуын тиененә хәтле белүе мәҗбүри түгел, ләкин акчасы барын ул һәрчак белеп торырга тиеш...

— Үз тиненне табу мәслихәт эш, артык акыллы яки күп белүче хатын да кулай түгел...

— Яшь хатынны калдырып, командировкаларга еш йөрү дә, гелән генә төнлә эшләү дә ярый торган гамәл түгел...

Миргаяз бераз уйланып утырды да әйтеп куйды.

— Әллә КамАЗ корырга Чаллыга китәсе инде.

Габделнур ана карап әйтте:

— Син теге кыз кебек.

— Нинди?

— Әллә урыска барасы, матур була баласы, дип әйткән ди бер кыз.

Миргаяз көлде генә, үпкәләмәде.

— Кияүгә чыкканмы соң?

— Чыккан. Аннан ник чыкканына үкенгән...

— Татарнын да була шакшысы, урыснын да була яхшысы...

— Ихтимал...

Әлфәс:

— Кайда да бер кояш инде, корыны бушка әйләндерү генә булыр, — диде. — Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер...

— ...барып карасаң, кәҗә дә бирмиләр, — дип дәвам итте Фәүҗәт. — «Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен...»

— Мин беркая да китмим. Монда саз ерган да җитәр.

Габделнурның бу сүзләренә каршы:

— Синең, ичмаса, фатир алырга өмет бар, — диде Миргаяз, соргылт кашларын җыерып. — Ә мин... җыештырып, кооперативка тырышсам гына инде...

— Әй, кайгырмасана, — диде Әлфәс һәм үзенең китап караштырганын белдерү өчен әйтеп куйды: — Марк Твен болай дигән: «Әгәр иртәдән бер дә елмаймасагыз, көнне бушка үткәнгә санагыз».

Миргаяз, каршы төшеп, төзәтмә кертте:

— Әлфәс, ул болай әйтергә уйлагандыр: «Әгәр йөз грамм эчмәсәң, көнең бушка үткән».

Аннары ул тагын стаканнарга аракы агызды. Монысы үзе кыстырып кайткан шешәдән иде. Әлфәсне мәҗбүриләп дигәндәй кыстаса да, ул үзе дә аракыны бик интегеп, авыр эчә, стаканын бушаткач, кулы белән авыз тирәләрен сыпыра да бер йотым сыра каба, аннан ашый башлый. Сөйләшкәндә, бик әкрен, һәр сүзен кысып чыгаргандай көчәнә — авыру кеше сыман сөйләшә, фәлсәфәгә бирелә.

— Берәр ямьсез кызга өйләнәм, — диде ул, бу юлы беркавым уйланып утыргач.

— Кызлар ямьсез булмый, — диде ризык капкалап утырган Фәүҗәт.

Ләкин аңа игътибар итүче булмады.

– Нигә? – дип сорады Миргаяздан өйләнгәч житдиләнеп киткән, арык тәненә ит куна башлаган дусты Әлфәс.

– Өйдә хозяйка гына итеп тотам. Чибәрләр алар читкә йөри.

– Кырыкта туктар әле, – дигән булды яшь егет Фәүжәт, янә олылар сүзенә кысылып.

– Киресенчә, – диде тәжрибәле Әлфәс, аңа каршы төшеп. – Кырык яшькә житкәч, хатыныгызга икеләтә-өчләтә күз-колак булыгыз.

– Ни өчен?

– Бу яшьтә алар утлы табага баскан уналты-унжиде яшьлек кызлар кебек булалар.

– Каян беләсең? Синеке әле ул яшькә житмәгән бит, – диде Миргаяз, күзләрен кыскалап.

– Теге хатын әйткәние.

– Бөтенесе дә алай түгелдер инде, – диде Габделнур, үзен бик белдеклегә санап һәм ул теманы үзгәртте: – Әгәр мин ил житәкчесе булсам, ашханә, кафе, мунча, чәчтарашханәләрне шәхси кулларга бирер идем.

Егетләр башта аптырап калдылар.

Ниһаять, Әлфәс телгә килде:

– Ни өчен?

– Конкуренция булсын һәм яхшырак хезмәт күрсәтсеннәр өчен.

Социализм чорында туган һәм яшәгән егетләр өчен бу тема ят, һәм алар университетта шактый белем эстәгән, политэкономия фәнен өйрәнгән Габделнур кебек фикер йөртмиләр иде. Шуңа күрә бик эчкә кереп китмәделәр.

Аннары сүз эш, уку, лотереяга машина оту хакында барды. Миргаязның бик отасы килә, ләкин әлегә автомобиль түгел, кырыну машинкасы да отканы юк. Ул отмасын да белә, әмма ләкин һаман лотерея билеты сатып ала.

Фәүжәт, яшь кенә булса да, үз чамасын белә.

– Егетләр, мин – пас, – диде. – Йокым килә.

– Син – үрдәк кебек – ашыйсың да йоклыйсың, – диде Миргаяз, янә шешәгә үрелеп. – Әйдәле.

– Үрдәк – йокламый, ашый да суга сикерә.

Көлештеләр. Әлфәс, Габделнурга карап, сорады:

– Синдә ни хәлләр бар?

– Тамак тук, өс бөтен, к...н чыга төтен, – диде Габделнур, уенга алып, аннан соң житдиләнде. – Укуны сорасаң, жай белән генә бара.

– Быел дипломны кесәсенә сала инде, түшенә «ромбик» та кадый, – диде Миргаяз, аның тавышында көнчелек түгел, ә бүлмәдәше өчен горурлык хисе чагылды. – Безнең авылда бер карт, оланнар, жырсыз-музыкасыз тормыш майланмаган арба кебек, дип әйтә торган иде. Мәрхүм, аз гына салса, жырлап жибәрер иде. Әйдә, Габделнур, суз әле баяныңны.

Габделнур ялындырып тормады, кем әйтмешли, «әргән»ен тартып та жибәрде. Миргаяз үзенең яраткан «Баламишкин»ы көенә жыр сузды:

Аракыны кем ясаган –
Иван белән Ычтапан;
Ал күтәреп, эчеп жибәр,
Үзеңә тигән стакан.

Озак еллар тулай торакта ялгыз яшәп, йөрәкләре янган зимагурлар кайчагында чыгырдан чыгып та куйгалыйлар: тозлырак жырлар да ычкына; шөкер, бүлмәдә

хатын-кыз заты юк бит. Бәлки, шунадыр, хатын-кыз заты булмагангадыр, асыл затларны сагынып искә алалар, һәм җырларның күбесе аларга багышлана.

Бераздан кабат «тәртипле егетләр»гә әверелделәр: җырларының сүзләре колакка да, күңелгә дә ятышлы, тавышлары матур яңгырый.

Уфа юллары пыяла,
Таш булса таймас иде;
Уф, яна йөрәккәй генәм,
Син булсаң янмас иде.

Карурманга кермәс идем,
Карурманда атларым;
Кычкырып җырламас идем,
Бик ямансу чакларым.

Шул рәвешле эчләрен бушаткач тынып калдылар, дөресрәге, Габделнур баян каешларын иненнән алгач, туктарга мәҗбүр булдылар.

Әлфәс китәргә җыенды. Миргаяз аны озата чыгасы итте. Ул кышкы җылы ботинкасын һәм яшел төстәге юка пальтосын киде, зәңгәр шарфын муенына салды, «Москвич» дип йөртелә торган, солдат пилоткасын хәтерләткән бүреген башына чәпәде, мех эчле перчаткасын кулына тотты. Күрәсең, бераз җилләнеп, үзе әйтмешли, хәмерле башын сафландырып керергә иде, ахры, исәбе.

Киенгәндә сөйләнде. Эш шунда ки: аның бу араларда, үзе әйтмешли, «кайгылы» чагы: өйләнә алмыйча калды. Туган авылына кайткач, яшьтән белгән бер кызны очраткан. Бик тиз сөйләшеп-аңлашып та алганнар. Кызның да яше шактый икән инде. Яңа елга кайтып язылышмакчы булганнар. Егет киткәч, әтисе эш йөрткән һәм хат җибәргән: «Кызың бер барганда риза иде, икенче барганда, йөрмәгез әле ачу китереп, дип әйтте», — дигән. Ялынып тормый Миргаяз, телеграмма җибәрә: «Мин сезнең белән риза, Оренбургка барыгыз». Әти-әнисе шунда кунакка барырга җыенган булганнар икән. Ә кызга ачу-ирония белән хат язган.

Чыгарга әзерләнгәндә, ул шуны Әлфәскә дә сөйли иде.

Ахырда:

— Яздым бөтенесен, — диде. — Гомеремдә онытмаслык иттем.

Фәүҗәт төрттереп алды.

— Безнең авылда бер хатын, әйттем әле, бик каты әйттем, синең артың — минем авызым, дип әйтеп әйткән, ди. Шулайрак түгелдер бит?

Миргаяз үпкәләмәде, ләкин җавапсыз да калмады:

— Кит әле моннан, анаң яламаган нәрсә, япь-яшь башың белән атаң урынына калган абзаннан көлеп торасың...

Егетләр чыгып кына киттеләр, ишек шакыдылар. «Керегез!» дип әйткәнне дә көтеп тормыйча, бүлмәгә әлеге дә баягы ЖКО башлыгы урынбасары килеп керде, үзе белән комендант һәм тәрбияче дә иярткән.

Габделнур ишеккә каршы баскан иде.

— Нәрсә, тәртип бозабызмы? — дип сорады симез гәүдәле «хуҗа», иснәнеп, аның сүзләре фактны раслау кебегрәк яңгырады.

— Юк, — диде Габделнур, урыныннан кымшанмыйча, киң җилкәсе, таза күкрәге белән өстәлне мөмкин хәтле капларга тырышты.

Тегеләр кергәләгәнче, Фәүҗәт өстәлдән кирәк-кирәкмәс нәрсәләрне җыеп өлгергән иде инде.

Шулай да хуҗа тиз генә чыгып китмәде, егетләрнең бүлмәсен күздән кичерде. Пөхтә итеп, солдат казармасындагыча тәртип белән җыештырылган дүрт койка, һәрберсендә мендәр, икешәр сөлге: берсе — алда, икенчесе — аяк очында;

салфетка җәелгән тумбочка өсләрендә китаплар, календарь, дәфтәрләр, газета-журналлар, линейка, хушбуй, дарулар, фотокарточка һәм открыткалар; бүлмә уртасындагы өстәл өстенә газета җәелгән, чәйнек кукыраеп утыра, бәләкәй көзге тора, шунда ук түгәрәк сәгать — будильник. Ә өстәл астындагы банка, кәстрүл, шешә һәм стаканнарны «хуҗа» күрерлек түгел — клеёнка итәге каплый. Бүлмәдә биш-алты урындык та бар, берсенә китап өелгән, икенчесенең артына Габделнурның аксыл пиджагы эленгән, калганнары өстәл тирәли тезелгән. «Хуҗа» иренмәде, ишек катындагы сары шифоньерларның берсен ачып та карады, анда элгечтә чалбар, замоклы мех куртка, пальто, плащ ише кием-салымнан гайре шикләнерлек әйбер күрмәде. Ишек янындагы радиоалгыч та, яшел чуклы абажур да үз урынында, тәрәзә төбендә зур гөл, ә кружкада чәнечкеле кактус. Дивардагы дөнья һәм СССР картасы егетләрнең сәяси яктан «тотрыклы» икәнлеген белгертеп тора, аларга карата булган «ышанычны» арттыра.

Кыскасы, үзенең күзәтүләреннән «хуҗа» канәгать калды булса кирәк, ризасызлык белдермәде. Бераз гәпләшеп, шулай да «кыйммәтле күрсәтмәләр» — «ЦУ» биргәч, делегация җитәкчесе ишеккә таба борылды.

Аның артыннан Габделнур:

— Бәйләнергә сәбәп эзләп йөри, — дип ризасызлык белдерде.

## 14

Габделнур Гөлзәрия янына китте. Кыз кичә авылына кайтасы иде. Бүген иртәрәк килергә вәгъдә бирде. Чөнки егет аңа театрга билет аласын әйтте.

Бүлмәдәш кызларының берсе — кечкенә юантык гәүдәле, ләкин нечкә билле, чәчен артка өеп, зәңгәр тасма белән бәйләп куйган көләч йөзле Мәсния — ялгызы гына чәй эчеп утыра, ә Гөлзәрия — юк.

— Ул кибеткә генә чыкты, — диде кыз, егеткә урын күрсәтеп. — Утырыгыз. Хәзер кайтыр.

Егет эшләпәсен генә салды да ишек катындагы урындыкка чүмәште.

Мәсния:

— Чәй ясыйммы? — дип сорады, карасу түгәрәк йөзен балкытып.

— Юк, рәхмәт! Сез мина карамагыз, эчегез.

— Эчтем инде, — диде кыз һәм, чынаягын күтәреп кухняга юнәлде. Ләкин чыгар алдыннан, халат кесәсеннән тарак алып, ишек янындагы көзге каршына басты да маңгай чәчен рәтләде.

Габделнур плащының эчке түш кесәсеннән китап алды. Ул ишеккә арты белән утырган иде. Бераздан бүлмә ишеге ачылды, ул әлеге кыз — Мәсния кергәндер дип борылып карамады, укуын дәвам итте. Ләкин шулчак кемдер арттан килеп егетнең күзләрен каплады. Йомшак, җылы кулның кемнеке икәнендә егетнең шиге юк иде. Ул, аптыраган булып, башын боргалады, китабын тезләренә куярга өлгермәде, күзләрен каплаучы, башын иеп, колагына пышылдады:

— Нишләп утырасың?

— Укыйм. Кайттыңмы?

— Әйе.

— С приездом!

— Рәхмәт!

— Өегездә ничек? Бер килеш кенә торалармы?

— Барысы да исән-сау. Рәхмәт!

— Нинди китап укыйсың?

— «Консуэло», — диде Габделнур, ә үзе аны ябып куйды. — Бик яхшы, кызыклы, җырчылар турында, дөресрәге, бер испан кызы турында.

Кыз өс киемен салып элде дә егет каршына караватка утырды, егеткә карады, егет — ана. Гөлзәрия елмая, иреннәре үзеннән-үзе ачылып китә, ул егетенен күзен каплавы өчен оялып та куйды, бит алмалары кызарды. Габделнур анын яшькелт-зәнгәр күзләренә туры карады: сынап, текәлеп, сагынып, яратып. Кыз, оялып, күзен йомды, янә ачып, ана карады. Кызнын карашында яраткан кешесенә бирелгәнлек, игътибар чагыла иде. Ул егетнен туфлиләренә күз төшереп алды да, тиз генә торып, чүпрәк белән аяк астындагы юешне сөртте. Әлеге гамәленнән үзе оялган сыман да күренде. Ул, гомумән, чисталык, пөхтәлек, төгәллек ярата: бу анын урын-жирендә дә, тумбочка-караватында да, киемендә дә чагыла. Өстендә көрән свитер, кара итәк, бер толым итеп үргән чәче бил тинентен төшеп тора. Бу киемнәре белән ул тагы да жыйнаграк күренә шикелле, биле дә нечкәрәк кебек, үзе дә кечерәебрәк калган сыман. Әмма анын һәр хәрәкәте, бар булган киеме (үтә затлыдан булмаса да) егет күнеленә якын, кадерле.

...Әгәр дә моннан ярты ел элек Габделнурга, син бер кызга үлеп гашыйк булачаксын, күзенә ак-кара күренмичә, анын янына йөгерә-чаба барачаксын, фәкать анын турында гына уйлаячаксын, дисәләр, ул мона ышанмас, хәтта, юләр, андый хәлнен булуы мөмкинме сон, мин Мәжнүн яшеннән уздым инде, дип көләр генә иде. Әмма егетнен бүгенге халәте нәкъ шулай: Гөлзәрия анын бөтен барлыгын биләп алды: хатын-кыз гүзәллегенен тулы чагылышы — ул, кызларнын чибәрлеге — ул. Кайчагында ул үз-үзенә әйтә: «Мәхәббәт янгын түгел, иптәш элекке пожарный, кабынып китсә, сүндерә алмассың!» Һәм Габделнур мона бер дә көенми, бәлки, сөенә генә. Бу халәт аны ялыктырмый, эшенә дә, укуына да зыян итми. Киресенчә, иннәренә канат куя, ана булыша. Ул табигатькә дә икенче төрле карый башлады — һәрнәрсәгә соклана.

...Урамда апрель. Яз кояшы көннән-көн юмартрак кыздыра — жылы, хәтта кичке якта да биналарны яктыга күмә. Әле агачлар яфрак ярмаган, ә шулай да нindiдер үзгәреш сизелә — алар өстеннән яшел йөгертелгән кебек.

Биек тупыл башларындагы бүрек-бүрек ояларга жир төсле кара, ябык каргалар хужа булып алган — шатланышып та, зарланышып та тавыш бирәләр, танышалар, кавышалар, сөйгән ярларын бүлешәләр; кайберләре инде тынычланган һәм үз хужалыгын тәртипкә китерә: чыбык-чабык, мамык-кауры ташый, жылыта, кыскасы, кукәй салырга һәм бала чыгарырга әзерлек эшләре алып бара.

Сыерчыклар да киң күнелле кешеләр ясап куйган бәләкәй өйләренә кереп-чыгып йөриләр, әзергә-бәзер кунсалар да, әле үзләренчә тикшергән булалар. Шәһәрдәге малай-шалай да аларны күзәтә, күнеленә хуш килер микән алар жан жылысын салып үз куллары белән әмәлләгән оялар...

...Габделнур хәзер урамда күргән кайбер кызларнын төс-битен Гөлзәриягә охшата, кайсыларынын тавышы анынкына тартым, икенче берәүләрнен сөйләшүе яки көлү-елмаюы анынкын хәтерләтә; бер-ике мәртәбә төшенә дә керде, андый чакларда сөйгәнен өнендә күрәсе килү теләге тагы да көчәя. Ул аны әнә шул рәвешле уйлап хозурлана. Ләкин егет бу хакта Гөлзәриягә әйтми, анын, и хыялый, дип әйтүеннән шикләнә.

Бераздан Гөлзәрия дә чыкты, һәм алар театрга киттеләр.

Опера театрында «Түләк белән Сусылу» спектаклен карап чыккач, тәэсирләре белән уртаклаша-уртаклаша, таксида кайттылар. Чөнки сигезенче яртыда башланган спектакль шактый сон бетте, шуна күрә егет машина тотты.

...Гөлзәрия, вахтёр белән сөйләшеп, егетне бүлмәсенә дәште.

— Мин сине авыл күчтәнәчләре белән сыйламадым бит әле, — диде кыз һәм, тиз генә кием алыштырып, кухня белән ике арада килеп сарып йөрде.

Бер керүендә ул китап укып утырган егетен арттан кочып алды, Габделнур анын башын сак кына борып үпте.

— Сагындыңмы?

— Юк, — диде кыз, ә үзе кысыбрак кочты. Аларның болай иркен кылануларының сәбәбе бар: бүлмәдә икәве генә. Мәсния төнге сменага эшкә киткән, икенчесе авылдан килеп житмәгән, өченчесе чираттагы ялда.

Гөлзәрия әүвәл егетне өстәл янына дәште, аннары үзе дә утырды, халат итәген тартып куйды, изүен рәтләде, чәй ясады, тәм-томнарны кунакка табарак этәрде. Табында шикәр, бал, булки, бер кисәк гөбәдия, балан пирогы һәм жир жиләге кайнатмасы бар иде. Габделнур кайнатма белән чәй эчкәч, чынаягын тәлинкәгә каплап куйды — кызы алдында ашап утырырга читенсенде.

— Рәхмәт!

— Тагын эч инде, — дип кыстады Гөлзәрия. — Ашамадың да.

— Рәхмәт! Соң инде, сина иртүк эшкә, миңа да, — диде егет һәм, буш караватларга таба ымлап, әйтмичә кала алмады. — Берүзең курыкмыйсыңмы соң?

Гөлзәрия аның тел төбен аңлады, билгеле, ләкин ачуланмады; гел елмаеп торган йөзе житдиләнде, нур чәчеп торган күз карашы да уйчанланды. Ләкин бу егетне калдырыргамы, юкмы?» дигән икеләнү түгел, ә сөйгәненең аңа карата мөгамәләсе ни дәрәҗәдә житди икән дигән шик бер генә мизгелгә уена килеп китү нәтиҗәсе иде. Ул икеле-микеле уйларга урын калдырмаслык итеп кистереп әйтте:

— Юк.

Хәер, Габделнур артыгын әрсезләнмәде, торып, өстенә киенде.

— Тыныч йокы, — дип, кызны кочагына алды, кайнар иреннәреннән озак итеп суырып үпте дә ишеккә юнәлде.

— Сина да, — сул кулы белән халат изүен тотып, уңы белән егетнең плащ жиңенә кагылып, Гөлзәрия аны озатып калды.

Сагызланмавы, ялынып-ялварып, үгетләп, кунарга калырга маташмавы өчен күңеленнән Габделнурга рәхмәт әйтеп һәм шундый асыл егеткә тап булуына, үзен чын күңелдән яратуына сөенеп, кыз кая басканын да тоймыйча очынып йөрде: өстәл жыештырды, кухняга чыгып керде, үзен тәртипкә китерде, утны сүндереп, урынына ятты. Бу очрашуларны киләчәк бәхетенә юрап, татлы хыяллар дингезенә чумып, ул әле бик озак йокыга китә алмады.

Ә бу вакытта Габделнур атлы егет тә, берьялгызы тыныч урамнардан биек йортларның тәрәзәләрендә берәм-берәм утлар сүнүен күзләп кайта-кайта, татлы хыялларга бирелде. Әле һаман да сөйгәненең кайнар иреннәре тәмен тойган кебек булды. Соңгы вакытта аның күнелен Гөлзәрия хакындагы уйлар бик еш били, аны гел күрәсе килә, аңа карата булган тойгыларының сафлыгына, яратуының ихласлыгына, үзенең дә рухы сафлана баруына сөенеп туя алмый.

Егет сизенә: аның шулай яхшыга таба үзгәрүе үзенә генә түгел, ә Гөлзәриягә дә бәйле иде. Чөнки кыз алдау-йолдауны белми, дөресен сөйли, үзен итагатьле тота. Кыскасы, егет холкының унай якка үзгәрүенә кызның да өлеше барлыгын чамалый иде. Ул шуны да искәрде: кыз әйтсә сүзен туры, кистереп әйтә, усал булмаса да, жебеп кала торганнардан түгел. Егет, беренче күрүдә үк, аның өске ирене аскысына караганда юкарак икәненә игътибар иткән иде. «Юка иреннәр — усаллык билгесе» дип ишеткәне бар иде аның. Юк, Гөлзәрия усал түгел. Өске ирене — әдәплелек, үз-үзенә таләпчәнлек билгеседер.

Хәзер ул киләчәк язмышын фәкать шушы тыйнак, йомшак, ләкин кирәк чакта кырыс та була белгән кыз белән генә бәйләргә тели. Моны бүлмәдәге иптәшләре дә сизделәр, шуңа күрә егетләр арасында була торган тупас шаяртуларын, фәлән-төгән дип авыз чайкауларын, киная белән сөйләшүләрен туктаттылар. Габделнур Гөлзәрияне коча, иркәли. Дәрте ташып торган чаклар еш була. Хәзер инде кыз тарафыннан да шундый ук дәрт сизелеп тора. Ләкин егет үзенең теләкләренә хуҗа була белә. Шуңа күрә дә ул аны тулай торакка бүлмәсендә иптәшләре булмаганда

да чакырмый. Бүтәннәр алай түгел, яшь кенә булса да, Фәүҗәт тә кызын дәшкәли. Алар бер-берсенә карата нинди мөнәсәбәттә? Анысы Габделнур өчен караңгы, аның кеше эшенә тыкшыну, кеше тикшерү кебек яман гадәте юк. Габделнурның бу кызга мөнәсәбәте бөтенләй башка. Ул аны чын ярату белән ярата, ана карата фәкать саф мәхәббәт хисләре генә тоя, шуның ялкынында көн-төн яна. Гөлзәрия дә моны сизә, аның да егеткә ышанычы көннән-көн арта. Бүген беренче тапкыр аны арттан кочып алуы да шуның хикмәтедер, мөгаен, чөнки монарчы егет кыз тарафыннан андый кыюлыкны күргәне, үзенең ихлас хисләрен тышка чыгарганны тойганы, назының шулхәтле кайнарлыгын татыганы юк иде әле.

Икенче атнада алар Спорт сараенда филармония артистлары концертын карадылар. Габделнур берочтан Гөлзәриянең иптәшләренә дә билет алган иде, бүлмәдәшләре дә, дус кызлары да концертны һушлары китеп карадылар. Кайтканда сүз әле генә тамаша кылган концерт хакында гына барды. Әлфия апаларының да, Венера апаларының да җырлавына сокландылар. Тик гәп һаман Илһам Шакиров тирәсенә әйләнеп кайта иде.

— ...Мина «Кама буе — туган як» җыры ошады.

— Ә мина — «Мәхәббәтем».

— «Имәннәр шаулый»га җитми инде.

— «Әниемә хат»ны җырлаганда, еламыйча көчкә чыдап утырдым.

Әмма бу юлы берсе дә, мина карап җырлады, димәде. Егетләреннән оялдылар булса кирәк, чөнки күбесе парлы иде.

Ахырда барысы да, егетләрен көнләштереп, аларга шундый яхшы «культпоход» оештырганы өчен, Габделнурны мактадылар. Үзләре генә калгач, Гөлзәрия дә ана чын күңелдән рәхмәт әйтте, бик җылы саубуллашты.

Габделнур бу бүлмәне үз итте. Чөнки мондагы мохит, хәтта ис тә бөтенләй башка — егетләрнекендәге кебек түгел. Егетләр бүлмәсе тәмәке, аракы, сыра исе сеңдергән була — ачы тәм кергән ризык кебек. Ә кызлар бүлмәсендә үзеңне шәһәр урамыннан болынга, урман аланына кергән кебек тоясың: тәрәзә төбендә төрледән-төрле гөлләр чәчкә атып утыра, диварда очсызлы булса да, зәвыклы картиналар, караватларда челтәрләр, күпертелгән мендәрләр, тәрәзәләрдә пәрдәләр, тумбочка өсләрендә китаплар, журналлар, кызлар гына куллана торган пудра, ислемай, крем, кечкенә көзге, тарак, заколка-приколкаише бизәнү әйберләре. Кыскасы, төрлесе төрле районнан җыелган, төрлесе төрле эшләр башкаручы кызлар бердә бер гаилә булып тату яшиләр, һәрхәлдә, Габделнурның ызгышу түгел, аларның хәтта сүзгә килгән чакларына да тап булганы юк. «Хәер, шул егетләр бүлешсәләр генә инде, — дип, үзалдына елмая егет. — Алары да шәһәр җирендә буа буарлык, янәшәдә генә ничә тулай торак бар». Модалы шәһәр кызларыннан аермалы буларак, боларның кием-салымы да гадирәк — үтә кыйммәтле түгел, алтын-көмеш чылбырлар, асылташлар да такмаганнар, әмма бар булганы чиста, пөхтә, үзенчә зәвыклы — егет-җиләнкүңеленә хуш килердәй; боларның куллары да теләсә нинди эшкә ятып тора.

Кызларның берсе дә тик утырмый. Габделнурның бу килүендә уртача буйлы, тулы көпшәк гәүдәле, уйчан аксыл йөзле Дәнисә өстәл янында нидер язып утыра иде. Ул башын күтәреп, егеткә сәлам бирде. Кыз саргылт чәчен, сулдан юл ачып, ике якка тараган, аның күз төпләре каралып тора, тулы битле, эре чәчкәле соры күлмәктән.

Фаһирә яткан көйгә китап укуын дәвам итте, өстенә одеялын тартыбрак куйды. Ул кичке урта мәктәптә, соңгы сыйныфта укый, заводта эшли. Мәсния кухня белән ике арада тыз-быз чаба.

Караватта утырган Гөлзәрия халаттан, гадәтенчә, аның итәгенә кагылып, йомры тез башларын каплады, изүен рәтләде.

Габделнур сокланып карады.

— Нихәл?

— Ярыйсы.

Ләкин кызның сөмсере коелган сыман, сөйләшергә дә атлыгып тормый шикелле, карашында даниндидер салкынлык бар төсле, үзе читкә караган. Егет сагая калды, ләкин эчке халәтен сиздермәде.

— Нәрсә укыйсың?

— Син биргән «Чалы кошы»н.

Сүз төрек язучысы Ришад Гюнтекинның татарчага тәрҗемә ителгән романы турында бара иде. Әле яңа гына китап кибетләрендә күренгән ул китапны Габделнур ике төндә укып чыкты. Бик ошагач, сөйгәненә дә укырга киңәш итте.

— Әле бетермәдеңмени?

— Юк.

Ничектер сөйләшер сүз юк кебек, әңгәмә ялганып китә алмый. Бераз дәшми торганнан соң, Гөлзәрия егеткә туры карап сорады:

— Кичә кайда идең?

— Кичме? Кинода идем, «Почтовый роман»ны карадым.

— Шәп булдымы соң?

— Әйе.

Кухнядан Мәсния кереп, үз караватына утырды, кулына китап алды — кыз техникумга керергә хәзерләнә.

Фаһирә, китабын ябып, урыныннан торды. Ул — озын сылу гәүдәле, көләч алсу йөзле, күзе якты, борыны туры, тулы яңаклы һәм түгәрәк иякле чибәр кыз. Анардан яшьлек-сафлык аңкып тора; кап-кара кыска чәчен артка тараган, өстендә аксыл кофта.

— Бу арада күзгә-башка күренмисен? — диде ул Габделнурга.

— Син отпускыда идең бит, — дип акланды егет һәм сүзне уенга борды: — Була инде ул, без бит синең белән бертуганнар түгел.

— Кызганычка каршы, — диде кыз. — Бәлки, капка баганалары бертугандыр?

— Онытып торам икән, рөхсәт итсәгез, розеткагызны карар идем, — диде егет һәм куен кесәсеннән кечкенә отвёртка чыгарды.

— Рөхсәт, рөхсәт, — диделәр кызлар беравыздан.

Узган килүендә Габделнур аларның ватык розетка белән җәфалануын күргән иде. Бүген шуны биш минут эчендә алыштырып-төзәтеп куйды.

Мәсниянең шатлыгы эченә сыймады:

— Кулың алтын икән!

Егет елмайды:

— Үзең бакыр булсаң да, дип тә өстә инде.

Фаһирә каршы төште:

— Алай димә, Габделнур абый, үзең дә көмеш.

Гөлзәрия дәшмәде, кызларның тел чарлавын читтән генә карап торды.

Дәнисә язуыннан туктады да каләмен өстәлгә ташлады.

— Кичә берүзем киногa барган идем, яртысын карагач чыгып киттем, — диде кыз, әллә Габделнурга, әллә үзалдына әйткәндәй.

Ул, гадәттә, уйчан, дәшми, бөтен эч серләрен әйтеп бетерми, ә бүген ничектер ачылып китеп сөйләшә. Ул шаян түгел, хәрәкәтләре дә әкрен.

Егет:

— Нигә? — дип сорады.

— Янәшәдә утырган яшь-җилкенчәк үбешә башлады, ачуым килде, барысы да парлы-парлы...

— Азагын да әйт инде, — диде Габделнур, елмаеп.

— Ничек?

Мәсния авыз тутырып дигәндәй әйтеп бирде:

— Безнең авылда болай әйтәләр: «Барсы да парлы-парлы, безгә фәләнем бармы?»

Кызлар көлештеләр, егет тә аларга кушылды. Гөлзәрия генә әллә оялды, әллә ошатмады — авыз чите белән генә елмайды, йөзен читкә борды.

Дәнисә бу юлы туп-туры Габделнурга мөрәҗәгать итте, шелтәсен белдерде:

— Бер егет тә табып бирмисең, ичмасам.

— Сорамыйсың бит, — дип акланды Габделнур, — монарчы үзең таба иден.

Дәнисә уйга калды:

— Китәм мин моннан. Туйдым. Районга китәм, райком комсомола инструкторы янына.

Күрәсең, сүз элек йөргән егете турында барадыр, кызлар бу хакта хәбәрдар. Габделнур исә төпченеп тормады, кызны юатасы итте:

— Мин сиңа егет табам, китмә.

— Шулаймы? Булды, алайса, китмим.

Мәсния дә сүзгә кушылды:

— Миңа да кирәк.

— Ә синеке кайда? Узган атнада бик матур итеп кочаклашып тора идегез бит.

— Китте ул. Кудым мин аны. Аш төрләндерергә кирәк, манный боткасы да туйдыра.

— Әллә күп ашадыңмы?

— Мин булнистә яттым, ике операция ясаттым. Шунда күп ашадым. Хәзер манныйга карыйсым да килми.

— Ә безгә армиядә «кирза» ашаттылар.

— Ул итек түгелме соң? — дип сорады Дәнисә.

— Юк. Перловканы шулай атап йөртә идек.

Фаһирә дә егет сорады, ә үзе көлә. Аннары ул, дивардагы рәсемнәрне күреп, бүлмәдәшенә дәште:

— Мәсния, теге морякны алып ташла, кызы гына калсын.

— Торсын, матур бит.

Фаһирә әйтеп куйды:

— Без кинога барабыз, сәгать сигезгә.

Габделнур әңгәмәне дәвам итте:

— Нинди фильм?

— «Күл буенда».

Бераздан Дәнисә кулына бәйләү алды. Мәсния, көлеп, аны үрти башлады:

— Син безне алдыйсың бугай, апаның кызына, дигән буласың. Авылда үзеңнең кызың бардыр әле, шуңа бәйлисеңдер.

— Лыгырдама, — диде Дәнисә дорфа гына һәм, үзалдына нидер көйләп, юантык бармаклары белән энәләрен тиз-тиз хәрәкәтләндерә башлады.

Көләч йөзле Мәсния, аны тынычлыкта калдырып, Габделнурга таба борылды:

— Ленин урамындагы хәзерге «Пионер» кинотеатры элек фәхешханә булган икән.

Егет белмәмешкә салынды, җавап кайтармады, инен генә сикертеп куйды.

Мәсния тагын теманы үзгәртте:

— Кызлар, кәртле уйныйбызмы?

Аңа җавап бирүче булмады. Алар кайчагында, уртага икешәр тиен акча салып, «Тугызлы» дигән уен уйныйлар иде...

Сылу гәүдәле Фаһирә егеткә бер елмаеп карады да аягына җылы тапочка киеп чыгып китте. Гөлзәрия сүзгә катнашмыйча, аскы иренен тешләп, гамьсез утыра бирде. Үзе кайчак егеткә дә карап куя һәм йөзендә мыскыллы елмаю чагылып киткән сыман була. Бүген анарда, элекке кебек, хуҗасы күзенә карап торган маэмай карашы сизелми.

— Кәефең юкмы әллә? — дип сорады егет, кызның уйчан йөзенә, боек күзләренә карап.

— Нигә? — дип, янә мыскыллы елмаеп куйды кыз. — Бар.

— Күренми.

Ишек шакыдылар. Ике яшүсмер килеп керде: берсе — Фаһирәнең йөргән егете, икенчесе — энесе. Габделнур алар белән кул биреп исәнләште, хәл-әхвәл сораштылар. Ул арада Фаһирә дә бүлмәгә керде, егетләргә урын бирде. Бер-берен күптән белгән кешеләр, туганнар арасында була торган әңгәмә башланды: эш, уку, авыл хәлләре, туган-тумача.

Габделнур бу бүлмәдә үзен артык кеше итеп тойгандай булды, китәргә җыенды һәм Гөлзәриягә:

— Әйдә чыгабыз, — диде.

— Юк, чыкмыйм.

— Коридорга гына озата чык, алайса.

Кыз риза булды, кузгалды. Егет бүлмәдәгеләр белән саубуллашты.

Коридорда тәрәзә каршында беркавым басып торгач, Габделнур йомшак кына сорап куйды:

— Берәр туганың авырмыйдыр бит?

— Юк.

— Эшеңдә берәр күңелсезлек бармы әллә?

— Юк, — диде кыз, егеткә туры карамыйча гына.

Егетнең тавышы элеккечә йомшак, әмма борчулы иде:

— Алайса, әйт: ни булды? Миңа сине бу хәлеңдә күрү...

Кыз аны кырт кисте, сүзен бүлде:

— Ни хәлдә?

— Хәсрәтле дип әйтимме, ачулы димме... Карашың салкын.

Кыз, аскы иренен тешләп, берникадәр вакыт тын торды. Егет ашыктырмады, гасабиланган Гөлзәриягә үзе дә борчылып карап торуын дәвам иттерде. Һәм, ниһаять, кызның теле ачылды.

Шул ачыкланды: күрше бүлмә кызлары егетне урамда бер хатын белән күрүләрен әйткәннәр. Гөлзәрия, бәлки, моңа әллә ни әһәмият тә бирмәгән булыр иде, ләкин Мәнзүрә исемлесе: «Бик күптәнге танышлар, ахры, авызга авыз куеп сөйләшеп торалар иде. Хатын егетеннең пальто төймәсен боргалый иде, син саграк бул, ул сине алдап йөри бугай», — дигән.

Гөлзәриянең күңеле тулышкан иде булса кирәк, ул менә-менә елап җибәрер сыман: башын аска игән, күзләре мөлдерәмә, берөзлексез халат билбавын бөтәрли.

— Әгәр бүтән кешең бар икән, туп-туры әйт, елап, чабуыңа ябышмам.

Габделнур җан сөйгәненең инбашларыннан тотты.

— Син ни сөйлисең? — диде ул, кызын бу халәткә төшерүе өчен чын күңелдән борчылып. — Минем синнән башка йөргән кешем юк.

Гөлзәрия башын күтәрде. Сөйгәненең күзенә, борчулы йөзенә карады. Әйе, бу минутларда егеткә ышанмау мөмкин түгел иде. Шулай да эчтәге корт үз эшен эшләүне — кимерүен дәвам итте. Ул көнчелек корты да түгел кебек,

әмма ышанган, чын күнелдән ярата башлаган кешеи хакында, ул мине алдый икән, ике төрле тормыш белән яши икән, башымны әйләндерә, дип шиккә төшү генә дә аның бәгырен телгәли. Чөнки кыз үзе алдаша белми иде. Шуңа күрә бу хәлгә ачыклык кертәчәк сорау үзеннән-үзе теленә килде:

— Ә теге хатын?

Габделнур: «Кем булыр икән?» — дип уйлады. Сораштыра башлады: кайчан, нindirәk кыяфәтле кеше белән сөйләшеп торган? Кызлар: «Озын зифа гәүдәле, кара чәчле, кара кашлы, кызыл иренле хатын», — диганнәр. Егетнең кылт итеп исенә төште: әйе, күптән түгел ул курсташы Фәнзия белән урамда очрашкан иде; аның шулай төймә боргалап сөйләшә торган гадәте бар.

Габделнур белән Гөлзәрия сөйләшеп торганда, әүвәл егетләр, аннары Мәсния белән Фаһирә бүлмәдән чыктылар. Соңгысы, тегеләрдән аерылып, коридор буйлап килде дә:

— Габделнур абый, минем туган көнгә баяның белән килерсең әле, — дип үтенде.

— Кайчан?

— Көнен Гөлзәрия аша әйтермен.

— Туган көненнән кайчан икәнен белмисеңмени? — дип шаяртты егет.

— Эш көненә туры килә, иркенләп утырып булмас, — диде кыз.

— Аңладым. Ярар, әйтерсең, килермен.

Фаһирә, рәхмәт әйтеп, елмайганда гадәтенчә бит очларын чокырайтып, китеп барды.

Габделнур өзелгән әңгәмәне дәвам итте.

— Ул хатын белән без университетта бергә укыйбыз, — диде, Гөлзәриянең кулын тотып. — Ышан. Ул бик порядочный гаиләдә үскән татар хатыны, ире — офицер, буй җиткән кызы бар, үзе Югары Советта эшли...

Тагын беркавым сөйләшеп-аңлашып торгач, Гөлзәрия йомшады, йөзендәге битарафлык юкка чыкты, карашындагы салкынлык сүрелде, күңел түрендә оешып, укмашып, ката башлаган боз кисәге эреде, ул Габделнур белгән элекке мөлаем кызга әверелде. Коридорда кеше булмаудан файдаланып, Габделнур аның күзләреннән үпте, аннары иреннәренә үрелде... Кыз тәмамысы аның кочагына кереп бетте, бөтен кайнарлыгы, назы белән ана җавап кайтарды...

Гөлзәрия киенергә дип бүлмәсенә кереп китте. Габделнур уйлана башлады, күрше бүлмәдәге Мәнзүрә белән булган хәлләрне зиһененнән үткәрде.

Бер ай чамасы элек, Мәнзүрә, егетнең баянда уйнавын белеп алгач, аны Брикетный бистәсендәге апаларына өй туена чакырды. «Баян бар, прокатка алып кайттык, — диде ул. — Ә менә уйнаучы юк». Ул көнне Гөлзәрия икенче сменада эштә буласы иде. Шуны сылтау итеп, егет бу тәкъдимне кабул итмәде. Билгеле, Мәнзүрәгә егетнең баш тартуы ошамады, чөнки аның бу егеткә күзе төшкән иде. Ул әүвәл аны юмалап-сыйпаштырып ризалатмакчы булды, күзләрен уйнатып, иясез кызлар да, тол хатыннар да була, җанына ошаганын сайлап алырсың, бөтен теләгенне үтәүчеләр дә табылыр, дип тә карады. Егет үз сүзендә нык торды. Шуннан соң Мәнзүрә, бу тискәрене үртәп: «Ялындыра, ялындыра, ялындыра, килми ул, килер иде, уйнар иде, бию көен белми ул», — дип, мин-минлегенә тиярлек итеп басым ясамакчы булды. Болай да күндерә алмагач, Гөлзәрияне хурлау юлына басты: «Кай төшенә кызыктың шуның? — диде ул ачу белән. — Ни бите, ни түше?!» Һәм егетне ымсындырырга ниятләп, үчекләп, үзенең тулы гәүдәсен (аның ирдән кайткан хатын икәнен егет белә иде инде) уйнаклатып алды. Янәсе, менә күр! Менә нинди була ул ир-егетләргә бәхет бирүче чын хатын-кыз заты! Алай да кызыктыра алмагач, күңләшүеннән гарьләнеп, асыл бөркетне кулына әләктерә-иләштерә алмавына офтанып,

аның үзеннән баш тартуына хурланып, үпкәләп китеп барган иде. Соңыннан Габделнур колагына Мәнзүрәнең җизнәсе оста гармунчы икәне чалынды. Чөнки ул мәҗлескә Дәнисә дә чакырулы булган икән, кызларга бик мактады.

Егет әлеге сөйләшү хакында Гөлзәриягә әйтмәгән иде, билгеле. «Мине Мәнзүрә үзенеке итмәкче, нияте — синнән тартып алу» димәс бит инде. Бу юлы да сүзне артык куертмаска, күрше бүлмә кызларына нидер исбат итеп маташмаска булды. Гөлзәрия егетнең чын-чынлап гашыйк булуына, ихлас күнелдән һәм житди уйлар белән янына килеп йөрүенә болай да ышанды шикелле. «Болай да яралы, төзәлеп житмәгән йөрәгенә тоз салмаска», — диде егет үз-үзенә.

Габделнур, гомумән, үзе белән Гөлзәриягә кагылышлы мәсьәләләрдә бик сак кылана, кирәк-кирәкмәстә тел озайтмаска тырыша иде. Күптән түгел, төнлә, кызын озатып кайтканда, аңа урамда ике егет каршы чыкты. Берсе Гөлзәрияне ишек төбендә көтеп торган әлеге дә баягы таныш иде. Габделнур, боларның явыз ниятен чамаласа да, үзе башлап һөҗүмгә күчмәде, кешегә кул күтәрмәде, ләкин сакланып та өлгерә алмады: таныш егетнең иптәше, бер сүз әйтми-нитми, кисәк кенә аның колак төбенә китереп сукты. Икенче тапкырга дип күтәрелгән кулдан Габделнур читкә тайпылды һәм бокс алымын эшкә җикте: күн перчаткалы уң йодрыгы белән яннан моның иягенә тондырды. Элекке танышына күз ачып йомганчы самбо алымы кулланды. Егет җирдә чалкан яткан әшнәсенең өстенә барып төште...

...Гөлзәрия киенеп чыкты, егет аны култыклап алды, һәм алар, әле кая барасыларын анык белмәсәләр дә, әмма татулашып, акрын гына атлап киттеләр.

## 15

Адәм баласы бүтән тереклек ияләреннән шуның белән аерыладыр инде — ул гел уйда. Әйе, күпчелек кеше уйламыйча яши алмый: тик торганда да уйга бата, нидер эшләгәндә дә; кайчагында моңа берәр төрле вакыйга, кем тарафыннандыр әйтелгән сүз дә сәбәпче булырга мөмкин.

Габделнур өйдә берүзе, гадәтенчә, китап укып утыра иде. Ишектә күрше бүлмәдә яшәүче яшь егет пәйда булды. Бик акыллы, укуга күңел салган бу егет быел университетның химия факультетына көндезгә бүлеккә керергә җыена иде. (Алга китеп, шуны әйтик: Габделнур аны ун ел узгач очратты. Егет хәтта аспирантура бетергән, фән кандидаты булган, шунда укыта икән.) Исәнләште. Аннары йомышын әйтте:

— Габделнур абый, гармунны алыйм әле.

Ул, чираттагы ялга киткәндә, гармунын, ышанычлы җирдә торсын дип, аңа кертеп биргән иде. Үз бүлмәләрендә — яшь-җилкенчәк, салып алсалар, белгәне дә, белмәгәне дә акыртырга тотыныр дип шикләнә. Аннары, бик җилле егетләр, бәргәләшкәндә, кулларына ни туры килсә, шуның белән томыралар. Менә хәзер үзе саклап кына тота торган кадерле гармунын (әтисе истәлеге) алырга кергән.

— Исән-сау, кабул итеп ал, — диде Габделнур һәм карават астындагы баяны янынннан аның кече туганын — ике рәтле хромканы тартып чыгарды.

— Рәхмәт, Габделнур абый!

Габделнурга шул җитә калды: чәч астындагы шариклары йөгерешә башлады. «Әйе, мина егетләрнең күбесе, абый, дип дәшә». Эшендә андыйлар бар, ә яшь кызларның бөтенесенә диярлек ул «абый». Моңа Габделнурның кайчак ачуы да килеп китә, ә вакыт-вакыт аны горурлык хисе биләп ала. Хәер, ачу килүе өстенлек итә шикелле. Күрәсен, картаела торгандыр, гәрчә карт аю урманда гына була дисәләр дә. Көзгегә караса, күз төпләре челтәрләнә башлагандай тоела,

битендә, мангаенда нинлидер сызыклар да хасил булган сыман (жыерчык дип авыз тутырып әйтергә теле бармый, хурлана). Эштәге кызларга ул юрамалый гына: «Абый, димәгез, яла яккан өчен судка бирәм, аның өчен УК РСФСРның йөз дә егерме тугызынчы статьясы бар», — ди. Дөрес, аның ул китапны кулына алып, әлеге статьяны караганы юк, каяндыр колагына чалынып кына калган. Һәрхәлдә, ни генә булмасын, яшь кызларның күбесе (аны ныклап белмәгәннәре): «Син өйләнгәндер», — дип тә жибәрәләр.

Әйе, егет өйләнү хакында да еш уйлана башлады. Авылга кайтса да, үзләре Казанга килсәләр дә, әти-әнисенең тел төбе шул тарафка таба авыша. Үзенә килгәндә исә, бер яктан, аны ялгызлык борчыса, тулай торак тормышы ялыктырса, икенчедән, аның әле ирегеннән ваз кичәсе килми, өченчедән, ул укуын бетермичә өйләнмәскә дип үз-үзенә сүз биргән иде бит. Менә хәзер укуы бетү алдында.

Өйләнү. Кызык икән бу тормыш: көне-сәгате житкәч, башлы-күзле булу мәсьәләсе көн тәртибенә килеп баскач, нәрсәдер йөрәкне тырнап, күңелне кымтырыклап борчып тора: курку дисәң, курку түгел, әллә камыт киярге теләмәгән тайның киреләнүеме — шайтан белсен. Ә тормыш үз таләбен бөтен кырыслыгы белән куйган: кәжәләнеп кенә котыла алмыйсың, яшәеш кануны каттый — өйләнергә кирәк. Өйләнү... Өйләнү түгел сөйләнү...

Шушы арада Габделнур урамда күптәнге бер дустын очратты. Сүзе гел бала, гаилә хакында. Баласын жәлләп, хатынын эшләтми икән, сәламәт булса — шатлана, авырса — борчыла. Дусты бала дип үлеп тора.

Габделнур үзе шулай куана-сөенә алыр иде микән?..

...Конторга баргач, ул техника куркынычсызлыгы инженеры Шәйгазамовны очратты. Солтангир Габсалихович аны гадәтенчә, кабинетына дәште.

Ул әүвәл егетнең көнкүреше, укуы белән кызыксынды, аннары жайлап кына гаилә кору мәсьәләсенә күчте, үз тормышыннан мисаллар китерде:

— Туганнан туган энекәшнең малае өйләнгән иде, ике елдан аерылыштылар. Ни әйттем мин аңа: «Энекәш, әйдә безнең авылга кайтыйк, бик әдәпле бер татар кызы табып бирәм үзенә», — дидем. Тыңламады. Шәһәр малае бит, авылныкына күңеле ятмый, янәсе. Ә безнең авыл, әйтсәм әйтим инде, бик тәртипле: бездә хатын аерган кеше юк, бер алкаш юк, бер генә кешенең дә өстермәндә утырганы юк, чит кавем белән кавышучы да юк. Ни өчен? Чөнки бездә гомер-гомергә мәчет булган. Аның яныннан үткәндә, егетләр тәмәкеләрен учларына яшерәләр, урамда сүгенү сүзен дә ишетмисең... Тыңламады сүземне, шайтан малай.

— Нишләп аерылыштылар?

— Хатыны үзебезнең кеше булмаганга. Өйләнсәң, Габделнур, татар кызына өйлән.

— Нигә?

— Аның сәбәпләре бик күп. Өйләнү — тормыш кору. Ул әле бер түшәктә яту гына түгел. Аның без яшь чакта искәрмәгән бик күп «эскиләре» бар. Өенә нәрсә куясың: шәмаилме, иконамы? Үлгәч кайда күмәләр: айлы мөселман зиратындамы, әллә тәреле православиенекендәме?

Әлбәттә, болар Габделнурның уена да кереп карамаган нәрсәләр иде. Өлкән абыйсының сүзләре башта аңа гайре табигый булып тоелды. Егетләр белән сөйләшкәндә, алар бу хакта бөтенләй телгә дә алмыйлар иде бит. Бу тумаган колынның билен сындыру яисә иртәгә өчен ишәк кайгырсын кебегрәк булып ишетелер иде.

Солтангир Габсалихович фикерен дәвам итте:

— Ә иң мөһиме — чит кавем белән бәйләнсәң, син татар баласы тәрбияли

алмыйсың. Татар егете маржага өйләнсә дә, татар кызы урыска чыкса да — балалары барыбер урыс була.

— Ничек алай?

— Тормыш-яшәеш шулай корылган, гыйбрәтләрне үзең дә күреп-ишетеп беләсеңдер.

Әйе, Габделнурның исенә төште: авыл егетләре йә армиядә хезмәт иткәндә, йә шахтада эшләгәндә өйләнеп кайткалыйлар иде, хатыннары да, балалары да бер кәлимә татарча сүз белми. Күршедәге бер кыз (ул Габделнурдан алты яшькә олырак) урыска кияүгә чыкты, аныкылар да шулай: беравыз сүз әйтмиләр иде.

Шәйгазамов белән сүзне бу авыр нотада бетерәсе килмичә, Габделнур:

— Солтангир абый, аның каравы, балалар кечкенәдән үк урысча белер, — дип елмайды.

Юморны аңласа да, Шәйгазамов үзенекен сукалады:

— Әллә син урысча начар беләсеңме? — дип кызып китте ул. — Кесәңә маржа тыгып йөрмисең бит? Синең бу мәсьәләдә тәҗрибәң юк, игътибар да итмисеңдер, ә мин күп нәрсәне искәреп, күзәтеп йөрим. Кайчандыр шәһәргә килеп төпләнгән авыл егет-кызларының да балалары (калада туып үскәннәрне әйтмим дә инде) ярты-йорты гына ана телендә сөйләшә, ә оныклары белми дә, теләми дә. Син хет шартла. Ни өчен? Чөнки вазгыять шулай көйләнгән: ясле, бакча, мәктәп, ГПТУ, техникум, вуз, эш — барысы да фәкать урысчага корылган...

— Анысы шулай инде, — дип килешергә мәҗбүр булды егет. — Миңа безгә дә древнерусский, латин, немец телләре керде, ә үзебезнеке — юк.

— Әйе, менә бит, үзең әйтеп торасың, — диде Шәйгазамов. — Әле татар кызына өйләнсәң дә ике сарылы: йә уңасың, йә юк. Кытайлар, женщина держит половину неба, дип әйтә торган булган. Күрдеңме, мин дә, үзем дә сизмәстән, урысчага күчтем әнә. Ә фикер бик мәгънәле, чөнки хатын-кыздан чыннан да күп нәрсә тора, ана күп нәрсә бәйле.

Егеткә:

— Әйе, — дип раслаудан башка чара калмады.

Ә Шәйгазамов үгет-нәсыйхәтен дәвам итте. Нишләптер яратты, якын итте ул бу ипле егетне, аны ялгыш адым ясаудан саклыйсы килә иде, ахры.

— Габделнур, тагы шуны колагыңа киртләп куй: бәхетеңне тапсаң, кулыңнан ычкындырма, нәфсеңне тыя бел. Ә кешенең нәфсесе дуңгыз баласы кебек чиный-чиный үсә; чибәрләр күп булыр ул, ә хатының — берәү генә, бердәнберең генә. Менә монысы инде синнән тора. Бик күпләр, итәк артыннан йөреп, теләсә кем белән чуалып, бәясен төшерә.

Техника куркынычсызлыгы инженеры бер участоктагы прорабны мисал итеп китерде. Ул, үз кул астындагы бер кыз белән буталып, гаиләсеннән аерылган икән. Ләкин, кызганычка каршы, янасы белән дә озак тора алмаган, аерылышкан, эчүгә сабышкан. Хәзер тулай торакта яши ди. Идарә башлыгы аны чак кына эшеннән кумаган.

— Әйе, — дип, янә килеште егет өлкән абзыйсы белән, ул да әлеге прорабның аянычлы язмышын белә иде. — Ахырдан исенә төшкән.

— То-то. Терсәк якын, әмма тешләп булмый.

— Хәзер бик үкенә.

— Хатының ул — балаларыңның анасы да. Аның бит әле шунысы да бар: читкә йөри башладыңмы, акчаң да бик тиз җилгә оча. Син авылга еш кайтасыңмы? — дип сорады Солтангир абыйсы.

— Җай чыккан саен кайтырга тырышам.

— Мин үзем һаман авылны сагынам, юкса анда мине көтеп торучы да юк инде, — диде Шәйгазамов һәм беравык тын утыргач әйтеп куйды: — Сугыш беткәч, без Украина аша кайттык. Һәр станциядә, эшелон туктауга, яшь хохлушкалар (ирләре сугышта үлгәндер инде) вагон каршына килеп җитә һәм кычкыралар: «Солдат, оставайся! Хата есть, сало есть, всю жизнь, гарный хлопец, тэбе кохать буду!» Ягъни яратачак. Калучылар булды. Безнең теплушкадан бер татар егете төшеп калды. Семьясы да булган, диделәр, күрәсең, авылыннан ямьсез хат алган булгандыр... Мин үзем шулхәтле җирседем, чит җирдә калу башыма да кермәде.

— Мин дә армиядән Казанга ашкынып кайттым, юкса Мәскәүгә, Ленинградка хәрби заводларга чакыручылар — вербовщиклар килгән иде, — диде Габделнур, һәм карт фронтовик белән элекке солдатның янә уртак уйлары, сөйләшер сүзләре табылды.

— Авыл бит ул, энем, бөтенләй икенче тормыш белән яши: бала-чага эшкә өйрәнеп үсә, рухи тормыш та анда бүтән: халкыбызның әйбәт йолалары, гореф-гадәтләре, тапкыр сүзләре, җыр-биюләре, мәкаль-әйтемнәре — барысы да авыл җирлегендә чыккан. Әле соңгы кайтуымда партком секретаре белән сөйләшеп тордым. Ул — килгән кеше, шаккаткан. Чөнки безнең авылда, бая әйткәнемчә, бер эчүче юк, хатын аерган кеше һәм караклык юк. Ни өчен? Чөнки авылда мәчет эшли. Партком секретаре: «Абый, аның яныннан узганда, яшьләр тәмәкеләрен яшерә, сүгенми, шуна күрә, райкомга сиздермичә генә, мәктәп, авыл советы һәм мулла бергәләп эшлибез», — ди, үзе көлә. Без үскәндә дә шулай тәртипле иде халык...

Ул тагын нидер әйтмәкче иде дә, туктап калды, шул урында әңгәмә өзелде, чөнки бүлмәгә кулына кәгазь тоткан бер ир-ат керде.

— Ни йомыш? — дип сорады Шәйгазамов, таныш түгел адәмгә карап.

— Эшкә урнашам, сезгә керергә куштылар.

Техника куркынычсызлыгы инженеры:

— Утырыгыз, — дип, урындыкка ымлады.

Габделнур кузгалды:

— Солтангир абый, киттем мин.

— Ярый, исән-сау йөре.

...Әнә шундыйрак сөйләшү булган иде күптән түгел.

Габделнур соңгы вакытта еш уйлана: иртә өйләнгән — улыннан-кызыннан кинәнгән дигәннәр. Ләкин бу күбрәк авыл кешесенә, шунда көн күрүчеләргә генә кагыладыр, мөгаен. Ә Габделнур ише тулай торакта гомер сөргән егет иртә өйләнеп кемне сөендерсен дә үзен ничек кинәндерсен соң?! Әмма... ничек кенә сузарга тырышма, кәҗәләнмә, вакыт җиткән, сәгате суккан... Сөйгән кызы да бар...

Тик шулай да синең уй-гамәлләреңә аяк чалырга, күңелеңә вәсвәсә салырга маташучылар да юк түгел икән әле.

...Габделнур, Гөлзарияне озаткач, әллә ни ерак китмәгән иде әле, алда тротуарда басып торган ике кызны күрде. Алар яныннан тыныч кына узып китмәкче иде, ләкин кызларның берсе ана урысча дәште.

— Сезне бер генә минутка мөмкинме?

— Әйе, — диде егет һәм туктады.

Ул, нинди йомышлары бар икән, дип уйларга, аларны күздән кичерергә дә өлгермәде, кызларның буйга калкурагы, бая сүз катканы як-ягына каранып алды, бик яшерен сер әйткәндәй, тавышын баса төшеп:

— Ул сине алдап йөри, — диде.

— Кем?

— Гульзария.

Егет сагая калды. Икенчесе ни әйтер икән дигәндәй, анысына да карап алды. Тәбәнәк гәүдәлесе дәшми генә читтәрәк торуында булды. Егетнең карашы янә үзенә якынрак торган кызга төбәлде:

— Ничек?

— Ул ике куян артыннан куа. Запас егете бар.

— Ә сез моны каян беләсез?

— Бер кыз әйтте.

Салынкы гәүдәлесе дә иптәш кызының сүзләрен җөпләүне кирәк тапты, ахры, сүзгә кушылды:

— Ул кыз да шушы тулай торакта яши, — дип, артта калган биш катлы бинага төртеп күрсәтте.

— Ә сез Гөлзәриянең үзен беләсезме соң?

— Беләбез, — диделәр кызлар икесе беравыздан.

Егетнең ачуы кабарды:

— Димәк, иптәш кызыгыз әйтте. Говорят, в Москве кур доят. Әгәр егете булса, ул үзе әйтер иде. Мин сезгә ышанмыйм.

— Ихтыярыгыз, — диде чандыр гәүдәле кыз һәм, үзе дә сизмәстән, тагын «син»гә күчте: — Минем эш — күзенне ачу. Калганын үзең кара.

Кыз шулай диде дә, житкергән «сере»нең «кирәгенчә» тәэсир итмәвенә үпкә белдергәндәй, иренен кыйшайтты. Алар култыклашып китеп бардылар.

Ни хикмәт, Габделнурның бу гайбәткә (ул аны фәкать шулай дип кенә бәяләде) ышанасы килми иде. Үз юлы белән алга атлаганда, кинәт башына нидер китереп бәргәндәй булды: ул бит бу кызны кайчандыр күрде! Әйе, Гөлзәриянең бүлмәдәше Дәнисәнен дус кызы бит бу! Егет җәһәт кенә төтен санаучы кызлар киткән тарафка борылды. Әнә бит алар Воровский урамына таба киттеләр дә бераздан, унга борылып, юкка чыктылар. Димәк, шул ук тулай торакта яшиләр. Ә нигә кирәк икән Дәнисәгә мондый гайбәт тарату, бүлмәдәшен каралту, аның базарын төшерергә тырышу?

Кайчак шулай була бит: нинди дә булса берәр хәлне күрсәң, вакыйганымы ишетсәң, үз вакытында аңа игътибар итмисең. Аннары, кемдер аны искә төшергәч яисә үзенә кирәге чыккач, бөтен вак-төягенә тиклем хәтерендә янартасың.

Дәнисәнең Габделнурга төче елмаеп, күзләрен майландырып, кашларын уйнатып, ягымлы итеп каравы да, ә Гөлзәриягә, кисесенчә, кисәк-кисәк астыртын, бертөрле усаллык белән каш астыннан күз ташлавы да, кирәксә-кирәкмәсә сүзгә кысылуы да, бүлмәдәше әйткәнне юкка чыгарырга тырышып төзәтеп куюы һәм үзен белдекле, укымышлы, ә аны түбәнсетеп күрсәтергә тырышуы да — барысы да күз алдына аермачык килде. Егет шундый нәтиҗә чыгарды, үз-үзенә ачыш ясады: димәк, Дәнисәнең үзенең Габделнурга күзе төшкән булса кирәк, фәкать үзен аңа тиң итеп күрә, ә Гөлзәрияне лаек түгел дип саный. Ә егет аңа берниндн дә илтифат күрсәтми, битараф. Ә бит аңа да егет-жилән күзе төшмәслек түгел! Менә шуна Дәнисәнең ачуы чыккан булса кирәк һәм, икенче бүлмәдәге иптәш кызы аша сүз йөртеп, Гөлзәрияне хурлау юлына баскан. Аларның икесен янәшә куеп, чагыштырып карау егетнең башына да килгәне юк. Чөнки аның күңеле, бөтен уе бары Гөлзәриядә генә!..

Габделнур, авыл картлары әйтмешли, колагына киртләп куйды: бу ачышын ул сөйгәненә әйтмәячәк. Бүлмәдәш кызы (баксаң, ул кыз да түгелдер инде, кияүдән кайткан нәрсәдер, төс-кыяфәтен — күз төпләре каралып торуын, тулышкан гәүдәсен күзаллап, егет шулайрак фикер йөртте) белән дә авыз чайкап вакланмас. Әгәр дә инде алга таба да нииндидер этлек эшләргә уе бар икән, ул чагында үзенә үпкәләсен: егет аны урынына утыртырга җаен табар...

...Егет Октябрь һәм Восстание урамнары чатында унга борылды, кайта-

кайтышка үзалдына елмайды. Аркадий Райкин әйтмешли, егетләр «дифсит товар»га әйләнгәнме әллә? Алай дисәң, әнә алда аларның биш катлы тулай торагы, аның артында уналтынчы заводныкы — егетләр буа буарлык. Кызык, Дәнисәнең дә уена Габделнур кергән булып чыга, күрше бүлмәдәге Мәнзүрәнең дә. Югыйсә, әллә кем түгел бит инде ул. Төзелештә прораб-фәлән булып, үз фатирында яшәсә бер хәл иде. Ә монда... гап-гади электрик, торган җире — тулай торак. Аның нәрсәсенә кызыгырга мөмкин?! Әллә Гөлзариягә берәр төрле үчлек белән генә эшләнәме бу эшләр — гайбәт чәчүләр? Белмәссең бу дөньяның серләрен...

Әйе, Габделнур аның серен белми иде шул. Ә сере бар: Гөлзариянең абыйсы кайчандыр Дәнисәнең апасы белән чуалган иде. Ләкин, араларыннан кара мәче уздымы, бүтәнме, эшләре пешмәде — алар кавышмадылар. Моны Гөлзария белми, чөнки бу хәл байтак еллар элек булган. Дөрес, Дәнисәнең апасы Гөлзариянең абыйсы тарафыннан алданмады, көмәнле булып калмады. Әмма, озын буйлы, кара бөдрә чәчле чибәр егетне яратуы бик көчле булгангамы, ара суынуны бик авыр кичерде, байтак вакыт балавыз сыгып йөрде. Дәнисә бу вакыйгадан хәбәрдар иде. Ул апасының кичерешләрен күңеленә якын алды: теге егетнең апасын ташлап, икенче берәүгә өйләнүен гафу итә алмады, әйтерсең лә болар үз башыннан үткән хәлләр. Апасының еш кына: «Ялгыз аккош очып бара, күлдә икән кышлавы; әҗәлләрдән читен икән сөйгән ярның ташлавы, — дигән җыруы Дәнисәнең дә йөрәген өзә иде. Менә шуңа күрә хәзер, ак эт бәласе кара эткә дигәндәй, бөтен авырлык кул астына эләккән Гөлзария җилкәсенә төшә иде. Дәнисәгә Габделнур кирәк түгел, ул бары бүлмәдәшенә ачу итеп кенә бу эшкә алынды, апасы кебек, аның да газап чигүен тели иде. Ул моның түбәнлек икәнен дә белә, әмма берни эшли алмый — сугышасы килгән кешенең кулы кычыткан кебек, гел кызга этлек эшләү теләге белән яна, үзенең бу халәтен тыеп, аңа йозак салып куя алмый иде.

...Күптән түгел Габделнур алар бүлмәсенә керде. Егет өстәлдә яткан «Огонёк» журналын актара башлады. Уртадагы куш битендә таныш рәсем — «Помпейның соңгы көне». Ул аңа бик озак карап торды.

— Кызлар, — диде егет, бүлмәдәгеләргә мөрәҗәгать итеп, — сез моның нинди фаҗига икәнен беләсезме?

Гөлзария сөйгәне янына килде, Мәсния китап укый торган җиреннән башын күтәреп карады, Дәнисә, бәйләвеннән туктап, бишинәсеннән күзен алды.

— Каян белик, — диде ул. — Әйт.

Габделнур башта кызларга бу картинаның авторы Карл Брюллов хакында бераз мәгълүмат бирде, аннары төсле рәсемнең үзенә күчте.

— Житмеш тугызынчы елның август аенда Помпей шәһәре янындагы янартау — вулкан баш калкыта.

— Ул шәһәр Испаниядә, — дип сүз кыстырды Дәнисә, үз-үзенә ышаныч белән.

— Юк, Италиядә.

— Житмеш тугыз алдындагы саннарны әйтмәдең, — диде Гөлзария, рәсемгә карап.

— Алда сан юк, — диде Габделнур һәм сөйләп китте: — Бу хәл Рим империясе чорында, бик борынгы заманнарда була. Янартау өч көн, өч төн аткан. Газ һәм һава болыты илле километрга хәтле күккә күтәрелә, аннары ташлар, вулкан көле бөтен шәһәрне каплый, калынлыгы метр ярымга җитә, йортлар җимерелә, бик күп кеше үлә...

— Брюллов унтугызынчы гасырда яшәгән бит, — диде Гөлзария, коточкыч гарасат сурәтләнгән рәсемнән күзен алалмыйча. — Ул аны үз күзе белән күрмәгән бит.

Урыныннан торган Дәнисә:

— Һи, надан, шуны да белмәскә, художник аны фантазировать иткән, — диде дә бүлмәдән чыгып китте.

Егет берни дәшмәде, Гөлзәриягә дә сүз кушмады...

Габделнур белән Гөлзәрия арасын бутарга тырышу монын белән генә бетмәде.

Беркөнне кинодан кайткач, Гөлзәрия егетенә бик озак сынап карап торды да ниндидер күңел төшенкелеге сизелгән басынкы тавыш белән сорап куйды:

— Ә син мине алдап йөрмисеңме?

Егет бермәлгә аптырашта калды. «Иске авыздан яңа сүз дигәндәй, бу нинди сорау тагы? Бер мәртәбә сөйләшү булган иде бит инде, аңлашканнар иде. Һаман бер балык башымы...»

— Нинди мәгънәдә? — дип сорады егет, кызның борчулы йөзенә текәлеп.

— Миңа бик ямьсез сүз ирештерделәр.

— Нинди?

Кызга бу турыда сүз сөйләве кыен иде. Чөнки ул да, Габделнур кебек, аңа жаны-тәне белән дигәндәй ышана. Күңеле түрендә хәзер фәкать ул гына. Әмма яшь кызның, риясыз, беркатлы, гөнаһсыз фәрештәнең, егет авызыннан чын дөресен ишетәсе, күзенә каратып, аңа ишетелгәннәрнең, аңа килеп житкән ямьсез сүзләрнең дөрес түгеллегенә ышанасы килә иде.

— Сине... хатын аерган, диләр... — Кыз сүзен әйтеп бетермәде, күңеле тулды, әмма шулай да үзендә көч тапты. — Баласы да бар, диләр.

«Әһә, — дип фикер йөртте егет эчтән генә, — монысы яңа нәрсә икән».

— Син шуңа ышандыңмы?

— Юк, — диде кыз.

Ул бу сүзне ихлас күңелдән әйтте, тавышында шик-шөбһә юк иде.

— Мин ипи тотып яисә кояшка карап ант итәргә жыенмыйм, — диде егет, аның тавышында ныклык, үз-үзенә ышаныч бар иде. — Фәкать шуны гына әйтәм: ул гайбәтнең каян чыкканын, кемнәр тарафыннан таратылуын чамалыйм мин. Бәлки, үзең дә сизенәсеңдер. Миңа унсигез яшь түгел, минем уем фәкать синдә генә, минем йөрәгем фәкать син дип кенә тибә. Минем кебек, син дә беркем сүзенә дә ышанма.

Гөлзәрия егетнең соңгы сүзләреннән аптырашта калды. Аның тел тибрәтеп берни дә әйткәне булмады бит бу хакта. Ул аңа күтәрелеп карады.

— Сиңа да мине яманладылармы әллә?

— Карлыгачым, әйдә, бу турыда сөйләшмик. Минем өчен синең янда булган һәр минут кадерле. Мин синең белән бик бәхетле: дөньяның бөтен ваклыкларын онытам, кайгы-борчуларым юкка чыга, һәрчак күңелем шат, гел елмаясым, синең нурлы йөзеңә генә карап торасым килә. Миңа синнән башка беркем дә кирәкми...

Егет кызны кочагына алды. Сөйгәне дә бөтен барлыгы белән аңа сыенды, тарсынып кына булса да кочаклады. Габделнур кызның күзләрен үпте. Ә алар яшьле иде... Алар бәхет яшьләре белән чыланган иде...

Яңгыр сибәли башлады. Гашыйклар бер йортның подъездына керделәр. Анда караңгы иде. Габделнур, куллары белән капшап, кызның йөзенә, чәченә сак кына кагылды, ихлас күңелдән иркәләп-назлап, битен, күзләрен, иренен үбә башлады. Гөлзәрия дә шулай ук дәртле үбү белән жавап кайтара, кысып-кысып коча иде. Егет, үзенең плащын ычкындырып, аны төреп алды. Кызның да плащының ике төймәсен ычкындыргач, Гөлзәрия аның кулын тотты.

Егет:

— Әллә куркасыңмы? — дип пышылдады.

— Юк, — диде кыз, тик үзе егетнең кулын җибәрмәде.

Габделнур анын янында күнелен аздырырга теләми иде, аягы белән генә ишекне ачты. Урамда, багана башында, ут яна. Бер егет белән кыз килделәр дә үбешеп тора башладылар, чөнки алар подъезддагыларны күрми иделәр.

— Ну бүген көн, — диде Гөлзәрия, көлеп. Алар кергәндә дә, бер пар нәкъ шул багана төбендә үбешеп тора иде...

...Тулай торак янында егет кызының кулын тотты.

— Без бәләкәй чакта әбиләр, берәр җиребез авыртса, менә шулай итеп өшкерәләр иде, — диде ул елмаеп һәм сөйгәненең кулына сулышын өрде: — Өф, өф, өф...

— Төзәлә идеме? — дип сорады кыз.

— Әйе.

Эш шунда: Гөлзәриянең, авылына кайткач, кулы пешкән иде. Хәзер төзәлә инде.

Бераздан алар, бер-берсенә тыныч йокы теләп саубуллаштылар.

Шушы сөйләшүләрдән соң егет төпле бер нияткә килде: моннан ары да сузарга ярамас — Гөлзәриягә үзенең ниятен җиткерергә, хәләл җефете булырга ризамы-юкмы икәнен тәгаен ачыкларга кирәк...

...Гөлзәрияне дә уй басты. Уйлары Габделнур тирәсендә бөтерелә иде. Егетнең үз-үзен тотышы гына түгел, тышкы кыяфәте дә кызның игътибарыннан читтә калмады: чалбары һәрвакыт җиренә җиткереп үтүкләнгән, күлмәгенең яка-җиңнәре чиста, җитмәсә әле, галстуктан да булыр. Ул кызы янына һәрчак кырынып килә, ир-атлар гына куллана торган хушбуйны да чамасын белеп кенә сөртә, исе борынны ярып керми. Кайбер егетләр аны аракы исен басар өчен сиптерәләр икән. Габделнурга моның хаҗәте юк, ул — аек. «Әллә минем янга килгәндә генә шулай микән?» Чөнки ул, үз абыйларыннан, авыл егетләреннән чыгып фикер йөрткәндә, аларның еш кына аракы эчүләрен дә белә, кайберәүләр (юашраклар, сүзгә саранныр) кыюлык өчен дип тә кызлар янына салгалап баралар, янәсе хәмер тел ачкычы бирә. Хәер, Габделнур җебегән егет түгел, сүзгә дә кесәгә керми. Шулай да кызның аны сынап карыйсы килгән чаклары да була. Әмма ничек? Һәм ул бу уен читкә куя. Бу гамәл анын дәрәҗәсен төшерү, ә сизелсә, егетнең хәтерен калдыру булыр иде, бер-беренә карата булган ышанычны какшатыр иде сыман.

Ә бит кызларның кайберләре, үткеннәре, егетләрен төрле яклап, төрле ысуллар табып, кат-кат сыный, тикшерә. Ләкин Гөлзәрия ул юлдан барырга җыенмый, беренчедән, холкы андый түгел, икенчедән, егетне алай сынарга сәбәп тә юк сыман. Кеше карбыз түгел, ярып карап булмый дисәләр дә, Габделнур юньсез, икейөзле кешегә охшамаган. Андый тискәре сыйфатлары булса, алар бер сизелмәсә, бер сизелер, Гөлзәриянең егеттән отыры гайрәте чигәр, яратуы басыла төшәр, гыйшкы акрынлап суыныр иде.

Учак янында утырган саен утырасы килә: уты никадәр көчлерәк дөрләп янса, ул кешене шулкадәр ныграк тарта. Мәхәббәт тә шулай: сөйгән кешеңне яраткан саен өзелеп яратасы килә. Гыйшкы никадәр көчлерәк булса, бу халәт кешене шулкадәр ныграк биләп ала: син гел сөйгәнең турында гына уйлыйсың...

## 16

Беркөнне Габделнур кызын шәһәргә алып чыгып китте.

— Кая барабыз? — дип сорады җәйге күлмәк өстеннән йон кофта кигән Гөлзәрия юл уңаенда.

— Трамвайга утырыйк әле, аннан күз күрер, — диде егет серле генә.

Ул да җәйге киемнән: өстендә пиджак, ак күлмәк, галстук һәм киң балаклы

чалбар, аягында юка табанлы ботинка; кыска итеп алдырган кара чәчен жиренә житкереп тараган (кайчагында ул бриолин да сөрткәли), чип-чиста итеп кырынган, хушбуй да сиптергән. Элек ул «Тройной», «Шипр» белән генә эш итә иде, хәзер, затлырагын — «Консул» дигәнен юнәтте. Бу егетләр игътибарыннан читтә калмады, билгеле. «Кара, кара, безнең Габделнур чын франтка әйләнде», — дип шаярттылар бүлмәдәшләре. Дөрес, ул хушбуйны көязләнү өчен түгел, ә кырынгач кына, битенә дезинфекция ясар өчен генә куллана (үзен шулай дип юата һәм егетләр алдында аклана).

Бер-берсенә сыенып утырган хәлдә, тегене-моны сөйләшеп, елга портына хәтле килеп життеләр. Вокзал тирәсе кайнап тора: кемдер кассага, кемдер теплоходка ашыга; кара халат кигән бер хатын резин шлангтан тажлары ачылган кызыл лаләләргә су сибә, икенчесе баскыч юдырта; милиционер, ялкау гына атлап, тирә-юньне күзәтә; троллейбус, автобус, машиналар килеп-китеп тора; киоскларда һәм зур зонтиклар астында кояштан качкан ак алъяпкычлы хатыннар квас, сыра, туңдырма һәм тәм-том сата.

Габделнур да Гөлзәриягә туңдырма тәкъдим итте, егетләр әйтмешли, андый «вак-төяк»кә исе китмәсә дә, үзенә дә алды.

— Мин моны сирәк ашыйм, — диде ул һәм елмаеп өстәде: — Компания хөрмәтенә яһүд тә асылынган, ди, аннары, сулавы авыр, төшерегез, дип әйтеп әйткән, ди.

Кыз да көлеп куйды һәм алар анда-санда тупыл мамыгы түшәлгән асфальттан су буена таба атлап киттеләр, шәмәхә, ак чәчәктә утырган сиреньнәргә карап соклана дылар.

Көн жилле, салкынча, жәйге кояш, болытлар арасыннан чыгып, бер генә карап ала да янә кереп югала. Каралҗым су өстендә берөзлексез вак дулкыннар йөгерешә, сирәк-мирәк акчарлаклар оча, каяндыр житез карлыгачлар килеп чыгалар да атылган уктай астан өскә күтәреләләр, аннары янә су өстенә төшкәндәй булалар, ләкин үзләре тәннәрен чылатмыйлар. Канатларын жилпи-жилпи бер кыр үрдәге пәйда булды.

— Әнә теге үрдәккә кара әле, — диде егет, иелә төшеп. — Ул миңа бик кызганыч. Аларны парлы итеп күрәсе килә. Менә мин үземне дә шул үрдәк хәлендәрәк сизәм. Ундүрт яшьтән бирле ялгыз бит инде. Жәлләүче дә юк.

Соңгы сүзләренә уенын-чынын бергә кушуын аңлап, кыз назлы гына итеп әйтеп куйды:

— И мескен!

— Көл, әйдә, көл...

Гөлзәрия — акыллы, зиһенле кыз. Габделнурның һәр сүзенә ниндидер эчке тирән мәгънә салынганын, житди сүз булачагын сизенә иде. Монда алып килүе, үрдәкнең ялгызлыгына басым ясавы да тиктомалдан гына түгелдер. Бүген кызның үзенең дә йөрәге көндәгедән ешрак тибә шикелле.

Бераздан кыр үрдәге судан күтәрелде, очып китте һәм бик тиз күздән дә югалды.

Сул якта, яр буенда, бер теплоход тора, аңа иптәшкә икенчесе елышкан. Аннан музыка агыла. Өченче теплоходның койрыгы гына күренә — ул порттан ераклаша бара. Причалдагылары янында бихисап акчарлаклар. Аларга теплоходлардан пассажирлар-туристлар ипи, булки кисәкләре ыргыталар.

Егет мәшһүр Идел елгасы, аның монда киң һәм мул сулы, ә ул солдат шулпасы эчкән якларда, Ярославльдә, таррак булуы, әмма барыбер пароход-теплоходларның йөрүе, матурлыгы турында хозурланып сөйли. Рус әдипләренең аны мактаган әсәрләрен, рәссам Илья Репинның атаклы «Бурлаки на Волге» картинасын телгә ала. Халкыбыз чыгарган һәм хәзерге заман жырларын да

шыншып күрсәтә. Ул аларны, туктале, бу кызны шаккатырыйм әле дип түгел, сүз унаеннан исенә төшерә. Ләкин шул ук вакытта ул Гөлзәриягә карата игътибарын да киметми: ана сокланып карый һәм, жырдагыча, күпме караса да карап туя алмый. Аның баш өстенә өеп, жыеп куйган кара чәче дә, текә мангае да, эскәк-фәлән тимәгән кара кашлары да, яшькелт-зәңгәр күзләрен бизәүче озын керфекләре дә, күперебрәк торган алсу иреннәре дә, карасу түгәрәк йөзенә килешле ияге дә һәм хәтта жыйнак кына борыны да — барчасы егетне сокландыра. Аның егеттән бер башка диярлек тәбәнәк, юка гәүдәсе дә Габделнур өчен кадерле, якын. Һәм мөнә таң калгыч шушы гүзәл фәрештәнең үз янында булуы, вакыты белән куенына ук кереп торуы егетне чиксез горурландыра, күнелен шатлык, бәхет һәм сөенеч хисләре белән тутыра. Хәзер инде анардан башка яшәүне, аны югалтуны ул уена да китерә алмый, бу — Габделнур өчен күнелдәге тирән ярага, гомерлек үкенечкә әйләнер иде сыман. Әлбәттә, аның Мәҗнүн һәм Таһирлар турында ишеткәне-укыганы бар, әмма үзе кайчан да булса шул егетләр хәленә төшәр дәрәҗәдә гашыйк булыр дип һич уйлаганы юк иде. Егет пиджагын Гөлзәриянең инбашына салды.

— Кеше алдында үзем жылыта алмыйм инде, — дип серле генә елмайды.

Сөйгәне аны аңлады, рәхмәт йөзеннән күз керфекләрен сирпеп, ягымлы, нурлы карашын бүләк итте.

— Үзенә дә салкын бит, — дип аны култыклап алды.

Әнә шулай уен-көлке белән мавыксалар да, егетнең башындагы уйлар су өстендә өзлексез чайкалган дулкыннар кебек гел тибрәлеп торалар.

Егерме сигез яшьлек ажгырып торган, утны-суны кичкән егет кайчак кыз янында югалып та кала. Ана саксызрак кагылудан курка, тиешле-тиешсез сүз әйтмәгәем, дип, шөбһәгә төшә. Ул ана кайчак Афродита-алиһә яисә кул белән кагылырга ярамаган чәчәк кебек тоела. Бу халәт ана әлегәчә таныш түгел иде кебек. Хәер, таныш икән: ул Рәйсәнәгә карата шундый ук мөнәсәбәттә иде бит. Тик ул вакытта әле Габделнур яшь, кызларның фәкать кулын гына тотып караган саф егет иде, хатын-кыз белән ир-ат арасында була торган иң якын мөнәсәбәтләрне татымаган иде. Хәзер бит ул бөтенләй икенче кеше, кем әйтмешли, азау ярган егет. Әмма Гөлзәриягә булган мөгамәләсенә карап, ана бу тамганы тагып булмый иде. Габделнур чамалый: бу — аның өчен яна хисләр ташкынына кереп чуму, һәм ул анда үзен бик иркен хис итә — колач салып йөзә. Хәтта ул үзенең бүгенге хисләреннән, хәзерге халәтеннән читенсенми дә — гыйшык утында дөрләпме дөрли. Ашкынып кызы янына күрешергә килү дә, аны урамда көтеп тору да — болар егет өчен ялыктыргыч түгел, ләззәтле минутлар. Ана Гөлзәрия белән шулхәтле рәхәт: кино-театрларга бару һәм кызның тән кайнарлыгын тоеп оеп утыру да, бала-чага кебек кулга-кул тотынышып йөрү дә, кача-поса гына һәм ояла-тартына гына үбешү дә... Ә калганы — аньсы киләчәктә булачак, алар икәве генә татыячак бәхетле мизгелләр булып алда күзаллана. Ләкин томан пәрдәсе белән өртелгән шул кавышу сәгатьләренең булачагына, икесенә дә сөю-сәгадәт китерәчәгенә, гомергә онытылмаслык һәм мәңге хәтердән җуелмаслык шатлык-куаныч бүләк итәчәгенә ул шикләнми.

Егет кызга өйләнешү турында сүз катмакчы, ләкин сүзне нидән башларга белми аптырады. Ул карашын алга төбәде.

Алар басып торган турыдан сулда, ерактა, ак төстәге су трамвае күренде. Ул причалдагы теплоходлар белән чагыштырганда бик кечкенә иде. Шулай булса да, портка якынлашкач, яр белән мол арасына килеп кергәч, отыры зурая барды.

Иделдән килгән дәү дулкыннарны тоткарлау өчен балчык өеп ясалган молның аскы өлешендә берни дә үсми, анда бетон плиталәр түшәлгән, ә өстендә тәбәнәк агачлар баш калкыткан, алар хәзер ямь-яшел. Каршыда — Ослан

таулары. Тау битендә — авыллар, дача өйләре, Идел уртасындагы теплоход һәм баржаларны агачлар каплый. Молнын уң ягында бер ак һәм бер кызыл маяк, ә сул якта ике кызыл маяк су өстендә чайкала.

Су трамвае вокзал турыннан, үткен борыны белән дулкыннар ярып, үз артыннан аксыл эз калдырып, койрыктагы байрагын җилфердәтеп узып китте. Аның эчендәге пассажирлар әле урыннарыннан кузгалмаганнар, чөнки трамвай, унга таба борылып, ерак причалларның берсенә барып туктаячак.

Монда килүнең сәбәбе булган төп мәсьәләгә күчәргә кирәк иде. Габделнурга ярдәмгә Гөлзәрия үзе килгәндәй булды: ул егетнең укуы белән кызыксынды.

— Диплом яклау ничек үтте?

Габделнур кызга беренче июнь көнне диплом яклыйсын әйткән иде.

— Отлично! — диде егет, аннары артык шапырынуын сизенеп исенә килде: — «Яхшы» билгесе куйдылар. Башта каушап та калдым: бишәү кереп утырганнар — барысы да профессор да доцент. Рәхмәт житәкчемә, тыныч кына сөйләргә, сорауларга да ашыкмыйча, уйлап җавап бирергә кушты. Тәки ерып чыктым.

— Әйбәт булган.

— Әйе, эш бетте, көлтә җыясы гына калды дигән кебек, дәүләт имтиханын бирәсе бар.

— КПСС тарихыннан дигән идең. Анысы кайчан?

— Егерме бишендә.

— Котыласың инде.

— Әйе.

— Гуманитарныйда укуы да җиңел түгелдер.

— Әйе. Техническида мәсьәләләр, сызымнар булса, бездә — күз бетереп уку. Бик күп укырга туры килде, фәннәрнең нindиләре генә кермәде, иң күбе — тарих. Бер уйласаң, тарих бүлегендә укуыма үкенмим дә.

Егет төрле вакыйгалар, шәхесләр турында сөйләде, императорларның, корольләрнең, патшаларның мәзәк якларын, кыланышларын, төрле тузга язмаган карарлар, указлар кабул итүләрен искә алды.

— Пётр Беренче келәшчә белән теш суырырга өйрәнгән һәм моны бик яратып эшләгән. Ирләреннән үч алырга теләгән югары катлау хатыннары еш кына аңа, ирем төне буе йокламады, теше сызлый, дип зарлана торган булган. Император тегеләрне чакырта да, тешең сызлый икән, утыр, ди. Мескеннәр, падишаһка каршы килә алмыйлар бит инде, тешсез кайтып китәләр икән...

Ахырда Габделнур сүзен болайрак төгәлләде:

— Рим императоры Август өйләнмәгән, егерме биштән узган егетләргә штраф санкциясе кулланган. Димәк, ул чорда яшәсәм, мин дә зур штрафка тартылган булыр идем. Бездәге бездетный налог кына түгел инде ул.

— Кызларга да штраф салганнармы?

— Әйе.

— Аларга ничә яшьтән соң?

— Егермедән.

— Ә?! Димәк...

— Әйе, икебезгә дә эләгәсе икән. — Көлешеп алдылар, ә егет дәвам итте: — Шуңа күрә, император Августның штраф кәгазе килгәнне көтмичә, безгә кавышырга кирәк. Мин сиңа бу хакта сүз катарга кыймыйча йөри идем.

Егет кызның күзенә текәп карады. Гөлзәрия керфекләрен аска төшерде, битенә кызыллык йөгерде, уйга калды, аннары тыныч кына әйтте.

— Әле бер-беребезне бик белеп тә житкермибез бит.

— Безнең авылда бер кыз әйткән ди: «Әнине әтигә биргәннәр, мине чит кешегә бирәләр».

— Ишеткәнем юк иде.

Егет, кызны жай гына әйләндереп, арка яктан кочаклап алды һәм пышылдады:

— Колагыңны тешлимме?

— Нигә?

— Үземә булырсың.

Гөлзәрия янә колак очларына кадәр кызарды:

— Авыртыр бит.

— Ә мин авырттырмыйм. Элек әнә шулай колак тешләтеп яраштерганнәр.

— Без ул яшьтән чыктык шул инде.

— Әйе, хәзер әти-әни хәл итми.

— Алай димә...

Егет дилбегәне кулдан ычкындырмаска булды, уен белән башлаган сүзен житди тонга күчереп, ниятенең изге икәненә төрле дәлилләр китереп дәвам итте. Һәм, ниһаять, гәпләшә торгач, кызның тел төбе ана өметләнергә урын калдырды:

— Ярар, әни белән киңәшкәч әйтермен.

Егет сөенеченнән янә уенын-чынын бергә кушып сөйләшүендә булды:

— Безнең эштә бер шаян абзый бар. Шул гел әйтергә ярата: «Ир-атның хатын-кызлары ничәү булырга тиеш?» Һәм үзе үк жавабын да бирә: «Основная, резервная, дежурная, про запас, для балов...» Ул аны дворяннар турындагы кайсыдыр бер китаптан укыгандыр инде. Хәзер дворяннар кебек баллар оештыру юк бит.

— Үзеңеке ничәү соң?

— Кая инде ана, — диде егет, көлеп. — Шаярта гына, үзе хатынын үлеп ярата, ике сүзнең берендә «минем карчыгым» дип кенә тора.

— Сезне үрти инде.

— Билгеле, — диде егет һәм, алар турыннан узып баручы «Ракета»га карап, бераз тын торгач, сүзен дәвам итте: — Ә безнең нәселгә килгәндә, берүк мактана дип уйлама, бу мәсьәлә бик каты куелган. Минем әти ягыннан бабайлар жиде бертуган булганнар, берсе турында да авылда ямьсез сүз ишетелмәде, хатын аеру, хатын өстеннән йөрү түгел, аларның берсе дә тәмәке тартмаган, тәртипле, йорт жанлы кешеләр булганнар, үз көчләре белән дөнья көткәннәр. Әтинең туганнан туган абый-энеләре дә шулай...

Артык шапырыну булып күренмәсен өчен, Габделнур сөйләүдән туктады.

— Әйдә, тегендә таба барыйк, — дип, ул Гөлзәрияне ары алып китте.

Уңда, тирә-юньне ямьләндереп, төрледән-төрле агачлар үсеп утыра, ә яшьләр туктаган почмакта ике катлы бина калкып тора: аскы өлеше кирпечтән, өсте — тоташ пыяла һәм ул түбәнге катка караганда зуррак — кечкенә тартма өстенә олырагын куйган кебек. Бинаның сул ягыннан карасаң, еракта-еракта Сөембикә манарасының өске ярuслары күренә. Каршыда су, арырак яшеллеккә төренгән агачлар белән капланган озынча Локомотив ярымутравы. Ә таллар арасыннан дүрт-биш катлы йортлары баш калкыткан Киров районы биләмәләрен, төтен чыгарып торган завод моржаларын, кукыраеп утырган телевышканы шәйләп була.

— Әнә, каршыга карале, — диде Габделнур, Гөлзәрияне инбашыннан бер кулы белән кочып үзенә таба якын китергәч. — Анда «Локомотив» пляжы. Үзеңне берәр көнне алып барырмын әле. Аның аргы башында Күсе Койрыгы бугазы һәм Карга Куагы утравы.

— Син аларны каян беләсең?

— Безнең белән бер егет укый, елга портыннан ерак яшәми. Ул судомоделизм белән шөгыльләнә, балаларны өйрәтә, заядлый балыкчы, кыш көне дә йөри. Шуңардан ишетеп калган идем. Әнә теге агачлардан арырак шәһәр халкы элек-

электән ял итә торган Маркиз утравы. Ул Иделнең уртасында ук, суднолар аның бу ягыннан йөри...

– Син бик күп беләсең, ә мин — аз, — диде кыз, уфтанып.

– Бу үзе үк яхшы.

– Ничек?

– Борынгы греклар әйтә торган булганнар: «Мин үземнең бернәрсә дә белмәгәнемне беләм, ә кайберәүләр моны да белми».

– Син һәр сүзгә җавап табасың, — диде кыз, егеткә сокланып.

Үтеп баручы «Метеор» һәм җәйге матур табигать белән хозурланып, иске Казанга бәйле хәлләрне искә алып, тагы да бераз гәпләшеп торгач, Габделнур әйтеп куйды:

– Кайтабызмы?

– Әйе, — диде кыз һәм, башын чак кына борып, иңендәге пиджакка ымлады: — Киясеңме?

– Трамвайга хәтле бар, салкынча.

Әмма кояш эреле-ваклы ак болытларны пыран-заран китереп тараткан һәм ул җир өстен кыздыра иде инде.

Алар килгән сукмактан акрын гына кирегә таба атлап киттеләр. Гәрчә кирегә булса да, чынында егет белән кыз аралары тагы да ныграк якынаюны тойдылар. Аларның тормыш баулары (җеп кенә түгел) төенләнүгә, мәңге чишелмәслек булып бәйләнүгә янә бер адым иде бу атлау.

Елга вокзалының тоташ пыяладан диярлек торган мәһабәт бинасына, теге икәве янына әле генә килеп туктаган зур ак теплоходка һәм шул тирәдәге ыгы-зыгыга карагач, егет уйлап куйды: «Бу бит язмышлар хәл ителә торган җир: кемнәрдер кавышу өмет итеп килә, кемнәрдер кабат күрешмәскә ант итеп китеп бара, кемнәрдер, саубуллашканда, янадан очрашу вәгъдә итеп кул болгый...»

Әйе, аларның да язмышы хәл ителде сыман. Егет аның ахыры хәерле булуын теләи, Гөлзәрия белән аерылышасы килми иде. Чөнки Гөлзәрия йөргән кыз гына түгел, ул — сөйгән кыз!

Егет Гөлзәриянең ниләр уйлаганын белми. Хәер, кызда да кеше күңелендәге хисләрне уку сәләте юк. Ләкин үзенә карата булган мөгамәләсеннән, назлы күз карашыннан, янәшә атлаганда кызның кайнар кулын үзенең зур, каты учына сак кына салуыннан, сөйләгәндә дулкынлануыннан, егетенең нинди халәттә икәнен, кичерешләрен тоя, аның йөрәк тибешен ишетә кебек. Берсен берсе яраткан, йолдызлары туры килгән кешеләргә күп кирәкмени?!

## 17

Икенче елда Гөлзәрия авылына кайтып китте. Күңеле алгысыган кыз, беренче тапкыр күргәндәй, туган авылына яратып, сокланып һәм... саубуллашкан кебегрәк итеп карады. Монда һәр йорт-ихата, һәр кеше — олысы-кечесе аңа таныш, якын. Чәчәкләрен коеп өлгергән биек шомырт агачлары, бакча эчләрендәге чия куаклары, ерактан зур шарларны хәтерләткән түгәрәк алмагачлар, әле шау чәчәктәге аксыл-шәмәхә сиреньнәр, ак шәлен ябынырга әзерләнгән купшы баланнар — барысы да аны сәламләп каршы ала кебек, чөнки ул аларныкы — шушы авыл кызы. Әнә еракта, урман авызында һәм авыл читендәге умарталык артында, кәккүкләр кычкыра, су буендагы тал-тирәктән һәм зирек агачларыннан төрледән-төрле кошларның тавышы ишетелә. Алар иртә-кич тә, төнлә дә тынып тормый. Авыл эчендәге күгәрченнәр гөрләвен, чыпчыклар чыркылдавын әйткән дә юк инде. Урамдагы шаян маэмайлар, кояшта кызынып утырырга яратучы пескәйләр дә, биләмгә чыккан әтәч-тавыклар да аны һәрчак боегып озатып кала һәм сөенеп каршы ала сыман.

Ә ерактан ук үз өйләрен — яшелгә буялган калай түбәле, урам якта зур, якты, өч тәрәзәле нарат йортны күрүгә, аны әйтеп бетергесез ашкыну хисе белән ала: анда Гөлзарияне газиз әнкәсе зарыгып көтеп тора бит.

...Мәдеһия түти кызының житди сүзе булачагын бик тиз сизеп алды. Хәер, баласы, күнелендәге уен яшереп, озакка сузып та тормады. Олы якта икәве генә калдылар. Улы белән килене эштә, оныклары урамда иде.

— Әйтер сүзен бар сыман.

— Әни, мине бер егет сорый, — диде кулларын тез өстенә куйган кызы.

Бу сүзләрне әйтү аңа бераз читен дә иде. Гыйшык-мыйшык, мәхәббәт мәсьәләсендә авыл кызлары элек-электән бик тыйнак. Әмма бүген мәсьәлә житди — язмышың хәл ителә. Анаңа әйтми кемгә әйтәсен?! Ике юл чатында торганда, анаңа барып сыенмыйча, кемгә сыенасың?! Аңардан да якынрак кемең бар?!

Мәдеһия түти бәйли торган оекбашын бер читкә куйды, игътибар белән кызына карады. Әйе, ана күңеле сизмиме соң?! И-и, гомерләр, төпчегенә дә вакыт житте.

— Нindirәк кеше соң ул?

— Әни, ул төзелештә гади электрик булып эшли, — диде кызы һәм, сөйли башлагач, күңелендәге шик-шөбһәләрен дә әйтмичә түзмәде. — Әни, ул укыган кеше, быел университет бетерә.

— Бик әйбәт.

— Әйбәтен әйбәт тә, ул бик күп белә. Ә минем нәрсә... училище гына. Сангa сугар микән?..

Мәдеһия түти кызының икеләнүләрен бик тиз юкка чыгарды:

— Кызым, сукыр сукырга иярсә, икесе дә базга очар, дигән борынгылар. Гыйлемгә омтыл. Юньле кеше булса, ихтимал, сина да укырга юл бирер. Курыкма, кызым. Кыз бала, кияүгә чыккач, кеше кешесе була инде ул. Каршы әйтмәсәң, жаенарак торсаң, рәнжетмәс, сүзен-теләгеңне аяк астына салып таптамас.

— Белмим шул.

Мәдеһия түти:

— Курыкма, кызым, — дип, янә баягы сүзен кабатлады.

— Быел укырга кермәсәм, аннан соң була инде, бала бага башласам...

— Бала белән дә укыйлар бит әле. Тәвәккәллә, кызым, — диде Мәдеһия түти, аның күзе дымланды, кулын Гөлзариянең кулына куйды, ә башында — уйлар.

Кызы егетне күнеле белән булачак ире итеп кабул кылганын ана кеше тоя иде, ана фәкать әнисенең фатихасы кирәк. Рәхмәт киңәш-табышка кайтуына. Акылсыз бала түгел. Кемнең кем икәнен таный, акны карадан аера беләдер. Үзенә ошагач, ана кеше ана ничек каршы төшсен ди. Әйе, бар андыйлар да — балаларының бәхетенә балта чабучылар. Соңыннан үзләре дә үкенәләр, әмма инде эш узган була. Ләкин Мәдеһия түти бер баласына да каршы килмәде, берсен дә ирексезләмәде, кызлары йөргән егетләренә чыктылар, уллары — үз теләгәннәренә өйләнделәр. Аллага шөкер, берсе дә ким-хур яшәми, ананың йөзенә кызыллык китерми.

«Белмәгән нәсел белән кан бутау — болганчык судан балык тоту белән бер», дип әйтә торган иде минем әти, дип уй йөртте Мәдеһия түти. Нишлисең, хәзер яшьләрнең күбесе үзләренчә хәл итә шул, бер минекеләр генә түгел, безгә килешергә генә кала. Авылда ул өйләндергәндә дә, кыз биргәндә дә — барысы да яшьләр сүзенә күнә. Шуңа күрә төпчегенә дә аркылы төшмәсен, фатиха бирәчәген алдан ук белә иде Мәдеһия түти. Бәхетле генә була күрсен күңел баглаган кешесе белән. Төс-битенә яки мал-мөлкәтенә карап фикер

йортулэрне дә Мәдеһия түти мәгъкуль күрми. Чибәрлек — туйда кирәк, бусы күбрәк кызларга карый. Байлык — бер айлык, дип тә әйткән борынгылар. Үзләре эшләп, күкрәк көче белән табарлар. Авылныкы булгач, кызына тиңдер, әллә ни иркенлектә, мул тормышта үсмәгәндер кияү буласы кеше, борынын чөймәс. Кызына ошаган кеше ана да чит булмас. Һәм тагын бер нәрсә ана күңелен кымтырыклап тора иде.

— Кызым, шешә белән бик шаярмыйммы?

— Минем янга эчеп килгәне юк. Тәмәке дә тартмый ул.

Авыл хатыннарының ин тенкәсенә тигән чир иде бу. Элек аракыны туй яки бүтән мәҗлесләрдә кача-поса гына эчкән ир-атлар сугыштан соң тәмам аздылар, ирләренә үч итеп, стакан күтәргән хатыннар да күренгәли башлады. Мәдеһия түти яшәгән кечкенә авыл да, аның гаиләсе дә халыкның җелегенә төшкән бу афәттән читтә кала алмады. Шуның аркасында өйләрдә талаш-кычкырыш, типсә тимер өзәрдәй ир-егетләрнең үлеме, гаилә таркалу — бу тискәре күренешләр авылга да хас иде. Мәдеһия түтинең намаз вакытларында Ходайдан бөтен теләгәне — кызларына юньле, аек ир насыйп итү.

Ана белән кыз әле бик озак гәпләштеләр...

Аннары Мәдеһия түти өйдә аш хәстәренә керештe, ә Гөлзәрия ишегалдына чыкты һәм, иңбашына көянтә-чиләк элеп, чишмәгә суга барырга җыенды. Шулчак аның күзе колгадагы сыерчык оясына төште.

Ике бала, бер-берсен этә-төртә, томшыкларын ачып, җим көтәләр иде. Аларны ата-анасы алмашлап ашата. Кеше, мәче яки карга булса, алар куркалар, ояларына кергәнче, өй түбәсенә кунаклыйлар, як-якка караналар, газизләрен үз телләрендә кисәтәләр — тавыш бирәләр.

— Курыкмагыз, юләркәйләрем, мин сезгә тимим бит, — диде Гөлзәрия һәм капкага таба юнәлде.

Ул ераклашкач кына, сыерчыклар ояга чумды. Әйе, Гөлзәриянең үзенең дә туган өеннән китәр чагы якынлашкан икән. Хәер, ул аннан күптән чыгып китте инде. Үзләрендә башлангыч мәктәп кенә иде. Шуңа күрә сигез классны күрше авылга йөреп, кышын интернатта торып укыды. Аннары абыйсы аны укырга калага алып китте һәм үзләрендә яшәтте. Рәхмәт аңа һәм... җиңгәсенә дә: кысан гына бүлмәдә ике балалары янына аны да сыендырдылар. Техник училищеда укыганда, тулай торакка күчте, заводка эшкә керде — янә тулай торак. И бала, бала... Унбиш яшеннән чыгып киткән икән бит. Ул әнисе янына атна саен диярлек кайта. Бер елын исәпләмәгәндә, чираттагы ялын да шушында уздыра. Ул елны иптәш кызы белән, эштән юллама алып, Кавказга барып кайтканнар иде. Ничек йөрәкләре житеп киткәннәрдер, әле дә гаҗәпләнә. Ә монда кайткач эш: печән әзерлисе, утын кисәсе, бәрәңге чүбен утыйсы... Киләчәктә ничек булыр? Еш кайта алырмы? Үз гаиләсе... Иренен дә, ерак булса да, әти-әнисе янына кайтасы килер. Гөлзәрия, юк, мин сезгә кайтмыйм, үз әнием көтә, дип кирелэнә алмый бит инде. Ал тәгәрмәч кайдан барса, арты да шуннан тәгәрәргә тиеш була түгелме? Кыз көлеп куйды: әле Габделнур аның ире түгел бит, ә шулай да... Ай бу дөнья, әллә ниләр уйлата икән, тормыш-яшәешенне үзгәртергә карар кылгач. Үзгәртмичә дә булмый, һәр җимешнең үз вакыты... Һәр кош баласының оясыннан очып китәсе, үзбаш яшисе килә.

Гөлзәрия чишмәдән кайтуга, шаулап-тузанлап, томанлап яңгыр яварга кереште. Ул бик куркыныч булып килде: яшен яшьнәде — кызгылт-аксыл чыбыркылар күкне кыерлады, гүя төрле кисәкләргә яргаларга, туракларга теләде, күк күкрәгәндә, тәрәзә рамнары зыңлап торды, гөрселдәтеп туптан аткан тавышлар ишетелгәндәй булды, суын чиләкләп түккәндәй, яңгыр койды да койды, өй почмагындагы мичкәгә түбәдән бервзлексез тоташ су акты. Аннары

бераз тына төште һәм көзге янгыр сыман пыскып кына бик озак яуды. Ахырда күк йөзе ачылды, салават күпере хасил булды, һава чистарды, бөтен тереклек яна сулыш алды.

Гөлзәриянен дә алгысыган күнеле тынычлана төште. Алда торган үзгәрешләргә сабыр гына, эчке бер күндәмлек беләнрәк карарга тырышты, язмышы белән килеште.

Ул башта ишегалдына чыкты, аннары, абзарга кереп, арт капканы ачты да бәрәңге бакчасына күз салды. Ике атна элек утыртылган бүлбеләргә жан кергән — тишелеп чыга башлаган. Тәбәнәк койма белән әйләндереп алынган яшелчә бакчасында кыяр, суган түтәлләре дә давыллы янгырга бирешмичә исән калганнар. Кура жиләге, крыжовник, карлыган яфракларыннан акрын гына янгыр тамчылары тама. Кыз табигатьтәге, ихата тирәсендәге үзгәрешләргә хозурланып, үзалдына сөенеп-елмаеп йөрде, урамга чыкты.

Үзләре әмәлләгән кармак сапларын олыларча инбашларына салып, кулларына бәләкәй чиләкләр яисә селәүчен салынган консервы банкалары тотып инешкә балыкка баручы малай-шалайлар күренде. Барысынын да чалбар балаклары сызганулы, беришләре, яланаяк лачтыр-лочтыр саз ерып, урам уртасыннан юлдан, икенчеләре юеш чирәм өстеннән бара, үзләре кызып-кызып, кулларын бутый-бутый гәпләшәләр, бәхәсләшәләр.

«Ниләр хакында сөйләшәләр икән бу почык борыннар? — дип уйлады кыз. — Менә боларга рәхәт, бәхетле чаклары! Аларнын гамьнәре дә әнә шул кармак-калкавычлар, эләгәсе табан балыгы тирәсеннән ары узмыйдыр. Кемгә тизрәк каба, кемнекенә зуррагы эләгә, кем күбрәк тота... Апагызныкы белән чагыштырганда... Хәер, һәр чорнын үз мәшәкате, үз уйлары... Сезнен кебек чакта безнен дә уй-фикерләр, борчулар бүтәнчәрәк иде шул...»

...Бу кайтуында Гөлзәрия үзе генә түгел иде. Габделнур кыз сорарга кайтты. Мәдеһия түти моны хуп күрде. Яшь кенә булса да, борынгы йолаларны белүе, онытмавы, ихтирам итүе ошады ана. Олырак оныклары, ят абый алып кайткан күчтәнәчләрне кулларына тотып, урамга чыгып киттеләр, өйдә кече сенелләре генә бишегендә ятып калды.

Габделнур шуна игътибар итте: абыйсынын балаларын урамга озатканда, Гөлзәрия аларнын чәчләрен рәтләп, башларыннан, аркаларыннан назлап-сыйпап, ягымлы иркәләү сүзләре әйтеп калды. Моны күреп, егет ана янә бер сокланды һәм үзе алай ук булдыра алмас иде кебек тоелды. Хәер, ул да абый-апасынын балаларын үз итә, ләкин анын яратуы аларны култык асларыннан күтәреп күккә чөюдән яисә кулларыннан тотып әйләндерүдән узмый иде кебек... Хәер, гомер буе зимагурлыкта йөргән кешедән тагы ни көтәсен...

Кызы алдан хәбәр биргәч, Мәдеһия түти табынын да көндәгедән мулрак-затлырак итәргә тырышкан — пешеренгән-төшеренгән. Әмма «кияү», юлдан килгән булса да, ачкүзләнеп бөтенесен рәттән сыпырмады.

Габделнур, сай тәлинкәгә салынган тәмле гөбәдия кисәген ашап, бер чынаяк сөтле чәй эчкәч, тәгам жыюдан туктады.

— Рәхмәт, бик тәмле булды! — диде ул, чынаягын тәлинкәгә каплап.

— Тагын берне ясыйм, — дип, Гөлзәрия ана күтәрелеп карады.

Әнисе дә кыстап карады, әмма егет сүзеннән кайтмады:

— Хушландым. Сез эчегез, мина карамагыз.

Ләкин хужалар да өстәл янында озак юанмадылар. Мәдеһия түти амин тотканда, Габделнур да, ике кулын күтәреп, битен сыпырды.

Чәйдән сон өчәү олы якка чыгып утырдылар. Егет өй эченә күз салды. Түр диварда, өч яклы көзгедән өстәрәк зурайтылган фоторәсем эленеп тора. Түгәрәк йөзле, ак яулык астыннан чак кына чыгып торган чем-кара чәчлесен

егет шундук таныды — Гөлзәриянең әнисе. Ул хәзер дә шулай мөлаем, сузып япкан ак яулыклы, фәкать өстендәге күлмәге генә бүтән төстә — яшел. Ә аның белән янәшә рәсемдә үткен карашлы, озынчарак ябык йөзле, кара бөдрә чәчле ир-ат әтиседер.

Өстәлдә «Весна» телевизоры, тумбочка өстендә магнитофон белән янәшә таушалган иске китап, аның өстендә дисбе һәм күзлек ята. Бакча ягына караган тәрәзә төбенә «Альпинист» транзисторы менеп кунаклаган. Уң дивар ягындагы тимер караватка кабартылган мендәрләр өеп куелган — һәрнәрсә чиста, пөхтә. Ишек өстендәге җыйнак кына шәмаил дә егетнең үткен күзеннән читтә калмады.

Габделнур сөйләшүне озакка сузмаска булды.

– Апа дип әйтимме, әби дип әйтимме, кызыгызны сорарга кайттым, әтиәни еракта, шуңа күрә үзем килдем, гаеп итмәгез, — диде ул, Мәдеһия түтинең йөзенә туры карап. — Минем кем икәнне Гөлзәрия әйткәндер инде (ике бите ут янган кыз бер читтәрәк, башын аска иеп утыра иде). Дөрес, мин әле хәзергә алтын таулары вәгъдә итә алмыйм. Шулай да кызыгыз ким-хур булмас, эшлим, фатирга чиратым бара, бүген-иртәгә булыр дип әйтмим, ләкин өмет юк түгел. Башлангыч чорда кеше өстендә торырга туры килер, тулай торакта яшәп булмас...

Мәдеһия түтигә егет буйлы-сынлы булуы белән генә түгел, үзен ипле тотуы, олыны олы итеп, җайлы сөйләшә белүе, камил акыллы, һушлы булуы белән дә ошады. Кешенең күзенә туры карап сөйләгәч, бохар мәчесе түгелдер, төпле адәмдер. Дөрес, азган айгырны өердә сына, дип әйтәләр әйтүен... Шулай да... Кияү булачак кеше базымлы да күренә, кемгәдер аркаланып яшәргә ният итми, үз көнен үзе күрә торганга охшаган, үзе табарга омтыла... Монысына да әби булачак кеше кул куйды, чөнки үзе дә кечкенәдән эшләп ашарга өйрәнгән иде...

Мәдеһия түти тумышы белән бу авылныкы түгел, бала чагы күрше авылда үтте. Хәер, кыз бәләкәй чакта бу авыл әле җир йөзендә дә булмаган. Ул совет заманында барлыкка килгән өр-яңа авылларның берсе. Андыйларга, бүтәннәрне кысрыклап, бераз җир бирделәр, тирә-күрше салалардан халык җыйдылар, заманасына хас якты, матур, революцияне данлаган һәм кычкырып торган исемнәр куштылар: Якты Көн, Ирекле Тормыш, Алсу Таң, Кызыл Байрак, Октябрь Бүләге, Ленин Юлы... Һәм андый авылларның кайберләре бик тиз таралып юкка чыкты, икенчеләренең халкы исә җиргә ябышып ятты: иген икте, яшелчә үстерде, умарта тотты, мал-туар һәм кош-корт асрады...

Мәдеһия түтинең әтисе монда бүлеп бирелгән җирдә әүвәл йорт җиткезде, каралты-кура тергезде, аннары гына гаиләсен һәм төп йорттан үзләренә тигән сыер белән ике сарыгын алып килде. Юлда арбага тагылган сыер, бавын өзеп, үз авылына кире кайтмакчы булды, аны көч-хәл белән куып җитеп арканладылар... Яңа урында яңа тормыш башланды.

Мәдеһия түтинең ата-анасы да көн-төн тир түкте, балалар үстерде, уллар өйләндерде, кызлар бирде... Дөньялар житеш дигәндә генә сугыш чыкты, басса бакыр өзәрдәй ир-егетләр яу кырына китте... Бик азлары гына кире әйләнеп кайтты, алары да саулыкка туймаган ярты-йорты кеше иде... Иренең дә сугышта алган җәрәхәтләре гомерен кыскартты... Мәдеһия түти, кырык яше тулыр-тулмас, биш бала белән тол калды. Ярый әле олы малае җидене бетергәч тә колхозда эшли башлаган иде, тора-бара тракторга да утырды. Ул армиягә киткәч, аның хезмәт көненә тигән икмәк капчыкларына башын куеп, ана сөенеченнән елады — ач булмаслар. Икенче улы да үндүрт яшеннән колхоз малларын көтте, олы кызы фермага сыер саварга керде. Ичмаса, сеңелләре укысыннар дип аларын ана шәһәргә җибәрде. Олы улы кире авылга кайтмады,

калада төпләнде, ә энесе, өч ел буып йөргән солдат каешын салу белән, йорт хәстәрен күрергә керешә, чөнки өйләре тузган иде. Көн-төн чабып (абыйсы да булышты, олы сеңлесенең дә бөтен тапканы шунда керә барды), тырышатырмаша тәки шыңгырдап торган нарат бүрәнәләрдән алты почмаклы йорт тергезде. Бары шуннан соң гына үзенә кәләш эзли башлады...

Мәдеһия түти бүгенге хәленнән канәгать, балаларының тормышы көйле. Менә төпчек кызына да чират җитте...

— Үзегез килешкәч, мин каршы төшмим, — диде ул, беравык тын торганнан соң.

— Рәхмәт! — диде Габделнур, җиңел сулап.

Мәдеһия түти егетнең кайсы яктан булуы (гәрчә ул кадәресен кызы әйткән иде инде), ата-анасы турында да белеште. Аларның үзе кебек гади кешеләр булуына да шатланды.

Кирәгенчә җиһазланган, тәрәзә төпләре төрледән-төрле гөлләр белән тулган, биек түшәмле, идәненә кулдан сугылган паласлар җәелгән җылы өйдә гәп корып бераз утыргач, Габделнур, якты чырайлы Мәдеһия түтигә гозерен аяк астына салмавына һәм сый-хөрмәтенә дә рәхмәтләр әйтеп, китәргә дип кузгалды.

Гөлзәрия белән ишегалдына чыктылар. Уң кул якта чиләкләр каплап куелган өстәл бар иде. Шул тирәдән нindидер тавыш килгән сыман булды. Егет, иелеп, өстәл астына күз салды. Зур гына сыерчык баласы (оясыннан егылып төшкән, күрәсең) шунда кереп кысылган, талпына, чыга алмый азаплана.

Егет бәлагә дучар булган кошчыкны җайлап кына эләктерде, торып басты, аннары сул кулына күчерде.

— Берәр җире сынмаганмы? — дип сорады Гөлзәрия, ана таба иелеп.

— Юк бугай, — диде егет һәм бармакларын аера төште.

Кош баласы, шуны гына көткәндәй, талпынып очып та китте, әмма ерак китә алмады, җиргә егылып төште. Егет аны янә җәһәт кенә эләктерде.

— Әле канатлары ныгымаган, — диде кыз.

— Мә, син тотып тор әле, — дип, Габделнур кош баласын Гөлзәриягә бирде.

Ул, мунча янында яткан озын баскычны алып, сыерчык оясы колгасына сөяп куйды, ныклыгын тикшерде.

— Әллә менәсең?

— Әйе.

— Егылып төшмә тагы, — дип борчылды кыз.

— Җирдән түбән төшмәм.

Әлбәттә, ул хәрби хезмәттә чагында янгын сүндерүчеләр ярышында «штурмовка» дип йөртелүче, озын ыргаклы, дюралюмин баскыч белән дүртенче кат тәрәзәсенә очып менгән шикелле кыланмады. Ни дисәң дә, агач баскыч ул максат өчен ясалмаган, искергән араталары да чыдатмас иде; шулай да, сөйгәне карап торганда, сер бирәсе килмәде.

Егет сыерчык баласын кулына алды, җитез генә, шулай да саклык белән баскычтан менеп, аны оясына, туганы янына төшереп җибәрде. Ул арада балаларның атасымы, анасымы кайтты һәм, чыр-чу килеп, тавыш кубарды.

— Курыкма, юләркәй, — диде егет, баскычтан төшешли башын югары күтәреп.

Төшкәч кул юып аласы итте. Гөлзәрия, өстәлдәге чиләктән чүмеч белән су салып торды.

Шулвакыт бәләкәй капкадан зур гына бер кара эт килеп керде. Башта сәерсенебрәк карап торды да Габделнур янына килеп аягына сыенды.

— Әбәү, кара ничек сырпалана, ятсына да белми, — диде Гөлзәрия, шаккатып, һәм кисәтеп куюны кирәк тапты: — Тешләмәсен тагы. Усал ул.

— Тешләмәс, — дип елмайды Габделнур һәм этне башта муеныннан, аннары маңгаеннан ук сыйпады. — Жизнәсен таный ул.

— Жизни булып житмәгән бит әле.

— Әби фатиха биргәч, була инде, була, — диде егет, кызга күз кысып. — Собака — друг человека, диләрме әле, ә мин аны, гашыйкларның да дусты, дияр идем. Ул нинди токымнан: бультерьерга да охшаган, мастиффны да хәтерләтә, әллә доберманмы?

— Көлмә инде, — диде кыз, бик тиз Габделнур белән үзләшкән этнең башыннан сыйпап. — Гади авыл эте инде, ихата сакчысы.

— Мине озатасыңмы?

— Үзең дә озаерсың әле.

— Чын әйтәм.

— Әнә Актырнак озатсын.

— Усал сөйләшә кешеләр. Шулай инде, эт оясында көчле.

— Мин этмени?

— Үпкәли күрмә берүк. Мин чыгарган әйтем түгел, халык авыз иҗаты. Ә нигә озатмыйсың?

Гөлзәрия башын түбән иде, урам ягына карады:

— Әнә, күрше әбиләр капка төбендә утыра. Үзең генә бар инде, яме.

— Ярар, — диде егет һәм, елмаеп, капкага таба юнәлде дә кинәт борылды: — Бер пәп итимме? Капка артына качып кына...

— Кит инде. Килешмәгәнне, — диде, кыз оялып аңардан читкәрәк тайпылды һәм гаепле кешедәй әйтеп куйды: — Җәяү китәсең инде...

— Котырган эткә мең чакрым — әйләнеч түгел, — диде егет, көлеп. — Мәхәббәттән тилергән дип әйтәсе идем мин... «Машиналарга утырып җәяү кайттым ат белән» дип әйтеп әйткән, ди, бер карчык, миңа да җай чыгар әле, чыкмаса, ике атлап, бер сикерүдә станциягә барып җитәм.

— Электричка расписаниесен бирдем бугай.

— Әйе, — дип, егет саубуллашты да китеп барды.

...Егеткә кызның әнисе дә бик сөйкемле күренде. Атага тартым ул тумас, анага тартым кыз тумас, дисәләр дә, төс-бите белән генә түгел, холкы-фигыле белән дә Гөлзәрия Мәдеһия түтигә охшаган иде. Бу очракта, агачы нинди, җимеше шундый, дияргә генә кала.

Егет матур табигатьле, урман-сулы кечкенә авылны да ошатты. Үз авылы белән чагыштырды. Монда урман, кем әйтмешли, өсләренә авып тора, биредә, нефть чыккан яклардагы кебек, буровойлар җир маен суырмый, электр линияләре басуларны аркылы-торкылы кисми — табигать бөтен гүзәллеген саклаган.

Егет үзенең Мәдеһия түтигә ошавын да сизде, димәк, борчагы пешәчәк, эштә бер прораб әйткәнчә, «шарлар аның ягында».

Кунак аз утырыр, күп сынар дигәндәй, ул аның күпне күргән, тормыш дигән дәрьяның ачы суын күп эчкән икәненә инанды. Бәхәс-низаг чыкканда (савыт-саба шалтырамый тормый бит), кайбер әбиләр кебек, кияүне гаепләп, үз кызын гына яклап утырмас шикелле. Урысларда «тёща»дан зарлану гадәткә кергән, ә бездә ул юк дәрәҗәсендә. Нилектән икән? Безнең әбиләрнең зирәк зиһенле булуыннанмы? Алай дисәң, тегеләрнең дә бөтен тёщалары җинел гөрәнкәле ангыра түгелләр бит инде... Габделнурның этисенә аръяк әбисе кияү дип кенә тора, Гөлсылу апасының иренә дә әнисе кияү дип өзелеп тора. Егет көлеп куйды. Энженең анасы да аңа кияү дип бик ягымлы эндәште бит, стакан тутырып, аракы да салып бирде. Әмма аныкы бүтәнчәрәк иде шул, тизрәк кызын «олактыру» максатыннан әйтелгән сүз иде. Ә чынлыкта... кызының элек йөргән нәрсәсе өендә кунып кайтуын яшерде... Биредә Габделнур андый хәлгә тарымас, шәт...

Урамда кармаклар күтәреп балыкка баручы малай-шалайга юлыкты. Аларга карагач, егет уйлап куйды: «Өйләнү дә балыкка барган шикеллерәк: анда йә тотасың, йә юк, ә хатыннан йә унасың, йә юк».

Егет, җәт-җәт атлап, әйләнә-тирәдәге басу-болыннарга, ерактагы урман-кырларга карап хозурланып барса да, күңеле һаман уйда булды. Ул Гөлзариясе (әйе, хәзер, авыз тутырып, шулай әйтсә дә ярый торгандыр), аның әнисе, ягъни булачак әбисе белән очрашу тәэсиреннән арына алмый иде. Каядыр караса да, күзе нидер күрсә дә, уйлары һаман алар тирәсендә бөтерелә. Ул сөенечтән авызын җыя алмый, кырмыска мәйдан тотар, кем дә белмәс дигәндәй, шатлыгын бүлешер кеше генә юк. Егет, «тиле кеше» кебек (мәхәббәт исереклеге, диик), үзалдына елмаеп, борынгы Рим императоры Юлий Цезарь сүзләрен исенә төшерде: «Килдем, күрдем, җиңдем!» Ләкин аныкы яу кырында ниндидер дошманны җиңү шикелле туры мәгънәдә түгел, ә булачак әбисенә ошау, күңеленә хуш килү җәһәтеннән иде. Ул белә: авыл корткалары бик зиһенле була, алар кешене бер күрүдә таныйлар, бигрәк тә кияү буласы кешегә сынап карыйлар, чит авылдан булса, һәр хәрәкәтен-торышын, үз-үзен тотышын күзәтеп-искәртеп торалар, үзләренчә бәһа бирәләр. Ул өйләндергәндә, кыз биргәндә, мондыйрак сораулар да куела: «Нәсел-нәсәбен тикшердегезме? Түбәләре безнеке кебек тигезме?» Монда сүз һич кенә дә йорт турында бармаган. Кеше кадерен белә торган тәүфыйклы, тәртипле нәселме? Ялкаулыктан айнымас ыру түгелме? Кыскасы, бик күп һәм үтә тирән мәгънәле төшенчәләр яткан бу сүзләрдә.

Менә шул күзлектән караганда, Габделнур үзен җиңүче итеп тойды. Ләкин моның күзгә күренмәгән икенче ягы да бар: ул хәзер биш бала анасының, кырык яше дә тулмастан тол калган ятимә карчыкның ышанычын акларга тиеш булачак. Ә бу нидән гыйбарәт соң? Мәгълүм ки, ин беренче нәүбәттә, гаилә өчен җаваплылыктан: аны тәрбия кылудан, яшәү шартлары тудырудан, кешенең кадерле баласына яхшы мөгамәләдән; икенчедән, хатынының анасына, туганнарына кадер-хөрмәт күрсәтүдән; өченчедән, намуслы, тәртипле балалар үстерүдән һәм аларга белем бирүдән...

Габделнур, телдән әйтмәсә дә, күңеленнән әнә шуларны уйлый-уйлый атлады. Болар әле генә борынлаган, бүген генә аның уена килгән фикерләр түгел иде, алар бәләкәйдән аның канына сеңгән, гаиләдә күреп-белеп үскән гореф-гадәтләрнең күркәм нәтиҗәсе иде.

Менә хәзер үзе дә Галләм абзыйның холык-фигылендә, эш-гамәлләрендә чагылган сыйфатларны үзләштерергә тиеш булачак иде. Моңа сабыры-түземе җитәрме? Гаилә кору дигән зур сынауны уңышлы тапшырырмы? Әйе, бу Казан университетының тарих бүлегендә укыган чорда тапшырган күпсанлы имтиханнардан да катлаулырак һәм авыррак, бу — Тормыш университеты сынаулары. Аңа вакыт та күп кирәк. Тегендә биш ел булса, монда — тулы бер гомер... Монысын киләчәк күрсәтер...

Ә хәзергә талгын гына искән җилгә битен куеп, каяндыр ишетелгән кош тавышларына колак салып, зәңгәр күк йөзендәге сирәк ак болытларга, шуларны бөтен тарафны мул итеп яктырткан кояшка, басу-кырларга, тирә-яктагы урманнарга сокланып атлаган егетнең кәефе шәп, ул үз-үзеннән канәгать. Әйе, Гөлзарияне сорарга кайтуы бушка булмады, кем әйтмешли, вакыт уздырып, чабата туздырып йөрмәде, эше пеште — егетне бусагадан кире борып җибәрмәделәр, аңа кадер-хөрмәт күрсәттеләр, ачык чырай — такта чәй булды. Ахырын хәерле әйләсен...

...Гөлзария өйгә кергәч, Мәдеһия түти аны үз янына дәште:

– Кызым, кил әле.

Гөлзария әнисе янына утырды.

Мәдеһия түти сүзне ерактан башлады:

— Әбиең сөйли торганые, элегрәк, безнең авылның бер кызы кияүгә чыккан икән. Атна-ун көннән яшьләрне кунакка дәшкәннәр. Әнисе кызыннан шыпырт кына сорый икән: «Кызым, кодагый бик рәнҗетмиме? Ят авылда, чит кеше өендә читен түгелме?» «Юк, әни, — дип җавап биргән кызы, — каенанамның авыр сүз әйткәне юк. Тик шунысы гына начар: мин торганда, сөлге юеш була». Анасы әйткән: «И кызым, син ана бер дә көенмә, үзең иң алдан сикереп тор, коп-коры сөлгегә сөртенерсең». Минем тел төбемне аңладыңмы?

— Әйе, әни, — диде Гөлзәрия, тулы гәүдәле Мәдеһия түти янында тагы да кечерәеп калгандай булды, аңа сыенды.

Аннары чит кешеләр алдында (әле кодагый-кодачалар белән чәй янында чөкердәшеп утырмаган бит) йөз кызармаслык итеп күчтәнәчен, тегесен-монысын хәстәрләргә, туйга хәзерләнергә кирәклеге хакында әңгәмә кордылар.

Әйе, кияү буласы кеше китеп барды, ә аңа, әби буласы кешегә янә мәшәкать (күңелле булса да) өстәлде. Мәдеһия кечкенә чакта карчыкларның, бирнә биргән бикә килен, бирнә бирмәгән чәүкә килен, дип сөйләшкәннәрен хәтерли иде. Үзе кияүгә чыкканда да ул әйтемне ишетте һәм кызларына чират җиткәч тә гел бу сүзләр хәтеренә килде. Хәзер дә хәстәренә керешергә кирәк иде, чөнки, яшьләрнең моңа исләре китмәсә дә, әле кода-кодагыйлар бар бит, «чүпрәк атыш уены» да онытылмаган. Сандык-сандык бирнә бирерлек рәт-чамасы булмаса да, хәл кадәренчә тырышырга кирәк иде...

Мәрхәмәтле ана белән итагатьле кыз бала әле бик озак яшәеш, тормыш итү хакында гәп кордылар. Күбрәк Мәдеһия түти үгет-нәсыйхәт бирде:

— Кызым, әбиең бик зиһенле, акны карадан аера белүче карчык иде. Миңа, кияүгә чыкканда, кызым, әйтеп үкенгәнче әйтмичә калып үкен, дип, кат-кат колагыма тукыды. Син дә иреннең җаена тор, тәмле телле бул, ачулансаң, иреңнне тешлә. Тол хатынның хәлләре бик мөшкел, ул аны үзе генә белә; бала үстерү дә җиңел түгел.

— Беләм, әни, синең хәлеңне аңлыйм.

— Су сипмәсәң, гөл дә үсми. Ялгыз килеш бала үстерүләре ай-һай авыр булды, кызым, җиде кат тир түктем. Берәү — бер кайгы, бишәү — биш кайгы, дигән борынгылар. Әле дә ярый олы абый-апаларың кул арасына керә башлаганые...

Гөлзәриянең үзенә дә кечкенәдән үк «уфалла» арбасы белән печән ташулар да (тау менә алмагач, әнисе белән бергә утырып елыйлар иде), апасы белән бергә (ана булышырга бара иде) фермада сыер савулар да эләкте, кыскасы, авыл кешесе җилкәсенә төшкән бик күп эшләрне башкарырга туры килде буыны ныгып җитмәгән үсмер балага.

## 18

Университет бинасында соңгы көрәшү булды. Курсташларыннан берничә кеше дипломга барып җитә алмады. Археология укытучысы узган ел Чабаксарга китеп барган иде, Габделнурлар белән бергә укучы хатыны да ире артыннан тегендәге университетка күчте. Бер авыру кыз вафат булды. Анасы белән генә яшәүче, Борисов фамилияле юаш кына Казан егете бар иде, анысы асылынып үлгән. Бу яңалыкларның соңгысын курсташы Фәнзия әйтте.

— Сәбәбе нидә икән соң? — дип сорады Габделнур теге егет хакында. — Белделәр микән?

— Анасы өйләндермәгән. Минем бер таныш хатын алар йортында тора, шул әйтте.

— Ә нигә өйләндермәгән?

— Үзенә кирәк булган.

Габделнур:

— Ничек? — дип аптырады курсташының бу сүзләренең асыл мәгънәсенә төшенә алмыйча, ә инде зиһененә барып житкәч, телсез калды.

— И-и Габделнур, бу дөньяда исең китәрлек әллә нинди галәмәтләр бар икән. Без бернәрсә дә белмичә яшибез икән.

Бу ямьсез, гайре табигый хәлгә кагылышлы сөйләшүне ары да дәвам иттерәсе килмичә, егет Фәнзиядән ире турында сорашты.

— Африкадан исән-сау әйләнеп кайтты, — диде хатын һәм аның моңа сөенеп бетә алмавы йөзенә чыккан иде. — Яңадан беркая да жибәрмим, Алла боерса.

— Хәзер кайда соң?

— Танковый училищеда укыта, — диде Фәнзия һәм горурланып өстәде: — Подполковник званиесе бирделәр.

— О, генерал булырга бер адым гына калган!

— Кирәк түгел, — диде хатын, кул селтәп. — Үзе исән-сау гына булсын. Отставкага чыгарга да күп калмый инде. Аннары, безнең егетләргә званиеләрне дә бик авыр бирәләр...

Укуны исән-сау тәмамлап, диплом алганнар кичен ресторанда очрашырга дип килештеләр дә таралыштылар.

Габделнур, Ленин урамыннан бераз баргач, сулга борылды һәм, кош тоткандай шатланып, түбән төшеп китте. Профсоюз урамы чатына житәрәк ул шып туктады. Чөнки тездән түбән итәкле, йомры гәүдәсенә мул итеп тегелгән кыска жиңле киң күлмәк, чүәкне хәтерләткән үкчәсез туфли кигән аякларын аерыбрак атлап әкрен генә тауга менеп килүче көмәнле бер хатын-кызны күрде. Ә ул... кем дә түгел... Тамара иде. Аны танып, Тамара да туктады. Беравык икесе дә сүз әйтә алмыйча тордылар. Ахырда егет телгә килде:

— Исәнмесез!

— Исәнме!

Ул кайчандыр яратып йөргән егетенә бу кыяфәтендә тап булуына уңайсызланды шикелле, бер мәлгә коелып төште, аннары үзен тиз арада кулга алды булса кирәк, аксыл йөзе яктырып китте. Өске ирене калынаеп кабарыбрак торса да, авызын ачыбрак суласа да, ул элеккеге матурлыгын жуймаган иде. Фәкать борынына житкән корсагы гына аның элекке зифа буйлы яшь кыз түгеллеген искәртеп тора иде.

Габделнурның да каушавы юкка чыкты һәм ул гади генә итеп сорап куйды:

— Кая юл тоттың?

— Мишаның әниләренә, каенанам янына барам, — диде хатын.

Егет тә үзенең каян кайтып килүен әйтте.

— Тәбрик итәм, — диде Тамара чын күңелдән һәм, аңа озын керфекле коңгырт күзләрен тутырып карады: — Теләгеңә ирешкәнсең икән.

— Әйе. Рәхмәт!

— Хәер, син һәрвакыт үз дигәненне итә, теләгеңә ирешә торган егет идең.

Монда кинаяә дә, соклану да, төрттерү дә, үпкә дә бар иде шикелле. Әйе, бүгенге Тамара Габделнурның күзенә генә карап, ул ни әйтсә, шуңа ышанып, риза булып торучы беркатлы кыз түгел иде инде.

Гәрчә шул ук уртача буй (түгәрәкләнгән генә), коңгырт чәч, ябыграк йөз, озынча борын — барысы да элеккечә кебек. Әмма ул инде озакламый ана булырга жыенучы, азмы-күпме тормыш тәжрибәсе туплаган, ак-караны аера белүче хатын.

— Сине дә алдан ук тәбрик итәм.

— Рәхмәт!

Габделнур аңа текәлеп, яратып, игътибар беләнрәк карады.

Әйе, яшь хатынның йөз-кыяфәте әллә ни үзгәрмәгән, нәкъ элеккечә диярлек, конгырт чәчләре генә ике яклап күкрәгенә төшеп, таралып тора. Кечкенә ридикюль тоткан уң кулының атсыз бармагында алтын балдак, ә озынча матур муенында туган көненә Габделнур бүләк иткән муенса. Егет уйлап куйды: «Әле дә салмаган, истәлек итеп саклый, күрәсең. Һаман ярата микәнни?»

— Кыз көтәсезме, малаймы? — дип сорады Габделнур, елмаеп, ләкин, күзем каты, көмәненә кадәм төшә күрмәсен дип, карашын Тамараның йөзеннән алмады.

— Белмим, — Тамараның йөзенә кызыллык йөгерде.

Егет бик белдекле кыяфәт белән әйтте:

— Кыздыр, мөгаен.

— Каян беләсең?

— Безнең авылда, йөкле хатын ямьсезләнсә, малай таба, матурланса, кыз таба, дип әйтәләр иде. Син бер дә үзгәрмәгәнсең, һаман да элеккечә.

Дөрестән дә, Габделнурның бу хакта авылда ишеткәне бар иде. Ләкин хәзер төгәл генә хәтерләми: әллә йөзе үзгәрсә, ямьсезләнсә кыз идеме шунда. Хәер, бу мизгелдә моның ни әһәмияте бар, иң мөһиме — Тамарага комплимент!

— Кызартма инде, — диде хатын һәм чыннан да оялды.

— Чын әгәр. Хәер, кем булса да, сезнең өчен куаныч инде.

— Әйе.

— Ирең сорадымы соң?

— Нәрсәне?

— Нишләп саф кыз түгел икәнеңне?

— Юк. Ул сорамады, мин әйтмәдем.

Тамараның йөзендә канәгатьсезлек билгеләре чагылып үтсә дә, Габделнур һаман үзенекен сукалый бирде. Бала көткән яшь хатынны үртәү яки мыскыл итү максаты белән түгел, ә ни дә булса сөйләшер өчен генә, әңгәмәне өзмәс өчен генә янә сорау бирде:

— Яратасыңмы соң?

— Баштарак бернинди хис тә юк иде. Ул алам, диде, мин барам, дидем. Фәкать сине оныtypга гына теләдем. Отыры иярләндем. Хәзер, уртак җимешебез буласын белгәч, бер-беребезгә тагын да якынайдык.

— Әйбәт булган.

— Ә барыбер мин сине оныта алмыйм, чөнки син — беренче... Син мине бик рәнҗеттең. Юк, мин сине каргамадым. Башта бик еладым. Аннары сине күралмас дәрәҗәгә килдем, тагын сүрелдем. Нәрсәгә дип кенә мине ташлагансыңдыр, белмим. Мин сиңа бик яхшы хатын булган булыр идем. Мин сине бик ярата идем...

— Мин дә сиңа карата безразлично түгел идем.

— Соң, шулай булгач?! — диде Тамара, өзгәләнеп.

— Шулай килеп чыкты инде, ачуланма.

Егеткә бик кызганыч булып тоелды бу авырлы хатын — яшьлегендә очраган гүзәл зат.

— Ачуланудан ни файда, — диде хатын уйчан гына. — Берәү булса, яшьлегемне әрәм иттең, дип, чәченә ябышыр иде. Ә мин сиңа авыр сүз дә әйтә алмыйм...

— Гафу ит, — егет гомерендә беренче мәртәбә хатын-кызга шушы сүзне әйтте.

— Хәзер соң инде, — диде Тамара һәм берникадәр паузадан соң өстәде:

— кире кайтарып булмый. Мин сине бик яраткан идем бит. Их, син... Хәзер дә... Хуш.

Ул кисәк кенә читкә борылды, урыныннан кузгалды.

Тамара китеп барды. Акрын гына тау менүче яшьлек юлдашы борылып карамасмы дип егет байтак вакыт ул киткән якка карап торды. Юк, борылмады. Туктап ял итеп алды, әмма артына борылып карамады. Ул тарафта аңа кирәкле кеше юк иде инде. Кайчандыр йөрәген жилкендергән, аны ашкынып тибәргә мәжбүр иткән, дөрләгәне күзгә күренмәсә дә, көн-төн мәхәббәт утында яндырган һәм шуның аркасында бөтен изге хисләрен генә түгел, саф тәнен дә бүләк иткән кыз өчен Габделнур чит-ят кешегә әйләнгән иде.

Хәер, ул бар. Ләкин шул ук вакытта юк та. Бу бер дә гажәп түгел. Чөнки хәзер Тамараның бөтен барлыгын, күңелен баласы биләп алган, бөтен уйлары туачак нарасыенда иде. Ул әледән-әле үзенең дөньяда барлыгын да искә төшереп тора. Әнә ул, әнисенең уйларын раслагандай, янә үзенең бар икәнен белдереп тибенеп алды. Булачак ана туктады, аякларын аерып басты, ун кулы белән зурая төшкән кендеге турысыннан түгәрәк корсагын йомшак кына сыйпады. «Дулама, дулама, тынычлан», — дип пышылдады. Әйе, ул күңеле белән Габделнурның әле һаман да аңа карап торганын тойса да, борылып карамады. Акрын гына алга атлады, тауга күтәрелде. Хәзер инде адым саен нарасыеның барлыгын сизеп, аның дөньяга сау-сәламәт тууы өчен борчыла, үзен юк-бар, чит-ят уйлар белән бимазаламаска тырыша. Дөрес, Тамараның да йөрәген нидер тырнап үткәндер, әмма озакка бармас бу вәсвәсә. Юкка гына әйтмәгәннәр бит: үпкән-кочкан — жилгә очкан. «Бу — тормыш диалектикасы. Дөнья Габделнурга гына терәлеп калмаган бит. Ә ул алга баруын дәвам итә. Ярый әнә Тамара үзенә тиң кешене тапкан. Начар егет түгелдер, бер дә зарланмады. Бәби алып кайтыр. Аннары... Габделнур атлы егет төшенә дә кермәс. Аның тормышы үз сукмагыннан китәр, минеке — үз юлымнан, — дип, үз-үзен тынычландырды Габделнур. — Хәер, бүген үк ул сукмак-юллар билгеле — аерылган һәм шома гына бара бит инде». Үзе дә искәрмәстән бу — кыз бала башына төшкән кәсафәттә, аның үкенечле мәхәббәтендә, жан газабында үзенең гаепле булуын тану, аның алдындагы гаебен йоларга тырышу, акланырга омтылу иде.

Егет тә урыныннан кузгалды, таутүбән төшеп китте.

## 19

Әгәр синең берәр төшең авырта икән, ул сине гел борчып, исенә төшереп торыр. Мәхәббәт тә шулай: берәрсенә үлеп гашыйк буласың икән, син күзең төшкән гүзәл кызны бер минутка да онытa алмыйсың, һәрчак аны гына уйлап йөрисең һәм... гелән генә аның янында буласың да килә.

Габделнур да хәзер әнә шундый халәттә: уйлары гына түгел, аяклары да аны һаман Гөлзәриясенә таба тарта, аның янына алып бара.

Троллейбустан төшкәч, юл аркылы чыгып, паркка таба юнәлделәр.

Унда кырык метрлар чамасы биеклектәге ак металл — титаннан коелган монумент күккә ашкан, аның төбендәге зур йолдыз уртасында мәңгелек ут яна, техник училищелардан китерелгән кызлар һәм үсмер егетләр сакта тора. Аларның матур формалы киемнәренә карагач, Габделнур үзенең хәрби хезмәттә чагын исенә төшерде.

— Армиядә, байрак янында, без дә шулай постта тора идек, — диде ул.

Аның белән янәшә атлаган Гөлзәрия:

— Нинди байрак? — дип сорады.

— Һәр хәрби частьның үз байрагы була. Ул бик кадерләп саклана, әгәр байрак югалса, часть таркатыла. Мин әле Казан Кремлендә дә дивизия байрагы янында тордым.

Габделнур анда нинди часть торганын, әйтергә яраган кадәресен генә шыпырт кына әйтеп, анлатып бирде.

Мәңгелек ут тирәсенә чәчәк бәйләмнәре салынган, веноклар куелган, анда халык кайнаша.

Обелисктан бирерәк гаять зур кеше сыны. Ул сул ягына яткан (күрәсең, яралы солдат), сул кулы белән җиргә таянган, ә уңын алга, мәңгелек утка таба сузган. Гүя: «Кешеләр, безне онытмагыз, мәңге хәтерегездә тотыгыз, без Совет иленең азатлыгы өчен көрәшеп, сез иректә яшәсен өчен корбан булдык», — дип әйтә кебек.

Габделнур белән Гөлзәрия парк эченә таба атладылар. Егет юл уңаенда туңдырма, су алды. Бакча эче тулы халык: өлкәннәр, урта яшьтәгеләр, бала-чага, яшь-җилкенчәк; монда һәркем үзенә бер шөгыль таба — аттракционнар бихисап.

Көн җылы, кояшлы, июль аена хас булганча, кая карама — чәчәк.

— Әйдә, су буена төшәбез, — диде егет һәм кызын култыклап алды.

Алар, сөйләшә-сөйләшә, агачлар арасыннан төрле кош авазларына колак сала-сала, Казансу елгасына тиклем төшеп җиттеләр.

«Прокат пляжного инвентаря» дигән игълан күреп, егет:

— Берәр нәрсә алыйкмы? — дип сорады.

— Юк, кирәк түгел, — диде Гөлзәрия, кызарып.

Ул чишенергә туры килмәгәе дип борчылды. Габделнур, авыл карчыклары әйтмешли, ярәшкән егете булса да, әле никахлы ире түгел бит. Аның алдында ялангач тәнен күрсәтәсе килми иде.

Яр буенда бала-чага мәш килә, аларны эти-әниләре күзәтә, елга уртасыннан бер су трамвае узып бара, аның әйләнәсендә акчарлаклар оча.

— Туфлиемә ком тулды, — диде Гөлзәрия, туктап.

— Сал да кулыңа ал, — дип киңәш бирде егет һәм елгада күренгән көймәләргә ишарәләде. — Әйдә без дә көймәдә йөзәбез.

Егет, берәү белән сөйләшеп, моторлы көймә яллады. Ярты сәгатьләп җилдергәч, көймәче аларны бая кузгалып киткән урынга китереп куйды.

— Монда рәхәт, — диде кыз, җылы җиргә аяк баскач. — Су өстендә салкынча иде.

— Көймәсе җилле чапты бит, — дигән булды егет.

Аннары алар төшкән юл белән өскә менеп киттеләр.

Габделнур «Үлем элмәге» аттракционы янында туктады.

— Утырабызмы?

— Юк, бар үзең генә.

— Ярар, — дип, егет «самолёт»ка менеп кунаклады.

Ә менә таганга Гөлзәрия курка-курка гына булса да утырды. Аннары кешене төрле кыяфәтләргә кертеп «мыскыл итә» торган кыек көзгеләр тезеп куелган «көлү бүлмәсе»нә кереп чыктылар.

Габделнурның күңеле күтәренке, аңа шулхәтле рәхәт, көн буена Гөлзәрия белән шушында йөрергә риза иде. Ул кызны, ай-ваена карамыйча, кафега алып керде.

Тамак ялгап чыккач, аллеяда йөргәндә, Габделнурның эшендәге берничә кыз очрады. Егет алар белән исәнләшеп үтте, сөйгәненә хезмәттәшләре, төзү идарәсендә эшләүче буяучы-сылаучы кызлар икәнен әйтте. Тегеләр исә Гөлзәриягә өнәмичәрәк, безнең асыл егетне эләктергәнсең, дигән кебек көнләшебрәк карадылар. Узып киткәч, артларына борыла-борыла нидер сөйләштеләр, күрәсең, лаекмы син безнең егеткә, юкмы, дип гайбәт сатканнардыр.

Алар арасында алтын сыман сары чәчле мари кызы да бар иде. Ул Габделнурга өздереп, әмма яратып карады. Бүтән кызлар — көнче күбәләкләр — чыннан да, Гөлзәрияне энә күзеннән үткәргәндәй, анардан ничек тә нинди дә булса гаеп табарга тырыштылар.

— Буе тәбәнәк икән...

— Төс-бите дә ташка үлчим...

Бары мари кызы гына дәшмәде, анын күк йөзе кебек зәп-зәңгәр күзләре сагышлы иде.

Габделнур белән Гөлзәрия, тирга барып, пневматик мылтыктан аттылар, дөресрәге, башта егет үзенең бәхетен сынады. Аннары кызны да атарга өйрәтте. Гөлзәрия җил тегерменәнә тидергәч, анардан да битәр сөенде, бала-чага кебек шатланды, мактап та куйды:

— Синнән шәп стрелок чыгасы икән!

— Син мине юри үсендерәсен инде, — диде кыз, әмма үзе дә куанды.

Тирдан ерак та китмәделәр, Габделнур каршыларына дусты Ирек килгәнне күрде, янында икенче хатыны, янәшәдә бала — өч-дүрт тирәсендәге кыз атлый. Ул — Ирекнен үги баласы. Анын атасы, милиция офицеры, моннан ике ел элек, хезмәт вазифасын башкарганда һәлак булган. Фәнирә белән араны өзгәч, берничә айдан соң Ирек шушы тол хатын белән кушылды. Гәүдәсенә караганда, инде буйга узган булса кирәк. Үзара таныштылар. Егетләр шактый озак хәл-әхвәл белешеп гәп кордылар, эскәмиягә утырган хатын-кызларның да сәйләшер сүзе табылды.

Ахырдан Ирек, күз кысып:

— Очрашуны билгеләп үтәргә кирәк инде, — диде, чөнки ул гражданский киемнән иде.

Габделнур:

— Бүтән вакытта, — диде дә сүзне икенчегә борырга теләде.

Моны сизеп, дусты:

— Минем эш — тәкъдим итү, ә синеке, — как всегда, отказать, — дигән булды.

Хатын-кызлар ягына баш кагуыннан Ирек дустының йөргән кызы алдында хәмер белән чуалырга теләмәвен аңлады. Ә анын инде кызлар каратасы юк. Шулай да үтереп кыстамады. Алар бик җылы аерылыштылар.

...Кич житте. Габделнур белән Гөлзәриянен икесенә дә монда ял итүе рәхәт булганлыктан, яшьләр кайтырга ашыкмадылар, аларны тулай торакта тимер караватларыннан башка көтеп торучы юк бит.

...Ачык эстрада. Утлар яна. Ян-якта — агачлар. Алда өсте ябулы, ярымтүгәрәк түбәле сәхнә, анда симфоник оркестр урнашкан: төрледән-төрле уен коралларынын тигез матур авазлары кичке тынлыкны яңгырата. Уйнаучыларнын бармаклары төймәләргә баса, кыллар чиртә, барабаннар кага, иреннәре мөштекләргә өрә, күзләре каршыдагы пюпитрда куелган нота дәфтәрләре битендә, әмма дирижёрга да карап алалар, чөнки алар тулысынча аңа буйсыналар.

Тәбәнәк гәүдәле, кин җилкәле, юан муенлы, житү чәчле, зур башлы дирижёрнын хәрәкәтләре кискен, тездән түбән кара фрагынын култык аслары менә-менә ертылып китәр сыман. Ул аста эскәмияләргә утырган тамашачыларга арты белән басып тора, уң кулында кечкенә таякчык та бар, үзе, тулы гәүдәле булуына карамастан, бик дәртле.

Дирижёр басып торган урынында сикереп-сикереп куйгандай итенә, талпынып-талпынып китә — гүя очарга әзерләнгән кош, канатлары гына юк. Хәер, куллары канат икән — уны да, сулы да өзлексез хәрәкәттә: бер карасаң,

җәһәт кенә өскә менеп китә, икенче карасаң — талгын гына аска төшә. Аның башы да тик тормый — әле югары чөелә, әле түбән иелә, як-ягына да карап ала.

Габделнур дирижёрны самолёт, танк, пушка, пулемётлар белән коралланган зур гаскәр — армия белән командалык итүче генералга тиңләде. Ул шуларның бөтенесен бер йодрыкка туплап, тиешле юнәлеш биреп, җиңүгә илтә. Ә дирижёр каршында утырган музыкантларның барысын бер максатка — композиторның иҗади җимеш аһәңен, энәсеннән җебенә кадәр дигәндәй, һәр нотаны бөтен нечкәлекләре белән тамашачыга дөрес һәм аңлаешлы итеп җиткерергә тырыша. Әлбәттә, моның өчен музыканы искиткеч ишетү сәләтенә ия булырга, һәр нотаны тотып ала белергә һәм, һичшиксез, даһиларча талантлы булырга кирәктер.

Габделнур белән Гөлзәрия дә, бер эскәмиядә буш урыннар табып, шунда урнаштылар.

Ә музыка агылуын дәвам итте. Ул тынгач, галстук урынына ак күбәләк таккан, ап-ак манишка кигән дирижёр тамашачыларга таба борылды, зур пеләш башын иде; аягүрә баскан музыкантларның osталыгына хәйран калган халык, бик канәгать калып, аларны алкышларга күмде; үз чиратында тегеләр дә баш иеп аларны сәламләде.

Ул арада сәхнәдә затлы озын күлмәк кигән бер хатын-кыз пәйда булды һәм нинди әсәр башкарылачагын игълан итте:

— Эдвард Григ. «Пер Гюнт» сюитасы.

Норвегия композиторының Габделнур да, Гөлзәрия дә моңарчы ишетмәгән музыкасыннан соң күңелгә ятышлы һәм колакка якын, үзебез тыңлап иялəнгән аңлаешлы аһәңнәр агыла башлаячагы беленде.

— Салих Сәйдәшев. «Совет Армиясе маршы».

Кырык-илле кеше, бер җан, бер тән булып дигәндәй ашкынып, дирижёрның һәр хәрәкәтен тоеп, дәртле музыка башкарды. Ул яңгыраганда, аяклар үзләреннән-үзләре, сафта йөргәндәй, атлап китәргә тели, бөтен барлыгың көч-куәт белән тула, тәнеңдә дәрт арта, кан уйный башлый.

Икесе дә, тын да алмыйча, әсәрләнеп, даһи композиторның гүзәл иҗат җимешен тыңладылар.

Алып баручы тагын сүз ала:

— Джордже Энеску. «Румын рапсодияләре».

Габделнур үзе музыка тыңлый, үзе Гөлзәриягә иелә төшеп, бая ишеткән марш хакында тәэсирләре белән уртаклаша, үзе белгәннәрне кызга да җиткерә. Ул, сөйгәнен үпкәләтмәскә һәм кимсетмәскә тырышып, сак кына искәрде:

— Бая конферансье маршның исемен дөрес әйтмәде.

Кыз, аптырап, аңа таба борылды:

— «Совет Армиясе маршы» диде бит...

— Әйе, — дип, башта егет ризалашты, аннары төзәтүне кирәк тапты: — Ләкин ул «Кызыл Армия маршы», егерме ничәнчедер елда язылган. Ул чакта әле безнең гаскәрләр Кызыл Армия дип йөртелгән.

— Безнең күңелгә ул революциядән соң ук Совет Армиясе кебек сеңеп калган, — диде кыз оялып кына.

— Бу марш Кызыл Армиягә багышлап язылган, — диде егет, кабатлап, аннары, алга карап, сәхнәдән агылган музыкага колак салып, бераз тын торгач өстәде: — Әле Бөек Ватан сугышы вакытында да солдатларны кызылармеец дип йөрткәннәр икән. Совет Армиясе дигән төшенчә соңрак, фәкать кырык алтынчы елда гына кулланылышка кергән.

— Син аны каян беләсең?

— Марш турында, Алабугада укыганда, композитор Әхмәт абый Хәйретдинов әйткәне хәтердә калган. Аның «Миндәдер күнелләре» дигән бик матур җырын ишеткәнең юкмы?

— Бар.

— Ә кызылармеец дигәнне әтидән отып калганмын, аның орден-медаль таныклыкларында шулай язылган.

Яшьләр сәнгать җитәкчесе Натан Рахлин җитәкчелегендәге симфоник оркестр башкаруында Чайковский, Хачатурян әсәрләрен тыңладылар. Алар кузгалып киткәндә, озын буйлы, бөдрә чәчле Эмиль Җәләлетдинов, оркестрга кушылып, «Туган ягым — Татарстан» дигән җырны башкарып калды.

Ачык эстрададан ераклашканда да, алар әле музыка тәэсиреннән һаман айный алмыйлар иде.

...Биек челтәрле койма белән әйләндерелгән, утлар белән яктыртылган танцы мәйданчыгына керделәр. Бераз биеп юангач, аннан чыктылар.

— Кайтабызмы? — дип сорады Гөлзәрия, сәгатенә карап.

— Иртә бит әле. Әйдә кичке елганы, шәһәрне күзәтик, бер дә болай ял иткәнем юк иде. Синең белән бик рәхәт. Әле тагын кайчан киләбез.

...Яр буе. Сукмактан читкәрәк чыгып, тау башына барып бастылар. Бирегә җылы, рәхәт, тыныч, ачык күк йөзендә йолдызлар җемелди, шәһәр өстеннән, кызыл утын бер яндырып, бер сүндереп, зур самолёт аэропортка төшеп бара, поезд үтеп киткәне ишетелде.

Гөлзәриянең монда беркайчан да булганы юк иде.

— Бу нинди поезд соң? — дип сорады.

Егеткә аңлатып бирергә туры килде.

Казансу өстендә акчарлаклар чыелдавы ишетелә, суга таш төшкән кебек тавыш чыга — зур балык чирткәне колакка чалына шикелле. Су өстендә күктәге йолдызларның аксыл яктылыгы белән талгын гына йөзгән көймәләрнең яшел, зәңгәр, бакен-маякларның ак, кызыл утлары аралаша. Коткару станциясе төбәсендә көчле прожектор яна, янәшәсендә катер тора. Шул тирәдән төрле тавышлар ишетелә: яшьләр су коена. Яр буенда бакча, ихата сакчылары — этләр аваз сала.

Елга уртасындагы утрауда учак ягалар, Казансуның аргы ягында, еракта, болын җәелеп ята. Арырак шәһәр утлары балкый — Ленин районы биләмәләре.

Сул якта, озын дамба буйлап, ут баганалары сузылган. Ә еракта-еракларда, кояш баеган тарафта, күк йөзе алсу төскә кергән; сирәк-мирәк болытлар да күренә, ә кое зәңгәр күк гөмбәзенең төбәсе чип-чиста.

— Иртәгә көн яхшы була, — дип әйтеп куйды Гөлзәрия, хозурланып.

— Әйе, шулай булыр, ахры, — дип, егет аны хуплады.

Кыз уң кул якта, еракта-еракта күренгән урманлы тауга карады. Анда Дербышки бистәсенең саргылт, ә бирерәк озын мачтаның кызыл утлары күренә иде.

— Теге нинди вышка? — дип сорады ул.

— Радио. Әнә тегеләй күз сал әле, — дип, егет кызга үзенә таныш көн-төн янып торучы факелны горурланып күрсәтте. — «Оргсинтез» утлары булыр ул.

Сүз эш тирәсенә күчте, аннары үзара мөнәсәбәткә. Сүз ияргә сүз чыгып, бу юлы Гөлзәрия дә бер мәзәк сөйләп алды:

— Мин укыган күрше авылда бер ир-атны «Биш прәннек» дип үртиләр иде.

— Ни өчен?

— Хатыны, беренче тапкыр авырга узгач, кеше күрмәгәндә прәннек ашаган.

Моны каенанасы белгән. Ә ул бик усал һәм саран икән. Улына әйткән. Өйдә тавыш чыккан. Улы анасы сүзеннән чыкмый торган юаш, күндәм нәрсә икән. Хатыны, үпкәләп, үз өенә кайтып китә. Егет бабаларына килә һәм әйтә: «Менә бит, биш прәннек ашаган. Шул гадәтен ташласа гына алып кайтам», — ди. Хатын-кызның андый вакытта әллә ниләр ашыйсы килүен белми...

Көлештеләр.

— Курыкма, мин сиңа биш түгел, бер кило прәннек алып кайтып бирермен, туйганчы ашарсың.

Гөлзәрия кызарды. Егет аны куенына алды, суырып-суырып үпте. Икесенә дә рәхәт иде. Икесе дә кыска җинле күлмәктән генә булсалар да, берөзлексез эзәрлекләгән черкиләргә дә игътибар итмәделәр, әмма күбәләкме, кондызмы, әллә инде ярканатмы очып үткәч, кыз курка калды, сөйгәненә тагын да ныграк сыенды. Ул да булмады, алардан түбәндәрәк бер мәче күренде. Габделнур, теш арасыннан һава чыгарып, песи булып кычкырды.

— Әбәү, әнә килә, — диде Гөлзәрия, көлеп.

Егет армиядә старшинаны казарма буйлап алдап йөрткәннәрен сөйләде. Ә беркатлы мәче аның янына ук килеп җитте. Егет песинең колагына җиңелчә генә чиертте. «Биләмче» китеп барды.

— Авырттырмадыңмы? — дип сорады кыз. — Җан иясе бит.

— Юк, яратып кына чирттем.

Танцы мәйданчыгы ягыннан дәртле музыка ишетелеп тора иде. Сүз хайваннар, җәнлекләр темасына күчте.

— Монда еланнар юк микән? — дип сорады кыз.

— Юктыр.

— Мин бер кино карадым. Ике кыз: берсе — барышня, икенчесе — аның хезмәтчесе. Барышня, нәрсәгәдер ачуланып, аңа сукты, мескеннең ирене ярылды. Шуннан болар урманга киттеләр. Барышняны елан чакты. Хезмәтче кыз агуын суырды. Ә ул аның ярасына эләкте.

— Кыз нишләде?

— Үлде. И кызлар белән җәлләдек инде шул бичараны...

Егет янә кызны коча, үбә башлады. Гөлзәрия дә аңа шундый ук дәрт белән җавап кайтарды.

Нәкъ шул мәлдә якында гына чыбык-чабык сынган шикелле булды. Габделнур ялт борылды. Алар янында ук ике егет басып торалар.

— Комачауладык, ахры, — дип, берсе авызын ерды.

— Чибәр күренә, — диде кулына яртылаш ачылган сыра шешәсе тоткан икенчесе.

— Кая, безгә дә биреп тор әле кызыңны, — дип, беренчесе Гөлзәриягә якыная ук башлады.

Бу кадәр оятсызлыктан Гөлзәриянең йөзе агарды, ә Габделнурның кашлары җыерылды, ирексездән тешләре шыгырдады.

— Тагын бер сүз әйтсәң, ярга тибеп төшерәм! — диде ул һәм кызын, сүз тидертмәс өчен, унгарак алды.

— Кемне? — диде сәрхуш, мыскыллы елмаеп.

— Сине! — диде Габделнур, ярсып.

— Кара нинди герой! — дип, икенче әрсезе Гөлзәриягә якын ук килде һәм кулын кызның җилкәсенә салды. — Хәзер мин аны кочакка алам.

— Кулыңны озайтма, юкса аягыңны сузарсың! — диде дә Габделнур егетнең чыраена төкерек өрде һәм, күз ачып йомганчы, боксчылар теле белән әйткәндә, «ике этаж»да эшләп алды: сул кулы белән аның бавырына, ә уңы белән ияк астына тондырды.

Таш кебек каты йодрыклардан сыны каткан теге егет кисәге, мәтәлеп, ярдан аска тәгәрәде.

Әгәр бу минутта каршында арыслан булса, Габделнур, Гөлзәриясен яклар яисә коткарыр өчен, Африкадагы бушмен кабиләсе аучылары кебек, һич куркусыз җанварлар патшасына да ташланыр иде. Аның кыяфәте коточкыч иде.

Моны күргән икенче бәйләнчек артка чигенде дә, сүгенә-сүгенә, санын җыя алмыйча бөгәрләнеп яткан шешәдәшенә булышырга дип, түбән таба төшеп китте.

— Алар икәү бит, — диде Гөлзәрия һәм кисәк кызып киткән егетен култыклап алды. — Әйдә.

— Мәнсезләр, шундый матур көннен ямен җибәрделәр. Гафу ит.

Кыз дәшмәде, бары ана ныграк кына сыенды. Һәм алар парк эченә таба атладылар.

Гөлзәрия егетен янгыр вакытында гына түгел, боз яуса да ышыкланырга мөмкин булган таш кыя итеп күзаллады һәм үзенен ышанычлы кулда булачагына инанды.

Габделнур дәшми генә атлады. Ә үзе эчтән генә боксёрлар даирәсендә йөргән гыйбарәне исенә төшерде: «Боксёрны теләсә кем кыерсыта ала, ләкин бөтен кеше дә гафу үтенергә өлгерә алмый...»

**20**

Габделнур үз «куыш»ына кайтып керде. Бүлмәдәшләренен дә икесе үз урыннарында. Ул әүвәл әти-әнисенә, авылга хат язды, аны конвертка салгач, кулына китап алды.

Ишек шакыдылар.

— Керегез, — диде ул, китабыннан күзен алмыйча гына, аннары, битләр арасына кәгазь кыстырып, ишеккә төбәлде.

Миргаяз:

— Бу вакытта кем йөри тагын? — дип, ризасызлык белдереп алды, чөнки сәгать кичке унга якынлашып килә иде.

Өстен алыштырып урынына ятарга әзерләнгән Фәүҗәт дәшмәде. Дүртенче егет кайтмаган иде әле.

Ишектә уртача буйлы, ябык йөзле, кыска кара чәчле бер егет пәйда булды.

Габделнур аны шунда ук таныды.

— Кер, кер, — диде.

Кин җилкәле, үткен карашлы, егерме яшьләр чамасындагы бу егет Габделнурнын туганнан туган энесе, ягъни әтисенен Әлмәттә яшәүче сенлесенен олы малае Фәнсит иде. Ул кыш көне монда бер булып киткән иде инде.

Егет тартынып тормады, ишек катыннан бүлмә уртасына узып, башта абыйсы, аннан сон анын бүлмәдәшләре белән күрешеп чыкты. Анын йөреше житез, бер урында тик кенә басып тора алмаучы кешеләргә хас булганча, гәүдәсе өзлексез хәрәкәттә, һәр мускулы кыймылдый-селкенә кебек. Аны беренче тапкыр күргәч, Миргаяз Габделнурга: «Синен бу энекәшен яшь тай кебек», — дигән иде.

Егетнен өстендә кара костюм-чалбар, кара күлмәк, юка табанлы, очлы башлы кара ботинка; йөзе аксыл, күзләре ут яна, янакларында юка гына бакенбардлары да бар.

— Утыр, — диде Габделнур һәм ана урын күрсәтте.

Ләкин егет урындыкка карамады да.

— Абый, мин үзем генә түгел. Динур аста калды, вахтёр янында.

Динур дигәне аның бертуган энесе иде.

— Әйдә, алып меник.

Габделнур аягына ботинка киде, өстенә пиджак элде, һәм алар беренче катка төшеп киттеләр. Озак юанмадылар, әйләнеп тә керделәр.

Бүлмәгә кергәч, Габделнур Динурга игътибар беләнрәк карады. Соңгы тапкыр күргәндә, ул ун яшьлек малай иде, хәзер егет булып житешкән — мыек чыгып килә. Буе уртача — абыйсы белән бер чама булса да, аңа караганда таза, эре сөякле, кызгылт йөзле, коңгырт чәче маңгаена төшеп тора. Ул бүлмәдәге егетләр белән күрешеп чыкты. Йодрыклары зур, кулы каты (моны Габделнур вахтёр янында күрешкәндә үк сизде).

— Йә, ни хәлләрегез бар? — дип сорады Габделнур.

— Менә Динурны да КХТИга кертергә иде, — дип сүз башлады Фәнсит, ул үзе бер ел укыган иде инде. — Ике экзамен бирдек.

— Ничәгә?

— Бишкә.

— Шәп, — дип, Габделнур кече энекәшенә карады.

Якасыз зәңгәр пиджак (соңгы вакытта андый кием Габделнур күзенә дә чалынгалады, әмма үзе якалы пиджакны хуп күрә иде), коңгырт күлмәк, кара чалбар, кызгылт көрән жинел ботинка кигән Динур турыдан ярып салды:

— Мин түгел, абый минем өчен сдавать итә. — Аның эчендәге тышында иде булса кирәк. — Минем мәктәптә дә уку шәптән түгел иде.

— КХТИда уку бик авыр, диләр, булдыра алырсыңмы? — дип сораулы карашын энекәшенә төбәде Габделнур. — Гелән генә абыеңа аркалана алмассың.

— Куып чыгармаслар әле, — дип кул селтәде Динур, аның урындыгы шыгырдап куйды. — Кусалар, бик ялынып тормыйм, эшкә керермен. Казанда эш бетмәгән, йә Себергә китәрмен, анда нефтяниклар акчаны шәп эшли, диләр.

Ул авыр табигатьле, бераз тотлыгыбрак, әкрен сөйләшә икән. Бу турыда Габделнур белми иде. Хәер, бәлки, кечкенәдән шулай булгандыр, хәтереннән генә чыккандыр. Ул аның малай чагын гына белә бит. Динур бәләкәйдән үк таза булды, «симез» дип үртиләр иде үзен. Алар авылга, Галләм абзыйларга, ел саен җәй көне кунакка кайталар иде. Берчакны аның әбисенә әйткән сүзе Габделнурның исенә төште.

— Сырлы ипиегез күп әле, дигәнне хәтерлисеңме?

Әбисе, әле генә ашадың, тагын сорыйсың, дип әйтте микән, хәзер инде Габделнурның хәтерендә түгел. Эш шунда: аның әнисе Гөлзифа түти ипине күршедәге тимерче абзый калайдан ясап биргән сырлы савытларда пешерә иде.

Габделнур хәзер шуны егетләрнең исләренә төшерде, көлешеп алдылар. Аннары ул егетләрнең әти-әниләре, туган-тумачалары турында сорашты.

Фәнсит абыйсына ияреп кухняга чыкты, тәмәке пыскытып керде, кечесе тартмый икән.

— Унынчы август көнне өченче экзамен, — диде ул, өстәл янына утыргач. — Динур өчен изложение язам.

Ул инде үзе өчен дә план корып куйган: өч айда ярты курс өчен сынауларын тапшырып, эшкә керергә нияте. Монысына Габделнур ышанып житмәде житүен, техник вузда укуның ни икәнен бераз чамалый. Шулай да энесенә шиген белгертмәде, бәхәскә кермәде. Алар хәзер дә өйдән акча килгәнне көтеп ятмыйча, букинист кибетләренә китаплар илтеп тапшыралар икән.

Динур:

— Берәрсен куркытырга, кыйнарга, сугышырга кирәк булса, мине дәшәләр, — диде мактанып. — Үз компанияләренә чакыралар эчәргә.

Габделнур баштарак, боларга аракы чыгарыргамы, юкмы дип икеләнеп торган иде, болай булгач, шиге таралды, һәм чәй янына мәй чыкмады. «Башың яшь әле, иркәм, авызыңнан ана сөте кипмәгән», — диде ул күңеленнән Динурга. Әлмәт ягы сөйләше белән эндәшеп. Чәйгә бүлмәдәшләрен дә дәште, ләкин алар инде йокыга куерып баралар иде, өстәл янына килмәделәр, рәхмәт әйтеп, чәйдән баш тарттылар.

Бераздан кунаклар кузгалдылар. Коридорда Фәнсит, тартынып кына:

— Габделнур абый, биш сум акча биреп тор әле, — диде.

— Аракыга булса, бер тиен дә бирмим, — дип кырт кисте абыйсы катгый рәвештә.

— Юк, юк, — диде энекәше, акланып.

— Кара аны, — диде дә Габделнур чалбар кесәсеннән унлык чыгарды. — Мә.

— Рәхмәт! — диде Фәнсит, шатланып, һәм кәгазьне кесәсенә шудыргач, әйтеп куйды: — Икенче килгәндә китерермен.

— Рәхәтен күрегез, — диде Габделнур һәм, егетләрне вахтёр яныннан үткәреп, урамга ук чыкты.

Тегеләр янә рәхмәтләр әйтеп саубуллаштылар һәм Восстание урамыннан җәяүләп өскә таба менеп киттеләр.

Егет алар артыннан карап калды. Һәм үз-үзенә әйтеп куйды: «Сез икенче юлы килгәндә, мин монда булмам инде».

...Күптән түгел ул кайчандыр шушы тулай торакта яшәгән Рәүхади исемле бер механизатор белән очрашкан иде.

— Нихәл? — диде Габделнурдан өч-дүрт яшькә өлкәнрәк Рәүхади.

— Сине күргәч бетте хәл, — дип елмайды Габделнур, тегенең итләч, таза кулын кысып.

Аннары, сүз иярә сүз чыгып, Габделнурның өйләнергә җыенуын һәм фатир эзләвен белгәч, ул аларны үзләрендә торырга чакырды.

— Мин бит үземә йорт сатып алдымые, — диде Рәүхади, Тау ягы сөйләшен кыстырып. — Әллә ни дан түгел, шулай да яшәрлек: ике бүлмә, бәләкәй генә кухнясы да, урамда сарай да бар. Теләсәң килеп кара, бер бүлмәне сезгә биреп торырбыз.

Габделнур сүз озайтып, ялындырып тормады, аның адресын хәтеренә сеңдерде.

— Килеп чыгармын.

Һәм ул, тимерне кызуында сугарга кирәк, дип, вәгъдәсендә торды, бер кичне аларга барып та килде.

Рәүхадинең хатыны белән танышты, биреләсе бүлмәне карады. Патша гаиләсендә туып, хан сараенда яшәгән малай түгел, бар күргәне авыл өе дә казарма белән тулай торак — бүлмә ярыйсы күренде, шәһәр уртасында диярлек, транспорт та якын. Ризалыгын белдереп, сораган хакны алдан ук биреп тә куйды.

Өйдән чыгып, ишегалдында җыелып торган суга күз салгач, ул үзалдына елмайды:

— Монда күнелледер, бакалар да сайрашадыр.

Ул бу гамәле хакында Гөлзәриягә дә әйтте. Булачак хатыны каршы килмәде.

— Абыйларга да якын икән, — дип сөенеп тә куйды.

Бик тиз ризалашуы өчен Габделнур аңа рәхмәтле булса, шундый ук хисләрне Гөлзәрия дә кичерә иде. Бердән, ире («булачак» дип уйламавына кыз үзалдына елмаеп куйды), санга сугып, аның белән киңәш-табыш итсә, икенчедән, чын ир-егетләрчә мәсьәләне үзе бик тиз хәл итүенә куанды. Габделнур аңа еш кына, шаяртып: «Я всегда готов подставлять свою широкую грудь за твою узкую спину», — дип әйтсә дә, чынында исә ул хатын-кызга аркаланып, аның артына ышыкланып яшәүче кеше түгел иде. Егетнең күз тирәге булырдай икәнен кыз бер генә искәрмәде. Аның да, Габделнур әйткәнчә, аеры-чәере яшисе килми иде. «Икең ике җирдә яшәгәч, гаилә булмый инде ул, — дип уйлады. — Кача-поса, кызлар яисә егетләр югында ялгыз калып очрашулар...» Андый тормышны кызның күңеле тартмый иде. Апалары да, кияүгә чыккач та, тулай торактан киттеләр, кеше почмагында яки баракта тора башладылар. Әнисенең дә тел төбе шуңа тартымрак иде. Шулай итеп, бәхетле көннәрне көтеп аласы гына калды.

...Туганнан туган энекәшләрен озаткач, ул уйлары белән алда башланачак тормыш чоңгылына чумды. Җырдагыча, хатын алгач, иләк-чүмеч кирәк ул, дигән кебек, иң беренче чиратта ни-нәрсә алачагын чамалады. Һәм шуңа бәйле рәвештә Гөлзәриясе турында уйлады. Егетне шушы җылы, якты август киче кебек шатлыклы һәм ләззәтле хисләр биләп алды.

Әйе, Гөлзәрия атлы кызга карашы аны, егерме сигез яшьлек егетне, беренче мәхәббәт тойгысыдай биләп алды. Кыска гына вакыт эчендә ул әле ярты ел элек кенә аның дөньяда барлыгын да белмәгән шушы гүзәл фәрештәгә баш-аягы белән гашыйк булды. Кыз аны үзенә бертөрле гадилеге һәм шул ук вакытта гүзәллеге белән шаккатырды. Уй-хисләре гел әнә генә аның тирәсендә бөтерелә. Аңардан башка яшәүне хәзер уена да китерә алмый. Моны мәхәббәт дими ни дисең?!

Ул ярты гомерен гомуми торакларда үткәрде: балигъ булуга, әти-әнисе канаты астыннан чыгып «очты» — техникумда укыды, армиягә киткәнче янә ике ел үтте, аннары көне-сәгате белән төп-төгәл өч ел солдат казармасы, Казанда гына да биш тулай торакта яшәп алды. Әйе, туйдырган икән һаман кәҗүнни койка-матрасларда аунау. Менә хәзер, берничә көннән дип әйтик, шул ялыктырган буйдак тормышыннан аерыла.

Егет тирә-ягына каранды, урамга күз салды, аннары, башын күтәреп, биш катлы кирпеч йортның дүртенче катына — үз бүлмәләренең зур тәрәзәсенә бакты. Әллә ничек кенә шунда: бер яктан, гарык булган буйдак тормышына нокта куела, сөйгәнең белән бергә янача яшәү рәвеше башлана, бу — куаныч. Икенче яктан уйлаганда, ямансу да шикелле: бергә эшләгән хезмәттәшләр, соңгы сынықны бүлешкән дуслар кала һәм, иң мөһиме, егет ирекле, типтереп яшәүдән үз теләге белән ваз кичә, һәрнәрсәне үз дигәнчә генә хәл итә торган кырыс холкына да богау салына. Чөнки башлы-күзле булгач, син монарчы күрмәгән-белмәгән кеше белән бер түбә астында гомер кичерергә мәҗбүр ителәчәксең. Ул синең холкыңны кабул итәрме? Син аның капризларына түзеп торырсыңмы? Бәлки, әллә ни капризлары да булмас. Ул бит «май өстендә йөзгән күкәй сарысы» Энҗе түгел. Шулай да ул бит хатын-кыз, бүтән мохиттә үскән, бүтән ата-ана тәрбиясе алган. Ул яктан, бәлки, әллә ни хафаланырга да урын юктыр, чөнки Мәдеһия түти Габделнур күңеленә бик хуш килгән иде. Димәк... димәк, сина, үзеңә, ул асыл затны хөрмәт итеп, яратып, сөеп һәм... күпмедер дәрәҗәдә үзгәреп тормыш итәргә туры киләчәк, ә бу бик авыр булачак. Егет үзен белә: холкы кырыс, үзсүзлелеге дә бар, күп нәрсәне фәкать үзенчә генә хәл итәргә ярата.

Соңгысы, мөгаен, ундүрт тулгач та үзбаш яшәргә мәҗбүр булудан, үз көченә, фәкать үз-үзенә генә ышанудан киләдер.

Университетның өченче курсында Габделнур психология фәнен бик теләп өйрәнде һәм үзенә-үзе анализ да ясап карады. Ул кем: кызу табигатьле холерикмы, әллә шат күңелле, хәрәкәтчән, тышкы тәэсирләргә җиңел бирешүчән сангвиникмы? Юк кебек. Тагын кем? Үзен төшенкелеккә бирелүчән, күңелсез, караңгы уйлар гына уйлап йөрүче меланхолик дип тә әйтә алмый. Димәк, флегматик кала. Анысы салкын канлы, пошынмый торган кешеләргә әйтелә. Кызык, егет кайсы төргә керә соң? Соңгысынамы? Салкын канлылыгы бар, ләкин йөрәгенә йон үскән пошмас җан да түгел бит ул. Ә менә үзсүзлелеге, кырыслыгы, һәрнәрсәне фәкать үзенчә генә эшләргә тырышуы... Психология фәнендә андый кеше күрсәтелмәгән иде. Бәлки, кешеләрне алай бүлгәләү фән өчен генә кирәктер, чынлыкта исә табигать тарафыннан бер үк кешедә берничә төрле сыйфат салынган буладыр?..

Һәрхәлдә, ничек кенә булмасын, ул Гөлзәриягә кыеңга киләчәген аңлый иде. Хәленә кирерме, түзәрме аның холкына?!

Егет белә: гаиләне ипле тоту һәм саклау, матди ягын кайгырту өчен, ул кулдан килгәннең барын да эшләргә теш-тырнагы белән тырышачак: сөйгәненә җил-яңгыр тидермәү дә үзен ир дип санаган кешенең вазифасына керә; үз куышын булдыру өчен чәче белән җир себерергә дә кыенсынмас; башлангыч чорда сабыр итәргә генә кирәк, хатынына гына түгел, үзенә дә. «Үзенә дә» дигәнне ул колагына киртләп куйды.

...Габделнур сәгатенә карап алды.

— Һай бу башны, ник тик кенә тормый икән инде, һаман уй, уй...

Шунсыз булмый, чөнки алда аны зур үзгәрешләр көтә бит...

## 21

Алар Декабристлар һәм Шамил Усманов урамнары кисешкән чаттагы биш катлы ак йортның беренче катында урнашкан ЗАГС бүлегендә язылыштылар. Кеше күп булмады: кыз ягыннан берничә хезмәттәше, ике бүлмәдәше — Мәсния белән Фаһирә һәм апалары, егет тә күп кеше дәшмәде: солдат дуслары Ирек белән Хөрмәт, эштән Дөбәрис һәм бүлмәдәше Миргаяз. Әмма бу көн хәтердә калырлык булды: Мендельсон маршы яңгырады, матур теләкләр әйтелде, чәчәкләр бүләк ителде, котлау-тәбрик сүзләрен дә җәлләмәделәр, фотоаппарат та өзлексез чертләп торды.

Кәләшнең Дәрвишләр бистәсендәге апаларында, җыйнак кына табын янында, аннары кафеда өйләнешүне билгеләп үттеләр. Кичен Габделнур хәләл җефетен алдан белешкән фатирга алып кайтты. Ленин һәм Киров районнары арасындагы түбән урында сазлыкка салынган агач йортта, кеше почмагында, аларның гаилә тормышы башланды...

Иртән чәйләп алырга кирәк иде. Габделнур аптырап калмады: икесенең чемоданнарын аслы-өсле куеп, өстәл әмәлләде, урындыклар ролен аның китап төргәкләре үтәде...

Көндез, кибетләрдән урап кайткач, Гөлзәрия сорап куйды:

— Кичкә нинди аш пешерим?

— Ни дә ярый, — диде ире, аны кочагына алып. — Син янымда булганда, мин ач торырга да риза. Ә болай... мин ризык тәфсерли, талымлый торган кеше түгел. Үзеңә кара.

Гөлзәрия, тәрәзәдән урамга карап алды, җай гына ире кочагыннан чыкты һәм абыйлары барагында, күрше бүлмәдә торучы бер ирне сөйләп алды. Ул хатынынннан көн саен яңа төрле аш пешерүне таләп итә икән.

— Юк өчен кайгырма. Миңа калган аш та ярый.

Һәм ул, сөйләшүне житдиләндермәс өчен, үзенең кечкенә чакта, мичтән

алган чуен чүлмәк күтәреп, өй базына мәтәлеп төшеп китүен сөйләп көлдерде.

...Гөлзәрия кер юган икән. Алар кипкәч, үтүкләргә кереште.

Габделнур анын эше беткәнне көтеп торды да:

— Сүндермә, мина да кирәк булыр, — диде.

— Нишлисен?

— Чалбар үтүклим.

— Үтүкли беләсенме сон?

— Ә?! Әле ничек кенә! Тик чалбарга кулынны тидермә яме, кагылма.

— Нигә?

— Стрелкасына кулын киселә күрмәсен.

Гөлзәрия, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, игътибар белән карап утырды. Чөнки абыйларынын андый «хатын-кыз эше» белән шөгыльләнгәннәрен хәтерләми. Күрәсен, аларнын кулларына үтүк тотканы да булмагандыр. Хәер, авылда андый вак-төяк нәрсәләргә игътибар итүче дә юк иде кебек.

Гөлзәрия, анын осталыгына шаккатып, беркавым карап утыргач, көлеп җибәрде.

— Нигә көләсен? — дип сорады Габделнур, бәләкәй тастагы суга манчылган марляны сыгып, бер читкә селкегәч.

— Син, үтүкне күчергән саен, сул кулынны күтәреп, учы белән кабат марля өстенә куясын.

Иренә дә кызык булып китте, шулай икән шул, үзенен монарчы бер дә игътибар иткәне юк иде.

Беренче көннәр әнә шулай уен-көлке белән, бер-беренә яраклашу-ияләнү, бер-береннән хәтерен калдырмаска тырышу, назга сусаган күнелләрнен ачыла баруы, җан-тәннен, ятсынудан арынып, отыры якыная баруы белән уза торды.

Икенче атнада Гөлзәриянен туганнары белән Габделнур авылына туйга кайттылар. Галләм абзый белән Гөлзифа түти, бөтен шартын китереп, никах укытып, ул өйләндерделәр — килен төшерделәр. Тыйнак, мөлаем, яулык чөеп, алъяпкыч бәйләп алган, эш рәтен белүче килен балакай каенана белән каенатага бик ошады.

Килен ягы да кода-кодагыйларны, туган-тумачаларын үз итте. Бер белмәгән кешеләргә дә әллә каян елмаеп сәлам бирүче авыл халкы да күнелләренә хуш килде.

Габделнур солдат дусларын туйга да дәшкән иде. Хөрмәтнен үз шәкертләрен ярышка алып барасы бар икән, бик теләсә дә, бу күнелле вакыйгадан мәхрүм калды. Ирек кенә кайтты һәм, туй узгач, Мөслимгә — әти-әнисе янына китеп барды. Дөбәрис белән Миргаяз да туйга кайта алмадылар — эш кешеләре бит, ара да якын түгел — өч йөз чакрым диярлек.

...Иректә йөргән дала таена арбага жигелү — тәртә арасына керү кыен булган кебек, үзбаш яшәгән тулай торак зимагурына да гаиләнен тар кысаларына ияләнү читен булыр сыман тоелган иде. Ләкин, үзе теләп кигән камыт булгач, ул аны башын аска иеп кенә, җинел генә муеныннан сала алмый иде инде. Хәер, беренче чорда, кем әйтмешли, баллы айда, әле анын читенлеге, камыт бөятенен кысуы әллә ни сизелмәде дә. Алай гына да түгел, ул, йөгерә-атлый дигәндәй, уртак куышка кайта иде. Чөнки бирелә аны сагынып көтеп торучы, тәмле ашлар пешереп сыйлаучы, ә кичләрен кайнар кочагында ояла-тартына назлаучы бар иде.

Яз көне яна оя корган яки искене рәтләп-төзәткәләп мәш килгән кош парлары кебек, ир белән хатын да яшәү урыннарын җайлау хәстәренә керештеләр. Дөрес,

бу аларның үз оялары түгел, шулай булса да күпмедер вакыт (анысын әлегә беркем дә төгәен генә белми) үзләре көн итәчәк бу бүлмәне буллыра алганча, хәлләреннән килгәнчә җиһазларга (әлбәттә, хуҗаларның рөхсәте белән), тегесен-монысын алырга кирәк иде. Габделнур — тулай торакларда, казармаларда әзергә-бәзергә өйрәнгән кеше. Гаилә тормышының бу якларын, кем әйтмешли, вак-төяген белеп бетерми, ә хатыны, гәрчә ул да бирегә гомуми торактан күчсә дә, хатын-кыз буларак, менә бүген-иртәгә ни-нәрсә кирәген чамалый иде. Шуңа күрә ир тулысы белән аның зәвыгына ышанды, бу эштә аңа юл куйды. Әйтик, тәрәзәләргә эләргә нинди пәрдә (хуҗаларныкы күңеленә ятмады булса кирәк), өстәлгә җәяргә нинди ашъяулык-клеёнка, ничә урындык, гомумән, тормыш өчен кирәкле кашык-чүмечкә кадәр хәзер алар үзләре кайгыртырга тиеш иде.

— Менә болай итсәк ничек булыр...

Шунда Габделнур, беренче мәртәбә дигәндәй, хатынына янә сокланып һәм хәтта бераз көнләшеп тә карады. Анардан берничә яшькә кече булса да, бу мәсьәләдә Гөлзариянең сүзе дөрес була һәм өстен чыга иде. Иренең моңа ачуы килмәде, фәкать сөендә генә. Ләкин мәсьәләнең бер кыен ягы гына аны борчый — кесәнең такырлыгы. Башына тартса, аягына җитми, аягына тартса, башына җитми, дигән кебек, акча кытлыгы Габделнурның эчен кимерә. Дөрес, аның хәле әлегә түзәрлек, мохтаҗлыкта яшәгән чакта өметсезлектән нишләргә белмичә колагын кисеп ташлаган рәссам Винсент ван Гогныкы кебек мөшкел түгел. Шулай булса да... Шуңа күрә ул, шимбә-якшәмбе эшләргә кушсалар, бик теләп риза булды, соңгарак калып яки ике смена эшләргә туры килгәндә дә авырыксынмады, чөнки иш янына куш була бит.

Кеше кесәсендәге акчаны санарга яратмаса да, ул идарәдә кемнең күпме хезмәт хакы алуын чамалый, партия взносы түләгәндә дә бу күренә, үзара сөйләшкәндә дә чагыла, эшче халкы арасында бу нәрсә яшерен-батырын түгел. Әйтик, торкретчылар (градирия резервуарларын цемент белән эшкәртүчеләр) аена биш-алты йөз ала. Дөрес, алар аз, барысы да күптән эшли. Тимер-бетон монтажлаучыларның да ике-өч йөзгә тарта... Әллә шулар янына күчәсе микән? Бу хакта ул Шәйгазамов белән киңәшкән иде. Абзый катгый рәвештә ризасызлык белдерде, бу уен башыннан чыгарып ташларга кушты. Аның хәзер югары белемле икәнен искәртте, муены булса, камыты табылачагын әйтте.

Бервакыт Габделнур, хатыны, өй җиһазларыннан нидер алыйкмы әллә, дигәч, читенсенеп кенә әйтте:

— Бераз сабыр итик инде, синең үзеңә бер әйбер дә алганыбыз юк бит.

Билгеле, мондый сүзгә, гәрчә әле сәгате-минуты белән кибеткә чыгып йөгермәсәләр дә, һәр хатын-кызның күңеле була. Гөлзария дә шундыйрак хис кичерде. Яшькелт-зәңгәр күзләрен тутырып, иренә сокланып һәм яратып карады. Аны, акча юклыктан кимсенмәсен өчен, сүзне уенга борып, үзенчә юатырга теләде:

— Әлегә миңа берни дә кирәкми.

— Алай димә. Мин бит эштә, урамда кеше хатыннарын күрәм...

— Чын әйтәм: бөтен нәрсәм дә бар. Рәхмәт.

— Рәхмәте соңыннан булыр.

Гөлзария иренең шулай кистереп әйтүенә күнегә башлаган иде инде. Ул сүз көрәштермәде, чөнки моның Габделнурга киресенчә тәэсир итәчәген, мин-минлегенә тиячәген вакытында шәйләп, бу уеннан кире кайтты. Ул бөтен кайнарлыгы белән аңа сыенды. Аның кечкенә гәүдәсе иренең кочагында эрегәндәй булды.

— Ярар, киләсе айда яисә бәйрәмгә алырбыз, — диде. — Алай мине бик киендерәсең килгәч...

Ул күзен йомды. Аны урап алган көчле кулларны тоюдан жан-тәненә әйтеп бетергесез рәхәт, жылы дулкын таралды. Шундый кешегә тап булуына сөенеп бетә алмады һәм күңеленнән илаһи көчкә ялваргандай итте: «Ходай бәхетемне генә күпсенмәсен иде».

Ләкин Ходайдан башка әле жир йөзендә кешеләр бар бит. Адәми затларда изгелек, яхшылык белән бергә хөсетлек, көнчелек тә хәттин ашкан иде шул. Гөлзәриягә дә боларны үз тормышында бер генә сынарга туры килмәде. Кешеләргә этлек эшли белмәгән, начарлык теләмәгән бу изге фәрештәгә, чиста күңелле гүзәл затка төрлесен татырга туры килер әле.

Яңа туган кар өстендә һәрнәрсә — зурмы ул, кечкенәме — үз эзен калдырган кебек, бала күңелендә дә һәрнәрсәнең — яхшылыкмы ул яисә яманлыкмы — йогынтысы кала. Шуңа күрә алар белән бик сак эш итү сорала.

Тормыш тәжрибәсе күбрәк булган һәм гәүдәгә дә шактый зур булган Габделнур да Гөлзәриясен әнә шундый балага тиңли иде. Аның йөрәген яраламаска, авыр сүз әйтмәскә, сөйгәненең күңелен кайтарырлык эш-гамәлләр кылмаска тырыша иде. Ә бу — ай-һай авыр вазифа. Тормыш дигән олы юлның сикәлтәләре бик күп көч сарыф итүне сорый, тормыш куйган сынауларны узарга зур түземлек таләп итеlә. Сикәлтәләрдә тормыш арбасыннан төшеп калмас өчен, үрәчәгә генә ышанырга ярамый, бер-береңә дә нык ябышырга кирәк, бер-береңә терәк булу да шарт.

## 22

Габделнур теләгенә иреште: алты ел парта артында утырып (бер ел хәзерлек курсларын да кертеп), ал-ялны белми китап кимереп, университет белән тулай тораклар арасында киләп сарып йөреп, яшь кешеләргә хас булган бик күп күңел ачуларның байтагыннан үзен мәхрүм итеп, укуын тәгәлләде, түшенә ромбик такты. Әйе, аның хыялы тормышка ашты. Мөмкинлеге булып та, кылынмыйча калган гамәл дип үкенерлеге юк. Чит-ят арасында да, туган-тумача каршында да йөзе ак. Әти-әнисенең дә уллары белән горурланырга хакы бар — ил-көн алдында йөзләренә кызыллык килмәслек итте.

Баштагы айларда ул, кош тоткандай шатланып, аягы жиргә тимәгәндәй очынып йөрде, чөнки жилкәсеннән тау төшкәндәй булды. Аны хезмәттәшләре, таныш-белешләре, бүлмәдәшләре, агай-эне — барысы да чын күңелдән котладылар, мактау сүзләрен жәлләмәделәр. Андый вакытларда егетне әйтеп бетергесез шатлык-куаныч, тыштан сиздермәскә тырышса да, эчке бер горурлык хисе биләп ала иде. Әйе, тырышты-тырмашты — гыйлем дигән дәрьяның кечкенә генә бер елгасын ерып-йөзеп чыкты.

Ул үзенең икенче бер уй-хыялын да тормышка ашырды — гаилә корып жибәрде. Бер күрүдә үк күңеленә хуш килгән сөйкемле кызны үзенеке итте. Телдән әйтмәсә дә, Гөлзәрия дә аны яратты шикелле, юкса кияүгә чыкмаган булыр иде. Кеше почмагында булса да, егет үз тормышларын жайга салды. Шулай итеп, аның буйдаклык дип аталган йөгәнсезлек чорына, кайда туры килсә, шунда — кафе-ашханәләрдә тукланып яисә тулай торакта коры-сары белән тамак ялгауларына да чик куелды.

Әмма Габделнурның күңелендә үзе генә белгән, хатынына да әйтергә базмаган борчу барлыкка килде: бу — университет бетергән башы белән, каргаборын күтәреп, электрик булып эшләп йөрүе. Дөрес, кулдашлары, хезмәттәшләре тарафыннан ул үзенә карата мыскыллы яисә кимсетүле караш тоймый. Ләкин арада төрле кеше бар бит.

Беркөнне участокта мастер аңа эш кушты да китеп барышлый гына әйтеп ташлады:

— Син төзелеш техникумына укырга кер.

Габделнур ана ни дип җавап бирергә дә белмәде. Хәер, ул башта мона әллә ни игътибар итмәде, бернинди әһәмияте булмаган гадәти сүз уйнату кебегрәк кенә кабул итте. Ә бераздан, төптәнрәк уйлый башлагач һәм мастер чыраенда чагылган мәкерле елмаюны да исенә төшергәч, аны бертөрле гарьләнү хисе биләп алды. Димәк, кара эчле бу адәм анын университет хәтле университет бетерүен бер тиенгә дә санамый. Чөнки төзелештә бу гуманитар белемнен кирәге юк. Янәсе, монда төп көчләрне төзүче-инженерлар институтын яисә, һич югы, төзелеш техникумын тәмамлаган белгечләр тәшкил итә. Ә синен университетың, тарих бүлеген чүп кенә, янәсе.

Югыйсә электр цехында да, участокта да анын йөзенә бәреп, бәгыренә тиярдәй итеп авыр сүз әйткән кеше юк иде әле. Киресенчә, алар Габделнур белән горурланалар шикелле тоелды ана. Кайберләре, бәлки, көнләшәләрдер дә, әлеге мастер кебек уйлаучысы да булгандыр. Ләкин берәү дә моны ачыктан-ачык әйтергә җөрьәт итми. Аннары, трест һәм идарә күләмендә дә укыган эшче-яшьләрне гел мактап телгә алалар. Бригадирлардан, партия оешмаларыннан егет-кызларны укуга тартуны таләп итәләр.

Ә барыбер дә мастернын әлеге сүзләре аны уйланырга мәҗбүр итте. «Мин ни өчен укып йөрдем сон? Алга таба үсү мөмкинлеге булмагач, минем тырышып-тырмашып алган дипломымнын нигә кирәге бар? Әнә шул салмыш баштан мыскыл иттерү өчен генәме?»

Ул хәзер, үзенең белеменә бәрабәр бүтән эш эзләп, һич кенә дә бу төзелеш идарәсеннән китә алмый: кая гына барса да, яна кеше булачак, хәтта шушы ук трестта калса да. Бөтенесен өр-яңадан башларга, абруй казанырга тиеш булачак. Трестның төзүчеләр хәзерли торган үз училищесы бар. Узган ел Габделнурны шунда тарих укытырга дәшкәннәр иде — ризалашмады. Партком секретаре урынбасары, кабинетына чакыртып, аны трестнын мәдәният йорты директорлыгына кодалаган иде — аннан да баш тартты. Быел ЖБИга кадровик кирәк булуын ишеткәч тә, егет ул урынга дәгъва кылмады. Шушы ук идарәнен кадрлар бүлегендә эшли алыр иде, ләкин әле Митрохинның китәргә җыенуы сизелми. Димәк, үз сәгатен сукканны көтәргә генә кала. Чөнки аны бу идарәгә бәйләп тотучы иң мөһим нәрсә — фатир чираты. Габделнурнын да чираты еллан-ел югары үрмәли. Анын бөтен өмете — әнә шул исемлекнен беренче битендә үз фамилиясен күрү. Чөнки хәзер ул гаиләсе өчен дә җаваплы, кашым да күзем, маңгаем да үзем дип дөньянын артына тибеп кенә яши алмый. Дөрес, бөтен ир-ат халкы да анынча фикер йөртми булса кирәк. Идарәдә эшләүче бик күп хатын-кызлар үзләре фатир чиратында торалар, толлар аңлашыла, ә күбесенен ирләре бар. Габделнур исә хатыны алган фатирда яшәүне күз алдына да китерә алмый. Ул Гөлзәриядән, син эшләгән җирдә фатир бирәләрме, дип, беркайчан да сораячак түгел. Шунлыктан, һичкемгә, һичнәрсәгә карамый, шушы идарәдә үз эшен дәвам итәргә мәҗбүр иде. Эт өрә бирер, бүре йөри бирер, дигән шикелле, берәүнен сүзенә карап кына ул хезмәт урынын, көйләнгән тормышын үзгәртергә җыенмады.

Беркөнне взнос түләргә кергәч, аны партия оешмасы секретаре туктатты:

— Ашыкма, — диде ул, ведомостьны бер якка этәреп, акчаны сейфка тыгып куйгач. — Октябрь бәйрәме житә, доклад әзерләргә кирәк. Мин узган ел үзем ясаган идем. Әзер текст бар барын, ләкин попугай кебек ел саен бер үк сүзләрне кабатлыйсым килми. Әле докладны кем ясыйсы хәл ителмәгән, шулай да баш өлешен һәм азагын әзерләү минем өстә. Син шуны әзерләп бирә алмассынмы?

— Ярар.

— Материал табарсынмы?

— Тырышырмын.

— Ә уртасын, идарәдәге хәлләрне, эшләрнең торышын үзем оештырырмын. Чөнки анда төрле бүлекләрдән, участоклардан мәгълүматлар җыярга кирәк. Килештекме?

— Әйе.

Габделнур, озын-озакка сузмыйча, Митрохинның йомышын үтәде, аның янына кадрлар бүлегенә керде.

— Булган бу, — диде партия оешмасы секретаре, текстны укып чыккач, аның калын иренле зур авызы тагы да киң булып җәелеп китте: — Рәхмәт.

Митрохинның Габделжановны үзенчә янә бер сынап-тикшереп каравы иде бу. Университет бетерү, диплом алу — яхшы нәрсә, билгеле. Ләкин әнә шул җыйган гыйлемне тормышта файдалана, кирәге чыкканда белемеңне куллана да белү — анысы иң мөһиме. Хәрби хезмәттә вакытта өлкән офицер Митрохин моны яшь лейтенантлар килгәч ачык күрә иде. Аларның училищеда белемне ничек үзләштерүләре, тормышка яраклаштырулары бик ачык чагыла иде. Дөресен әйтергә кирәк, партия оешмасы секретарена кичәге студентның доклад караламасы ошады. Хәер, ул аның диплом эше белән дә якынча таныш иде бит. Материаллар җыйганда, егет аның белән дә киңәш-табыш итте, файдасы да тиде шикелле. Митрохинның «киләчәктә бу кешене тиешенчә, белеменә бәрабәр эштә файдаланырга кирәк» дигән ышанычы бермә-бер артты.

Габделнурга кеше почмагында эш юк иде. Ул ни өйдә, ни ишегалдында, ни сарайда хуҗалар рөхсәтеннән башка нәрсәгәдер үзе башлап тотына алмый, хәтта диварга кадак та кага алмый иде. Үз куышы булса, әле тегесен, әле монысын караштырыр, нинди дә булса уңайлыклар тудыру хәстәрен күрер, хатынына җайлы булуны кайгыртыр иде. Эштәге, күптән гаилә корган өлкән хезмәттәшләренеке кебек дачасы да юк. Кыскасы, монда вакытны ни беләндер үткәрергә кирәк иде. Габделнур китап укырга һәвәсләнеп китте. Әлбәттә, аның укыган китаплары башлыча тарихка кагылышлы, ә Гөлзәриягә ул әдәби китап кыстырып кайта иде.

Беркөнне ул соң кайтты.

— Ашым суынды бит, — дип каршылады аны хатыны. — Нишләп соңга калдың?

— Ачуланмасаң, тагын кибеткә сугылдым әле, — диде Габделнур һәм кулындагы китапларны өстәлгә куйды. — Бусы — Барлас Камаловның яңа китабы.

— Ул җиңел яза, укуы рәхәт, бигрәк тә яшьләр турында күп яза.

— Монысы «Мөдир Саҗидә». Нурихан Фәттахныкы.

— Аны укыганым бар. Шәриф Хөсәеновның «Мәхәббәт сагышы»н да яратып укыган идем.

— Яхшы повесть.

— Әбәү, монысы бигрәк калын.

— Монысы сиңа кызык булмас, тем более русча, «Татары Среднего Поволжья и Приуралья».

— Әле һаман андыйларны укып туймагансың икән.

— Без бит университетта дөнья һәм рус тарихын гына өйрәндек. Үз халкыңны да белергә кирәк ләбаса. Укыган саен, күбрәк беләсең, үз халкыңа хөрмәт тә арта. Хөрмәт дигәннән, мин кайдадыр Наполеон сүзләрен укыган идем. Ул: «Татар милләте белән дус булырга кирәк. Бу — бөек халык», — дигән. Тевтон орденының бөек магистры да безнең бабайларга үзенең соклануын яшермәгән: «Алар, татарлар, ышанычлы, төпле кешеләр, тормышта башлаган эшләрен

ахырынача житкерәләр... Акыллы, көчле, гадәттән тыш чыдам һәм гаҗәеп саглам, барысын да — яманын да, яхшысын да алдан исәпләүче милләт». Сүзен-сүзгә, бәлки, төгәл әйтмәгәндер, ләкин төп фикере шулай.

— Фикер иясе, — диде өстәл тирәсендә мәш килгән хатыны, елмаеп, — бар инде, юын.

Юынып, кием алыштырып, хәләл җефете хәстәрләгән гади генә, әмма бик тәмле ризыкларны ашап-эчеп диванга утыргач, Габделнур, кулына кызыл тышлы калын китап алып караштырып чыкты. Хатынының вак-төяк эшләре беткәч, аны да үз янына дәште:

— Гөлзәрия, кил әле. Әнә борынгы әби-бабайларның киемен күрәсең киләме?

— Әбәү, күлмәкләре бигрәк озын икән, аяк йөзеннән, — диде Гөлзәрия, китаптагы рәсемгә карап. — Бу әбинең күлмәк итәге җирдән сөйрәлеп йөргәндер.

— Ә менә бу биттә шәһәр кызлары.

— Бай балаларыдыр инде, алтын чылбырлары нинди озын.

— Калфаклары матур, әйеме?

— Әйе. Үзләре дә.

— Юк, синнән дә чибәр түгелләр.

— И-и сине...

Габделнур хатынының кыйгач кара кашларына, янып торган бит очларына, чәкәндәге кукуруз орлыгы кебек тыгыз утырган, әмма ап-ак тешләренә, күпереп, үзенә ымсындырып торган алсу иреннәренә сокланып карады.

— Кая, үзенне бер пәп итим әле.

Гөлзәрия ишеккә күз салды:

— Хуҗалар килеп кермәсен...

...Укый башлаган китабының ахырына җитәрәк, Габделнур шундый юлларга тап булды: «В.И.Ленин, Отто Гетчаның «Рус Төркестаны» китабын укыганда, шуңа игътибар иткән: «...Казан татарларында 150 кешегә — 1 мәчет һәм 1 мулла, русларда 1500 жанга 1 рухани туры килә; татарларда 1 мәктәп — 100 жанга, православныйларда — 1500-3000 кешегә».

Габделнур моны үз авыллары мисалында да бик яхшы белә. Өч мәчет, һәр мәчет каршында мәдрәсә булган. Үз төбәкләрендә малайлар һәм кызлар өчен югарырак сыйныфлы аерым мәдрәсәләр булуын да ишеткәне бар иде. Язу танымаган кеше юк иде алар авылында. Егетнең әти-әнисе дә гарәпчә таный, латинча да укый белә, кириллицаны да чит итмиләр.

Аннары Габделнур киосктан алып кайткан газеталарны караштырды. Чир китә, гадәт китми дигәндәй, ул дөнья, ил-көн яңалыкларына колак салмыйча яши алмый иде. Аны Чаллыдагы автогигант төзелеше дә, Американың Вьетнамны бомбага тотуы да, атаклы хәрби истребительләр конструкторы Артём Микоянның үлеме дә кызыксындыра иде. Шуның өстенә әле спорт яңалыклары...

Кайчагында Габделнурга дөньякүләм, илкүләм вакыйгаларга, халык язмышына кагылышлы уй-фикерләрен Гөлзәриягә әйтүе мәзәк сыман да тоела. Тулай торакта яшәгәндә, алар егетләр белән нинди генә темаларга сөйләшмиләр иде! Вакыт-вакыт бәхәсләшеп тә алалар иде. Хәзер бит ул берүзе. Ә аның үзен борчыган, күңелендә генә йөрткән, хезмәтендә, күп кеше алдында, бәлки, кычкырып әйтергә ярамаган уй-фикерләрен кем беләндер уртаклашасы килә. Кызыкмы, әһәмиятлеме аның бу уйлары хатыны өчен? Ул кыз бала буларак та үзгә кеше, аннары, гелән генә авылга, әнисе хозурына кайтырга күнеккәнлектән, ире әйткәннәргә исе китәр микән? Көлмәсме? Һәрхәлдә, әлегә ул-бу сизелми, аның сүзләренә битарафлык күрсәткәне юк. Аңлый булса кирәк иренең халәтен.

Әллә, кем чанасына утырсаң, шунын жырын жырлыйсың, дип, ире белән бер дуэт тәшкил итмәсә дә, сирәк-мирәк сүз кыстыргалап, түзеп торамы? Үзе ул күбрәк эше, андагы хәлләр хакында сүз куерта. Габделнур эштәгене эштә калдыра, аныкы өйгә ияреп кайтмый.

Әйе, иренең элек үзе өчен ерак һәм ят булган уйлар уйлап яшәвенә Гөлзәрия башта бераз сәерсенсә дә, отыры ияләнә төште.

Ул кыз чагында авылда кошлар очканны күзәтергә ярата иде, бигрәк тә карлыгачларның кичке уенын. Алар бер-береләнең хәрәкәтен шулхәтле оста кабатлый ки, сокланып туймаслык. Ир белән хатын да шулай булырга тиештер, күрәсең. Ул ире белән шулай яши алырмы? Дөрес, тормыш уен түгел, ләкин тәңгәллек — бер уй, бер теләк белән тереклек итү, гомер кичү булырга тиештер, дип уйлый иде яшь хатын, «берлек барда тереклек бар» дигәннәр бит борынгылар.

Китап уку, бергәләшеп театрларга йөрү — рәхәт бер мизгелләр иде. Чөнки, кайткач, алар әле бик озак фикер алышалар: артистларның уенын, спектакльнең эчтәлеген, сәхнә һәм музыкаль бизәлешен энәсеннән җебенә кадәр күз уңыннан үткәрәләр. Кайчагында үзара бәхәс тә куба. Ләкин Габделнур хатынына һәрчак юл бирә, аның фикере белән эчтән килешмәсә дә, ярар, синенчә булсын, бәлки, син хаклыдыр, дип, эшне зурга җибәрми. Аңа, кайчандыр Алабугада режиссура фәнен Мәскәүдә театр институтын тәмамлаган укытучыдан өйрәнгән кешегә, спектакльнең теге яки бу уңышлары һәм кимчелекләре күренәрәк төшсә дә, низаглашасы килмичә, телен тыя иде.

Шулай итеп, Габделнур әнә теге күңел бушлыгын күпмедер күләмдә тутырды диярлек.

Шунын өстенә икесенә дә уртак бәхет насыйп булачагы беленде: Гөлзәрия балага узган иде. Ир белән хатын арасын тагы да якынайта торган яна чор — бәби көтү чоры башланды.

Әлеге куанычлы хәбәр Гөлзәрия тарафыннан кыз кешедән ана кеше булу чорына күчешне чагылдыручы эчке кичерешләргә бай олы вакыйга дип кабул ителсә, Габделнур исә әхлакый үзгәрүгә, бер-береңнең кадерен ныграк белергә, бер-берен хөрмәт итеп яшәргә юнәлгән янә бер этәргеч булды. Дөрес, егет кешедән кемнеңдер атасы булу процессы әле аңа таныш түгел иде. Яше белән Гөлзәриядән өлкәнрәк булса да, ул бу сөенечле хәбәрне шатланып кабул итсә дә, барыбер хатыны кебек бөтен барлыгы һәм тулылыгы белән кабул итә алмый иде әле. Хатыны, үзен һәрдаим сиздереп-белгертеп торачак ул сабыйны йөрәк астында йөртә бит (әле туганчы, тагын җиде ай буе йөртәчәк). Үзенең әти кеше икәнен аңлау иренә соңрак киләчәк.

Ләкин шулай булса да, әле аталык хисләре аны бөтенләе белән биләп алмаса да, Габделнур хәзер үзен Гөлзәриясе өчен генә түгел, ә аның карынындагы нарасый өчен дә җаваплы икәнен тоеп яши башлады.

...Алда максат юклыгын чагылдырган тойгы-кичерешләр, Габделнур идарәнең төзелеш комитеты рәисе итеп сайлангач, басылды, юкка чыкты. Чөнки монда инде ул идарәдәге эшләр өчен җаваплы кешеләрнең берсенә, күпчелек эшчеләргә һәм инженер-техник хезмәткәрләргә Габделнур Галләмовичка әверелде.

Тормыш — ул ярыштагы юртак кебек — алга таба чаба да чаба. Ләкин аның юлы тигез генә булмаска да мөмкин. Шуңа күрә Габделнурны, аның дуслары Ирек белән Хөрмәтне дә алда зур сынаулар көтүе ихтимал.



Рифат Җамал

# АГЫМНАРГА ЯТЫП АКМАДЫМ

***

Мин — көтүче!
Бар да дөнья көтә.
Бар да көтә нидер булса да.
Кемдер — караватта, күге — түшәм,
Кемнәр атлап чыга бусага.

Каз көтүе көтә, сыер-сарык...
Адәмнәрне жинел алдарга.
Мәйданнарда кайчак нидер көтә,
Ялгыз гына күккә ялвара.

Бар да сорый, бар да өметләнә,
Дөнья тулы бәхет көтүче.
Халык өчен димим, нигә сирәк
Бер ятимнең яшен сөртүче?!

***

Гомер елгасында
Баткан чаклар булды,
Тик шулай да
Агымнарга ятып акмадым.
Тормыш булгач
Төрле хәлләр булды,
Тик шун(ы)сы хак —
Сатылмадым һәм дә сатмадым.

Рифат ЖАМАЛ (1951) — *шагыйрь, ветеринария фәннәре докторы; Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. «Күңел суралэре», «Ташта үскән чәчәкләр», «Өзгәләнмә, күңел» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Алыштыралар Туган илне,
Модада алыштыру динне,
Алыштырып торалар ирне...
Инде тагын нәрсә диимме,
Оныттым ла әйтер сүземне.
Искә төште: Бик, бик теләсәң дә,
Алыштырып булмый үзеңне.

***

Бар да үтә, ләкин бар да
Онытылмый бөтенләй,
Әйтерсең лә, сүнгән учак
Акрын гына төтенли.

Ышанмасаң, яшьлегеңә
Син бер борылып кара.
Искә төшә яшьләй сөйгән.
Ябылмый татлы яра.

***

Куркыныч төш күреп уянгачтын,
Кеше җиңел сулый, шатлана.
Авырлыктан котылам, дип кемдер
Кыялардан түбән ташлана.

***

Бу дөнья кызык икән...
Син «дус» диеп йөргән кеше
Сине «дус» дия микән?!

***

*Алдагыларның хатасын*
*Кабатламасын яшьләр!*
Р.Мингалим

Кабатламас! Үз хатасы
Үзләре белән яшәр.

***

Әй зарлана! Зарларын да
Син ишет тә, мин ишет.
Зарлансам ишетмәсеннәр,
Куямын тимер ишек.

***

Карап торам: кайберәүләр
Яманлый үткәннәрне.
Инде нишлим, мин сагынам
Һаман да үпкәннәрне.

***

Кешелеккә бәхет даулый
Алладан, хакимнәрдән,
Тик кызгана үз тиенен
Мескеннән, ятимнәрдән.

***

Учактан ерак торсаң,
Тунар күзәнәкләрен.
Тик күп күрдем учакта
Янган күбәләкләрне.

***

Урыс баеса да ярый,
Хет кәчтүн кидерәләр.
Татарны, баймы, ярлымы,
Кәфендә индерәләр.

***

Кемдер урын били,
Кемне урын бизи,
Урындагы гына
Моны сизми.

***

Кәккүк тынды бик тиз. Унмы, унбиш...
Санаргамы әллә сонардым.
Монсу. Тукта, шун(ы)сын яшим әле,
Ә аннары... янә сорармын.

***

Иң матур чагы урманның
Көзләрен,
Әйтерсең лә Сабан туе
Төсләрнең.

## Яшерен мәхәббәт

Төшләремә керәсен дә
Кочаклыйсың, үбәсең.
Ә иртәсен яннарымнан
Мине күрми үтәсең.

***

Ничә еллар инде сине күрми,
Тыныч кына тып-тын яшим мин.
Бүген төштә синең белән йөрдем
Һәм аңладым — синсез ятим мин.



Гүзәл
Әдһәм

# МЕҢНӘРНЕҢ БЕРСЕ

БӘЯН

*Әлифба авторлары Рәмзия Вәлитова белән Сәләй Вәгыйзовның якты истәлегенә багышлыйм.*

Авыр таш җилкәсен изде, иңбашларын сытты. Каш-керфекләр аша үтеп, күзне ярып кергән тозлы тирне сыңар кулы белән сыпырасы, аның тәкатьсез ачыттыруыннан котыласы килеп китте. Мангаена үрелүе булды, таш, җилкәдән шуышып, өздән генә җиргә капланмады. Зиннур гарип кулы белән ташны тәненә тагын да ныграк кысты. «Юк! Төшерергә ярамый! Бер төшерәсең икән, җирдән алып, яңадан җилкәгә салулары — ай-һай...»

Алда — такыр басу. Ник бер агач, ник бер куак күзгә чалынсын. Зиннур моны болай да яхшы белә. Арча белән Наласа арасы — тугыз чакрым. Шул тугыз чакрымны йөз генә түгел, мең тапкыр җәяүләп үткәндер ул. Ә менә болай — җилкәгә таш салып узулары — монысы беренче тапкыр. Дөрес, таштан аның «бәхет»е мул булды. Башта ике ел буе — немец әсирлегендә, аннан биш ел — үзебезнекендә... Башы шул каһәр суккан таштан арына алмады. Җилкәләре дә инде таш авырлыгына әллә кайчан күнегеп беткән: җәрәхәтләр өсте-өстенә өстәлеп, яралары да әллә ничә рәт төзәлеп тупасланган, сөялләре дә кытыршыланып каткан аның.

Монысы шома, әмма шактый авыр таш. Кабер ташы... Әнисе каберенә...

Юл буенда ялгыз карама күренеп, шунда килеп җиткәч, кабер ташын иплән кенә җиргә шудырды ул. Карамага сөялеп, ташны яңадан иңбашына салу җаен ничек тә табар әле.

— Карамага кадәр — төгәл ике чакрым, — ди иде әнисе.

Димәк, авылга чаклы тагын җиде чакрым калган.

Зиннур юл читендәге үләнгә тәгәрәде...

...— Әни! Әни дим!

— Әү, балам!

— Бу караманы кем утырткан?

— Кем белсен инде аны. Мин белгәннән бирле үсә ул.

— Ай-яй, юан! Минем кочак кына житәрлек түгел. Моңа йөз яшь бардыр...

— Йөз генә булса... Өч йөз-дүрт йөз яшьлек карамалар да була.

— Дүрт йөз? Анысына синен кочак та житмидер, имә?

Әнисе елмаеп куйды.

— Әни, ә ул чакта безнең авыл булган микән?

— Менә анысын төгәл генә әйтә алмыйм, балам... Мөгаен, булгандыр... Булырга тиеш.

— Булгандыр?! Андагы кешеләр дә нәкъ безнең кебек булганмы?

Әнисе көлеп җибәрде:

— Безнең кебектер инде: ике куллы, ике аяклы!

— Безненчә сөйләшкәнме?

— Безненчә, билгеле.

— Ай-яй, кызык...

— Безнең зиратта бик борынгы бер таш бар. Биш гасырлык, диләр...

...Тр-р-р, бахбай!

Әнисенең мөлаем моңсу йөзе эреп юкка чыкты.

Зиннур сискәнеп сикереп торды. Аякларын асылындырып арбада утырган ир белән хатын, танырга тырышып, аңа төбәлгән иде.

Ир сап-сары тешләрен күрсәтеп шаркылдады.

— Әллә йоклап ятачың инде? Ай-яй чәп чир тапканчың. Тияреп бирчән, Налачага кадәр утыртып кайтам. Кая барыч чун?

— Наласага...

— Кем булачың чуң? Танымадым... Әйдә, үрмәлә...

Ә Зиннур аны шундук танып алды: «Хөсәен!»

«Ш», «з», «с»ларны әйтеп мәшәкатьләнми торган Хөсәен бар иде алар авылында. Зиннурның әнисе дә сакаулыгын бетерә алмады шуның, уку-язуга җиңел өйрәнсә дә, гомерлек сакау булды да калды.

Зиннур, кабер ташын алырга дип, түбән иелде:

— Минем йөгем дә бар...

— Булча чуң! Чал, әйдә! Арба барыбер буч ла, ат кына тартырлыктыр әле.

Зиннур, җиңел генә күтәреп, ташны арба читенә терәде.

— Рәхмәт, агайне. Ярый әле син очрадың, югыйсә...

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, Хөсәен шулчак Зиннурны танып алды. Тануы булды, җен ачуы белән ташка китереп тә типте:

— Әй, чин, придател!

Кабер ташы шапылдап юл тузанына капланды.

Ай-һай! Кеше хәтере — тишек иләк, дип, юкка гына әйтмиләр икән. Моннан унбиш еллар элек Балтай тавында чаңгы шуганда аягын имгәткәч, Зиннур Хөсәенне озын кыш буе, чанада тартып, мәктәпкә йөртте, ә язлар җиткәч, Зиннурның әнисе — укытучы: «Бала сыйныфташларыннан калмасын, наумиз булмасын!» — дип, аны һәркөн өенә барып укытып йөрде. Хәзер шул хатынның кабер ташы юл тузанында ауный.

— На-а-а, бахбай!

Арбага сыдырылган ярасын учы белән кысып, Зиннур авыртудан җиргә чүкте. Бармак арасыннан сытылып чыккан кан ташка чокып язылган хәрефләргә тамды. Бер тамчы, ике, өч... Башта бер хәрефне, аннан икенчесен кызартып, әнисе исемен кызылга манчыды: «Җ-ә-в-ә-һ-и-р-ә»...

...Әнисе Җәвәһирә исемле иде аның. Мондый матур исемле башка берәүне дә белмәде Зиннур. Тукта, тукта! Белә икән бит! Онытып җибәрүен күрче! 42нең салкын кышында окопларда җырлап, татар егетләрен атакага озаткан җырчы кызның исеме дә Җәвәһирә иде бит! Җәвәһирә Сәләхова!

Инде шактый китеп өлгергән арба шыгырдавын күмеп кычкыручы теге ирнең карлыккан авазы килеп ирешә:

— Чатлыкчан! Гитлир көтүчече!

Зиннур дәшмәде. Чөнки ул дәшә алмады. Бер Хөсәен генә түгел, авылдагы тагын бик күпләр аны шулай чит итеп каршы алды... Авыл әле сугыш афәтен онытмаган. Мөгаен, беркайчан онытмас. Мәңгегә... Яралары бик тирән шул авылның. Өч йөз йортлы Наласадан бу сугышта һәлак булучылар саны гына да ике йөзгә якын! Кайгы, афәт — йорт саен диярлек...

Әтисенең һәм Зариф абыйсының гомерләрен дә нәләт төшкән шушы сугыш өзгәнен Зиннур менә хәзер — сугыш бетеп, биш ел узгач кына белде. «Теге» җирләргә хат-хәбәрләр килеп ирешмәде шул...

Нинди гаилә иде бит! Әти-әнисе көне-төне мәктәптә булды. Зариф белән Зиннур да шунда үсте диярлек. Соңыннан, мәктәпне бетергәч, ике малай икесе дә бер-бер артлы Арча педучилищесына барып керде. Кырык бердә Зиннурның кулына да диплом тоттырдылар: Наласа мәктәбенә тарих укытучысы итеп билгеләделәр үзен. Тик укытулар гына насыйп булмады. Сугыш башланып, атна-ун көн дә узмагандыр, абыйсына да, үзенә дә военкоматка чакыру килеп төште. Ике туган бергә-бергә чыгып китсәләр дә, юллары Арчада ук аерылды. Станцада, вагоннарга төялергә торганда, әллә кайдан гына Зөбәрҗәт килеп чыкты.

— Зиннур!

Зиннур да, сакчы солдатлар да аның тавышын берьюлы ишетеп алды, барысы да аңа борылды.

— Назад!

Кызны, кысырыклап, егеткә якын җибәрмәделәр, әмма Зиннур аның сүзләрен аермачык ишетте:

— Хат яз, Зиннур! Мин сине көтәрмен!

Зөбәрҗәт ул чакта әле беренче курсны гына бетергән иде...

«Зөбәрҗәт! Эх! Зөбәрҗәт!»

Бу карама күпме хатирәләргә шаһит икән лә!

...— Зөбәрҗәт!

— Ә-ә-ә-ү...

— Зө-бәр-җә-ә-ә-әт!

— «Әү!» дим бит!

— Исемең бигрәк матур инде, гел кабатлап кына торасы килә...

Кызның иреннәреннән көмеш кыңгыраулар коелды:

— Ти-ле... каем...

Егет бәхетеннән күкнең җиденче катында иде. Әйтерсең, кызның сүзләре, кыңгырау чыңнарына уралып, «бәгърем!» дип челтерәде.

— Зөбәрҗәт исеме — авылда бер синдә генә! Педучилищеда да Зөбәрҗәт исемле бер кыз да юк! Син — берүзең!

— Әти Казаннан ишетеп кайткан да шул исемне куштырган...

— Зөбәрҗәт — ул «изумруд» дигәнне аңлата. Изумруд — бик кыйммәтле таш...

Кыз сокланып аңа төбәлде:

— Син әллә ниләр беләсең!

— Әллә ни дип инде... Педучилище китапханәсендәге бер сүзлектән карадым... Кыйммәтле асылташ дигән...

— Һе... Ә нинди төстә?

— Менә анысы язылмаган... Мөгаен, зәңгәрдер... Миңа шулай тоела... Синең күзләрең кебек...

Оялудан кызның битләре алсуланды, күзләренең зәңгәрлеге куе керфекләр күләгәсенә яшеренде.

Ялгыз карама төбенә янәшә утырдылар. Икесе дә шундый яшь, саф һәм

гөнаһсыз иде: ялгыш кына инбашлары тиеп киткәч тә, Зөбәржәт «дерт» итеп читкә тайпылды. Зиннур да гәүдәсен турайта төште.

— Менә бу карамадан безнең авылга чаклы — төп-төгәл җиде чакрым...

Аның әйтүе булды, кыз «ялт» кына сикереп тә торды:

— Сабантуйга соңга калмыйк тагын. Тагын җиде чакрым дисең бит...

— Ашыкма инде... Өлгерәбез лә...

Бераз гына сүзсез утырдылар. Икесенә дә рәхәт, бик рәхәт иде. Бу юлы Зөбәрҗәт сүзне үзе башлады.

— Син быел да көрәшкә чыгасыңмы?

— Чыкмый ни...

— Имгәнә күрмә... яме...

— Һи-и-и! Без күнеккән бит! Кечкенәдән көрәшеп үскән.

— Син шулайдыр да... Менә мин генә бер дә күнегә алмыйм. Узган ел да, син сыртың белән җиргә төшкәндә, кычкырып җибәргәнемне сизми дә калганмын... Кызлар көлде инде үземнән...

Зиннур да шатлыгыннан көлеп җибәргәнен сизми дә калды:

— Алайса... Алайса, сине куркытмас өчен, мин үзем бер дә егылмам! Бүтәннәрне генә чөярмен, яме...

— Мин риза... Сиңа әзерләгән бер бүләгем дә бар иде... Мин аны сиңа иртәгә бирермен, яме...

— Иртәгә тек иртәгә!

Егет белән кыз, сандалиларын селки-селки, янәшә китте. Табан эзләре, җылы юл тузанына бизәк ясап, тәртипсез тезелеп калды.

Ул чак — кырык бернең Сабантуй иртәсе иде.

* * *

Шәп көрәште ул көнне Зиннур. Әллә ни көч куймый гына, бер-бер артлы өч егетне чөйде дә атты. «Түбәтәй»гә дә ул беренче булып атлады.

Сабантуй мәйданы читендәге калкулыкны авылда шулай «Түбәтәй» дип йөртәләр иде. Берәр егет турында: «Түбәтәй»дә ял итте», — дисәләр, димәк, ул сиңа тегенди-мондый гына малай-шалай түгел инде: Сабантуйда үзе кебек өчәүне еккан, «каеш тоткан» көрәшче булып чыга. Көрәш кызган саен, «түбәтәй»дәгеләрнең дә саны арта бара. Болар инде үзләренчә бер горурлык һәм дулкынлану белән сабыр гына «каеш тоту»ны көтә.

Кырык бердә «түбәтәй»дә ял итү бәхете Наласаның сигез егетенә тәтегән иде: Шәрифҗан, Габделхак, Шакир, Исмәгыйль, Нәбиулла, Исхак, Нургали... һәм Зиннур... Барысы да ут уйнатып торган егерме-егерме биштәге егетләр. Ул арада, «каеш тоттырып», көрәшчеләрне парлап та куйдылар: Зиннурга Югары оч Шакир белән көрәшү насыйп икән. Шакир Зиннурга караганда өлкәнрәк, көрәш буенча да тәҗрибәлерәк егет иде. Бик күп көч, хәйлә, зирәклек кирәк булачак бу сынауда. Зиннур, шактый дулкынланып, үз чиратын көтте.

«Туры килүен күр әле! Кем белән диген, бүген аңа Шакир белән көрәшергә чыкты бит!»

Үзеннән дүрт-биш яшькә өлкәнрәк бу егетне Зиннур бик үк яратып бетерми иде. Сәбәбе, әлеге дә баягы, шул Зөбәрҗәткә барып тоташа. Имеш, Шакир: «Нигә өйләнмисең?» — диючеләргә: «Күнелем төшкән бер генә кыз бар! Зөбәрҗәтнең үсеп җиткәнен көтәм!» — дип җавап биргән ди. Кыз үзе бу сүзләрдән хәбәрдар булганмы, юкмы, ә менә Зиннурга исә аны сәгате-минуты белән китереп җиткергәннәр иде.

«Зөбәрҗәтнең үскәнен көтә, имеш!»

Бөтен йөрәге сулкылдап, җаны-тәне белән үртәлде ул чакта Зиннур.

Шакирның үзенә сиздерми генә, егетнең кояшта янган мускулларына карап-карап алды ул. Янарак кына сабан эшләре тәмамланган чак, авылның иң шәп тракторчысы Шакирның көн-төн басудан кайтып кермәве берәүгә дә сер түгел: йөзе дә кояшта янып, гел кара чутырга әйләнгән икән бу. Зиннур кебек, баш күтәрми, имтиханга әзерләнеп утырмаган шул.

...Әмма аларга көрәшүләр насыйп булмады. Сугыш хәбәрен ишетеп алган мәйдан, сыкрап-үксеп, елый-елый өйләренә таралышты. Халыкта Сабантуй кайгысы калмаган иде. Колга башындагы сөлгеләр дә, батырларны көтеп алалмый, нәүмиз җилфердәп калды...

...«Зөбәрҗәт» ...«Зөбәрҗәт»...

Йөрәк тагын кысылып куйды. Бугазына ниндидер бер төер бөялеп, бер мәлгә тынын буды. Авылга кайткач та булган очрашу тагын хәтердә яңарды.

...Зөбәрҗәт аны каберлеккә кергәндә куып тотты. Егетнең муенына сарылды да, бөтен гәүдәсе белән сыенып, шактый озак сүзсез торды. Зиннур баштарак аны танымады да, кем булыр бу дигәндәй, каушады да калды. Аннан, танып алгач, кочаргамы, читкә тибәрергәме белми аптырады. Кочаклар иде — ул инде күптән чит кеше хатынындыр, ә үзеннән этәрергә — ул бит Зөбәрҗәт!

— Мин синең зиратка киткәнеңне күреп калдым...

Зиннур кызның йөзен дә, күзләрен дә күрмәде. Аның кояшта уңган баш яулыгы егетнең нәкъ ияк төбендә иде. Бите белән аның күкрәгенә капланган, аерып алмасыннар дигәндәй, беләкләре белән чытырдатып кысып тынып калган кыз бөтен гәүдәсе белән дерелди иде. Күзне әллә нәрсә әчеттерде. Борынга күптән онытылган таныш ис — Зөбәрҗәтнең чәч исе килеп бәрелде. Юк, бәрелмәде, ә тынына уралды...

Шул ук ис... Әмма барысы да инде бүтән, һәммәсе — үзгә, чит... Зиннур үзе дә башка... Арада — тугыз ел... Арада — сугыш... Бөтен өмет-хыялларны чәлпәрәмә китереп, язмыш юлларын чуалткан әсирлек...

Зөбәрҗәт кисәк бөтен гәүдәсе белән алга томырылды:

— Әйдә!

Зиннур сүзсез генә аңа иярде.

Кыз, былтырдан калып кипкән үлән сабакларын ерып, алга атлады, аяк асты баскан саен «чытырт-чытырт» килде. Зиннур көчкә генә аңа ияреп өлгерде. Чардугансыз-ташсыз бер кабер янына житкәч, Зөбәрҗәт кинәт туктап калды.

— Менә монда...

Кабердәге яшь шомырт шактый күтәрелгән, буйга инде Зиннурның үзен дә узып китеп, ап-ак чәчәккә күмелгән иде. Әчкелтем хуш ис борынга тулды. Икесе дә, кабергә төбәлеп, шактый тын торды.

— Әни ничек...

«Үлде» сүзен әйтә алмый, тотлыгып калды Зиннур.

— ... яшәде?

Зөбәрҗәт бу сорауны көтә иде. Зиннур үзе кайткач, нәрсәләр сөйләячәген инде йөз-мең кат күңелдән исәпләгән иде...

...Кырык өченең урталарында, Зиннурдан хатлар килү тукталгач, Зөбәрҗәт ут эчендә калды. «Бәлки әнисенә хәбәре бардыр» дигән өмет белән, сәбәп тапкан булып, мәктәп тирәсен әллә ничә кат урады. Әмма укытучысы янына барып керергә кызның кыюлыгы житмәде, оялчан яшь күңеле, горурлыгын җиңеп, егет турында сорашып йөрергә батырчылык итмәде.

Җәвәһирә кыз янына үзе килде. Күзләр очрашуга, бар да аңлашылды: Зиннурдан ана да хәбәр юк иде.

Өч айлап вакыт шулай билгесезлектә узды. Арча военкоматыннан хәрби киемле бер кеше килеп төшкәндә, Җәвәһирәнең беренче сыйныфларда әлифба дәресе бара иде. Ягылмаган бүлмәдә бишмәт-шәлләргә төренеп утырган балаларга да игътибар итмичә, хәрби түргә үк узды. Җәвәһирәнең йөрәге «жу» итте, бөтен эче куырылып килде. Улы Зарифның кара хәбәре килүгә атна-ун көн дә тулмас борын, ире турында да җан өшеткеч хат алган хатын әле яна гына һушына килеп маташа иде. Зиннурның немецка плен төшкәнен ишеткәч, яшерен-батырын түгел, ул хәтта сөенеп тә куйды.

«Исән! Исән икән бит! Исәнлеге хак булсын! Түбән очның Лотфи картны да Герман сугышында әсирлектә булган дип сөйлиләр иде. Кайткан бит. Гомере авылда үтте. Сугышы булгач, әсирлеге дә булмый калмас инде! Минеке дә кайтыр, кайтыр, Алла боерса».

Курку-борчуга уралган шөбһәле шатлыгы озакка бармады: атна да үтмәгәндер, районга — мәгариф бүлегенә чакыртып алдылар үзен. Анда исә бик яхшылап аңлаттылар: «Улы сатлыкҗан булган кешенең совет балаларына белем бирергә хакы юк!» икән. Нәкъ менә шулай әйттеләр: «Сатлыкҗан!» — дип.

Җәвәһирә ышанмады. «Аның улы, аның Зиннуры сатлыкҗан була алмый! Монда ниндидер аңлашылмаучанлык килеп чыккан. Бераз көтәргә генә кирәк. Зиннурның да сатлык түгеллеге ачыкланыр».

Һәм ул көтә башлады. Бер атна, ике, өч атна көтте. Йокысыз төннәре белән айлар да үтеп китте. Алары исә елларга барып тоташты...

Мәктәптән үк кумадылар үзен. Педучилищеның соңгы курсында укып йөргән Зөбәрҗәтне укытучы итеп кайтардылар да Җәвәһирәне җыештыручы итеп калдырдылар. Кара төннән торып, мичкә ягарга дип, мәктәпкә йөгергәндә дә, буялмаган идәннәрне мунчалалап ышкый-ышкый юганда да ул бәхетсез түгел иде.

«Исән! Исән! Зиннур исән!» — дип ышкыды ул һәр сайгакны. «Килер бер көн — сугыш бетәр, аның улы да исән-сау кайтыр. Кайтыр, кайтмый калмас! Ул сатлыкҗан түгел!»

Бераздан ул мәктәптән дә артты: җыештыручы итеп башка хатынны билгеләделәр, Җәвәһирә исә колхоз эшенә йөри башлады...

Таныш-белешнең, күрше-күләннең куркуы көчле булды ахры: Җәвәһирәдән читләштеләр. «Улың сатлыкҗан!» — дип каһәрләүче, җаның телгәләүче булмады анысы, әмма элекке эчкерсез аралашулар бетте. Хатын үзенең хәвефле уйлары белән ялгыз калды. Дөрес, Зөбәрҗәт аны ташламады. Әле монысын, әле тегесен сорашкан булып, кичләрен Җәвәһирәгә еш килде ул. Аралар якынайды, ана белән кыздай, икесе бербөтен булып, Зиннурдан хәбәр көтте.

...Бер очрак бу якынлыкка да балта чапты. Шундый итеп чапты! Зөбәрҗәт калтырамый искә дә төшерә алмый аны.

— Кит! Бүтән килмә!

Шулай диде дә Җәвәһирә, кисәк борылып, өйалдына атлады ул чакта.

— Җәвәһирә апа! Син мине дөрес аңламадың! — дип иңәлгән кызның борын төбендә үк ишеген ябып, эчке яктан келәсен элде.

Зөбәрҗәт өнсез калды, елый-елый тәрәзәсен күпме шакыса да, Җәвәһирә ана бүтән ишек ачмады. Ана күңеле кызның сүзләрен гафу итмәде. Кичерә алмады... Юкса, Җәвәһирәгә яхшылык теләп әйтелгән сүзләр иде бит...

— Рәбига апаны үз эшенә педучилищега кире алганнар... Башта «сатлыкҗаннан ваз кичәм», дип райкомга хат язарга мәҗбүр иткәннәр... Ул чын күңелдән түгел, болай гына язган, билгеле... Бәлки, сез дә...

Зөбәрҗәт җөмләсен дә тәмамлый алмады, Җәвәһирә аны кисәк бүлде:

— Кит! Бүтән килмә!

Ишек кызның борын төбендә үк «дык» итеп ябылды...

Ике көн буе күзгә-башка күренмәгәч, Җәвәһирә янына күршеләре ишеген ватып керде. Катып үлмәле булып суынган өй тагын бер үлем турында җан өшеткеч хәбәр җиткерде...

...Соңгы курсны Зөбәрҗәт педучилищеда читтән торып укыды диярлек. Үз мәктәбенә эшкә кайтуга укытучылары каршы килмәде аның. Педсоветта шулай сөйләшенде: һәр дүшәмбедә, дәресләрен иртәрәк тәгәлләп, училищега килергә, атналык зачётын биреп кайтырга килешенде. Шул көннәрдә, җитмәсә, педучилище бинасында госпиталь ясап, училищены тагын да ераккарак — Үрнәккә үк күчереп куйдылар. Басу юлы буйлап Үрнәккә кадәр барып кайтулар — ай-һай! Бу инде сиңа Арча белән Наласа арасы гына түгел, егерме чакрымнан да артып китә! Ярый да, бәхетеңә, берәр атлы очрап утыртып куйса. Гел җәяүгә калган чакларда бигрәк яман. Мондый көннәрдә Зөбәрҗәт ничек кайтып егылганын үзе дә сизми иде. Әмма һәр дүшәмбедә, чаңгыларын киеп юлга чыкканда, аның кебек ашкынган берәү булды микән Наласада. Мөгаен, юктыр... Ничек ашкынмаска ди: кызны Үрнәктә атналык ипи паёгы көтә бит! Училищеда (рәхмәт төшкереләре!) аны шул паёктан сызмаганнар иде. Иң җайсыз ачлы-туклы көннәрдә әнә шул «кәртечке»гә тигән ипи эне-сеңелләренә никадәр юаныч булды. Ашханәгә кереп, үзенә тиешле ипине юл капчыгына салганда да, Зөбәрҗәт авызына бер валчык та капмый иде.

«Түзәргә, ничек тә түзәргә! Ипи ул шундый әйбер, бер кабасың икән, отыры ашыйсыны китереп кенә тора. Өйгә кайткач... бергәләп...» Ә өйдә аны дүрт пар күз көтә.

Бер баруында: «Инде эшләрем бетте, кайтырга чыксам да була», — дип торганда, завуч Ханипова аны беләгеннән тотты:

— Кая ашыгасың? Актлар залына — марш! Җыелышка, барыгыз да — җыелышка!

Җыелыш инде башланган, зал шыгрым тулы иде. Никтер, башка чактагы кебек яшьләрчә ыгы-зыгыны да сизмәде ул, никтер бар да үтә шыпырт булып, нәрсәдәндер уңайсызлангандай, башларын түбән иеп тынып калган иде. Инде көн дә кичкә авышып, бүлмәгә караңгылык иңеп өлгергәнгә, сәхнәдәге өстәл артына тезелешеп утыручыларның да йөзе-бите юньләп шәйләнми иде.

— ...Совет солдатлары гомерләрен аямыйча кан койганда... тылдагылар көнне төнгә ялгап, бөек җиңү өчен тир түккәндә...

Ниндидер хатын-кыз, кулын болгый-болгый, ачы тавыш белән шактый озак сөйләде.

Зөбәрҗәт бермәл сүзнең ни турында барганын төшенмичәрәк торды.

— ...Ватанга хыянәт иткән ул сатлыкҗаннарны җир өстеннән себереп түгәрбез... Бер-берегезгә ныгытып карагыз... Арагызда хыянәтчеләр юкмы?.. Ул да бит укытучы булып йөрде... Сизеп алып, шул чакта ук тотып атарга кирәк булган үзен!

Зөбәрҗәт кисәк калтыранып куырылып килде.

«Кем турында сөйли ул?»

Хатын шактый озак сөйләде, сүзләре, кызның тынын буып, бөтен гәүдәсен изде.

Кемдер өстәлгә лампа чыгарып куйды. Саргылт яктылык, шомлы күләгә булып, өстәл читендә утыручыларның да йөзенә кунды. Директор янәшәсенә таныш түгел тагын ике ир урнашкан икән. Хатын сүзен тәмамлауга, сәхнәдәгеләр башлап кул чапты, соңрак аларга залдагылар да сүлпән генә кушылды.

Өстәл янында күләгәдәй басып торган Рәбиганы Зөбәржәт шунда гына шәйләп алды. Күрүе булды, бөтен эче «жу» итеп китте. Рәбиганың төсе качкан, әле кайчан гына сокландыргыч төз булган зифа гәүдәсе бөтенләй бөкрәеп гарипләнеп калган, үзе, «менә авам-менә авам» дигәндәй, чайкалып-чайкалып куя иде.

Зөбәржәт дерт итте. Башында барысы да буталды, Зиннур, Җәвәһирә, Рәбига турындагы уйлар, барысы да бергә чуалып, чигәләрен дөмбәсләде.

— Нәрсә булган?

Янәшәдәге кыз анын колагына пышылдап өлгерде:

— Ире пленга бирелгән!

«Ире? Салих Гарифовичмы?!»

Зөбәржәтнең башына балта түтәсе белән китереп тондырдыылармыни. «Теге ямьсез тавышлы хатын Салих Гарифовичны пычраткан булып чыга түгелме соң? Кемне диген? Салих абыйны! Салих абый сатлыкжанмы?»

Рәбига белән Салихтан да матуррак пар дөньяда булды микән?! Икесе дә яшь, чибәр, югары белемле! Сугыш алдыннан гына институт бетереп укытырга кайтканнар иде. Училище яшьләренең гадәти тормышы үзгәрде дә куйды ул чакта. Ярты төнгә кадәр гөр килде училище. Рәбига оештырган драма түгәрәге «Беренче театр» белән башлады да ай саен бер спектакльне табадан төшереп кенә торды. Хан заманыннан калган киемнәр сандык төпләреннән актарылды, мунчала, сүс, ат кылларыннан сакал-мыек, чәчпариклар ясалды, грим өчен әллә никадәр буяу, майлар табылды. Әй күнелле чаклар! Тагын бер яналык барысын да шаккатырды: Салих абыйлары шагыйрь дә икән бит! Юка гына шигырь җыентыгы кулдан-кулга йөрде. Салихтан күреп, бөтен егет-кыз шигырь язарга тотынды. Әдәби кичәләр атна саен шаулап үтә, һәркем узыша-узыша шигырь, хикәя укый. Әле, җитмәсә, кайберәүләрнең язмалары өлкә газетасында да басылып чыккан! Ул Салих абыйлары ничек өлгерә диген, һәрберсен тикшерергә вакытын таба, киңәшен бирә, ярдәмен кызганмый.

— Безнең Салих абый...

— Безнең Рәбига апа!

Кызлар, Рәбигага охшарга тырышып, анынча итеп чәч үрергә, билләренә тар гына күн каеш буып йөрергә күнекте, ә малайлыктан чыгып җитмәгән үсмерләр, тарак күрмәгән тыңлаусыз чәчләрен Салих абыйларыныкы кебек артка чөеп җибәрергә гадәтләнделәр.

...«Училище күрке булган Салих абый пленга төшкән ди! Нәкъ Зиннур кебек!»

Зөбәржәтнең бөтен башы шаулады, йөрәге күкрәктән чыгарлык булып дөпелдәде. Ана кинәт эссе, бик эссе булып китте. Кыз, изүен чишмәкче булып, бишмәт якасына ябышты, сәдәфләренең әле берсен, әле икенчесен тарткалады.

«Рәбига апасы да шуны ук кичергән икән! Нәкъ Җәвәһирә апа кебек!»

Бермәл залдагылар бар да тып-тын калды. Нинди дер куркыныч, шомлы тынлык иде бу. Шулчак сәхнә ягыннан кемнеңдер ишетелер-ишетелмәс хәлсез авазы килеп ирешт е:

— Мин аннан... Мин аннан... ваз кичәм...

Зөбәржәт дерт итте.

«Кем тавышы соң бу? Бик таныш та, шул ук вакытта ят та аваз!»

Активист хатынның яшелле-кызыллы итеп кычкыруы кызның шикләрен дә, залдагы тынлыкны да чәлпәрәмә китерде:

— Кычкырып әйт! Бөтен кеше ишетерлек булсын! «Мин хыянәтчедән

ваз кичәм!» — диген! Йә! Ник дәшмисең? Кабатла! Ваз кичәм, диген! Әйт! Кычкырып әйт!

Теге мескен авазның Рәбига апаныкы булу мөмкинлегеннән өркеп, Зөбәрҗәт калтырап куйды, күзләре белән укытучысының сәхнәдәге шәүләсен эзләп тапты.

Шәүлә дә, тавыш та, сүзләре дә Рәбиганыкына охшамаган, чит-ят иде:

— Ваз кичәм...

...Зал тынсыз-өнсез генә тарала башлады. Сәхнәдәге лампаны да кайсыдыр үзе белән алды ахры, бөтен дөньяны шыксыз караңгылык басты. Залдагылар, шуннан качарга теләгәндәй, коридорның теге башында шәйләнгән яктылыкка ашыкты. Берәү дә көлми, сөйләшми, аяк тавышлары гына:

— Шшыш-чышш... Шшыш-чышш...

Бишмәт сәдәфе өзелүен хәтерендә яңарып, Зөбәрҗәт идәнгә чүкте. Тизрәк сәдәфен табып аласы да бу куркыныч бүлмәдән котыласы, караңгылыгыннан арынасы килеп китте, ашыга-кабалана идән сайгагын кармалады. Бармаклары нииндидер юеш лайлага тигәч кенә, кызый, чирканып, кулын тартып алды. «Кирәге юк сәдәфенең дә!»

Зал ишегенә килеп җитәм дигәндә, бик якында, янәшәдә генә ишетелгән сәер ым Зөбәрҗәтне кисәк туктарга мәҗбүр итте. Юк, ул бу ымны ишетмәде, ә тәэсирләнүчән вөҗүде, барлык күзәнәкләре белән сизеп алып, сәхнә чаршавына сыенган күләгәгә таба омтылды.

— Рәбига апа...

Күләгә үксү катыш ыңгырашып җавап кайтарды.

— А-а-а-hhh!

Зөбәрҗәт укытучысының калтыравык хәлсез гәүдәсен кочып алды...

* * *

Рәбига йоклап киткәч тә, шактый озак уяу ятты әле Зөбәрҗәт.

«Өйдәгеләр аның бүген кайтмавы турында ни уйлый икән? Әллә ни борчылмаслар анысы. «Соңарсаң, кунып кал!» — дип, кат-кат кабатлады ла әнисе. Яктыра башлау белән юлга чыкса, дәресләренә кайтып житешә әле ул».

Рәбига апасын бүлмәсенә кадәр озатып куярга гына теләгән иде дә, әмма укытучысының уттай янган кайнар кулына кагылгач, әллә нишләп китте.

— Рәбига апа, сез авырыйсыз бугай!

Рәбига дәшмәде, өстерәлеп диярлек, аның белән янәшә атлады.

Тулай торакка житәрәк, Рәбига бөтенләй хәлсезләнде. Әле ярый Зөбәрҗәт аны биленнән кочып алырга өлгерде, югыйсә, укытучы апасының башы белән карга төртелүе дә бар иде.

— Мин хәзер монда яшәмим... Тулай торактан кудылар бит, — дип, пышылдады Рәбига.

Зөбәрҗәт «дерт» итте.

— Ничек кудылар? Ә кызыгыз кайда?

— Нәфисә апада... Ул сыендырды...

Алар урамның теге башына кадәр шулай атладылар әле. Нәфисә карчыкның мунча кебек кечкенә өе шактый жылы иде. Килеп керүгә, нәни Сания әнисенең итәгенә сарылды:

— Әни, мәм-мәм...

Нәфисә карчык шул сабыйны ашатырга берни булмаудан уңайсызлангандай, авыз эченнән генә зарланып та алды:

— Юк шул, балам... Бер телем дә ипи калмады шул...

Аннары кемнәрнедер сүгә башлады:

— Жыен дивана... Баланын ни гаебе бар ди...

Рәбига сабыенын башыннан сыйпады:

— Иртәгә, балам, ипине иртәгә бирәләр...

Зөбәржәт шунда гына, Рәбига эштән куылгач, ипи карточкасыннан сызылган бу ике жаннын инде атна буе ач булуын абайлап алды. Ул, ашыгып, капчыгына үрелде. Нәни кызчык кара ипигә ике куллап ябышты:

— Мәм-мәм...

...Сабый да, карчык да йокыга киткәч, Рәбига белән Зөбәржәт тә, урын табып, такта сәкегә сыенды. Зөбәржәт шактый вакыт йоклый алмый ятты, шулай да укытучы апасын уятудан куркып, селкенергә дә базмады.

«Йокласын әйдә. Аз булса да кайгылары онытылып торыр...»

Кинәт ул шушы кечкенә генә йортның иске диварларына эленгән карангылык пәрдәсе аша Рәбиганың елмаеп ятуын сизеп алды.

Шулчак Рәбига бу икәү генә ишетерлек итеп пышылдап та куйды:

— Мин аларны алдадым...

Зөбәржәт «ялт» аңа борылды:

— Кемне?

— Аларны... Барысын да... Юләрләр! Мин Салихтан ваз кичә аламмы инде? Ә алар шуңа ышанды... Бөтен өметем, ышанычым — Салих... Ул мине һәрвакыт аңлый иде... Бу юлы да аңлар...

Зөбәржәт шатлыгыннан апасын кочып алды. Рәбиганы юатасы, күңелен күтәрәсе килү теләге шундый зур иде!

— Аңлый, билгеле! Аңлый! Ул бит — Салих абый!

Аларның йокысын урлаган төн шактый озын иде әле...

— ... Әти-әнине бөтенләй хәтерләмим диярлек. Институтка кергәнче, гомерем детдомда үтте... Зарланмыйм: детдом үз йортым кебек булды. Аннан соңгы тормышым Салих белән бәйле. Ул институтны миннән алданрак бетерде, гел бишлегә генә. Аннары — аспирантура... Фәнни эшен дә төгәлләп килә иде инде, тик... Йә ярар, анысын бөрәр вакыт сөйләрмен әле... Мине Салихтан ваз кичте дип юансыннар... Тиләләр...

Аннан соң ул кинәт елый башлады, үкси-үкси бик озак елады. Аларның Рәбига апасы...

...Боларның барысын да Зөбәржәт Зиннурга зират буенда сөйләде. Сөйләп бетерде дә, гаепле кешедәй, аңа төбәлде.

Егеткә кызның күзләре элекке зәңгәрлеген җуйган, ничектер, тоныкланып, төссезләнеп калган күк тоелып китте. Шулай да ул күзләр шундый якын һәм үз иде...

...Зиннур кабер ташын теге шомырт төбенә ялгызы гына урнаштырды. Авыртудан сулык-сулык килгән гарип кулы белән сыпырып-сыйпап, әти-әнисе һәм Зариф абыйсы турында хатирәләргә бирелеп, шактый озак басып торды әле...

***

Зиннур турындагы хәбәр Зөбәржәткә узган ел ук килеп ирешкән иде.

Барысы да шундый көтмәгәндә булды. Арчада укытучылар семинарында Рәбиганы очраткач, Зөбәржәт аны күреп шаккатты: укытучы апасы бик тә, бик тә үзгәргән иде. Теге вакыйгадан соң күзгә күренеп олыгайган, йөзләре сулып, күзләре тоныкланып калган хатын — бүген бөтенләй башка кеше диярсең. Тагын да ябыгып китүенә карамастан, иреннәренә ниндидер серле елмаю элгенгән Рәбига искиткеч гүзәл тоелды аңа. Әле тормышлар һаман да рәтләнмәгән чакта,

туйганчы ашарлык ипи чырае күрмәгән заманда, шундый чибәр, бәхетле тол хатынны күрү — әллә ничек сәер дә һәм шикле дә иде.

Рәбига никтер аны күрмәмешкә салынды, сәламен дә алмыйча, очрашканда да күзләрен читкә борды. Шулай да Зөбәрҗәтнең кулына сизелер-сизелмәс орынып:

— Аулакта сөйләшәсе бар! — дип пышылдарга өлгерде.

Шулай туры килде инде: очрашып сөйләшергә һаман да җай чыкмады. Зөбәрҗәтнең янарак кына килен булган, бәбәйдән котылган чагы, житмәсә яңа уку елы башланып китте, ана тагын бәрәңге алу мәшәкатьләре килеп өстәлде. Рәбиганың теге чактагы серле пышылдавы, күнел түренә оялап, үзен гел сиздереп, каядыр ымсындырып торса да, күрешеп сөйләшү мөмкинлеге генә табылмады.

Бервакыт дәресләр тәмамланып, кайтырга дип торганда, Рәбига үзе мәктәпкә килеп керде.

— Бертөркем студент белән колхозга бәрәңге алырга килдек. Әбәт вакытыннан файдаланып, сезнең дә хәлегезне белеп чыгарга булдым, — диде ул директорга.

Шунда ук йомышын да сөйләп китте:

— Дүрт студентны педпрактикага сезгә җибәрергә планлаштырып торабыз. Кабул итәрсез бит?

Роно житәкчелегенең педучилище укытучыларын мәктәпкә тикшерү-мазар белән җибәрү гадәте бар иде. Рәбиганың менә шулай көтмәгәндә-уйламаганда килеп керүе директорны шактый пошаманга калдырып өлгергән иде. Сүзнең педпрактика турында баруын төшенеп алгач, ул да җиңел сулап куйды.

— Әлбәттә, әлбәттә... Нинди каршылык булсын ди... Көтәбез, рәхим итегез! — дип сөйләнеп алды. — Кстати, менә Зөбәрҗәт — үзегезнең кадр, икенче сыйныфта укыта...

Рәбига, яңа гына күргәндәй елмаеп, Зөбәрҗәткә төбәлде:

— Шулаймыни? Икенче сыйныфтамы? Әйбәт, әйбәт... Мөмкин булса, миңа сыйныф бүлмәгезне күрсәт әле, Зөбәрҗәт.

— Нишләп мөмкин булмасын ди! — директор ашыга-кабалана алдан атлады.

Рәбига гаепле кешедәй кызарынды:

— Сезне һич борчыйсым килмәгән иде, зинһар, мәшәкатьләнмәгез! Менә Зөбәрҗәт үзе күрсәтер...

...Ниһаять, алар икәү генә калды!

Рәбига житез генә ишекне япты да шактый дулкынланган тавыш белән тезеп китте:

— Сөйлисе сүзләрем шундый күп — каян башларга да белмим! Кыскасы, мин Салих белән күрештем!

— Ул кайттымыни?

— Кайтуын кайтмады, әмма ул исән!

— Исән!

— Исән шул, исән! Җәен мин Салихтан хат алган идем, Печора лагереннан. Аны, әсирлектә булган өчен, шунда сөргәннәр икән. Ана хат язарга да рөхсәт иткәннәр. Менә шул! Отпускымны алдым да Печорага киттем.

— Рәбига апа! Күрештегезме?

— Ике тапкыр!

Дулкынланудан Рәбиганың бөтен гәүдәсе калтырап, куллары дер-дер килә иде:

— Ишетәсенме? Без ике тапкыр күрештек! Берсендә — ун минутка гына рөхсәт бирделәр. Аннары — бер көн, бер төн буе бергә булдык! Шундагы бер сакчыга акча биреп...

— Шулай да буламы? Ә кайчан кайтачак?

— Ун ел биргәннәр...

— Ун ел?

Зөбәрҗәтнең башы әйләнеп китте: «Ун ел ди бит!»

Ә Рәбига шундый шат: менә-менә сикергәләп биеп китәр кебек. Ул Зөбәрҗәтне инбашларыннан эләктереп алды да зыр-зыр әйләндерә дә башлады.

— Тилекәем, ничек шуны анламыйсың? Ул — исән! Тагын алты елдан кайтып та житәчәк! Без аны өчәүләп көтәрбез!

«Нигә өчәүләп?»

Шулай дип уйлады да, онытты да Зөбәрҗәт.

Кинәт икесе дә берьюлы елап жибәрде...

Бер-берсенә сыенышып, тып-тын гына яшь түкте алар. Бераздан Рәбига тиз-тиз яшьләрен сөртте.

— Сина да хәбәрем бар: Зиннур турында...

Зөбәрҗәт бу көтелмәгән яналыктан әздән генә артына авып китмәде, шаккатып укытучысына төбәлде.

— Синең авылдашыңны әйтәм, Зиннурны! Әллә оныттыңмы? Ул да лагерьда, ди. Салих белән бергә...

Зөбәрҗәт шунда гына аңына килде:

— Зиннур шунда? Ул да исән?

— Шунда, Печорада! Аңа рөхсәт бирмәгәннәр, хат язарга... Шуңа исәнлеген дә хәбәр итә алмаган.

— Ул да ...ун елгамы?

— Түгел! Биш кенә ел! Инде кайтыр чагы житеп килә, ди!

...Зөбәрҗәтнең төн йокысы качты. Салих белән Рәбига вакыйгасы, шуларга Зиннур турында хәбәр дә өстәлеп, бөтен уйларын чуалтып, хатынның башын бутап ташлады.

«Зиннур кайтачак! Ул исән! Тиздән кайтачак, ди!»

Ә ул аны ничек көткән иде! Сугыш тәмамланып, исәннәр инде кайтып беткәч тә, өметен жуймыйча көтте. «Мәнге шулай көтәрмен дә барыбер көтеп житкерермен», — дип хыялланган иде. Сигез елдан артык бер хаты-хәбәре булмаган кешене гомер буе көтәргә дә риза иде Зөбәрҗәт. Тик кайтсын гына! Кайтуы гына хак булсын!

Әллә ничек кенә булды шунда...

Узган ел печән өстендә кишәрлекләре Шакир белән бер тирәгә туры килде аларның. Ял итәргә тукталгач, Шакирның титаклап елгага таба китүен дә искәреп калган иде югыйсә. Бит-кулны юарга дип инешкә юнәлгәч, ирнең өстенә үк килеп чыгармын дип башына да китермәде Зөбәрҗәт. Шакир әллә ничек бик җайсыз итеп жиргә утырган да яралы аягын ниндидер пычрак чүпрәк белән урап маташа икән. Кызыл кан таплары белән чуарланган агач аяк исә янәшәдә генә аунап ята. Зөбәрҗәтнең йөрәге авырттырып кысылып куйды, ул, башындагы яулыгын салып, чиләнеп торган канлы «чукмар баш»ны шул ак яулыкка төрде...

— Бик авыртамы?

— Иялэндем инде...

...Болыннан кайтканда, ат арбасында урыннары да янәшә туры килде.

Шакир кызга назлы сүзләр дә пышылдамады, «яратам», дип тә әйтмәде, Зөбәрҗәт үзе дә андый сүзләрне көтми иде. Барысы да бик гади, артык гади

булды: кичен әти-әнисенең ризалыгын алдылар да иртән, туйсыз-нисез генә килен төшерделәр. Ел дигәндә, кызлары туды. Зиннур турындагы хатирәләр бик-бик тирәнгә яшерелеп, Зөбәрҗәт үзе дә инде, язмышына буйсынып, шуңа ияләшеп, «шулай тиештер» дип, яшәп яткан көннәре иде...

* * *

Арчага җыелышка киткән җиреннән Шакиры сүгенеп кайтып керде.

— Ни чыкса, шул укытучы халкыннан чыга инде. Адәм страмы...

Шакирның укытучылар белән «тел чайкарга» яратуын, эчтән генә аларга үч саклавын Зөбәрҗәт күптән белә иде. Хатын дәшми-тынмый үз эшендә булды.

— Бөтен райкум шаулый анда! «Рәбига апа!» дип, бик авыз суыңны корыта иден... Әнә — булдырган, уйнаштан корсак тутырган!

Зөбәрҗәт «дерт» итте.

«Булмас! Мөмкин түгел! Рәбига апа бит ул!»

Иренә каршы дәшмәкче булып, үз гомерендә беренче тапкыр авызын ачты... Ачты да, лып итеп, сәке читенә утырды.

«Без аны өчәүләп күтәрбез!»

«Шулай диде бит! «Өчәүләп күтәрбез!» — диде Рәбига апасы. Менә нигә шундый серле һәм бәхетле тоелган икән ул!»

— Шакшы гайбәтең белән пычратма Рәбига апаны! Аның ире бар! Печора лагеренда Салих абый белән очрашкан бит ул!

...Әллә инде Шакир райкомга барып чакты, әллә башка юллар белән Рәбиганың сере фаш ителде: күп тә үтмәде, «Сатлыкҗан ире белән очрашу өчен Печорага барган Арча педучилищесы укытучысы Рәбига Вәлиеваның эштән чыгарылуы» турындагы хәбәр район газетасында басылып та чыкты.

...Рәбига инде ул чакта нәни улын сөя иде...

* * *

Алдагы тормышын әле төгәл генә күз алдына китерә алмый иде Зиннур. Наласага кайтканда, ниндидер өмет-ышаныч кебек нәрсәләр күңелдә житәрлек булып, күрешеп очрашасы кешеләр дә шактыйдыр тоелган иде. Бик күпләрне югалткан икән шул. Ашкынып кайткан иде югыйсә, ә авылда аны кырыс ялгызлык көтеп алды.

Туган нигездәге йорт та шактый искереп, таушалып беткән, шулай да торырга яраксыз ук дип әйтеп булмый үзен. Идән-түшәм сайгаклары да урынында булып, ни гаҗәп, тәрәзә пыялалары барысы да төзек иде бу ялгыз йортның. Дөрес, капка-койма дигәннәрнең инде эзе дә юк, йортка терәп салынган абзар-кура да күптән җимерелгәнгә охшый, такта-тукталары таралып бетеп, кайбер бүрәнәләре генә тегендә-монда тәгәрәп ята. Корыган алабута, тигәнәк ботаклары тырпаешып торган ишегалдын ялт итеп җыештырып чыгаргач, өй тирәсе дә шактый ямьләнеп, күркәмләнеп китте.

Бүген авылда Сабантуй иртәсе. Кояшы да әллә ничек монсу гына күтәрелеп, талгын гына җил исеп куйды. Хатирәләргә уралган моңсулык ирнең керфек очларына эленеп, күңел дингезенә «менә тамам!», «менә тамам!» дигән бер мәлдә, ул житез генә кузгалды да Сабантуй мәйданына юл алды.

Көрәшнең иң кызган чагына килеп житеште ул. Мәйдан тирәли тезелешеп утырган хатын-кыз, бала-чага гөж килеп, тирә-юнь аларның көлгән, чырылдаган авазлары белән тулган иде. Тик Сабантуй мәйданына нидер житми кебек. Нәрсә соң бу? Югыйсә, барысы да гадәттәгечә шикелле: чиккән сөлге, яулык ише

бүләкләр бәйләнгән колга да элекке урынында җилферди, түгәрәк ясап, күңел ачкан яшь-җилкенчәк тә гармунга кушылып җыр суза:

Наласаның күлләрендә
Тезелеп йөзә аккошлар,
Үсеп җиткәч, чит җирләрдә
Йөртә безне язмышлар...

Зиннурга аңлашылмаган ниндидер үзгә бер сәерлек бөтен тирә-юньне сарып алган да, мәйданга төбәлгән хатын-кызның моңсу карашына эленеп, сабый балалар чыркылдавына да сыланырга җай эзли сыман. Зиннур кинәт шул сәерлекне төшенү шөбһәсеннән җыерылып калтырап куйды. Мәйдандагы ир-ат халкы бармак белән генә санарлык, бик аз калган икән бит! Үз ишләре-чордашлары булмау аны шулай тетрәндереп, күңелен шомландырып җибәргән ләбаса!

Нинди авыл иде бит! Кырык бернең Сабан туенда «түбәтәй»дә ял итү» бәхетен сигез Наласа егете татыган иде! Шәрифҗан, Габделхак, Шакир, Исмәгыйль, Нәбиулла, Исхак, Нургали һәм Зиннур... Бүген әнә каршы ярда агач аягын сузып утырган Шакирның кырыс чырае мәйданга төбәлгән дә, Зиннур үзе, гарип кулын күкрәгенә кысып, сүзсез генә көрәшчеләрне күзли. Икесе дә мәйдан тотасы ирләр иде лә!

Шәрифҗан, Габделхак, Исмәгыйль, Нәбиулла, Исхак, Нургалиләр! Сез кайда? Башын салган миллионнарның берсе булып, Европаның кайсы илләрендә ятып калдыгыз сез?

Теге сәерлектән йөрәк сулкылдый, сулыш алу җайсызланып, күкрәк кысылып куя. Тизрәк, тизрәк котыласы иде шуннан. Котыласы да, теге бөтен читенлекләрдән арынып, күкрәкне тутырып сулыш аласы иде. Әллә кайларга, ерак-еракларга ишетелерлек итеп кычкырып җибәрәсе килеп китте:

— Эһе-е-е-һе-һе-е-е-е-й! Нургали, Исхак, Нәбиуллалар! Бил алырга — мәйданга чыгыгыз!

...Әнә «түбәтәй»дә егетләр ял итә. Берәү, икәү, өчәү... ... ... тугыз, унау! Барысы да яшь, көчле, житезләр... Дөрес, күбесе әле гәүдәгә юкарак та сыман, ә күзләргә никадәр дәрт-дәрман сыйган!

Зиннур житез генә кузгалды да мәйданнан читкә атлады. Каршы яктан үзен күзләүче ике пар күзне ул күрми дә калды сымак. Зөбәрҗәт нәни кызын Шакирга тоттырды, иренең йөзенә төбәлеп, тиз-тиз генә нидер әйтте кебек. Тегесе исә, ризалыгын белдереп, теләр-теләмәс баш кагып куйды.

Зөбәрҗәт Зиннурны авылдан чыкканда куып тотты.

— Әллә китәсең?

Зиннур ни дияргә белми тынып калды.

Ә Зөбәрҗәт исә ашыга-кабалана әйтеп калырга теләде сыман:

— Авылдашларга рәнжеп китеп баруыңмы? Китмә, кал, Зиннур! Авылның хәтере артык кырыс кебек тоелса да, күңеле шундый киң аның...

— Хуш...

Зиннур инде берничә адым атларга да өлгергән иде, Зөбәрҗәт аны тагын дәшеп туктатты:

— Бу — синеке! Ал! Тагын онытуым бар...

...Ялгыз карамага җиткәндә, Зөбәрҗәт биргән йомшак төенчектән кызның кул җылысы да сүрелеп өлгермәгән иде әле. Әллә нигә Зиннур аны чишеп карыйсы итте... Төенчек сүтелеп китте дә киндер сөлге рәвешенә кереп сузыла бирде... Нәфис чигешләр, күк чәчәкләр, ромашкалар тезелеп киткән зәңгәр хәрефләргә уралды...

## ХАЛЫКЛАР АРАСЫНДА ОЯТКА КАЛМЫЙК ИНДЕ!

**Менә Халыкара мөселман киносы җыенының унберенчесе дә шаулап узды. Чит ил киночылары олы-олы бүләкләр алып китте. Быел Татарстан киночыларына да ару гына өлеш чыкты, шөкер. Актёр Илдус Габдрахманов «Ир кеше ролен иң яхшы башкаручыга» дигән бүләкне алды, Салават Юзеевның «Ишекне каты ябып чыгып киттем» фильмы «кыска метражлы фильмнарның иң яхшысы» дип табылды. Фәрит Дәүләтшинның «Рудик» фильмы «Тюрксой»ның махсус бүләгенә лаек булды. Димәк, әкрен булса да, уяна башладык.**

**Узган елгы кино җыенында Кырым татарларының «Кайтарма» фильмы җаннарны тетрәтте, чөнки ул фильм Кырым татарларының кара язмышы, фаҗигасе турында иде.**

**Без бит кайчандыр Урта Азия халыкларының кино сәнгате башында торган, урыстан кала иң беренче нәфис фильмнар төшергән халык: утызынчы еллар башында ук «Койрыклы йолдыз» (1926), «Булат батыр» (1927), «Рабат шакаллары» (1928) кебек фильмнарда татар артистлары башлап йөргәннәр. Казакълар, үзбәкләр, кыргызлар, таҗиклар кино өлкәсендә татарларны куып җитеп, узып китте менә.**

**Кино мәйданында аерым уңышлар булгаласа да, башка халыкларны шаккатырырлык татар фильмы әлегә төшерелмәгән. «Татар фильмы» дигәннән, нәрсә соң ул «татар фильмы», ул татар телле фильм булырга тиешме, әллә татарлар турында урысча фильммы? Урысча төшерелеп тә татарчага күчерелгән тасмамы? Документаль фильмнарның урысча булуы ярый. Ул чакта да фильмның татарча нөсхәсе булырга тиеш. Ә менә нәфис фильмның татарча булуы зарур. Татарча аңламаган тамашачыга аскы язулы фильм яки тулысы белән урысчага тәрҗемә (дубляж), яки диктор тавышы белән тәрҗемәдә булырга тиеш.**

**Фильмнарның атамалары кем тарафыннан татарчага күчерелә торгандыр, белмим, әмма ел саен тәрҗемә ителә торган атамаларда хаталар тулып ята. Тәрҗемәче фильмнарны карамыйча, атаманың мәгънәсенә төшмичә, турыдан-туры гына тәрҗемә итә кебек. Республикабызда Фәннәр академиясе, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Язучылар берлеге, Журналистлар берлеге була торып, без бөтен халыкларга үз наданлыгыбызны чыгарып салабыз. Озын сүзнең кыскасы, «Халыкара мөселман киносы җыены»н оештыручылар тәрҗемәчеләрне җентекләп сайласыннар, абруйлы тел белгечләре белән киңәшеп гамәл кылсыннар иде.**

**Гомумән, Татарстанда уздырыла торган фестивальләрдә, съездларда, слётларда, форумнарда, конференцияләрдә Ана телебез (дәүләт теле саналса да) сирәк кулланыла, кулланылган очракта да корама тел, чит-ят сүзләр белән чуарланып кына яңгырый килә. Гәрчә «фестиваль, съезд, слёт, форум, конференция» сүзләрен дә тирән мәгънәле ике татар сүзе «җыен, корылтай» белән алмаштырып булыр иде. Шулай язсак, шулай сөйләсәк, безне кем ачуланыр иде икән?**

**Рабит БАТУЛЛА**

«Сабантуй батырына! 1941 ел».

Наласаның инеш-күлләрен, болын-яланнарын үзенә сыйдыра алган бу гаҗәеп манзара әллә инде сихри көчкә ия идеме сон? Жир йөзеннән инде яшәп киткән, бик күп таныш һәм таныш түгел күзләр балкышы, шул чигешләргә сыенып, ана төбәлгәндәй тоелып китте...

...Ялгыз карамадан анын авылына кадәр төгәл жиде чакрым иде...

***

...Арча педучилищесындагы бу музей турында: «Ул дөньяда — бердәнбер!» дип әйтү күптән гадәткә кергән инде. Югыйсә, искитәрлек берние дә юк кебек. Диварларга эленгән саргая төшкән язу-рәсемнәре дә, йөзләгән әлифбалары да артык гади күренә анын.

Чит ил туристлары белән әвәрә килгән житәкчеләр төркеме дә, экскурсовод кызлар да музейга килеп кергән бу озын буйлы, арык гәүдәле картка бөтенләй игътибар да итмәде кебек. Бүлмәдәге ыгы-зыгы басылып, музей бушап калгач кына, язу-документларны укып, дивар буенда ялгызы басып торган картны күреп алдылар.

— Сорауларыгыз булса, рәхим итеп бирә аласыз! Мин сезнен карамакта! — диде яшь кенә кыз, ана якынлашып.

— Рәхмәт, борчылмагыз, — диде карт, бераз гына уңайсызланып. — Мин үзем генә, картларча...

Музейнын серле дөньясына чумган бу сәер картка башка берәү дә комачауламады. Көн кичкә авышып, музей хезмәткәрләре өйләренә жыена башлагач кына, карт алар янына атлады.

— Миндә бер истәлек бар иде. Бәлки сезнең музейга ярап та куяр.

Карт, портфелен ачып, ниндидер төргәк алды да саргая төшкән киндер сөлгене буй итеп сузып та салды. Нәфис чигешләр, күк чәчәкләр, ромашкалар тезелеп киткән зәнгәр хәрефләргә уралды...

«Сабантуй батырына! 1941 ел».

Бүлмәдәгеләр «ах!» итте.

— Искиткеч зәвык! Безнен музей өчен бу сөлге — гажәеп хәзинә бит!

Карт бәхетле елмайды.

— Чигешнең авторын, экспонатны тапшыручынын исем-фамилиясен әйтегез, зинһар!

Карт тагын елмайды.

— Анысы — кирәкмәс! Яраткан укучылары исеменнән диярсез... Мин — меңнәрнең берсе генә... Безнен Рәбига апа! Безнең Салих абый бит ул!

Чигешле сөлге белән әвәрә килеп, картнын чыгып киткәнен дә сизми калганнар түгелме сон?

— Кем булды ул?

— Кем булса да барыбер түгелмени? Меңнәрнең берсе, диде бит!

...Түр диварга эленгән ап-ак чәчле ике фидакарь жан рәсеменә кичке шәфәкъ алсулыгы эленгән иде инде...



Фарсель
Зыятдинов

# ӘРЕМНӘРНЕ МАКТАП ҖЫРЛАРМЫН

## Кайту

Идел-йортым кат-кат чайкалганда,
Сибелгәнбез бөтен дөньяга.
Бүленешеп гомер итәрбез, дип,
Ул чагында кем соң уйлаган?

Бүленгәнне бүре ашаганын
Төшенсәк тә, соңлап төшендек.
Идел-йорттан һаман ераккарак —
Аю урманына күчендек...

Аерылганны аю таптаганны
Анласак та, бик соң анлаштык,
Җанын саклап калыр өчен күпләр
Манкорт булып җирдә җайлашты —
Аю табанына ябышты.

Бүленгәнне бүре эләктерде,
Аерылганны аю таптады...
Изге сукмакларда туфрак булдык,
Ә туфракны үлән каплады.

Тапталсак та, бер горурлык хисе
Сүнми калган күңел түрендә:
Сынауларда сынмас Ватаным бар —
Туып килә ал таң күгендә.

Кыр казлары кебек каңгылдашып
Кайта татар изге иленә.
Тамыр төпкелләре тарта аны,
Нәсел тарта Болгар җиренә.

Фарсель ЗЫЯТДИНОВ (1937) — *шагыйрь, икътисад фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе; «Онытылмас авазлар», «Яшәү мәгънәсе», «Безнең гомер» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, А.Алиш исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

## Арышларым

Бер көн килер — мин китәрмен:
Чыгар, бәлки,
некрологы дусларымның,
Дерелдәп куяр өстәлемдә каләм,
жылысын сагынып
учларымның.
Пышылдарлар кырларымда
арышларым,
Күреп, бәлки,
күзләрендә сагыш барын,
Алар мине искә алып
гел шауларлар.
Югалтсаң да, онытсаң да,
сөйгән ярым.
Иксез-чиксез арышларым,
арышларым,
Сездә кала шатлыкларым,
сагышларым.
Сагышларым таратмагыз,
шатлыкларым өләшегез
Улларыма, кызларыма,
дусларыма...
Ә хәзергә атлый торыйм
яланаяк —
Күнсен тәнем,
күнә торсын туфрагыма...

***

Житәрмен күк тоелса да
Хыялдагы гүзәл таңга,
Булмас инде, ялкын беткән,
Күкрәктә тик күмер калган.

Жылы куллар кагылсамы?!
Кагылса да китмәс көйрәп
Күмер кебек, күмер кебек
Күмер кебек калган йөрәк.

Аны ташлап киткән инде
Соңгы очкын, соңгы ялкын.
...Барып булмый киләчәккә,
Үткәнгә дә булмый кайтып...

## Яратам әремнәрен

Нинди генә гөлләр үсми монда —
Нәфислеге,
Күрке кырларның...
Ә шулай да,
Ул гөлләрдән бигрәк,
Әремнәрне мактап жырлармын.
Хәтфә үзән, күпме үлән монда,
Мең төр бардыр, санап карасаң.

Ә шулай да бу үзәннең, белсәң,
Атлыкларын күбрәк яратам.
Әремнәре чорның әчесенә
Өйрәттеләр түзем булырга.
Атлыклары, татлы икмәк булып,
Гомер бирде безнең буынга.

## Соңгы күбәләк булып

Күзләр килде сиңа никтер иртә —
Җилләр яфракларны куып йөртә.
Яфрак ята янып тезләреңдә,
Нәрсә бардыр, белмим, йөрәгеңдә...
Язлар нуры әле дә күзләреңдә.

Бакчаң инде синең бушап калган,
Тик арчыма, иркәм, яфраклардан.
Кышлар карсыз килеп, җилләр купса,
Җилләр бөтерелеп мине куса —
Яфрак саклар сине суыклардан.

Чәчәкләрнең хуш исләрен сөйсәң,
Һәм бакчаңа язлар килсен, дисәң,
Кояш булып үтим күзләреңә.
Күбәләктәй куныйм иңнәреңә,
Урын калса әгәр йөрәгеңдә...

***

Җырларыңны тыңлыйм.
Күңел тартмасында
Үз урынын ала һәммәсе.
Һәр сүзнең, көй-моңнарның
Синең аша ачам мәгънәсен.
Син белгәнсең,
Төгәл төшенгәнсең
Бу дөньяда яшәү мәгънәсен:
Яратмыйча яшәү мөмкин түгел,
Яратмыйча яшәү — мәгънәсез.

## Нәфес

Суга салсаң, су күтәрми аны,
Утка салсаң, утта янмый ул.
Кайда гына булып, кая барма,
Гадәтләнсәң, синнән калмый ул.
Бер дуслашып алгач, пошмас җаннар
Теләсә дә, аннан качалмый.
Үлчәүләргә салсаң, авыр тарта:
Мең алтының аны басалмый.
Бер карасаң, сине «кеше» итә,
Бер карасаң, юкка чыгара...
Акылыңа нәфес хуҗа икән,
Күпме талпынсаң да чыдарга,
Туры килер барыбер сынарга.



Асия Юнысова

## ХИКӘЯЛӘР

### Талисман

Зөлфия бәлеш капкачын матурлап бөрде дә аны сак кына газ мичено утыртып куйды. Бәлеше тәмле килеп чыга аның – «Фирменный!» Сыйланган кешеләр шулай диләр. Бәлеш бәлеш инде ул. Кем пешерсә дә тәмле. Зөлфия аны ясарга җайлы, бөтен кеше яратып ашый торган мактаулы сый саналган, кунак ашы итеп кабул ителә торган ризык булган өчен еш пешерә.

Кетер-кетер бәлеш пешә,
Килгән кунак безгә төшә,
Безгә төшми, кемгә төшсен,
Минем бәлеш тәмле пешә,

– дип, үзеннән бик тә канәгать Зөлфия, билендәге алъяпкычын сала-сала, үзалдына тыпырдагандай итеп, такмаклап та алды.

Булды бу. Бәлеш пешә торсын. Зур якта җәеп куелган өстәл өстенә табын сые тезелгән. Тәлинкәсе, кашык-чәнечкесе тәртибе белән куелган.

Инде икенче көн тәртибенә күчәргә, ягъни үзен, төсен-битен карарга кирәк азрак. Мирхәтим туган көненә кемнәрне дәшәсен бу юлы да әйтмәде. Ул гел шулай, сюрприз ясарга ярата. Ин мөһиме син, карчык, әзер тор. Кунаксыз калмассың, ди.

«Карчыгының» холкы әйбәт икәнен белә, шуңа күрә сюрпризлар ясаудан бер дә курыкмый. Зөлфия дә, чыраена ризасызлык галәмәте чыгарып, юк өчен ара бозып тормый. Әзерләр ул сыйны, нәрсәсе бар аның. Кунак килә дә китә ул. Өйдә шул Мирхәтиме белән каласы бит. Татулыкка ни җитә!

Мирхәтим, менә егерме биш ел инде, туган көнендә ательега барып фотога төшә. Ел саен ни рәвешле үзгәргәнемне белү, картаю карышларын күреп тору кызык мина, ди ул. Чыннан да, кызык шул. Әле бүген дә иң элек чәчен алдырып чыгар, аннары фотоательега керер. Кунакларыннан алдарак кайтып житсә, шул житкән инде. Аңа – туган көн иясенә – бүген бүтән йомыш юк.

Ярар, Зөлфия дә үзен карасын. Иң элек күлмәк! Кунакларны өйдә йөргән күлмәк белән каршылауны ошатмый ул. Шкафтан тартып чыгарган беренче

Асия ЮНЫСОВА – *шагыйрә һәм журналист; «Айлы юл», «Сагынырсың әле» исемле шигырь җыентыклары, нәниләр өчен язылган биш китап авторы. Хикәяләре вакытлы матбугатта еш басыла. Сәҗидә Сөләйманова исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

күлмәкне үк киеп тә куйды. Фирүзә төс аныкы инде... Күзләренә бик килешә. Муенына, колагына гәрәбә зиннәтләрен сайлады. Яшел төскә болар ятышлы. Җинелчә генә бизәнде-төзәнде, иннек сөртте, сөрмә тартты, хушбуй тигерде. Булды бугай инде – кунаклары, Мирхәтимнең хатыны ярыйсы гына чибәр икән, дип китәрлек Зөлфия ул хәзер.

Газ миченең капкачын ачып, бәлешенә күз сирпеп алды да кабат көзге каршына килде. Бая көзгедә чагылган күзләрендә ул ниндидер сорау, яшерен сер барын абайлап калгандай булган иде. Үзе дә белмәгән нинди сере бар икән аның? Менә син агай, ә. Көзгеләрдә, күзләрендә сакланган хәтер микән әллә ул? Тик нәрсәне, әллә кемнеме соң, хәтерли икән соң бу ике сердәш?

Кайтты, Мирхәтим кайтты. Авызы ерык. Үзе белән тыш һавасын, парикмахерларда гына була торган ислемай исләрен ияртеп килеп керде:

– Карчык, тышта, билләһи, яз! Белеп туганмын бит мин. Менә сиңа да бераз яз алып кайттым. Тал песиләре... Утыртып куй, кунаклар килүгә өйләр ямьләнеп китсен.

– Кунакларың ни җитте түгел, ахрысы, бу юлы.

– Ни җитте түгел, карчык. Ни җитте түгел – сыйныфташлар, сабакташлар!

– Кызлар да буламы соң?

– Мальчишник безнең. Хатын-кыз белән бәйрәм ямен җибәрәләр димени!

– Мин кем соң?

– Синме, син – хатын! О-һо, бәлеш исе дөньяны алган! Иң шәп хатын бит син, иң тәмле бәлеш пешерүче! Табының да әзер. Бишле сиңа! Шахмат такталарын әзерләп куйыйм әле. Турнир уздырырбыз малайлар белән.

«Мальчишник»ка сыйныфташлар бик кубарылмаган. Мирхәтим белән дүртәү булдылар. Аз кунакны көйләү Зөлфиягә дә җиңел булыр. Мирхәтим бит ул кунак килгәндә үзе иң зур, иң көйсез кунакка әйләнә.

Дүртәү генә булсалар да, сабакташлар хәтәр җанлы гөрләшә. Сый арты сый авыз итә, чәркә арты чәркә чәкештерә торгач, тавышлары тәмам көрәйде. Аратирә сүз көрәштереп тә, җырлашып та алалар.

Табын янындагыларның кәефе яхшырган саен, Зөлфиянең кәефе төшә барды. Кара син аны, иренең туган көне хөрмәтенә корылган табын тирәсендә аңа урын табылмасын әле. Юри генә, берсе генә булса да: «Зөлфия, ике арада чабулап, безне көйләп йөрүеңнән тукта әле син, безнең янга кереп утыр инде», – дип әйтсен, йә! Төне буе алма, каражимеш бәлешләре белән кайнашып – йокысыз, иртәдән бирле салатлар ясап, табансыз калды. Аннары табын бизәп әвәрә килде. Җитмәсә, ай тулган вакытны һич ялгыштырмый торган баш өянәге кузгалды. Башны мигрень дигән нәрсә кыршаулап алдымы, күзенә якты дөнья күренми инде ул. Башкалар нишлидер, андый чакта Зөлфия маңгай турыннан башын яулык белән кысып бәйли дә, цитрамон кабып, караңгы һәм тын бүлмәгә кереп ята. Йоклап китә алса, шуннан терелеп уяна инде... Бүген алай итеп булмас шул. Һич югы шаулашмасыннар иде.

– Егетләр, бик тавышланмагыз әле, ярармы, – диде ул, чәй китергәч. – Башым авыртып тора. – Үзен һичшиксез аңлауларына ышанып әйткән иде.

«Егетләр», аптырашыпмы, «баш авырту» хәлләре үз өйләрендә дә булгалап торгангамы, гаепле сыман тынып калдылар. Кайбер күзләрдә алар ишектән кергәндә гөлчәчәк кебек балкып торган, ә хәзер агарынып калган Зөлфияне чын-чынлап кызгану галәмәте дә чагылып китте.

– Бетте-бетте, шаулашмыйбыз, матур абыстай, – дип, Вәлиулла дигәне хатынның иннәреннән сыйпап алды.

Баш өянәге монын ише хәлгә керүдән генә җибәрмәсә дә, барыбер, хатынга рәхәт булып китте. Менә аның барлыгын да белделәр!

Зөлфиянең сансызлыгыннан Мирхәтим генә гөлт итеп кабынды:

– Яп ишекне теге яктан. Башың авыртса, йокы бүлмәсендә генә утыр!

Ә бит ул хатыны янына торып чыгарга, хәлен сорашырга тиеш иде. Югыйсә ул Зөлфиянең юкка-барга зарланмаганын, чәүчәләк хатын түгеллеген белә.

Мирхәтимнең тәкәллефсез сүзләреннән соң, залдагылар ризасыз шаулашып алдылар: «Син нәрсә, кордаш? Карчыгына алай каты бәрелмә. Безгә алар белән картаясы», – диде берсе. Һаман да шул Вәлиулла бугай. «Хатын кадерен белми бу безнең сабакташ. Менә ташлап китәр әле үзеңне бер». – Ачынып әйткән сүзләр иясе Фатих булырга тиеш. Яшьли тол калды ул.

Мирхәтим, сабакташының тел төбендәге нечкә кинаяне төшенергә азапланмыйча гына, канәгать гөрелдәп алды:

– Никак нет, егетләр. Беркая да китми ул. Мин өйләнгәндә үк хатынның кеше күзе төшмәслеген сайлап алдым. Үземә генә була торганын. И кисәттем. Мин идеалымны эзлим, тапсам, бернигә дә карап тормыйм, дидем. Шуна күрә түзә ул. На коротком поводке чөнки!

– Ярпачлыгың бетмәде инде синең. Дәрәҗәле генә урында эшли түгелме соң синең хатын? Ә ул, әнә, без шалапайларны көйләп йөри. Хатынны вакытыннан алда картайтырга ярамый, Мирхәтим...

– Чибәр дә әле ул синең. Ия табылыр ана, ә син менә...

Зөлфия сүзләрнең нинди юнәлеш алганын тыңлап бетермәде. Чөйдәге иске кайры туның эләктерде дә карангылык капкан урамга атылды. Алар Кабан күле буендагы урамда торалар. Кабан күле аның күптәнге сердәше. Бу юлы да хатын үзе белгән сукмактан атлады. Таныш карама өстенә килеп утырды.

Ауган карама... Ул да, күрәсең, нахак, урынсыз гаепләүләрдән арып ауганды. Гел генә сабыр итеп булмый шул. Гел генә акыллы булып калулар да кыен. Гел генә кеше хакын хаклау да ярамыйдыр. Ара-тирә тәртәгә тибеп алулар да кирәктер ул. Әллә син, карама, чана табаны бөгәселәрен белгәч, авып төшкән идеңме?

Нишләп әле мин ауган карама белән серләшеп утырам. Аварга уйлаганым да юк лабаса. Менә күл күзенә карап, уйларымны дөреслим дә, баш өянәге басыла төшкәч кайтырмын. Ул вакытка, бәлки, кунаклар да таралышырлар. Бәлки әле кирәксез хатынның да кирәге чыгар. Ямьсез хатынның да...

Иң ачу китергәне шушы «кеше күзе төшмәслеген» дигән җөмлә булды, ахрысы. Мигреньне дә кысрыклап чыгарып, баш миен һаман шушы җөмлә бораулый. Сабыр, Зөлфия, сабыр! Син бит бәянне беләсең. Кабан күленең яшел күзенә – бәкедә мөлдерәп яткан тонык суга – кешеләрнең мәңгелек сер сандыгына зарыңны түк тә тынычлан.

Ә нинди зары бар соң аның?

Нинди сере бар?

Бар! Булырга тиеш...

Көзгедә чагылган күзләрдә абайлап калган иде ул онытылган серне. Аннары теге – «кеше күзе төшмәслеген» дигән җөмлә Зөлфиянең күңел кылларына килеп тигәч, кыллар ачыттырып, зарлы һәм каһкаһәле итеп сыкрап алган иде.

Беләсең пычагым!

Ә нәрсәне? Нәрсә соң ул?

Бәке нидер белә бит – түгәрәк йөзендә тигезле-тигезсез дулкыннар йөгертеп ала. Нәрсәнедер хәтерләтмәкче була.

Әйе, Зөлфиянең сере бәке белән бәйле булырга тиеш.

Уйлаганын раслардай шаһит, теләктәш эзләп, Зөлфия күзләрен күккә төбәде. Җиһан ул үзе сер дәрьясы. Андагылар белмәгән сер булмас.

Монарчы күк йөзендә җилкәнле көймәләр сыман өерелеп йөзгән ак болытлар кайсы кая таралышкан, җиһанга тулган Ай хуҗа булып калган. Зөлфиягә рәхәт булып китте. Күзләре талганчы Айга карап утырды. Аннары Ай нурлары аның карашын, азимут сыман, янәдән бәкегә юнәлтте. Имеш, шуннан эзлә син серенне, шуннан.

Юк, тулган Аем, син бәкедә күпме генә коенсаң да, мин берни дә аңламам. Алай да иптәш булганың өчен рәхмәт. Моңа кадәр дә бар серемне сиңа сөйләдем. Бәлки, шул серләр арасында мин онытып та син саклаганы бардыр. Уйлашырбыз әле.

Зөлфиянең өйдән чыгып киткәндәге ярсуы басылган иде инде. Баш өянәге дә узды бугай. Төнката күл буенда утыру ярамас. Хатын сынын турайтып торып басты. Күшеккән куллары кайры тун эченнән җылы эзләде. Кара син, бу онытылган тунның куен кесәсе дә бар икән.

Студент елларда бушлай эш көчен төзелешләргә йөртәләр иде. Бер елның кышы бик салкын килде. Туңып йөрмә, балам, дип, әнисе бер килүендә базардан шушы тунны алып калдырган иде. Затлыга түгел, әрсезгә кияр өчен. Шул кыштан бирле кигәне дә юк иде бугай бу тунны.

Ни микән бу?

Яшерен кесәдән ефәк бауга тагылган талисман килеп чыкты. Шул мизгелдә көзгедәге күзләр сере дә, бәке йөзендәге яшерен ым да, бизәкле келәсе ачылган тартмадай, ачылды да китте. Чөнки бу талисман Зөлфиянең күзләре төсендәге нефрит таштан ясалган иде. Күл-бәкенең дә төнге чагылышы нәкъ шушы нефрит таш төсендә иде. Бәке, Зөлфиягә талисман ташындагы табигый сурәтне – агач кисемендәгегә охшаш нечкә җыерчыкларны хәтерләтергә тырышып, вак дулкыннарын йөгерткән икән ләбаса! Болытлар белән качышлы уйнап йөргән Ай, бәкегә сикереп төшеп, нефрит таштагы кыз йөзе – Зөлфия йөзе икәнлеген искәртмәкче булган икән.

Ә өйдәге көзге нинди серне белгән соң алайса?

Көзгеме, көзгеме?

Көзге икенче бер көзге каршында Зөлфиянең шушы талисманны фирүзә төсендәге бүтән күлмәк белән киеп караганын белеп калган ул. Күрәсең, көзгеләр дә үзара хәбәрләшә! Юк ла инде. Көзгеләр түгел, көзгедә күргәнен күзләр хәтерләп кала. Менә нигә фирүзә төсле күлмәгән киюгә аның күңел кыллары зынлап куйган икән.

Инде хәзер бәкедәге яшькелт су – нефрит ташны, вак дулкыннар – талисман ташындагы нечкә җыерчыкларны, Ай исә ташка нәзек сызыклар белән төшерелгән кыз сурәтен хәтерләтергә тырышканнар.

– Менә шундый чылбыр, туташ! – диде үз-үзенә Зөлфия, талисманны салкын яңагына куеп. Ай яктысында талисманга төшерелгән сурәт бигрәкләр дә сагышлы күренде. Йөз сызыклары – Зөлфиянеке, ә сурәт үзе Бакый Урманче ясаган «Сагыш» дигән картинадагы Сөембикәгә охшаган иде. – Әй Араик, Араик, тун кесәсенә салып калдырган булгансың икән бу талисманны. «Кемгә бүләк ясыйсың? – дип сорагач, бик тә җитди итеп: «Сөйгәнемә!» – дигән идең. «Кем синең сөйгәнең? – дип сорагач елмайдың гына: «Синең кебек бер чибәр. Яратырмы икән, йәле, киеп кара әле», – дип, Зөлфиянең фирүзә төсендәге свитерына куеп карадың. – Синең күзләреңә бик тә туры килә икән. Әле моңа бик матур шнур тагасы бар».

Әйтергә өлгермәде. Араикның сөйгәне кем икәнен Зөлфия белми калды.

Әрмән егетен ошатып, ошатып кына түгел, яратып та йөрүчеләр бар иде югыйсә. Зөлфия үзе дә бу кара бөдрә чәчле, кара күзле, акыллы һәм эшчән егетнең сөйгәне булырга риза иде. Әмма тыйнак авыл кызы чәчрәп чыкмады.

Чөнки Араикның әрсезләргә мөнәсәбәтен күреп тора иде. Параллель төркемнән Лариса егетнен күзенә керә. Буш вакыт булган саен, кулына нәни игәвен алып, төрле-төрле ташлар игәүләп утырган Араикка гел бәйләнә ул:

— Араичек, син Казанга нигә килден?

— Укыйм мин монда. Табиб булырга жыенам.

— Син ювелир, да?

— Әрмәннәр бөтенесе дә ювелир. Дөресрәге, асылташлар телен белүчеләр. Таулар төрле ташларга бай бит ул.

— А я думала, что әрмәннәр базарда гына саталар. Ә син шахмат та уйныйсын...

Ларисаның мондый әдәпсез, һавалы сөйләшүе Араикның гына түгел, калганнарның да ачуын чыгара. Хезмәт практикасындагы студентлар мединститутта укып йөрүче тау егетенең максатлы, сабыр, ихтыярлы икәнен беләләр. Күпләр аның белән дус булырга тырыша.

Институтта укып йөргәндә — бер хәл. Менә шушындый хезмәт практикасы вакытында кешеләрнең яшерен сыйфатлары да ачылып китә.

Ул кыш декабрь башыннан ук зәһәр килде. Вузара ашханә төзелешен тизләтү өчен укуларыннан бүленгән «комсомоллар» — төрле тарафтан жыелган студентлар кышның зәһәрлегенә сөенәләр генә. Чөнки салкынлык утыз дәрәжәдән түбән булганда, ачык һавада эшләр туктатыла. Әмма кайтып китәргә дә ярамый. Көнозын домино сугып, дуракны уйнап, бер дә юктан шыр-шыр көлеп тә уздырып була ул көнне. Араик кебек таш игәүләп тә...

Беркөнне, жыйнаулашып, Араикның көмеш йөзеккә таш куйганын карап тордылар. Ул куйган ташның әрмәнчә исеме «каш» була икән. «Татар телендәге «йөзек кашы» дигән сүз шуннан» — бу кадәресен Әбугалисина кушаматлы Зәки белә булып чыкты. Араик аңа карап, матур итеп елмайды. Ике егетнен серләре килешә. Хәер, зат затына тартыла бит.

— Ә син, Зәки, башка ташларның хасиятләрен беләсенме соң?

— Ну малай, беләмдер дә, әмма тау-таш арасында яшәгән әрмәннәр хәтле түгелдер инде. Мин синнән артык гыйлеменне әжәткә алып торырга һич тә каршы түгелмен.

— Азрак бирен торам, алайса. Тыңла, Әбугалисина. Син кайсы айда тугансың әле. Июль бит, әйеме? Синең ташың — якут. Бу таш усал кешене тәмам явызга әйләндерә. Яхшы күнелле кешегә уныш китерә. Якут ташы йөрәкне дәвалый, хәтерне яхшырта, зиһенне үткенәйтә. Син табиб буласы кеше, якут кашлы йөзек сатып ал. Миңа ук заказ бирсәң дә була.

— Ә минем ташым нинди? Октябрьнең ташы?..

— Октябрьме? Опал кирәк сина. Гажәеп таш инде ул.

— Минеке? Мин мартта туганмын.

— Мартка — энже. Әйдәгез, бөтен ташларны берьюлы сибеп жибәрәм дә, үзегезгә кирәген сайлап алыгыз: декабрь — фирүзә; ноябрь — топаз; апрель — алмаз; май — зөбәржәт... Һо-һо, жыегыз, — дип, Араик кесәсеннән алып, ирис конфетлар сибеп жибәрде.

Кызлар, чыр-чу килеп, «асылташларны» жыярга керештеләр.

Зөлфия «Кыз» йолдызлыгында туган. Аның ташы — нефрит. Тик ул аны ошатмый. Матур түгел лә ул. Зөлфия якут ярата. Кайчан да булса якут кашлы йөзек, якут кашлы алка кияр әле. Эшли башлагач... Араик та «якут» сипмәде. Шуңа күрә Зөлфия «асылташ» чүпләргә ташланмады. Ларисага да «асылташ» чыкмаган икән. Шуңа күрә ул уенны икенче якка борып жибәрде:

— Әйдәгез, йөзек салышлы уйныйбыз! Араикның өр-яңа йөзеген салабыз!

Ларисаның бу тәкъдиме барысына да ошады. Араик та хуплады:

— Татар яшьләре уенын минем дә отып каласым килә. Ничек уйныйлар соң аны — йөзек салышны?

Уен гади, әлбәттә. Татар өчен. Гади уен, әмма күңелдә йөрткән серне сиздерергә яраган ул. Ничек дигән әле бер мут агай: күк төймәм кемдә — күңелем шунда, дигәнме? Йөзек йөреп торды. Учына йөзек төшкәннәр җәза ала торды. Менә бер заман йөзек әрмән егетенә дә төште. Лариса салды инде аны егет учына.

— Мин нишләргә тиеш инде?

— Җырлыйсың! Җырлыйсың!

Моңа кадәр җырлап күрсәткәне юк иде. Нишләр микән? «Бүтән җәза сорармы, җырлап карармы? Җырларга ризалашты. Әбүгалисина түш кесәсеннән кубызын тартып чыгарган иде дә, Араик аңа: «Куй, дустым», — дигәндәй ишарә ясагач, кубызын янәдән кесәсенә шудырды. Без тынып калдык. Әрмән җыры тыңларга әзерләндек. Араик, озын кара керфекләрен түбән төшерде. Бераз уйланып торды. Аннан тирәннән — күкрәк түреннән чыккан моң белән җырлап җибәрде:

Нигә, нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә: нинди көчләр
Керфек очларыңнан тамалар?

Бер генә куплетын җырлады. Ләкин әчтән сискәнеп алыр өчен җырның шушы бер куплеты да җитте. Әйе, кубыз белән җырлана торган җыр түгел бу. Монда скрипка — кимәнә кирәк!

Һади Такташ сүзләренә язылган бу романсны Зөлфия бик ярата. Үзе генә калганда, гел шуны җырлап йөри. Кеше алдында җырларлык моңы булмагач, ялгыз чакларында кинәнә.

Араик бу җырны каян белә? Һәм ул аны саф татарча җырлады бит әле! Моңы-мәкаме дә бик ягымлы икән... Тигез генә баритон. «Урман кызы»н нәкъ менә шулай тыенкы, сагышлы җырларга кирәктер дә аны. Барысы да тәэсирләнде, уйчанланды. Татар моңын шулай үткәзеп җырлый алган егет алдында, ничектер, оят та иде бугай. Һәрберсе күңеленнән: «Ә без монда!» — дип уйлап утыргандыр, мөгаен. Саега барабыз бугай ла...

Бу җырдан соң җиңел-җилпе уеннар уйныйсы килмәде. Инде кайтырга да ярый, диделәр. Ул көнне Араик беренче мәртәбә Зөлфияне тулай торакка кадәр озата кайтты. Ул үзе фатирда торып укый икән.

— Син татарчаны каян беләсең, Араик? Җырлавың нәкъ безнеңчә, моңлы...

— Татарча белмәсәм, гаҗәп булыр иде. Мин бит Казанда өч ел яшим инде. Бик таләпчән, бик гыйлемле апада фатирда торам мин. Элек укытучы булган. Татарча өйрәнергә теләгем барлыгын белгәч, үз методикасы белән өйрәтергә кереште. Ул методикада җырлар өйрәнү дә, театрга йөрү дә, китаплар уку да бар. Хәкимә апа миңа шигырьләр дә ятлата. Сөйлимме: «Кое яны яшел таш, су алырга чык, туташ!» Чыгарсыңмы, йә, әйт әле?! Хәкимә апага, шул шигырьне укып, бер чибәрне кое янына чакырдым, диярмен. «Кое яны...» Кызык бит. Бездә суны тау чишмәсеннән алалар. Чишмә суы бәллүр кебек. Бездә һава да бәллүр кебек. Матурлык! Һуштан язмалы... Кызлар суга көянтәчиләк белән түгел, озын муенлы чүлмәк белән төшә. Безнең яшәү рәвешен син дә аз-маз беләсеңдер инде. Укытучыма мин татарча «Безнең табигать», «Безнең бәйрәмнәр» дигән темаларга бәләкәй хикәятләр сөйләп, имтихан тотам. Оныттырмый туган илемне. Ул миннән ай саен имтихан ала. Бик уңдым мин Хәкимә ападан.

Болай да өйрәнергә тырышкан булыр идем татар телен. Америкага яки Англиягә барган студентлар өч айда инглиз телен өйрәнеп кайталар. Беркем гаҗәпләнми. Шул ук кеше гомер буе Казанда яши, әмма татар телен белми. Бу кадәресенә дә гаҗәпләнмиләр. Сез – татарлар, үртәлмисез бит шуна. Безнең Әрмәнстанда халыкның 97 проценты әрмәннәр. Без үз мәдәниятебездән тәм табып яшибез. Безнең арага килеп кергән башка милләт кешесенә ярашырга тырышмыйбыз. Ул ярашсын! Үзебез башка халык арасында яшәргә керешсәк, ул халыкның гореф-гадәтен, телен, мәдәниятен өйрәнәбез, хөрмәт итәбез. Зөлфия-җан, татар телен өйрәнүем – сине, синең халкыңны хөрмәт итүем ул. Бик яраттым мин татарларны. Сез дә, әрмәннәр кебек, кайгылы халык бит!

Кайгылы халык?!

Бу гыйбарә Зөлфиягә таныш түгел иде.

Әллә ничек сәер яңгырады. Кайгылы кеше була, кайгылы заман...

– Кайгылы халык диюенне аңламадым?

Араик ул вакытта Зөлфиягә шундый сәерсенеп, хәтта кызганып карады ки:

– Сез ачыктан-ачык кайгырырга да кыймыйсыз шул. Бу дөньяда геноцид кичергән халыклар күп түгел. Яһүдләр, әрмәннәр һәм сез – татарлар. Дәүләтен югалткан, иң асыл ирләре кылычтан үткәрелгән халык шат була алмый. Сез – кайгылы халык! Без дә... Шуңа күрә кыйтгалар буйлап сибелгән дә инде безнең халыклар. Сибелеп, исән калыр өчен.

Араик сөйләгәннәр хакында Зөлфия озак уйлап ятты. Нәрсә белә соң ул үз халкының тарихы турында. «Казан ханлыгы» дигән ханлык булганлыгын да университетта укый башлагач кына белде. Ә бүген менә медицина институтында укып йөрүче әрмән егете аңа үз халкының тарихына гел бүтән күз белән карарга өйрәтте. Әле ул аны, аны дип, татарларны инде, шелтәләп тә алды. «Сез бит «Хәтер көне» дигән матәм йөрешенә чыгарга да иренәсез. Ярый әле Зөлфия: «Кайчан була соң ул?» – дип сорамады. Тәмам оятка калыр иде. «Чыгам мин», – дип хәйләләде.

Араик, әрмәннәр фәкать үз мәдәниятләре белән кинәнеп яши, дип сөйләде дә бит. Ә менә Зөлфия күптән түгел мәшһүр рус рәссамы Иван Айвазовскийның Миңнегөл исемле кырымтатар кызы белән Оганес исемле әрмәннән туган «рус» икәнен белде. Араик моңа каршы нәрсә дияр иде икән? Берәр вакыт әйтер әле ул аңа бу хакта. Хәер, Араик аны беләдер. Татарларга тартылуының, ни өчен укырга нәкъ менә Казанга килүен дә сорашыр әле. Айвазовскийның әнисе татар кызы булган икән дип әйтсә, Зөлфияне ялгыш аңлавы да бар бит әле егетнең. Юк, моны кыз әлегә әйтми торыр.

Икенче көнне дә носилка белән өстәге катка кирпеч ташып йөрделәр, тиз арада күшегеп, тагын җылыга кереп утырдылар. Башкалар «балык!», «кәҗә!» дип мәш килгәндә, Зөлфия, бер читкә китеп, китап алып утырды. Сильва Капутикянның бу юка шигырь җыентыгын көз, авылына кайтканда, автовокзалдагы киосктан сатып алган иде. Юлда укырга гына дип алган китабы сердәшенә әверелде. Сильва Капутикян гел Зөлфия кебек уйлый, гел Зөлфия кебек хисләнә. Әрмән шагыйрәсенең шигырьләрен кат-кат укудан бер дә туймый кыз. Ул моңа кадәр яраткан шагыйренең милләте хакында уйлап та карамый иде. Ә хәзер шигырь юллары арасыннан бу халык турында белемен тирәнәйтердәй нәрсәләрне дә күрергә тырышып укый. Гашыйк булып барамы соң әллә?

Зөлфия янына Араик та килеп утырды. Кулында һаман да шул игәве:

– Менә бу таш синең ташың – нефрит.

– Беләм, – диде. Ләкин яратмыйм мин аны, дип әйтмәде кыз.

Егет дәвам итте:

— Нефрит — хикмәтле таш ул. Сердолик та ярый «Кыз»ларга. Син «Кыз» бит әле, әйеме? Сентябрьдә тугансың.

— Сентябрьне татарлар «сөмбелә» дип йөртә, — Зөлфия моны юри, татарларның да үз дөньясы, Җиһандагы йолдыз атамаларына кадәр ирешкән кинлеге барлыгын белдерер өчен әйтте. — Анысы, дөньяда бер мәшһүр обсерватория Әрмәнстанда булгач, йолдыз гыйлемең минекеннән баерак инде синең.

Араик Зөлфия тавышындагы кичәге сөйләшүдән соң реванш алу омтылышын сизмәде. Үзенекен дәвам итте:

— Тик сиңа нефрит килешер. Ул — тормышны, яшәүне раслый торган таш. Син озын гомерле бул, яме.

— Ай-һай-һай, килешең! Наданлыгыбыз белән без сине тәмам узындырдык, ахры. Син гел зирәк бабайлар кебек сөйләшә башладың. Тау бабайлары, озак та яшәгәч, бигрәкләр дә акыл иясе була торганнардыр инде.

— Ярар, алайса, малайларча сөйләшермен. Гашыйк булгансың димме соң сине, кызый. Кара аны, рөхсәтем юк!

— Гашыйклык билгесе дә ташка уелганмы әллә? — Араик аның йөрәгендә бөреләнә башлаган хисләрне сизеп алганмы соң? Сүзләре кинаяле тоелды. Кызга унайсыз булып китте.

— Шигырьләр укыйсың. Мәхәббәт шигырьләре. Сильва Капутикян лирикасын минем сенлем дә ярата. Ә мина аның кулъязмалары ошый. Гамьле алар. Канадада, Ливанда булып, читтә яшәгән әрмәннәр — спюрк язмышын өйрәнде ул. «Юлдагы кәрваннар» дигән китабын укытырмын әле, яме. Болай ни... рәхмәт сиңа.

— Ни өчен миңа рәхмәт, мин нишләгән әле сиңа, әй?!

— Әрмән шагыйрәсен укыганың өчен рәхмәт. Һәм... дөньяда булганың өчен.

Зөлфия кып-кызыл булды. Оялганын башкалар да сизмәсен өчен, ишек катындагы көрәкне алып, баскычка чыкты, каткан цементны кыра башлады. Оеп утырмасын әле. Көрәк белән бераз селтәнсә, суыкны сизмәс, башындагы иләс уйлар да чыгып очар. Ана башкалар да иярде. Күрәсең, доминодан туеп киткәннәр иде. Бетсә бетсен дә инде бу каткан бетон кыру, укырга кайтсыннар. Тиздән сессия житә.

Араик Зөлфияне тагын озата кайтты. Ишек төбенә житкәч, әллә ничек монсу гына: «Зөлфия, бу юлы озаккарак саубуллашыйк әле. Минем Әрмәнстанга кайтып киләсем бар. Мин сиңа аннан шалтыратырмын. Сиңа бер сүз әйтәсем бар иде», — диде дә, артыгын сөйләшеп ташладым бугай дигәндәй, ашыгып-ашыгып, трамвай тукталышына китте. Аннан кире йөгереп килеп, Зөлфиянең алма битеннән үбеп алды: «Хуш, жаным! Син Галәмдәге иң чибәр кыз! Хуш!»

Кайры тун тулай торак бүлмәсендәге шкаф өстенә үк очты. Төзелешкә бүтән барып йөрмәделәр. Яңа елга да күп калмады бит инде. Араик бәйрәмнән соң гына килә торгандыр инде ул. Килсен иде инде тизрәк! Тагын ике атна ничек түзәрсең? Теге «бер сүз»не бик беләсе килә кызның.

Бөтен гомер буе түзәргә, сабыр итәргә туры киләсен, «бер сүз»нең һичкайчан әйтелмәсен ул чагында кем белгән?!

Өч көннән соң бөтен дөнья телевизорлар каршында тынсыз калды. Әрмәнстанда жир тетрәгән! Араикның туган шәһәре Спитак тәмам хәрабәгә әйләнгән. Күп меңләгән корбаннар! Имгәнүләр! Фажига коточкыч. Газеталар фажига урыннарыннан репортажлар белән чыга.

Йа Хода! Араик!

Араик югалды. Зөлфия начарын уйламаска тырышты. Ләкин яхшы хәбәр дә килмәде. Кыз «Комсомольская правда» газетасында, «Огонёк» журналында

басылган фотоларны, таныш йөз чалымнарын күреп алудан курка-курка, жентекләп карый. Шөкер, таба алмый.

Өч айдан соң Зөлфиягә Араикнын абыйсыннан телеграмма тапшырдылар: «Араик погиб. Он до последнего думал и говорил о Вас. Он мечтал жениться на Вас».

Шуның белән шул.

Бөреләнде, чәчкә атмады дигәннәре шул буладыр, күрәсең.

Ул афәтле вакыйгалардан соң инде 25 ел узды. Жир шарының берәр ноктасында жир тетрәгәнен ишетсә, Зөлфия дә тетрәнә. Араикны оныттым дип әйтә алмый. Ул аның гомеренең иң якты тәрәзәсе. Менә бүген дә, үзен кадерсез тоеп үртәлгән бер көнендә, яшерен куен кесәсеннән табылган талисманы белән ул тәхетенә кайтарды.

Рәхмәт сиңа, Араик! Зөлфия нефрит ташка иреннәрен тигерде. Нефрит – хәзер аның иң яраткан ташы. Ханым талисман йөзен яше белән юды. Чү! Монда ниндидер язулар бар түгелме соң? Яктыда укырга кирәк!

Зөлфия, хатынын югалтып, урамга ук чыккан Мирхәтим янынннан жил кебек узып, өенә атылып керде дә, бүлмәсенә үтеп, өстәл утын кабызды. Нефрит таш өстенә бизәк сыман сырлап язылган сүзләрне укырга азапланды. Укыды, ләкин берни дә аңламады. «Ес сирум, ем кеиз»... Ни дигән сүзләр булыр бу?

Иртәгәсен Зөлфия таныш әрмән хатынын эзләп китте. Ул язуны бик тиз укып бирде: «Мин сине яратам», – дигәннәр монда, жаным».

Һай, Зөлфия, бу талисманны 25 ел элек үк табып аласың калган ла! Хәер, бернәрсә дә тиктән генә булмый. Димәк, Араик аны нәкъ менә бүген якларга уйлаган! «Галәмдәге иң чибәр кыз син, Зөлфия!» – дип, янәдән искәртүе аның. Ерак дөньялардан, тулган Ай күзе белән карап, Зөлфиясен күзәтә, саклый икән ул! «Мин сине яратам» дигән бер жөмлә аңа калган бөтен гомеренә житәр. Ташка язылган сүзләр бит ул! Аны яраткан кеше кулы белән язылган сүзләр.

Талисманын ул хәзер беркайчан да салмас.

## Курку

Йа Аллам! Китте! Юлларына ак жәймә.

Язга чыкканнан бирле, Ходай бирмеш һәр көнне кузгатылган сүз көрәштерүләр тәмам.

Сәлимә кулына кечкенә чемоданын тоткан, иненә көрән курткасын элгән ире артыннан ул, урам почмагыннан борылып, күздән югалганчы карап калды. Жинел-жинел атлап китте, каһәр! Югыйсә, койма буенда куерып үскән кычыткannар ышыгындагы шезлонгында, мүкләнгән олы таш сыман, көннәр буена кузгалырга иренеп ята торган иде. Бәрәңге бакчасы ягыннан ихатага үтеп кереп, тавыкларны бимазалаучы алабайларга таяк ыргытырга да иренә торган иде. Хәзер, әнә, кая таба житезләнгән!

Ишегалдындагы теплицаның түбәсе ишелеп төшкәч тә пошынмады ир. Пыяла өеме, гарасат калдыгы сыман, кеше куркытып ята торгач, Сәлимә, эшчеләр яллап, пыяла ватыкларын балчык белән күмдертте. Югыйсә мондый тәртипсезлеккә, Сәлимәнең түгел, Ихсанның эче пошарга тиеш иде. Әле кайчан гына прораб булып төзелешләр башында торган кеше ләбаса ул.

Прораб сиңа. Сәлимә эштән кайтуга аш салып торырга да булдыра алыр иде. Кая ул! Беркөн юри исемлек язып, эшләр кушып калдырды хатын. «Итне суыткычтан ал, эресен. Эрегәч, юып, шулпа кайнатырга куй. Бәрәңге әрче. Мин үзем кайткач, ашны пешереп бетерермен», – дип язып та калдырды. Хөрәсәнә кымшанмаган да. «Язуың озын иде. Укырга ирендем», – булды жавап.

Сәлимә кайткач: «Карчык, кыздырып калдырган балыгыңны ашап куйдым мин. Тәмле ие. Инде ачыктым. Ашыңны кайчан булдырасың?» — дип, олы корсагын кашый-кашый, эшне кай тирәдән башларга белми йөдәгән хатыны янында таптанды.

Йорт тирәсендәге мәшәкатьләргә тәки җәлеп итә алмады ирен Сәлимә. Эш кушкан булуы да Ихсанның үзен җәлләгәннән генә лә инде. Озын көннәрне ничекләр итеп койма буе күләгәсендә уздырып бетермәк кирәк. Бер мәшәкатьсез. Бер максатсыз. Ирек куйсаң, максатны тиз табасы ул. Иң мавыктыргыч максат, әлбәттә, сыра! Кай арада бик һәвәсләнеп ала. Кулына акча биргән юк инде. Әмма ир бик максатчан чагында, түтәлдәге кыярларны кибет янына алып чыгып сатып, акча эшләп ала. Андый көннәрне ул үтә кәефле йөри. Үз күзендә бәясе дә күтәрелә бугай. Һәрхәлдә, күкрәген кагып, мин — ир кеше, мин — патша, дип йөри башлый. Хәтәр усалланып та китә патша булган көннәрдә.

Шулкадәр арый Сәлимә иреннән. Эшләгән чагы булып, һич югы берәр яры командировкага китсен иде. Хастаханәдә ятып чыкса да ярар иде әле, ачуым да бер килмәгәе. Китмәде дә, ятмады да. Эшендә дә, өендә дә ял күрми Сәлимә. Кеше ирләре, әнә, пенсия яше кергәч тә, ничек итсә алай дигәндәй, эшендә эләгеп торырга тырыша. Барыбер дә файда бит. Юк, Сәлимәнеке пенсия көнен сәгатьләп санап көтеп алды. Костюмын, галстугын салып, трико киеп алды да менә биш ел инде сафа күрә.

— Бер файдаң юк, — ди аңа Сәлимә, бик ачуы килгәндә. — Карга куркытырга да ярамыйсың. Курыкмыйлар алар синнән, үзләренә иш дип беләләр.

— Җен-пәри куркытам мин, әнкәсе.

— Куркытыр идең дә, элекке заман булса. Хәзер курыкмыйбыз шул инде. Ир-ат заты җен-пәри куркытыр өченгә дә ярамый бүгенге тормышта. Пәриләрне качырдык. Сыра эчеп, сүгенеп, транзистор акыртып, үзең качырдың безнекеләрне.

— Патшаңа тел тидермә, хатын. Киттем-бардым булыр Камчаткага, яшьлек эзләрен эзләп.

— Камчатка тагын... Идел буйлап бер йөреп кайтсаң да, әле колагым тынып торыр иде. Берәр атна ашарга әзерләмәс идем...

— Әй хатын, бар кайгың шул гынамы? Бүтән кайгың булмаса, кайгырма син. Үзем дә җилләнеп кайтыргамы әллә диебрәк уйлап тора идем әле. Тутыр чумаданны!

Әнә, китте! Исән генә йөрсен. Сәлимәгә ялның, ирсез тормышның бер атнасы да бүләк кебек аның.

Сәлимә тимер капканы бикләп, ишегалдына керде. Кояшка йөзен куеп, киерелеп, кинәнеп бер сулады да тиешсез урында үскән кычытканнарны йолкырга кереште. Аннары аларны тапап, тавыклар алдына салды. Мунча алдын җыештырып куйды. Утыны беткән утынлык янышнан сукранып узды. «Күрше Кәрим малаена әйтеп куй әле. Аны утын сата, диләр. Каен утыны сора», — дип ирен кымтырыклый башлаганына байтактан. Ни уйлап йөридер бу адәм? Югыйсә, үзе мунчаны бик ярата бит.

Караңгы капканчы үзенә ишегалдында мәшәкать табып йөрде Сәлимә.

— Хатын, ашарга бармы? — дигән өн ишетелмәгәч, кич житкәнен дә абайламаган икән ләбаса.

Кулындагы үлән яшелен мунчага кереп озаклап чистарткач, өйгә узды. Әңгер-меңгергә чумган өй эче Сәлимәгә әллә ничек ятим булып күренде. Кинәт кенә хатынга бик ямансу булып китте.

Теплоходына кереп утыргандыр инде. Кесә телефонын алды бугай. Шалтыратыр. Шалтырата белсә... Телефонын юлда ук югалтмаса яки сатып

җибәрмәгән булса. Юк, алай итмәс. Яшь чакларда Сәлимәне кайларда гына йөртмәде бит ул. Гаярьлеге бар иде инде. Шул пенсиягә чыгу гына харап итте аның кешелеген. Менә кузгалды бит әле. Бәлки кеше арасында йөреп, рухы уянып кайтыр. Берәр эшкә тотыныр. Хас итсә, БМО рәисе булырлыгы бар аның.

И-и Сәлимә, иреңне ярты көн күрми торуга ук үлчәүнең әйбәт сыйфатлар тәлинкәсен авырайта башладың! Хатын, берьялгызы икәнлеген дә онытып, яңгыратып көлеп җибәрде. Шушы көлү белән бергә өйгә ингән ямансулык та таралып китте.

Хатын бер чынаяк сөт белән өч-дүрт прәннек ашады да, шуның белән хушланып, икенче каттагы йокы бүлмәсенә менеп китте. Урын хәстәрләде. Телевизор кабызып тормады. Кулына китап алды да рәхәт бер халәткә чумды. Ара-тирә, «кара тегене, шалтыратмый бит», кебегрәк уй гына борнап-борнап алды алуын. Тик ул уй да тамыр җибәреп тормады. Хатын йокыга оеды.

Ул кинәт уянды. Сискәнеп уянды. Сәгатькә карап алды: беренче егерме минут кына икән әле. «Җен-пәриләр төнге уникедән соң кубарыла», дигән уй башыннан сызылып үтте. Аннары бу уй, кара йомгак кебек отыры зурая барып, шомга әйләнде.

Нәрсә уятты аны? Нидән уянды ул? Бер йоклап киткәч, иртәнгә кадәр бүленмичә йоклый торган Сәлимә бит ул! Хатын кабат йоклап китә алмады. Тыңланып ята башлады.

Дөпелт!

Ни булыр бу? Мәче дияр иде, Сәлимә мәчесен юри тышта калдырды. Кыш түгел, тунмас, бөтен мәче халкы урамда хәзер. Кыштыр-мыштыр авазлар тагын кабатланды. Курку шомы куенгарак үрмәләде. Сәлимә караватыннан торып, тәрәзә янына килде. Ишегалдында ул-бу юк шикелле. Тавышлар өйдә — беренче катта! Тик хатын беренче катка төшәргә шүрләде. Гайрәтле генә итеп: «Ихсан, төн ката нишләп йөрүең? Эшеңне иртән эшләрсең!» — дип кычкырды. Имеш, аның таза беләкле ире өйдә, әле йокларга да ятмаган, уяу йөреп тора. Аны юк дип белеп, өйгә караклар кергәнме әллә дигән уйдан аваз салган иде.

Кайтарып эндәшүче булмады. Хатын кабат урынына барып ятты да тагын тыңлана башлады. Юкка гына курыккан бугай ла. Курыкканга куш димәсләр иде аны. Сәер халәт икән ул курку. Янәшәңдә кемдер барында игътибар да ителмәгән кыштырдаулар сискәндерә, моңынчы уйлап та карамаган нәрсәләр искә төшеп бимазалый, юк кына нәрсәләр өркетә. Ә бит күпләр бала-чага гына курка дип уйлый. Бала кешесе караңгыдан, әкиятләрдәге җен-пәриләрне, хәзергеләр мультфильмнардагы ямьсез монстрларныдыр инде, чын дип кабул итүдән шомлана. Моржа ачарга менгәндә, бәләкәй Сәлимәнең коты ботына төшә торган иде. Төннек авызыннан корымлы кул сузылыр да кызны караңгылыкка суырып алыр кебек иде. Яши-яши адәм баласы хорафатлардан арына, һәммә нәрсәгә аек акыл белән карый башлый бугай. Тик менә күпне ишетү, күп нәрсәдән хәбәрдар булу, телевидениедән ишетеп калган куркыныч хәлләр тәэсирендә кешеләрнең күңелендә барыбер шом яши. Ни булмас! Кара син аны, белгесезлек кенә түгел, күпне белү дә курку өчен сәбәп була ала икән.

Күпне белүдән курку бала вакытта да бар иде. Имештер, авылга Ык аръягындагы авылдан Будик килгән. Бар иде андый дивана кеше. Шул өй саен кереп йөри икән. Сәлимәләр очындагы бала-чага бөтенесе бер ишегалдына җыелып уйный торганнар иде. Будик хәбәре чыгуга, ни кояшлы, ни ямьле көнне өерләре белән бәләкәй өйгә кереп бикләнерләр дә, тәрәзәдән караганда үзләре күренмәслек почмакка сыенышып, тирләп-пешеп, өлкәннәрдән кем дә

булса берәү үзләрен бу бәладән йолып алганчы, коткарганчы утырырлар иде. Пышын-пышын гына сөйләшәләр, төрткәләшәләр, елашалар... Әмма барысына да кызык. Бу нindидер ләззәтле курку иде! Будикның, килеп, тәрәзәдән караганы булмады.

Авылның бердәнбер исереге, сәрхушләнеп, урамга чыгуга, капка бикләп кереп качу, бәлки, чын куркынычтан качу булгандыр әле ул. Ә менә чегәннәрдән нигә курыктылыр икән? Бала-чагасы итәгенә тагылган әби-сәбиләр дә, авыл башында чуар күлмәкле чегәннәр күренүгә, ишек-капка бикләргә ашыга торганнар иде. Күмәкләшеп куркуларда нindидер бәйрәм-уен төсмере бар иде. Бу куркуларның берсе дә чын курку булмаганга шулай ул.

Сәлимә әнә шулай үз халәтен вәземләп ята торгач, тынычланды, торабара аны йокы биләп алды. Иртән ул йокысы туеп, яхшы кәеф белән уянды. Ихсан диванында йомарланган песине күргәч, төнге шомлануның да сәбәбе аңлашылды. Хәерсез мәче ачык калган форточкадан юл тапкан икән. Мәченең гаебе юк. Сәлимә үзе ачыгавыз — сагайгач, форточканы тикшер иден. Алай ук өметсез куркак түгел икән әле. Куркуы сәбәпсез түгел — дөпелдәү чыннан да булган, хатын кыштырдауларны чыннан да ишеткән!

Шимбә көн. Эшкә барасы юк. Карлыган яфраклары өзеп кереп, тәмле итеп чәй пешерде. Тәнгә янәдән рәхәтлек ләззәте таралды. Көр күңел белән бакчасында казынды. Аннары кичәдән суынмаган мунчасын, йомычка ягып янартып, юынып чыкты. Кеше тавышы тансыклагач, радио кабызып җибәрде. Дөньяга музыка тулды. Бернинди курортларың кирәк түгел, билләһи. Ни тели — шуны эшли.

Көн ничек кенә озын булмасын, барыбер кич житте. Аның артыннан төн килде. Төн белән бергә балачактан ук калган карангыдан шикләнү күзәнәге янәдән терелде. Бүген инде хатын бөтен тәрәзәләрне тикшереп чыкты. Капка бикле, ишек бикле. Тик менә ихатаның чокырга чыга торган ягы нығытылмаган. Жәнлек тә, кеше дә үтеп йөри торган. Йә сәнә, чит кеше анда аралык барын каян белсен! Юрап утырмасын әле...

Ихсан бәгырькәе шалтыратып алды. Аның хәлләр көйлегә охшап тора. Тавышы да аек ишетелде. Йә ярар, юләр түгел лә ул кеше арасында затсызланып йөрергә. «Суны сагынганмын икән, — моряк булган кеше ләбаса. — Төне буе Иделгә карап утырдым, таң белән генә кереп яттым каютага», — ди.

— Бер тирәдә уяу булып, бер тирәдә йокларга ятканбыз икән, — дип көлештеләр. — Ара ерагайгач, уртаклыклар да табыла башлады.

Сәлимә, әлбәттә, төнлә курыктым, дип, сер биреп тормады. «Ярты төнгә кадәр башлаган эшләремне бетерә алмый утырдым», — дип хәйләләде. Миннән башка шул кирәк сина дип, ирәймәсен әле. Бүген курыкмас ул — төн артыннан якты таң туганын, яктының шомны йотканын белмиме әллә ул?!

Ярар, Ихсаны исән, капка бикле, ишек бикле, форточкалар ябык — шушы жөмләне дога сыман кабатлый торгач, керфекләренә йокы эленде. Әмма йокысы барыбер тирән йокы түгел. Күңелдә әллә ниткән бер Сак уяу тора. Онытылып булмый. Менә-менә сикереп торырга тиешле кеше кебек яту үзе үк йокыны качыра. Нигә соң ул көндез кыю, тәвәккәл дә, төнлә жебеп төшә? Диванда яткан Ихсан аны берәр афәттән коткарамы инде, йә? Димәк, кеше афәттән түгел, ялгызлык халәтеннән курка. Алай дип санаганда, күп фатирлы йортларда күмәкләшеп яшәү — кешене дөм ялгызлыктан, нигезсез куркудан аралый торган әйбәт нәрсә! Абау, әстәгъфирулла, әгәр дә мәгәр, Сәлимә Ихсаннан калса, йортын сатар, шәһәр фатирына күченер. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла! Менә нинди йогышсыз уйлар керә башлады ялгыз башына. Бу бит әле ялгыз үтәчәк төннәрнең икенчесе генә.

Сәлимә, курыкканда да, дога тиеш дип уйлаганда да укый торган «Колһуалла»сын кабатлап, уң ягына әйләнеп ятты. Инде йоклар кебек. Сулышы тигезләнә башлаган бер мәлдә...

Чылтыр!!!

Аһ, тәрәзә пыяласын ватып керделәр!

Веранда кыегыннан менгәннәр!

Сәлимәнең чәч төпләренә кадәр салкын тир бәреп чыкты. Сикереп торды. Озын йокы күлмәгеннән тораташ кебек катып тик тора.

Нишләсен?

Кая барсын?

Кемгә кычкырсын?

Кая качсын?!

Телефоны кайда?

Сәлимә, песи кебек кенә сак басып, зал ишеге янына килде. Ишек ачык икән. Зал уртасында — идәндә озын чиратлар торып сатып алган зонтик-люстрасы көл булып ята.

— Син икәнсең! — Бу ике сүзгә Сәлимәнең куркудан котылу, имин калу җиңеллеге сыйган иде. — Син икәнсең, нәгъләт.

Түшәмдә люстра эленгән кадакка ни өчен нәкъ менә бу төндә сынарга кирәк булгандыр? Егерме ел тик торган кадак бит ул, йә! Ана бит беркем тимәгән, беркем аны какшатмаган. Ә ул нәкъ менә Сәлимә өйдә ялгызы, курка-курка төн кичкәндә сынган!

Сәлимә пыяла вагын җыеп тормады. Урынына барып ятты да, буласы булган дигәндәй, тынычланып тирән йокыга талды.

Иртәгесен якшәмбе бит әле. Сәлимә, камыр куеп, пәрәмәчләр пешерде, кызын, оныкларын дәште. Кияү эштә көнне кыз әнисе янында иркәләнеп, оныклары сыйланып китсеннәр әле. Юк, китмәсеннәр — куна калсыннар!

Балалар белән көн тиз һәм рәхәт үтте. Өйнең астын-өскә китерде инде малайлар. Китерсеннәр әйдә. Үзенекеләр! Кадерлеләр!

— Иртәгә балаларга мәктәпкә! — дип, кызы әйберләрен җыештыра башлагач, Сәлимәнең куенына тагын төн шомы үрләгәндәй тоелды. Шуна күрә гүпчем тәвәккәлләнеп:

— Малайлар калсын. Миндә кунсыннар. Иртән үзем озатырмын, — диде.

Кызы башта ризалашмаган иде дә, аннары әнисенең нигә өтәләнүен төшенде булса кирәк, кечесен дәү әни янында калдырып китәргә күнде.

— Аязы калса да ярый. Каникуллары башланды инде аларның. — Аннары, сабыеның башыннан сыйпап: — Бабаң кайтканчы дәү әниенә иптәш булырсың, улым, яме, — диде.

— И-и, мондый да иптәш барында!

Кино карап, китап укып, бик тиз үтеп китте кич дигәне. Ни гаҗәп, тәрәзәләргә капланган төн бүген бер дә шомлы күренмәде. Урам яктан ишетелгән авазларда да тормыш гаме генә абайланды.

Почмакларга елышкан күләгәләр, өйдә ир заты барын сизеп, дәһшәтен һич тә сиздермәде. Җен-парийләрнең ир затыннан куркулары хак икән.

Сәлимә янында җәйрәп, йокыга изрәгән оныгына берара яратып, олы сөенеч белән карап ятты. Менә шушы бармак башы чаклы малай берзаман егет булып, ир булып җитешәчәк бит инде. «Әбием, минем белән ят, яме, күчеп ятма, яме», — дип, дәү әнисенә бер олы терәк, яклаучы итеп караган малай берзаман үзе Сәлимәнең таянычы булачак. Ә бүген Сәлимә үзе сабый йокысын саклаучы! Баласын яклаганда хатын-кыз чамасыз гайрәтле була ул.

Һи-һи-һи! Гайрәтләнгән иде ул бервакытны.

Ире командировкада. Нарасый кызы бишектә тирбәлеп ята. Бишек жырын бер генә сулышка да туктатасы түгел, бәбкәч шунда ук кыймылдый башлый. Төннәр буе жырлатты инде анасын. Инде төннең яртысы узгач булыр, ишеккә килделәр. Торулары – берәүнең сыер абзары белән тоташкан сипушкада. Хужалар да төнге сменалы эштә. Ә бу сипушка шәһәр читенең бер очы сазлыкка чыга торган урамында. Димәк, ана белән бала кара төнне үзләре генә кичеп яталар.

Ишектә кемдер бар! Башта ишек тоткасын болай гына тарткаладылар. Аннары кага ук башладылар. Яшь ана тәмам куырылды. Нишлисен белми ул. Бала да тәмам уянды. Сыер да мөгрәп куйды.

Инде ишеккә нindидер әйбер белән шак та шок суга башладылар. Такта-фәлән белән бугай! Болай булгач, ишекне ватып керә бит инде болар. Бәлки кагучы берәү генәдер. Икәү булсалар, сөйләшкәләп куярлар иде.

Димәк, яшь хатынга бермә-бер каршы торасы! Тора да ул. Бишек тибрәтеп кенә утыру ярамас. Сәлимә, мич катында яткан балтаны алып, ишек төбенә килеп басты. Тынын да алмый. Ала да алмый иде бугай. Бөтен куәте – балта сабына ябышкан кулларында. Залим ишекне ватып керүгә, башына балта белән алачак! Кызын харап иттермәячәк Сәлимә!

Бер мизгелгә ишеккә такта белән тондыру тукталды. Ишек артында да тыңлап торалар бугай. Күпмедер тынлыктан соң тәрәзәгә кагылдылар.

– Сәлимә, ач! Мин бит бу!

Ире кайткан төн уртасында. Шундук тәрәзәгә килеп, иплэп кенә шакыса, ни була иде инде, йә?! Бала баккан хатынның йокысы сак булганын белмиме инде ул? Йөрәге ярылып үлә иде бит хатыны.

Хатирәләрнең шул ноктасына житкәндә генә капка кага башладылар. Вәт хикмәти Хода. Татар юрап китерер, ди. Баягы хатирәләре Сәлимәне төннең мондый борылышына әзерләп куйган идеме соң – дәү әни, фонарен алып ишегалдына чыкты. Куркып, койрык кысып утыру эш түгел. Куркынычның күзенә багарга кирәк.

– Абзый, абзый! – утын китердем, – диде капка артындагы тавыш.

Кәрим малае икән! Ихсан тәки утын хакында сөйләшкән, күрәмсең. Менә бит, гел юкка әрләгән ирен.

– Улым! Утының ни төсле утын соң. Туралганмы, каен утынымы?

– Нәкъ абзый әйткәнчә! Каен түмәрләре.

– Урамга гына бушат.

– Юк, күрше апа, ярамый. Капка төбендә күрмәсеннәр. Төнлә тапкан мал бит.

Аһ, алай икән әле. Кушып китерткәч, алып кит утынынны, дип тә булмый. Төн уртасында, ялгызы гына чагында киереп капка ачасы да килми:

– И-и, энем, самосвалың әржәсеннән ишегалдына ташларга бик уңай лабаса! Шулай гына ит сәнә... Өстәп түләрмен...

Берара дөбердәп алгач, түмәрләр ишегалдына тәгәрәде. Менә утын да булды.

– Энем, акчасын иртән анаңа кертермен. Акчаны төнлә түгел, кичтән дә бирергә ярамый кулга. Рәхмәт яусын үзенә, көндезге эшләрең дә унсын.

Күрше малае сүз кайтарып тормады. Тиз генә машинасын кабызды да китеп барды. Капка шакыган кеше гел явыз ният белән генә йөрми ул. Курка белеп куркырга кирәк. Әмма да мәгәр, Ихсаны исән-сау йөреп кайтса, Сәлимә аны моннан ары, тегендә бар, монда кит, дип йөдәтмәс. Йөдәтмәс кенә түгел, бер яры да жибәрмәс! Ятсын шунда кычыткан арасында.

# «ҖИР ШАРЫ РӘИСЕ» ВЕЛИМИР ХЛЕБНИКОВ

ТУУЫНА 130 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Поэтик фикерләүнең сәерлеге сәбәпле аңлашылмаган, шуның аркасында серле булып тоелган, серлелеге белән кызыксыну уяткан шагыйрьләр дөнья әдәбиятында бик күп түгел. Рус әдәбиятында шундыйларның берсе һәм иң күренеклесе, һичшиксез, Велимир Хлебников.

Ул айның 28нче көнендә туган, катлаулы математик тикшеренүләр аша 28 саны кешелек дөньясының серләрен ача ала торган ачкыч булырга тиеш дигән фикергә килгән һәм шул юнәлештә гомере буе тикшеренүләр алып барган, фәнни эксперимент белән әдәби иҗатны берләштерергә омтылган. Шундый идеяләргә бирелеп китеп, Виктор Владимирович үз исемен Велимирга (Дөнья белән идарә итү) үзгәрткән, үзен Җир Шары рәисе (Председатель Земного Шара) дип атаган. Бу титул ана Сергей Есенин тәкъдиме белән 1920 елда Харьков шәһәр театрында рәсми рәвештә бирелә. Парадокслардан хасил бу шәхесне Маяковский, Бурлюк, Кручёных һәм башкалар «заманабызның бөек даһие», хәтта «сүзләр Лобачевские» дип атаганнар, шул ук вакытта «Хлебников акылдан язган» дип әйтүчеләр дә табылган.

Аның исемен мин беренче мәртәбә футуризмга кагылышлы рәвештә ишеттем. Безгә, үткән гасырның 60нчы еллар студентларына, профессорларыбыз, әдәбиятта формализм үрнәге итеп, Велимир Хлебниковның «Заклятие смехом» шигырен укыдылар:

*О, рассмейтесь, смехачи!*
*О, засмейтесь, смехачи!*
*Что смеются смехами, что смеянствуют смеяльно,*
*О, засмейтесь усмеяльно!..* һ.б.

Реалистик әдәбият традицияләрендә тәрбияләнгән, шигырьнең мәгънәсенә өстенлек биргән, фикер матурлыгына сокланган укучыга мондый шигырьләр, әлбәттә, сәер булып күренде, «житди кеше эшеме икән бу?» дигәнрәк шикләнү дә тудырды.

Әйтергә кирәк, Хлебников 1908-1909 елларда, ягъни иҗатының башлангыч чорында, рус һәм дөнья әдәбиятындагы революцион янарышка бик житди караган, һәм аның карашы тотрыклы булган. Ул, хәтта ун елдан соң да, фикерен үзгәртмәгән, киресенчә, яшьлек мавыгуларының нигезен теоретик базис белән ныгыткан. 1920 елда «О стихах» дигән мәкаләсендә ул, үз фикерен куәтләп, күп халыкларның догалары үзләренә аңлашылмаган телдә язылган, шаманнарның сәер сүз тезмәләре дә конкрет мәгънәгә ия түгел, ә шулай да алар кешегә гаҗәеп нык тәэсир итә, дип яза. Шагыйрь Велимир Хлебников өчен иң мөһиме: «Стихи могут быть понятными, могут быть непонятными, но должны быть хороши, должны быть истовенными[1]...»

Шулай да, Хлебниковның эксперимент рәвешендә, әдәби-эстетик модага бирелеп, неологизмнарга, стильләштерүгә омтылып, «акыл арьягы» («заумь») теле белән язган шигырьләрендә мәгънә бер дә юк, дип әйтү зур хата булыр иде. Аларга, күпмедер дәрәҗәдә, суггестивлык, ягъни, гади логика белән әйтеп биреп булмаган хисләрне, тойгыларны сиздерү, уяту, көтелмәгән фикер бәйләнешләре тудыру, ягъни, ассоциативлык хас.

Билгеле, Велимир Хлебников футуризм колы булып калмаган. Аның төп иҗаты, төп әсәрләре аңлаешлы тел белән, ләкин авангардчыларга хас алымнар белән язылган. Ләкин аларны беркатлы дип һич кенә дә әйтеп булмый. Укыр өчен дә, төбенәчә төшеп аңлар өчен дә алар, чыннан да, шактый катлаулы. Чын футуристик шигырьләрне башка телгә тәрҗемә итү мөмкин түгел, чөнки алар фәкать шул тел нигезендә, андагы сүзләргә шул телгә хас, ләкин көтелмәгәнчә үзгәрешләр кертеп язылa. Мәсәлән, «О, достоевскиймо бегущей тучи! О, пушкиноты млеющего полдня!»

[1] Истовенный *(неологизм)* — подлинный, *татарчасы* — чын.

яки «Крылышкуя золотописьмом тончайших жил...» кебек җөмләләр рус телен белүчеләргә күпмедер аңлашыла. Ләкин аларны татар теленә ничек тәрҗемә итмәк кирәк?! Булмый, чөнки мөмкин түгел! Ләкин татар телендә, телнең үз хасиятләре нигезендә чын «татар футуризмы» белән шөгыльләнеп була. Моны заманасында Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Хәсән Туфаннар эшләп караганнар. Ләкин бу — рус әдәбияты йогынтысында, Хлебников, Маяковский, Каменский, Бурлюкларга иярүдән барлыкка килгән мода гына булган, дип уйлыйм мин.

Ә Велимир Хлебниковның күпчелек поэмаларын, шигырьләрен, драма әсәрләрен, авыр булса да, тәрҗемә итеп була. Һәм мин шулай эшләдем дә, чөнки ул — гаҗәеп шагыйрь булу белән беррәттән, күпкырлы шәхес тә, кызыклы галим дә, Казан кешесе дә. Казанның бөек кешеләре белән мактанганда, без һәрвакыт, хаклы рәвештә, рус язучыларыннан Гаврила Державин, Лев Толстой, Сергей Аксаков, Евгений Боратынский, Максим Горький исемнәрен атыйбыз, Велимир Хлебниковны никтер онытабыз. Ә ул — Казанның олы мактанычы һәм горурлыгы. Тора-бара Казанда Хлебников музее да, Хлебников урамы да барлыкка килер әле, дип уйлыйм мин.

Виктор Владимирович Хлебников 1885 елның 28 октябрендә калмык далаларында, орнитолог-галим гаиләсендә дөньяга килә. 1898 елдан алып 1903 елгача Казанның 3нче ирләр гимназиясендә укый һәм аны тәмамлый. Шул елларда күренекле рәссам-нәкышчы (живописец) Павел Беньковтан[2] хосусый дәресләр ала. Рәссамлык сәләте аңа, еллар үткәч, В.Маяковский белән бергә «Окна РОСТА»да эшләргә мөмкинлек бирә.

1903 елда В.Хлебников Казан университетының физика-математика факультетына укырга керә һәм Лобачевский геометриясе, саннар сере белән мавыгып китә. Ул «яңа космик аң» турында уйлана һәм математик хисаплау ысулы белән «вакыт кануннарын» ачыкларга тырыша, шуларны колачлый алырдай, барлык кешелек дөньясына да аңлаешлы «сверхъязык» булдыру идеясенә килә. Ә бу идея аны футуристлар, ягъни «киләчәкчеләр», хәрәкәтенә алып керә.

Хлебников беренче әсәрләрен дә Казанда яшәгәндә яза, димәк, аның шагыйрьлеге безнең шәһәрдә ачылып китә. Ләкин җанына тынгы таба алмаган, бик күп нәрсәләр белән кызыксынган, ялганмасны ялгарга, бүленмәсне бүләргә, фонетика белән математиканы кушарга хыялланган яшь шагыйрь 1908 елның көзендә, Казан университетын ташлап, укуын Санкт-Петербург университетының табигать белеме факультетында дәвам итә. 1909 елда шул ук университетның тарих-филология факультетына күчә. Ләкин 1911 елның июнендә, «за невзнос платы» сәбәпле, университеттан чыгарыла. Шул көннән аның «сукбайлык» тормышы башлана. Ул ил буйлап сәяхәт итә, төрле шәһәрләрдә була, Октябрь революциясеннән соң вакыты-вакыты белән эшләп тә ала. 1922 елның 28 (!) июнендә Новгород өлкәсендә, Санталово дигән авылның бер мунчасында гаиләсез, йорт-җирсез, акчасыз, бөтен язганнарын һәм кирәк-ярагын иске капчыкта асып йөрткән бөек шагыйрь, 37 яшенә дә җитә алмыйча, вафат була. Шактый еллар үткәч, Велимир Хлебниковның җәсәден Мәскәүнең танылган шәхесләр күмелә торган Новодевичье монастыре зиратына күчереп күмәләр.

Синтетик аңга омтылган, энциклопедик белемле Велимир Хлебниковның күпкырлы иҗаты күләмле һәм зур. Аның шигырьләре, поэмалары, драма әсәрләре, фәнни-теоретик хезмәтләре 1928-1933 елларда 5 том булып нәшер ителгән һәм әледән- әле томлыклар, сайланмалар, җыентыклар булып дөнья күрә торалар. Димәк, Җир Шары рәисенең күпкырлы иҗаты һаман да актуаль.

Хлебников әсәрләренең башка телләргә, бигрәк тә — төрки телләргә, тәрҗемә ителү-ителмәве миңа билгесез. Һәрхәлдә, мин таба алмадым. Шуңа күрә дә бу сәер шагыйрьнең сәер, фәкать рус теленә генә хас «акыл арьягы» үзенчәлекләре нигезендә язылган шигырьләрен татар теле мөмкинлекләренә салып карыйсым килде. Бәлки, тәрҗемә шигырьләр укучыларга кытыршы, мантыйксыз, мәгънәсез, башы-койрыгы булмаган фрагментлар кебек тоелырлар. Алар хаклы булыр, чөнки мин тәрҗемәләремдә Велимир Хлебников шигырьләренең төп хасиятен татар телендә дә сакларга тырыштым. Ләкин барысын да саклау мөмкин түгел. Минем бу хезмәтем, бәлки, Хлебников шигырьләрен төрки телләргә тәрҗемә итүнең беренче очрагыдыр...

**Ренат ХАРИС**

[2] П.П. Беньковның (1872-1949) иң күренекле әсәрләреннән берсе булган Галимҗан Ибраһимов портреты Казан Сынлы сәнгать музеенда саклана.



## Велимир Хлебников

***

Чибәрлекнең карлы-кодрәте һәм
Матур төшләр күргән күзләрен,
Төн уртасы төсле толымнарын,
Тилерттеләр минем сүзләрне.
Шатлык үреп биргән бу такыя
Нинди вәсвәсәле, карагач...
Ялгызлыкта озак очкан козгын
Калдыргандыр аны, арыгач.
Буй-сынының кардай аклыгында
Тиккә түгел мондый купшылык —
Бер-беренә ишетелсен кеше
Галәм өне булып, жыр булып.

***

Үлгәндә атлар — сулыйлар,
Үлгәндә үләннәр — корыйлар,
Үлгәндә кояшлар — сүнәләр,
Үлгәндә кешеләр — жырлыйлар.

### Ягъни-кешеләр

***(Па-люди[3])***

Кош, биеклеккә омтылса,
Оча күккә,
Панна, биеклеккә омтылса,
Кия биек үкчә.
Аяк киемем булмаганда мин,
Барып, базардан аламын.
Нинидер бер борынсызы
Сатып ала балавыз.
Жаны-рухы булмаганда, халык
Керергә мәжбүр күршеләренә
Һәм түләргә олы түләм —
Мәхрүм ителгән булса жан-рухтан!..

[3] Рус телендә «пасынок» дигән сүз бар. «Па-люди» шуңа охшатып ясалган неологизм. «Па» — якобы мәгънәсендә.

***

Еллар, кешеләр, бар халыклар
Мәңгелеккә китәләр
Агымсу кебек.
Табигатьнең сыгылмалы көзгесендә
Йолдызлар — ятьмә, без — балыклар,
Аллалар — караңгылык янында шәүлә.

## Курган

Татар сөңгесе кагылган һәрни
Җиргә бөгелеп төшә дә әрни.
Хатын-кызларны ялангач иткән
Себер гаскәре Себергә киткән.

Курган батыры, үләрдән элек,
Кыскан Еврейнең тимер битлеген[4].

Сызгыра йомран, якында өне,
Тиз үтә тора курганның көне.

Төлке өере уйнаган була,
Чегән урлаган ат чаба дулап,
Бер запорожец курган астында
Ята гасырлар сәгатен тыңлап.

## Азатлык турында

Акыллы, бердәм өермә булып
Алиһә[5] дәшкән якка ыргылыйк!
Аккош канаты итеп, кешеләр
Хезмәт байрагы күтәргән анда.

Азатлык күзе куырып ала,
Чагыштыр: ялкын — бары тик суык!
Җирдә образлар[6] инде булса да!
Яңасын ясар аның ачлыгы.

Бердәм кузгалыйк җырларга таба!
Бөек азатлык артыннан — алга!
Җиргә әйләнсәк — янә калкырбыз,
Һәммәбезгә җан керер яңадан!

Без сокландыргыч юл буйлап атлыйк,
Адымнарыбыз шавын ишетеп.
Әгәр аллалар богауда булса,
Аллаларны да без азат итик!

***

Кешеләр!
Кояш яктысына батырып дөмектерик дошманлашуны!
Уйдырма йолдызлар плащын киеп йөриләр
Кыю ният балалары,
Кыю гакыл улы —
Көтәм шуны.

***

Мәскәү, син кем?
Сихерлисеңме, әллә сихерләндеңме үзең?
Азатлык чүкисеңме,
Әллә богаулымы үзең?
Маңгаеңны нинди уйлар җыерчыклый?
Син — дөньякүләм заговорчы.
Башка вакытта син, бәлки,
Якты тәрәзәдерсең,
Әй, бәлки, тәҗрибәле мәчедерсең:
Шәкертләре арасында,
Язу өстәле янында,

---

[4] Иисус Христоска ишарә.

[5] Шагыйрь азатлыкны алиһә дип атый. *(Р.Х.)*

[6] Образлар — тәреләр, иконалар.

Иске киталар каршында
Катып калган
Акыллы галимнәр,
Үткер пычаклар астында,
Тәрегә кадакларга кушамы фәннәрне?
О, үзгә йөз еллыклар кызы,
О, дары тулы мичкә —
Богаулар шартлаткычы.

## Баш тарту

Үлем карарын
Имзалауга караганда,
Йолдызларга карау
Күпкә рәхәтрәк мина.
Мина, бакча аша үткән чакта,
Гөл-чәчәкләрнен, баш иеп,
«Ул үзе!» дип, пышылдавын
Тынлап йөрү
Мине үтерергә теләүчеләрне
Үтерергә җыенган сакчыларнын
Кара мылтыкларын күрүдән
Күпкә рәхәтрәк.
Шуна күрә дә мин
Беркайчан да,
Әйе, беркайчан да Хаким булмаячакмын!

***

Халыкта өметсезлек. Җан елый.
Арыш көлтәсен җиргә бәреп,
Ул көнчыгышка китеп барды,
Самолёт җырына ияреп.

Дала да, урләр дә —
Ялкында һәммәсе.

Балалар күзендә
Батый шәүләсе.

Башак юк... аларны ачудан
Ходай орган чак...
Көнчыгышка кача качак.

***

*(Вафатына 1 ай кала язылган шигырь. — Р.Х.)*

Тагын да, тагын да
Мин сезгә
Йолдыз.
Кайгы-хәсрәт дингезчегә,
Әгәр дә каегына һәм йолдызына
Ялгыш юнәлеш
Сайласа:
Кыяга бәрелеп ватылачак,
Сайга утырачак.
Кайгы-хәсрәт сезгә дә,
Мина таба йөрәк юнәлешегезне
Дөрес алмаучылар:
Ташка бәрелеп уләчәксез,
Ташлар сездән көләчәк,
Сез миннән
Көлгән кебек.

**Ренат ХАРИС** *тәрҗемәләре*

# *«Казан утлары» архивыннан*



*Язучылар очрашкач. Сулдан уңга: Зөфәр Фәтхетдинов, Ямил Мостафин, Зәки Нури, Ринат Мөхәммәдиев. Үткән гасырның 80нче еллары.*

*Мәгъсүм Насыйбуллин (1925-2009) озак еллар хокук саклау органнарында эшләгән, күп санлы детектив әсәрләр язган юрист-язучы.*





*Төрле елларда «Сөембикә» («Азат хатын») журналының баш мөхәррире булып эшләгән каләм ияләре Венера Ихсанова (уңнан сулга), Роза Туфитуллова, Фирая Бәдретдинова М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында басманың 80 еллыгына багышланган тантанада. Р.Туфитуллованың үзенең дә бу айда юбилей бәйрәме. Артта – аның җәмәгате Миргалим Туфитуллов. 2006 ел.*



*Ике бөек замандаш: Бакый Урманче (сулда) һәм Нәкый Исәнбәт. Үткән гасырның 80нче еллары.*



*Мәшһүр Матбугат йорты (Бауман, 19)! Кемнәр генә күтәрелмәде бу баскычлардан! Шагыйрьләр Сибгат Хәким һәм Равил Фәйзуллин. 1971 ел.*




*Хаҗ сәфәрендә булган бер төркем артистлар Җиддә шәһәренең Рамада кунак йорты каршында. Сулдан уңга: Айдар Хафиз, Наил Шәйхетдинов, Халил Мәхмүтов, Исламия Мәхмүтова, Идрис Мәсгуди, Юныс Сафиуллин. 2007 ел.*

# ЧИГЕНҮМЕ, ҖИҢЕЛҮМЕ?

«ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ»

*Әңгәмәдә катнаштылар: Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты директоры, тарих фәннәре докторы, академик **Рафаэль Хәким**, Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре **Разил Вәлиев**, сәясмән (политолог) **Фәндәс Сафиуллин**, Тарих институтының баш фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы **Дамир Исхаков**.*

*Глобаль дөнья үзе дә, аерым регионнар да катлаулы чорлар кичерә. Татарстан җәмһүрияте һәм татар халкының хәзерге хәл-әхвәлләре ничек? Соңгы ике дистә елда ирешелгәннәр сакланамы, акланамы? Шул сәбәпле күп-күп борчулы сораулар туа. Редакция өстәле янында — аларга җавап бирә алырлык затлар. Әңгәмәне журналның бүлек мөхәррире **Рәфикъ Юныс** алып бара.*

**Р.Юныс:**

*— Әңгәмәне Тарих институты директоры Рафаэль Хәким белән кыска гәптән башлап җибәрик әле. Рафаэль әфәнде, безнең икәү гәпләшкәннәр булды инде. 1996 елны: «Демократия көчәер генә, минемчә», — дидегез сез. Ә менә болары 2004 елны әйтелгән сүзләр: «Рәсәйнең мондый сәясәте озак бара алмый. Чөнки дәүләтне җимерүгә илтә». «Татарстанның киләчәге өчен хафаланмыйм мин. Татарстанны элекке хәлгә төшерә алмаячаклар». Хәзер ни диярсез?*

**Р.Хәким:**



— Демократия бүген дә бар. Ләкин ни дәрәҗәдә ул? Без татарча сөйли алабыз бит, мәкаләләр бастырабыз, яхшымы-начармы, телевидение эшли. Теге совет чоры белән чагыштырганда, без күп алдарак хәзер. Мин шул күзлектән карыйм. Без көткәннәр тиз генә килми, әйе. Тарихчы өчен ун-егерме ел аз вакыт ул. Тарихта тагын революция дигән гыйбрәтле нәрсәләр дә бар. Революцияләрдән иркенлек килә, аннан соң аны кыса башлыйлар. Француз революциясеннән соң да, әнә, Рәсәйнекеннән соң да шулай булды. 1929 елга хәтле татар хөр яшәде. 1929да инде бөтенесен дә яптылар. Хәзер вакытлы матбугат бик сыек, телевидение кысылган, ләкин интернетта ни генә әйтмиләр. Ә федерализм дигәндә, без күпмедер файдаландык аннан. Бүтәннәр бит бу юл белән бармады, уйнады гына. «Парад суверенитетов» булды. Тарихи күзлектән карасак, Рәсәй киләчәктә демократиясез яши алмаячак. Бер үзәктән идарә итеп булмый аны, артык зур ул.

*— Суверенлык декларациясе игълан иттек, референдум үткәрдек, аның нәтиҗәсенә таянган Конституция кабул иттек, Рәсәй белән Шартнамәгә дә тиендек хәтта. Ягъни бөтен мөмкинлекләр дә ачылды диярлек. Һәм шуннан соң һич көтмәгәндә чигенү башланды. Ни дип аңларга икән моны?*

— Элек берничә республика эшли иде мөстәкыйльлек юнәлешендә. Япа-ялгыз торып калдык. Күршеләр дә качты хәтта. Шуннан соң кысу башланды.

*— Киресенчә түгелме соң бу? Сезгә суверенлык бирсәк, башкаларга да бирәсе була дип тукып торды Мәскәү. Ләкин башкалар чәчелеп-сибелеп, суверенлыгын референдум белән ныгыткан Татарстан гына торып калгач, Мәскәү кулындагы бу хәлсез дәлил дә юкка чыкты бит инде. Чигенергә нинди сәбәп бар соң, алайса? Без*

*артында ни торганын белмәгән куркумы? Ә, бәлки, шәхси мәнфәгатьләр дә килеп чыккандыр? Ельцин «Обогащайтесь!» дип оран салгач?*

— Анысы бар анын. Булды инде. Ә Шартнамәне закон чыгарып юк иттеләр. Вакыты бетте дип. 2007 елгы янартылган Шартнамә барып чыксын дип тагын өч ел көрәшәсе булды! Ничек кенә кысмадылар, булмасын дип. Барыбер янарттык Шартнамәне!!!

Әйткәнемчә, һәр революциянең менү вакыты һәм төшү вакыты була. Аны узарга кирәк. Мина калса, Татарстан шәп файдаланды — суверенитет еллары дип атыйбыз бит инде — шул еллардан. Икътисадны ныгытты. Заманында Солтангалиев белән Галимжан Ибраһимов арасында бәхәс барган. Галимжан Ибраһимов халыкны үстерер өчен иң алда мәдәният булырга тиеш, ди. Солтангалиев исә иң әүвәл икътисадны ныгытырга кирәк, шунда гына халык сакланып кала, ди. Икътисадың булмаса, йә, мәдәниятне ничек аякка бастырасың инде?

*— «Без икътисадта үз сәясәтебезне кора алмадык, уртак икътисади кыр дип мавыктык», — 16 ел элек Рафаэль Хәким шулай дип тә әйткән иде. Татарстандагы завод-фабрикаларның нибары 2 проценты гына Татарстанга караган бит әлек. Компрессор заводы директоры мәрхүм Әхмәт Галиевнең фидакарь башлангычы аларны 92 процентка җиткерергә мөмкинлек бирде. Үткән елны: «Сез башлаган теге олы эштән ни калды?» — дип сорагач, Әхмәт абый: «Берни дә калмады. Янә бар да Россия кулында хәзер», — диде. «Безнең хатабыз нидә?» — дигән соравыма исә җавап мондый булды: «Мөстәкыйльлекне якламау. Чигендек. Нык чигендек. Яуланган бөтен нәрсәне дә диярлек җуйдык».*

— Юк, ике хәрби завод кына Мәскәүнеке. «Татнефть» — Татарстанныкы, бюджетның яртысы шуннан. «Таиф» та тулысынча бездә.

*— Әхмәт абыйның Компрессор заводыннан башланган иде «бөек күчеш». Мәскәүдәге «Гидравлик машиналар системасы» дигән компанияләр төркеменең бер өлеше ул хәзер! Гомумән, керемнәрнең Мәскәүгә күчә торган өлеше күп артты бит инде.*

— Әйе, 1994 елгы Шартнамә буенча бу 22-25 процент иде, ләкин фәлән елга кадәр дип куелган иде бу, ул вакыт үтте, Мәскәү өлеше артты, әйе.

Тәнкыйтьләү җиңел ул. Бүген мин кайсы якка барганыбызны карыйм. Рәсәйдә кризис булса да, без әле алга барабыз. Заводлар ачылып тора. Өмет бар. Халык рухланган. Мин менә авылларга да йөрим, мәктәпләрдә дә булам. Әле форумнар да уздырабыз — укучылар белән. Ул яктан бернинди сүрелү юк. Бетми әле халык. Әле тиз генә бирешергә җыенмый. Мәктәпләрдә дә эш бара... Күпме бизнесменнар йөри — акчалары капчык-капчык.

*— Ә сез, татарлар череп баесын, дидегез.*

— Череп баесын ул, мин бит әле намусын онытсын дип әйтмәдем. Революциягә кадәр кем татарның мәдәниятен тотты? Байлар гына.

*— Әйе, мәгариф системасы тулаем шулар иңендә булган. Сезне нәрсә борчый хәзер?*

— Шул ук мәгариф. Бу өлкәдә соңгы елларда күп эшләнде. Әмма эшлисе тагын да күбрәк.

*— Энгель Фәттахов башкачарак эшләп китте кебек бит.*

— Тагын бер кат әйтәм: кешедән тора. Аның нәрсәсе шатландыра: ул татарча сөйләшә. Элеккесе гомумән татарча сөйләшми иде.

*— Сез бит инде безнең Тарих институты директоры гына түгел, элек-электән милли хәрәкәт җитәкчеләреннән берсе дә. Татар интеллигенциясе, милли интеллигенция бармы ул?*

— Менә шул милли дулкын көчәеп, аң үсеп килгәндә, кинәт шулай бар да киселү-өзелү — милли хәрәкәткә дә йогынтысын ясады. Беләсезме, мин бер 15 ел ялынып йөрим язучыларга — языгыз милли тарих, милли хәрәкәтебез буенча гади китаплар, дип. Нигә язмадылар? Кайда интеллигенция? Без ярый шундый журналистны таптык — ничә меңләгән журналист арасыннан. Айгөл Шәрәфиева язды балалар өчен.

*— «Без әле һаман меңләгән кеше җыеп, кул күтәреп, нидер хәл итеп була дип уйлыйбыз... Өч кеше җыелсын, әмма фикер туплансын» — 1996 елны гәпләшкәндә шулай дигән идегез. Хәзер исә фикергә генә терәлмәде безнең хәл. Тәвәккәллек кирәк, кыюлык кирәк, чигенмәскә кирәк.*

*Сезнең менә бу 7 томлык «Татар тарихы» — могҗиза ул. Гади генә эшләмәдегез сез аны, чит ил галимнәрен дә катнаштырып, объектив тарих итәргә омтылып.*

— Нинди дәүләт эшләде аны тагын? Казакъстанмы, Төрекмәнстанмы? Рәсәйдә дә юк әле. Аны Мәскәүдә дә тәнкыйтьли алмыйлар — алардагы галимнәрне дә керттек. Бөтен дөнья буенча — күпме кулай галим бар, күпме университет. Күрмиләр! Татар тарихы кемгә кирәк соң ул? Менә, әзер булса, бәйләнергә журналист бар, шул ук татар. Ә булышканы урыс булып чыкты, Олег Морозов.

*— Беләм мин Морозовны. Миңа «Татарстан референдумы» дигән китабыма да кергән бик кирәкле мәгълүмат бирде ул. Безнең референдумны яклап СССР Югары Советы рәисе Хасбулатов белән бәхәскә керүдән дә курыкмаган кеше бу!*

*Рәсәй демократиягә килер, дисез сез. Ләкин демократ дигәннәре дә Рәсәйдә беркайчан да милли мәсьәләдә демократ булмыйлар шул. Ике галим — Андрей Сахаров белән Юрий Афанасьев кына искәрмә була ала дыр монда.*

— Аның бүтән юлы юк. Йә син шул якка барасың бөтен дөнья белән, йә таралаcың. Шуңа ул мәҗбүри шул якка барачак. Аның иле зур, халыклар күп. Болай гына булмый аны идарә итеп, бөтенесен тигез ясап.

*— Интенсив үсеш бар, экстенсив үсеш бар. Рәсәй элек-электән соңгы юлдан — яулап алу, киңәю юлыннан барган бит инде. Халык та шуңа ияләшкән. Рәсәй халкы менә кайсы патшаларны ярата? Иң усалларын — Иван Грозныйны, Пётр I не, Сталинны. Демократиясез дә яши алалар, димәк.*

— Мин килешәм сезнең белән. Ләкин мин бит бүген димим. Барыбер мәҗбүри рәвештә шул якка барачаклар. Йә федерализмга киләчәк, йә таралачак бу ил.

**Р.Юныс:**

*— Йә, шушы урында әңгәмәбезне киңәйтеп җибәрик инде. Бу сорау — барыбызга да. Чигенү нигә һәм ничек башланды ул?*

**Р.Вәлиев:**

— «Чигенү» — хәрбиләр тарафыннан күбрәк кулланыла торган термин. Безнең элеккеге хәрби кешебез бар бит монда, полковнигыбыз. Ул гаскәрдә генә түгел, сәясәттә дә полковник, хәтта генерал дияр идем мин. Шуңа күрә, Фәндәс абый, сүзне сез башласагыз, дөрес булыр.

**Ф.Сафиуллин:**



— Татарстанның суверенитеты турында мин бу ике терминны кулланмас идем. Минемчә, без җиңелмәдек тә, чигенмәдек тә. Без — җимерелдек. Моны болай дип аңлатасым килә. Татарстанның суверенитеты турында декларация кабул итүгә аннан алдагы лозунгка таянып килдек без. Югары Советка сайланган депутатларның яртысы диярлек менә мондый уртак лозунг белән чыккан иде: Татарстанның статусын союздаш республика дәрәҗәсенә күтәрергә. Декларация кабул ителгәч тә, Татарстанның статусын үзгәртмичә, союздаш республика дәрәҗәсенә күтәрелмичә, без моны тормышка ашыра алмас идек. Беркайдан да чыгып китү түгел, әмма союздаш республиканың хокукларыннан, ул биргән вәкаләтләрдән, ул биргән ирektән без инде үсеп китә ала идек. Безнең менә бу югалтулар, Декларациянең күп өлешен җую — ул СССРның җимерелү нәтиҗәсе булды. Кемнендер безне җиңүе түгел, безнең үзебезнең чигенү түгел. Тормыш белән чагыштырсак, без күп фатирлы йортның бер фатирында татарчалаштырып евроремонт ясарга җыенган вакытта йорт җимерелде дә куйды.

1991 елнын 21 августында яңа союз шартнамәсенә кул куелырга тиеш иде. Янартылган СССРда. Әмма 19ында ГКЧП башлану аны юкка чыгарды. Без ул яңа Шартнамәгә ничек кул куябыз — Россия делегациясе составындамы, әллә аерыммы? Аерым имза кую инде асылда килешенгән иде. Өч көн кала җуйдык без бу мөмкинлекне.

**Р.Вәлиев:**



— Фәндәс абый, безнең өчен ин якын булган төрки республикаларнын — Үзбәкстан белән Казакъстанның җитәкчеләре ни өчен Татарстанның союздаш республика булуына каршы чыктылар икән?

**Ф.Сафиуллин:**

— Төрки халыкларнын гомер буе яшәп килгән бер яман традициясе — көнчелек. Мәскәүгә якынрак булгач, багланыш яхшырак булгач, бәлки, Татарстан үсеп китеп, алардан да алгарак китәр дип уйлаганнардыр. Ул гына да түгелдер, безнең тарихта матур булмаган эзебез дә бар бит: татар бригадаларынын басмачыларны үтерү-кыруы. Бу да тәэсир иткәндер инде... Зур комиссия эшләде Горбачёв җитәкчелегендә. Горбачёв үзе риза иде. Ельцин да каршы булмады ахыр чиктә.

**Р.Юныс:**

*— Мин исә бу хакта Горбачёвның үзеннән сорадым. Россия президентлыгына кандидат буларак килгән иде ул Казанга. Авиация институтының төп бинасында сайлаучылар белән очрашты. Берьюлы ике сорау бирдем мин. Беренчесе нәкъ менә шул хакта: «Татарстан чыннан да союздаш республика булачак идеме, бу мәсьәлә хәл ителеп беткән идеме?» Икенче сорау артык мөһим түгел иде. Ләкин Горбачёв нәкъ менә шунысыннан башлады һәм 15-20 минутлап сөйләде. Ул утырыуга, мин торып бастым да: «Михаил Сергеевич, а где ответ на первый вопрос?» — дидем. Ул исә: «На него я уже ответил», — диде. Шунда мин аның нинди кеше икәнен аңладым, ниһаять. Союздашлык мәсьәләсенең нинди кимәлдә хәл ителгәнлеген дә чамаладым.*

**Ф.Сафиуллин:**

— Бәлки, безгә СССРнын бетүе ахырына кадәр кирәк тә булмагандыр. Әмма без суверенитетны яклау мөмкинлекләреннән файдаланып өлгерә алмадык. Үзебез югалтканнары да күп. Ин зурысы — мәгариф системабызны булдырмау. Балалар бакчасыннан алып университетларга кадәр. Һәм кире чигенеп булмаслык итеп без моны ныгытып та өлгерә ала идек әле. Шунын аркасында без үзебезнең бик күп нәрсәбезне җуйганбыз.

**Р.Юныс:**

*— Фәндәс абый, иң әүвәл үзебез чигендек түгелме? Референдум, яңа Конституция һәм Рәсәй белән Шартнамә Рәсәй субъектлылыгыннан котылу булса, Шартнамәгә кул кую белән диярлек, «Без Рәсәй субъектлары» дип сөйли башладык. Һәм бу сүздә генә калмады... Ни сәбәп булды моңа? Капитализм төзи башлады бит инде Рәсәй. Һәм ашыгыч рәвештә миллионнар, миллиардларга ия затлар кирәк булды. Һәм Ельцин «Обогащайтесь!» дип оран салды. Ләкин ул миллионнарга юлны һәр кешегә дә ачмадылар, аерым исемлек буенча гына бугай. Менә шул хәл тәэсир итмәде микән монда? Акча дигән әйбергә мөнәсәбәт ул заманда бөтенләй башкача булды инде. Чубайслар, Гайдарлар хәрәм акчага капиталистик чорга күчерүче изге нәрсә дип карыйлар иде инде әллә... Юрий Афанасьев миңа 2004 елда чыккан, «Опасная Россия» дигән китабын бүләк иткән иде. Анда менә мондый сүзләр бар: «Халыкара валюта фонды 1998 елның августында Россиягә бурычка биргән акчаның 235 миллион доллары — Ельцин кызы Дьяченконың, бер миллиард 400 миллион доллары — ул чактагы премьер Черномырдинның, ике миллиард 415 миллион доллары Ельцинның чит ил банкларындагы исәпләренә күчкән». Менә бу фактор да эшләмәде микән?*

**Ф.Сафиуллин:**

— Бу фактор сонрак булгандыр. Безнең җитәкчеләребез дә башта бик зур

батырлык күрсәттеләр. Мәсәлән, шул референдумны үткәрә алу — шундый зур басым булган чакта. Корал куллануга кадәр ишарәләр ясалды бит аларга. Рәсәй Президентының да мөрәҗәгате булды безгә, туктатыгыз, үткәрмәгез, дип. Россия Югары Советының, Конституция судының карарлары булды. Нинди көчле пропаганда барды, Россиянең барча телевизион каналлары безгә каршы эшләде. Ул басымны җиңеп чыгарга кирәк бит, курыкмыйча. Иң соңыннан прокурорлар десанты да килеп төште, кесәләре тулы кулга алу ордерлары белән. Без тискәре тавыш биргән булсак, өләшеп кенә чыгалар иде ул ордерларны! Хәтерлисезме, Югары Советның коридорларында ыспай гына киенгән егетләр парлашып йөриләр иде. Лифтка да ияреп керәләр иде кайвакыт. Аста сак кешеләрен алыштырып бетерделәр. Шуңа карамастан, чигенмәде бит безнең җитәкчеләр.

Чигенүнең сәбәбе мал бүлешү булгандыр димим. Минем хәзерге фаразым бүтән, бу — илебез таркалачак дип уйлау, мәсәлән. Бәлки, әлегә милекне үзара тигезләп бүләбез, вазгыять үзгәргәч, янадан кушабыз, дип әйтелгәндер. Номенклатура кулындагы милек яңадан кушылса, бездә берни дә үзгәрми бит. Бәлки, әнә шундый фикер дә булгандыр. Аннан соң инде нәфес үзгәрә башлый, бүлешә башлагач.

**Р.Вәлиев:**

— Мин башкачарак фикердә. Сез әйткән сәбәпләр дә өлешчә булгандыр. Әмма сәяси мәсьәлә түгел, икътисади мәсьәлә төп сәбәпчесе булгандыр. Әйткәндер Мәскәү: нефть торбаларыгызны ябабыз, нефтегездә үзегез коеныгыз, газ бирмибез, катып утырыгыз шунда, сезгә — буш вагоннар, чимал китермибез, моны эшләмибез, тегене эшләмибез, дип. Менә шул вакытта, бәлки, аптырап та, куркып та калгандыр безнең җитәкчеләр. Чөнки үзебезнең халык ук, татары да, урысы да, башкасы да: «Безгә бу суверенитет нәрсәгә кирәк булды?!» — дип әйтәчәк иде бит.

**Р.Юныс:**

— *Үзәк белән шәп Шартнамә төзедек тә, кабат үзәкнең субъектына әйләндек.*

**Р.Вәлиев:**

— Анысы инде күбрәк сәяси мәсьәлә. Ул вакытта бит инде Россиянең Конституциясе кабул ителде. Татарстанның Конституциясе бер ел элек кабул ителгән иде инде. Һәм Россия Конституциясенә «Халыкара хокук нормалары Россиянең хокук нормаларыннан өстенрәк», дип язылды. Без моңа бик куандык инде. Ә халыкара хокук нормалары буенча да, Россия законнары буенча да без ул чакта Россиянең сәяси һәм хокукый кырыннан читтә калдык. Чөнки Федератив шартнамәгә кул куймадык. Татарстан, әгәр дә теләгән булса, референдум үткәргәннән соң, бөтенләй аерылып чыгу юлыннан да китә алган булыр иде. Россияне, бәлки, күпмедер дәрәҗәдә шунысы да куркыткандыр. Чөнки алар безнең мондагы бөтен хәлне нечкәләп белеп бетергәннәрдер дип уйламыйм. Әмма тагын бер сәбәп бар. Ул да булса, безнең халыкның дәүләт белән идарә итү иммунитеты инде шактый хәлсезләнгән булуы. Без Мәскәү нәрсә кушса, шуны үтәргә өйрәнгән идек инде. Колхоз бригадирыннан башлап олы җитәкчеләргә кадәр инде мөстәкыйль уйлау, мөстәкыйль идарә итү сәләтен югалтканнар иде. Менә монысы да төп сәбәпләрнең берсе булгандыр.

**Д.Исхаков:**



— 90нчы елны безнең өлкә комитеты үткәргән бер социологик тикшеренү сакланып калган. Анда шундый саннар бар. Халыкның 11 проценты — Татар иҗтимагый үзәген, ягъни ул вакытта иң көчле милли хәрәкәт оешмасын яклаган, коммунистларны исә — 7 проценты гына. Монда шундый сорау туа бит: милли хәрәкәт артында кемнәр торган һәм аларга бу санны нәрсә бүлү биргән? Русча әйткәндә, «молчаливое большинство» бар бит әле. Бу чынлыкта бик зур көч. Чөнки Мәскәү галимнәре дә шундыйрак фикергә килделәр: Россиядә демократиянең барып чыкмавы чынлыкта халык массаларының төп өлешенең моңа әзер булмавыннан. Минемчә, безнең халык массаларының төп өлеше дә шулай ук яңалыкларга бик әзер түгел иде. Мин сезнең белән килешәм, абсолют рәвештә. Без нык Рәсәй эчендә, ана

артык береккән идек шул. Мөстәкыйльлек алган милләтләрнең барысы да Рәсәйгә соңрак кушылган халыклар бит. Алар әле аның кочагына кереп, анда эреп бетәр дәрәҗәгә житмәгәннәр. Балтыйк буен әйтмим дә инде, Кавказ республикалары да Урта Азиянекеләрдән соңрак килеп кушылганнар. Безнең мөстәкыйльлек алырга талпыну ул үзенә күрә бик зур адым булды. Аннан, бәхетсезлеккә каршы, үзебезнең тарихны начар белеп, беренче чиратта, 20нче елларда нәрсә булганны белмичә яшәдек. Минем хәзер бер аспирант диссертация язып бетерде — 20нче елларда, 30нчы еллар башында Татарстанда милли төзелеш мәсьәләсе буенча. 20нче елларда булган бөтен нәрсә дә 90нчы елларда кабатланган бездә. Бу ни дигән сүз? Чынлыкта, Рәсәй эчендә үзенә күрә бер вектор бар, психологлар аны «базовая личность», ди. Бу — Рәсәй шәхесе инде. Шул вектор гел нык кына йогынты ясый, без шуннан котыла алмыйбыз. Аннан котылу юллары бар, ләкин без барган юл түгел бу.

Бәхетсезлеккә каршы, менә бу мәсьәләнең бер глобаль ягы да бар. Аны, һәрхәлдә, бездә бик искә алучылар булмады да. Без бит 1917 елга кадәр буржуаз милләт төзү буенча шактый уңышка ирешкән булганбыз. Аның үз механизмнары, шәхесләре булган. Шул әйбер 17нче елгы революциядән соң бөтенләй кисеп атыла һәм татарлар социалистик милләткә әйләнеп калалар. Ул социалистик милләт белән буржуаз милләтнең аермалары зур. Шул аермаларны да истә тотарга кирәк. Тәҗрибә күрсәткәнчә, социалистик милләттән автомат рәвештә буржуаз милләткә күчеп булмый, шактый гына күчеш чоры кирәк. Безнең 17нче елга кадәр яшәгән теге милләткә нык ярдәм иткән ак байлар килеп чыкканчы, татарлар арасында баю күренеше һәм буржуазия үсү күренеше өч буынны алган әнә. Шуның дүртенче буынында гына килеп чыга яна типтагы байлар. Ә без тиз генә баеп киткән чиновникларыбыз арасыннан хәзерге заманча буржуазия барлыкка килер дип уйлыйбыз. Күзне ачыбрак карасагыз, Татарстандагы иң зур байлар — милли эшкә бер тиен дә бирмәүчеләр. Әгәр дә милли эшкә нәрсә булса да бирәләр икән, алар йә уртакул, йә аннан да түбәнрәк байлар, яисә читтә яшәүчеләр. Безнекеләр шул мәчет төзүдән ерак китә алмыйлар. Гомуми эшләр турында уйлау, милләт вазгыятен кайгыртып, уртак кассага бирү һәм шуннан файдалану дигән нәрсә бөтенләй юк. Шуна күрә безнең чигенеш ул үзенә күрә закончалыклы һәм әле тиз генә бетмәстер.

Бервакытны Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы булган Мәхмүт Гәрәев трибунадан әйтте: «Чигенмәскә иде, алганны кире бирмәскә иде!» — диде. Димәк, Мәскәүдә яшәгән милләттәшләр дә (алар бит инде жете Россия патриотлары саналалар) безгә кисәтү ясадылар, башка чигенмәгез, дип. Көрәшмичә генә яулап алганнарны юкка чыгару, билгеле, безнең эчке сәясәткә дә бәйле. Кызганычка каршы, безнең эчке сәясәт Рәсәйнең гомуми моделендә корылган, һәм бездә халык сәясәттә катнашмый, элита гына эшли сәясәтне. Күп партиялелек һәм демократлык чынлыкта юк. Безнең җәмгыятьнең шулай оешуы милек бүлешүнең законсыз рәвештә алып барылуыннан килеп чыкты. Халыкка бернәрсә дә эләкмәде чынлыкта. Татарстанның суверенитетын күпме чикләсәң дә, урамга халык массалары чыкмаячак. Чөнки аларның жуяр әйберләре юк.

**Р.Вәлиев:**

— Россиядә зур ыгы-зыгылар чыгып, хәлләре катлаулана башласа, милләтләргә бераз игътибар бирә алалар. Пугачёв яуларыннан соң безгә мәчетләр төзергә ирек бирделәр, Әби патша заманында бу. Чөнки әзрәк кенә ирек биреп, безне тынычландырырга кирәк иде. Бишенче елдан соң да урыс патшасы безгә күпмедер ирек бирде: татар телендә журналлар, газитләр ачылды, күпләп китаплар чыга башлады, мәктәпләр ачыла башлады, 17нче елгы революциядән соң безгә тагын бер кат ирек биреп карадылар, анда да бары тынычландырыр өчен генә, чөнки башка юллары юк иде. 80нче еллар азагында, 90нчы еллар башында Татарстан халкы, башка республикалардагы халыклар күтәрелә башлагач, эт күнеле бер сөяк дигәндәй, безгә тагын сөяк ыргыттылар. Менә сезгә шуны бирәбез, тегене бирәбез, йота алган кадәр йотыгыз, диделәр. Без тагын тынычландык. Без шул хәтле дә беркатлы халык инде, ышандык. Күпчелек халык та ышанды, житәкчелек тә. Әмма кан түгеп яулап алынган жирне империя безгә жинел генә бирмәс шул. Бары тик, әйткәнемчә, мәжбүрият юлы белән генә бу нәрсәгә ирешеп була. Әгәр дә мәжбүр итәрлек дәрәжәдә көч туплый алабыз икән, шул вакытта гына без үзебезнең максатыбызга ирешәчәкбез.



5*

**Д.Исхаков:**

— Өстәп әйтим әле шуна. Безнен тәҗрибә бар бит инде, хәтерлисезме, Башкортстан белән 1919 елны Совет Россиясе килешү төзи, аннан соң бу килешүне «кусок бумаги» дип игълан итә. Чынлыкта һәрбер килешү артында реаль көч чагыштырмасы тора. Реаль көчебез бар вакытта, милли күтәрелеш вакытында алар безнең белән санлашырга мәҗбүр булдылар. Ә ул милли хәрәкәт сүнгәч, элита үзе генә калгач, һәм ул элита Мәскәүгә бик нык бәйле булгач, син инде беркая да китә алмыйсың, сине шунда ук артына утырталар. Һәм бездә шулай булды да. Билгеле, бу вазгыятьне бераз катлауландырып та була иде. Бәлки, барыгыз да белмисездер, Рәис Тузмөхәммәтов атлы бер халыкара хокук белгече бар иде. Ул безгә килешүебезне халыкара документка әйләндерергә тәкъдим итте. Һәм ул моның механизмнарын да күрсәтте. Юридик яктан моны эшләп булыр иде. Әгәр ул шушы кимәлгә күтәрелгән булса, соңыннан Мәскәүнең Шартнамәне Федераль законга әйләндерү мөмкинлеге калмас иде. Бу эш вакытында эшләнмәде. Монысы инде безнең сәясәтчеләрнең күз үткенлегеннән тора. Шуна күрә чигенүнең объектив һәм субъектив сәбәпләре бар.

**Р.Юныс:**

*— Мәхмүт Гәрәев исеме аталды монда. Мәхмүт ага — татарның иң зур гаскәрие, армия генералы, Хәрби фәннәр академиясе президенты. Совет армиясенең генераль штаб башлыгы урынбасары булган кеше. Хәрбиләрдә погон гаменнән дә олы гамь юк, диләр. Ә бу агай милли гамьне беркайчан да җуймаган. «Чигенмәскә иде!» — дигән, лаеклы рәвештә яңакка сугуга тиң сүзне дә ул әйтте бит әнә. 1993 елда Мәхмүт ага зур тәвәккәллек күрсәтте, татар генералларын һәм адмиралларын Мәскәүгә җыеп, Рәсәй армиясенең татар бәйрәмен дә үткәрә алды бит ул хәтта!*

*Татарстанның 20нче, 30нчы еллардагы түрәләре арасында да батырлар шактый күп булган. Аларга ул заманда эштән алыну гына янамаган юкса... Каян килә икән ул җитәкченең шулай курка белмәве?*

**Ф.Сафиуллин:**

— Иң кирәкле сыйфатларының икесен генә әйтәм. Җитәкче курыкмасын өчен, иң әүвәл, аның гөнаһлары булмаска, ил алдында, халкы алдында намусы чиста булырга тиеш. Икенчедән, халыкта аның таянычы булырга тиеш. Әгәр таянычы җуелган икән, ул куркак була. Референдум вакытында нигә халыкка таянып була иде? Бөтен мәйдан тула иде чөнки. Боларның икесе дә җуелды. Ә халыкның яклавы нигә җуела? Алдарак әйтелгәнчә, халыкның өметен акламадык без. Ул көткәнне бирмәдек халыкка. Менә монысы инде безнең иң зур югалту булгандыр.

**Р.Вәлиев:**

— Нәрсә алдык, нәрсә югалттык дигәндә, Рафаэль Хәким бик дөрес җаваплар бирде. Алган нәрсәләр чыннан да бар. Менә без хәзер бик тә четерекле мәсьәләләрне тикшерәбез. Болай сөйләшеп утыруны элек мин күз алдына да китерә алмый идем. Без элек кача-поса «Азатлык» радиосын тыңлый идек. Мин журналда эшләгәндә, өч юллык текстны да «главлит»тан укыта идек. Цензура бит, укытмый кара! Әфганстанга барып кайтканнан соң, йөздән артык битле юльязмамны нәшриятка кертеп биргән идем — юкка чыгардылар, эзе дә калмады. Хәзер, шөкер, матбугатта күпмедер дәрәҗәдә ирек барлыкка килде, яңа газета-журналларыбыз ачылды, яңа телеканаллар пәйда булды һ.б.

Әгәр дә без дәүләтчелек турында сүз алып барабыз икән, дәүләтчелек бит әле ул үзеннән Президентның, парламентның булу гына түгел. Аларның хокуклары, мөмкинлекләре бармы соң? Мәсәлән, безнең бүгенге көндә хәтта «Татарстан» дигән поездыбыз да юк, инде ул исемне дә алдылар, димәк, безнең үз тимер юлыбыз юк, дигән сүз. Хәтта ике шәһәр арасында, районнар арасында йөри торган электричкаларыбыз да безгә буйсынмый. «Татарстан» дигән авиакомпаниябез юк. Элек бар иде бит ул. Башкортныкы да бар ул, хәтта Оренбургныкы да бар. Безнең пароходчылыгыбыз юк бүген. Элек безнең «Татарстан», «Тукай» дигән һәм башка шундый исемдәге пароходларыбыз булган, хәзер алар да юк. Татарстанда Татарстанныкы дигән бер генә югары дәрәҗәле уку йортыбыз-университетыбыз да юк. Алар Федераль хакимияткә буйсынса да, Татарстанныкы дип атала ала бит

инде, югыйсә. Әнә, Башкортстанда университетлар башкортныкы дип, Чувашстанда чувашныкы дип атала бит. Бездәгеләре бөтенесе дә Казанныкы дип атала. Бездә «Татптицепром»нар бар, «Татовощепром»нар, «Татсвинпром»нар бар, «Татар» исеменен шуннан да югары күтәрелә алганы юк. «Татар», «Татарстан» дигән сүзләрдән ниндидер курку бар. Безнен үзебезнен дә эчкә сеңгән ул курку.

**Р.Юныс:**

*— Фәндәс абый! Татарстан хакимиятенең басым ясау белән, чигенергә әзер торуы сез 11 ел элек китергән мисалда бик ачык чагыла. Россия Президенты аппараты җитәкчесе урынбасары Сурков латин имлясы мәсьәләсен «примем закон в первом чтении и подвесим», дигән. Сез бу хәлләрне шәп беләсез, чөнки ул чакта Дума депутаты идегез. Ягъни кабул ителеп бетмәгән килеш калдырмакчы булганнар. Чөнки Татарстан күтәреләчәк, каршылык зур булыр дип уйлаганнар. Ә без куркуга калдык һәм шундук латиннан баш тарттык. Шуннан белгәннәр инде безне чигендерү җиңел икәнне. Дөресме, Фәндәс абый?*

**Ф.Сафиуллин:**

— Дөрес, әлбәттә. Шунысы да бар: халыкта, җәмәгатьчелек арасында һаман шул латин турында сүз чыкканда, «Россиядә латинны тыю турында закон кабул ителде», дип сөйлиләр. Россия латинга каршы закон кабул итмәде. Минем дә латинга күчик дигән таләбем юк. Татар халкынын үз ана теленә, туган теленә хуҗа булу хокукын тартып алу турындагы закон бу. Ул законда латин турында бер сүз дә юк. Анда, «Кириллица белән язасыз», диелгән. Димәк, татар халкынын табигый хокукын, үз ана теленә үзе хуҗа булу хокукын тартып алу турындагы закон бу. Аннан, ул ничек итеп кабул ителде сон? Анын нигезе шулай булды бит. «Татарстан төрек службалары белән Төркиянен экспансиясенә ярдәм итә һәм латинга күчү Россиянен иминлеге, бөтенлеге өчен куркынычлы», дип. Шулай булгач, бу закон, имештер, бездән килеп чыккан куркынычны бетерүгә юнәлтелә. Сталин заманында мондый гаеп белән халыкны сөрергә дә була иде. Шуна күрә мин Татарстан җитәкчелегеннән Татарстан Югары Советынын чираттан тыш сессиясен җыеп, латин турында бер сүз дә әйтмичә, менә бу безгә ташлаган гаепне генә алып ташлау турында, һәм татар халкы алдында, Татарстан алдында Россиянен гафу үтенүен сорауны таләп иткән идем. Ә реакциянен булмавы ул нәкъ менә син әйткәнчә килеп чыкты.

**Д.Исхаков:**

— Икенче ягын да исәпкә алырга кирәк. Кызганычка каршы, мондый вазгыятьтә безнең читтәге татарлар белән бәйләнеш җитәрлек булмау да үзен сизлерде. Беренче чиратта латинга читтәге татарлар каршы чыкты. Моны исә оештырдылар. Менә бер мисал: Әдһәм Тенишев төн уртасында шалтыратты. «Дамир, татарга каршы чыккан шундый кәгазьгә кул куйдым мин, мәҗбүр булдым», — ди. Мәскәүдәге Тел белеме институтынын сектор мөдире иде ул. Ана, әгәр дә кул куймасан, мөдирлектән алабыз, дигәннәр. Менә шундый юллар белән, күп кенә кешеләрнен кулларын боргычлап эшләнде бу эш.

**Р.Вәлиев:**

— Ул вакытта бик күп буталчыклыклар да булды безнен арада. Буталчыклыкны халкыбыз арасына махсус та кертергә тырыштылар. Мәсәлән, Татарстан Дәүләт Советында депутат булган чагында бер язучыбыз «латин законы»н яклап доклад белән чыгыш ясады, ә Мәскәүгә киткәч, шушы законга каршы исемлеккә кул куйды.

Дәүләт Думасына мин ул вакытта бу мәсьәлә буенча еш йөрдем. Шунда бер депутат җыелышта, Татарстан латин теленә күчә, дип чыгыш ясады. Латин язуы белән латин телен аера белмәгән Дума депутатлары шушы мәсьәләне безгә каршы борып куйдылар да үзләренчә карар кабул итүгә ирештеләр. Аннан сон тагын бер коткы булды: Татарстан латинга күчә, имеш... Мин аларга анлатырга тырыштым: Татарстандагы бар телләр дә күчми, татар теле генә күчә, дип. Дөресрәге, күчми, кире кайта, дип. Дума депутатлары арасында, бөтен Татарстан латинга күчә, дип янә коткы тараттылар, ягъни, урысы да, чувашы да, марие да, мордвасы да, күчә имеш. Менә шул да тәэсир итте. Аннан сон тагын шундый коткы да булды: әгәр дә без, татар халкы, латин имлясына күчсәк, мона кадәр басылган бер китапны да, ягъни, язма мирасыбызны укый алмаячакбыз, без үзебезнен рухи байлыклардан аерылачакбыз, имеш. Мин шулчак Дәүләт Думасында чыгыш ясадым. Без ничек аерылабыз икән? Без бит, телибезме, теләмибезме, Россиядә

яшибез, ә Россиядә дәүләт теле — урыс теле. Телибезме, теләмибезме, балалар бакчасыннан, мәктәптән башлап, бөтен югары уку йортларында һәммәбез дә рус телен укыячакбыз-өйрәнәчәкбез, ул телне укыгач, без бит инде кириллицаны беләчәкбез, дидем. Аннан соң тагын бер Дума утырышында чыгыш ясаганда, Жириновский һәрвакыттагыча акырды. «Сез, латинга күчеп, Россияне таркатырга, җимерергә телисез», — диде. Һәм мин шунда болай дип әйткән идем: «Татарлар инде мең елдан артык гарәп язуында язды. 1552 елны Россия дәүләтенә кертелгәннән соң да, без 400 елдан артык гарәп язуында булдык. Һәм шушы вакыт эчендә Россия таркалмады. Ә нигә әле ул хәзер генә, латин язуына күчкәч кенә таркалырга мөмкин? Аннары сез бит әйтәсез, Владимир Вольфович, Россия — великая держава, дисез. Без латин хәрефләренә күчүгә таркала икән, ничек «великая держава» булырга мөмкин соң ул? Димәк, Сезненчә, бу «великая держава» татар хәрефләренә генә таянып торган булып чыга...» Шуннан соң ул нәрсәдер кычкырган булды да шунын белән бетте... Үзебезнең Казаныбызда мина Тел, әдәбият һәм тарих институтының бер галиме: «Баш тартыгыз, нәрсәгә кирәк булды ул сезгә?!» — дип, төннәр буе шалтыратып чыга иде. Димәк, галимнәр белән дә кайбер кешеләр шәп кенә эшләгәннәр инде. Бу латин язуына каршы бик хәйләкәр оештырылган акция булды һәм алар үзләренең максатларына ирештеләр.

**Р.Юныс:**

*— Күпләр инде оныткандыр да, латинның безгә нигә кирәклеген дә әйтик әле.*

**Р.Вәлиев:**

— Латин ул — татар теленең авазлар системасына иң тәңгәл килә торган имля. Аннан, ул безне янә шул имляда язучы башка төрки халыкларга ялгаячак, якынайтачак иде.

**Р.Юныс:**

*— Разил Вәлиев белән әңгәмәбездән бер цитата китерик әле. Инде 2002 елда ук миңа ни дип әйтте ул: «Әмма булган мөмкинлектән файдаланып җиткерә алмадык без. Мәңге шулай дәвам итәр дә, әкрен-әкрен генә, ашыкмыйча гына файдаланырбыз шунда дип уйладык. «Йомшак керү»нең сәясәттәге варианты инде бу. «Гел болай бара алмый!» дип кисәтүчеләр булды булуын, әмма ләкин без аларны ишетмәмешкә салыштык. Әгәр дә шушы ун елны акыллырак файдаланган булсак, без берничә баскыч югарырак күтәрелгән булыр идек».*

**Р.Хәким:**

— Баштан ук тәвәккәлрәк булырга иде. Минимумга ризалашканбыз икән, анын максимумын алырга. Юк шул, минимумнын да минимумын гына алдык — тавыкка ярма сипкән кебек кенә!

**Д.Исхаков:**

— Безнен унышлар бар үзе. Менә гади генә мисал китерәм. Башкортстанда бер мәгълүмат басылып чыкты. Башкортстан бит, без үзгәрешләр башлап җибәргәндә, икътисади яктан бездән көчлерәк иде. Хәзер алар бездән 1/4гә калышалар. Димәк, кайсыдыр бер борылышта без нииндидер үзгәлек кerтканбез һәм ул икътисад өчен унышлы булган. Һәм безнең тулаем керем башкаларныкына караганда зуррак. Ә менә уртача хезмәт хакы бездә дә аларныкы түләнерәк. Димәк, бездә азрак түлиләр диган сүз бит бу чынлыкта. Рафаэль Хәкимов менә, Солтангалиев карашын алга куеп, икътисад беренче урында булырга тиеш, диде. Гади әйбер түгел бу. Икътисадтан башка мәдәниятне үстереп булмый, әйе. Ләкин шәп мәдәниятсез юньле икътисад та корып булмый бит чынлыкта.

**Р.Вәлиев:**

— Икесе дә беренче урында булырга тиеш.

**Д.Исхаков:**

— Әйе. Ләкин бездә бу пропорция сакланмый. Мәдәнияткә һаман акча җитми. Бу совет чорындагыга бик охшаган. Һәм, минем күзәтүләр буенча, бу чынлап та безгә зыян китерә. Аннан сон, уңышлар дигәннән, бездә бит элек булмаган социаль институтлар да оешты. Фәннәр академиясе, Татар конгрессы барлыкка килде. Һәм тагын Федераль

Сабантуй уйлап чыгарылды һәм тормышка ашырылды. Берничә варианты. Бик кин яссылыкта таралып урнашкан татарны берникадәр дәрәҗәдә туплый төшәргә ярдәм итә ул. Ләкин безнең Фәннәр академиясендә гуманитар фәннәр гел икенче урында калып бара. Татар конгрессына да тукталыйк. Ул бит чынлыкта яна институт түгел. 1917 елдан соң барлыкка килгән Милли Мәҗлес шул ук нәрсә инде. Чөнки милләтнең бер органы булырга тиеш. Татарстан бит бөтен милләтнең теләкләрен тормышка ашыра алмый, ул аны күтәрә дә алмый. Чикләр белән чикләнгән без, татар Татарстан эченә сыймый. Ләкин бүген артка борылып карасак, күрәбез: ул җыела, анда кызык кына әйберләр дә була, әмма Татар конгрессы чынлыкта гомумтатар парламентына әйләнмәде әле.

**Р.Вәлиев:**

— Дамир әфәнде, Татар конгрессының эшчәнлеген күреп торабыз, ул милләтне оештыру, милли хәрәкәткә юнәлеш бирү ягыннан шактый эшләр башкара — анысы бик әйбәт. Ләкин без аны ахырынача структур яктан төзеп бетермәдек кебек. Һәрбер дәүләттә башкарма хакимият-хөкүмәт бар, һәм хөкүмәт өстеннән парламент бар. Конгрессның менә шундый иң югары органы төзелмәде, ул төзелергә тиеш иде бит.

**Д.Исхаков:**

— Ну, җәмәгать, монда хәл итәсе мәсьәләләр!.. Беренчедән, читтәге татарлар белән бәйләнеш барыбер күпкырлы түгел әле. Күпме тырышсак та, моны югары кимәлгә кую өчен безнең финанс базасы юк. Менә безгә килгән бер ханым, әле генә эшли башлаган, әйтә, карале, сез министрлык кебек эшлисез икән, ди. Әйе, ул Татар конгрессы чынлыкта татар диаспорасы буенча министрлык инде. Яһүдиләрнең Израильдә шундый министрлыклары бар. Безгә дә кирәк бу, чөнки татарлар бик таралып урнашкан. Ләкин без бит бөтенләй үк иҗтимагый оешма да түгел, тулаем дәүләт оешмасы да түгел, ике арада асылынып калганбыз, шуна күрә аның стратегия мәсьәләсе эшләнмәгән.

**Р.Вәлиев:**

— Без еш кына зарланабыз, бер-беребезне тәнкыйтьлибез, шулай булырга тиеш тә инде, кимчелекләрне күрергә кирәк. Бүгенге сөйләшүдә әгәр дә без ирешкән уңышларыбыз турында да сөйләмәсәк, дөрес булмас. Монысы инде зур сәясәттән читкә китебрәк булыр. Рәсәй кешесе Татарстан аша үтеп киткәндә, ана карап соклана. Безнең Татарстандагы авыллар Россия авылларыннан яхшы якка аерылып тора. Бу бүгенге көндә бирелгән, дөресрәге, яулап алган мөмкинлекләргә бәйле. Татарстан беренче булып бөтен авылларны да газлаштырып бетерде. Хәзер юллар сала. Үткән елда гына Татарстанда 57 клуб, йөзләгән балалар бакчасы ачылган. Мәктәпләр ремонтлана. Соңгы 4-5 елда 500дән артык мәктәп ремонтланды. Боларны ни өчен әйтәмме? Гадәти хәл, шулай булырга тиеш, диярсез, бәлки, әмма Россиядә бер генә төбәктә дә, бер генә республикада да эшләр бу дәрәҗәдә алып барылмый бит.

**Д.Исхаков**

— Алай ук дип әйтмәс идем. Кайбер өлкәләрдә бара.

**Р.Юныс:**

*— Чувашстандагы Шыгырдан кебек зур һәм көчле татар авыллары да бар. Аларда кирәк нәрсәләрне үзләре салалар, мөһим мәсьәләләрне элекке замандагы кебек җыен җыеп хәл итәләр...*

**Р.Вәлиев:**

— Үткән елны Чувашстанда 4 балалар бакчасы төзелгән. Татарстанда исә йөздән артык. Шәһәрләребез дә башка шәһәрләрдән арурак күренә. Менә Ульяновскига барып карадык, бөтенләй башка дөнья анда. Бездә дә халык артык бай яши дип әйтә алмыйм, әмма башка төбәкләр белән чагыштырып караганда, тормыш барыбер шактый яхшырды. Мине иң нык борчыган нәрсә, бу хакта әлегә нишләптер берни дә әйтмәдек: татар халкының милли йөзен, милли рухын җуя баруы. Бигрәк тә мәгарифтә. Татарның милли мәгарифе Татарстанда да, читтә бигрәк тә инде, аяныч хәлдә. 10-15 ел элек кенә безнең Татарстаннан читтә мен ярымнан артык мәктәбебез бар иде. Хәзер ике йөзләп мәктәп калды микән? Аларын да бит татар мәктәбе дип әйтеп булмый. Анда бит бөтен фәннәр русча укытыла, атнасына нибары бер яки ике мәртәбә татар теле керә, шуларны да татар мәктәбе дип сөйләп йөрибез. Үзебезнең Татарстанда да татар мәктәбе дигән мәктәпләрнең бик күбесе чынлыкта татар мәктәбе түгел. Анда татар теле

һәм татар әдәбияты гына татарча укытыла. Әгәр дә шушы мәсьәләне көн үзәгенә куеп хәл итә алмыйбыз икән, бүген сөйләшеп утырган сүзләребез, хыялларыбыз чәлпәрәмә килеп убылып төшәчәк. Әгәр дә минем милләтем булмый икән, анын теле, мәдәнияте, мәгарифе, үз гореф-гадәтләре, үз рухы булмый икән, мина ул республиканың, ул дәүләтчелекнең нигә кирәге бар? Шуңа күрә без бу мәсьәләгә аеруча игътибар итеп, аны сөйләшүнең, сөйләшүнең генә түгел, эшебезнең дә кыл уртасына куярга тиешбез.

**Д.Исхаков:**

— Өстәп кенә әйтим әле. Яна күренешләр күзәтелә башлады. Башкортстанда бит татар телен соңгы дистә елларда бик каты кыстылар һәм татарлар, башкортлаштырудан котылыр өчен, рус теленә күчтеләр. Хәзер, берничә мисалын үзем дә беләм, яшь балалы гаиләләр Татарстанга күчә башладылар, балаларны тәрбияләү шартлары юк дип. Биздә балаларын татарча укытырга ниятли алар.

**Р.Вәлиев:**

— Дамир әфәнде, Башкортстанда гына түгел, менә бер-ике атна элек кенә Мәскәүдән, бик тә зыялы татар гаиләсеннән шалтыраттылар. Бер ир-ат. Безнең өч балабыз бар, аларны татар балалары итеп тәрбиялисебез килә. Зинһар өчен, безгә ярдәм итегез әле, ди. Мин хатынымны балаларым белән Казанга күчерәм, үзем Мәскәүдә торачакмын. Хатыным атна саен кайтып килер, үзем дә килеп йөрермен, шул балаларыбызны Казанда татар мәктәбенә урнаштырырга ярдәм итсәгез иде, ди. Бу мөмкин эш микән, чөнки пропискаларыбыз юк Казанда, ди. Без бу мәсьәләне хәл иттек. Бераз хәрәкәт бар, ягъни.

**Р.Юныс:**

— *Шәп мисал бу! Әти-әни, әби-бабай булу татар өчен бик тә катлаулы вазифа хәзер. Нигә татар телен өйрәтмәдегез, татарча укытмадыгыз дип дәгъва белдергән балалар булды әнә туксанынчы елларда. Чыннан да, баланы туган теленнән, табигый үсешеннән аерып, бүген аларга отышлы булып күренгән чит юлга кертеп җибәрергә ни хакы бар әти-әниләрнең?! Баланың нинди дөньяда яшәгәнен, берәүләрнең аны кайсы юлга кертергә теләгәннәрен, шуннан китеп барса, ниләр буласын белмәгән килеш без балаларыбызга игелек кылучылар түгел, аларны каһәрле язмышка дучар итүчеләр дә була алабыз бит. Аннан, үзебезгә ни булып әйләнеп кайтыр әле бу? Тамырдан өзелгән, ят гадәтләрне үз итеп үскән бала өчен әти-әниләре, әби-бабалары кадерле, газиз булырлармы, үз өйләрендә үк артык җаннар булып калмаслармы алар?*

*Дамир әфәнде әнә Башкортстанны искә алды. Сәяси хокуклары күпкә азрак булган Башкортстанда башкортлар биздәге кыенлыкларның әсәрен дә күрмәделәр. Шуңа күрә Башкорт мәгарифен, башкорт мәдәниятен үстерүгә дә анда күптин-күп көч куелды. Башкорт теле анда үзен иркен хис итә. Башкортстан җитәкчеләре күбрәк башкортча сөйли. Безнең югары түрәләр исә чыгышларында татарча берничә җөмлә кыстырып куялар да сиптерәләр аннары урысчалатып. Менә сиңа Татарстанның ике дәүләт теле!*

*Быел суверенитет турында декларация игълан ителүнең 25 еллыгыннан тыш та бер юбилеебыз бар әле безнең. Югары Совет Милли университет ачу турында карар кабул иткәнгә 20 ел тулды. Йә, бу хакта ни дибез?*

**Р.Вәлиев:**

— Фәндәс абый, Милли университет ачу тәкъдиме белән башта сез чыктыгыз. Шактый озак барды бу «тарих», ләкин акрынлап аны сүндерделәр. Аннан соң инде Гуманитар институт ачылды. Моннан ерак түгел генә, балалар бакчасы бинасында. Әнә шул кечкенә бинада да ул барыбер үз эшен эшләде, без хәтта анысына да рәхмәтле идек. Татар исеме йөрткән шул бердәнбер югары уку йорты бар иде. Ләкин күп тә үтмәде, Россия Дәүләт Думасында мәгариф турындагы законга үзгәреш керттеләр. Россиядәге субъектлар үзләренең югары уку йортларын булдыра алмыйлар, имеш, һәм шуна таянып, бу университетны юкка чыгардылар. Һәм шуннан соң инде нишләргә? Аңлап булмый торган бик кызык хәл килеп чыкты. Россия субъектлары, шул исәптән милли республикалар да әлеге Россия законы буенча үзләренең югары уку йортларын булдыра алмыйлар, ә шәһәрләр, шәһәр округлары булдыра ала. Мәсәлән, Әлмәт ача ала, Чаллы, Түбән Кама ача ала, ә Татарстан ача алмый!

**Ф.Сафиуллин:**

— Бусы — соңрак булган хәлләр. Татар университетын ачмауда Мәскәүнең катышы юк. Ачылган хәлдә, бетерә алмыйлар иде аны. Чөнки гамәлгә куючылары — учредительләре — берничә булачак иде. Рәсәйдә яһүд университетлары гына да өч хәзер. Безнең өчен бу — коточкыч югалту. Милли университетыбыз бөтен милли мәгариф системабызны үстерәп алып барачак иде бит.

**Р.Вәлиев:**

— Әйе, ул чакта бик кызык вазгыятькә куйдык үзебезне. Шуннан соң без бу хакта бик күп сүз алып бардык. Россия Дәүләт Думасына мөрәҗәгатьләр җибәрдек һәм өч ел элек, 2012 елның азагында, Россиянең мәгариф турындагы яңа законы әзерләнеп беткәндә, без Татарстан парламенты исеменнән, Россия субъектлары үзләренең югары уку йортларын булдыра алалар, дигән тәкъдимебезне җибәрдек. Ни сәбәпледер, белмим, аңламадылармы, әллә аңлап эшләделәрме, ул матур гына узды да китте. Шуннан соң бу маддәне без Татарстанның мәгариф турындагы законына да керттек. Бүгенге көндә Россиянең мәгариф турындагы законы буенча да, үзебезнең законга таянып та Татарстан рәхәтләнеп югары уку йортлары ача ала. Әлегә бу эш белән шөгыльләнүче генә юк.

**Д.Исхаков:**

— Нәтиҗәсе мондый аның. Әле шушы көннәрдә генә без Татар конгрессының башкарма комитеты бюросында шундый бер мәсьәлә карадык. Федераль университетта математиканы һәм информатиканы татарча укыту бетерелде. Димәк, татар мәктәпләрендә укытучылар булмаячак. Аннан алда шундый нәрсә килеп чыкты: КФУ ректоры Татарстан Фәннәр академиясенә мөрәҗәгать итте, бөтен татар филологиясен үзегезгә алыгыз, үзегез укытыгыз, дип. Әмма, беләсез, Фәннәр академиясе укыту белән шөгыльләнми. Нәрсә дигән сүз бу? Федераль университетка, Казан университетына татар юнәлеше бөтенләй кирәк түгел булып чыга... Ә татар мәктәпләре әле бүген бар. Аларда кем эшләргә тиеш буладыр алга таба — бусы билгеле түгел. Бу бит инде җитәкчелекнең уйламавыннан килеп чыккан нәрсә.

**Р.Юныс:**

— *Безнең әлеге сөйләшү — киләчәккә төбәлгән. Әйтелгән сүзләр — нәтиҗә ясау, уйлану һәм киләчәктә эшлисе эшләр.*

**Ф.Сафиуллин:**

— Алай гына түгел. Без зарланып әйткән сүзләр, теге нәрсә бетерелде, бу нәрсә бетерелде, дип, бу — торгызылырга, кайтарылырга тиешле әйберләр.

**Р.Вәлиев:**

— Сөенерлек нәрсәләр дә бар... Мәсәлән, чит илләрдә йөргәндә дә, башка төбәкләрдә булганда да, иң нык куандырганы — татар дигән халыкның дәрәҗәсе күпмедер артканын сизәсең. Әбрар Кәримуллин белән 1991 елда Канадага барып төштек. Татар дигәч, куллары белән менә болай итеп тә, тегеләй итеп тә күрсәтәләр. Лондонга бардык, анда да шул ук хәл. Татарны атта кылыч селтәп чабып йөргән ярымкыргый зат итеп күз алдына китерәләр. Ике ел элек Төркиягә баргач, Тукайның дүрт телдә чыккан әкиятләрен Төркиянең ул чактагы Президенты Абдулла Гөлгә бүләк иттем. Китап татарча, русча, төрекчә, инглизчә иде — ул шунда төрекчәсен рәхәтләнеп, бөтен нәрсәсен онытып, кычкырып укып утырды һәм шунда әйтеп куйды: «Татар халкы — галим халык, татар халкы төрки халыклар арасында иң алга киткән халык», — дип. Димәк, әгәр инде Президентлар шулай уйлый икән, юктан гына барлыкка килгән фикер түгел бу.

Әмма начар якка үзгәрешләр дә бар. Менә Фәндәс абый әйтте бит, басмачылар чорын искә ала башладылар, дип. Анысы да бар, әйе. Беркөнне Казанда казакъ язучысы белән сөйләшеп йөрдем. Ул хәтта XIX гасыр азагында, XX гасыр башларында Урта Азиядә мәгърифәтчелек белән шөгыльләнгән милләттәшләребезне дә гаепләргә маташа. Менә сез безне тамырларыбыздан читләштердегез, сез безгә рус мәдәниятен алып килдегез, рус культурасын керттегез, руслаштыруда, европалаштыруда татарларның өлеше бик зур, ди бу. Без һич тә күнеле Исламга ята торган халык түгел идек, мәҗүсиләр идек, тәңречеләр идек, сез безне ислам диненә өстерәп алып керттегез, дип, безне хәтта шул яктан гаепләүчеләр дә барлыкка килде.

**Д.Исхаков:**

— Күзне ачып карарга кирәк, күрәш ул төрки дөньяда да бара, әйе, ике генә әйберне әйтәм. Казакълар белән хәзер без Алтын Урда мирасын бүлешәбез, һәм бу җинел әйбер түгел... Аларда элек тә Шәрекъ институты бар иде. Алар мирас белән күбрәк эшлиләр. Казакълар һәм алар артыннан башкортлар борынгы төрки мираска да бик каты дәгъва белдерәләр. Һәм бу — безнең өчен катлаулы проблема, чөнки борынгы төркилекне өйрәнгәндә, иң әүвәл кабилә системасы килеп чыга. Татарда кабиләләр сакланмаган, шуна күрә кабиләләр аркылы турыдан-туры төпкә төшә алмыйбыз. Һәм болар хәтта кыпчак яисә татар кабиләләренә дә дәгъва кылалар. Менә бу — катлаулы әйберләр, алдан уйламыйча, эзләмичә генә бу әйберләрне күтәреп чыгып булмый.

Тагын бер ягын әйтер идем: мәдәният ягыннан, никадәр генә тырышсак та, бездә стратегик юнәлешне билгеләүче институтлар барлыкка килмәде. Беләсез инде, Татарстан стратегия белән бераз шөгыльләнә. Әгәр дә «Татарстан — 2030» дигән программаны ачып карасагыз, анда татарның эзе дә юк. Ә бит бу — дәүләт программасы. Билгеле, Леонтьевлар (беренче каналның «Однако» тапшыруын алып баручы) эшләп биргәч, анда татар булмый инде. Ә менә үзебез шундый әйберне күтәреп чыга алмыйбыз. Галимнәр дә тупланмаган, аннары бу эшне оештыра алырлык эшмәкәрләр дә җитәрлек түгел. Быел Алтайга барганда, алдан сөйләшеп, 12 кешене чакырдык. «Алтай» исемле клуб төзеп, шунда уртак милли проблемаларны тикшерербез дигән идек. Ләкин күпчелек халык килмәде, чөнки матди як бар бит, ә безнең эшмәкәрләргә милли проблемалар ят нәрсә. Дәүләткә исә кирәк түгел. Бераз интеллигенция вәкилләре бар. Ләкин аларның да күбесе тиешле кимәлдә түгел, чөнки бик катлаулы проблемалар хакында сөйләшергә кирәк. Һәм без киләчәккә шул Леонтьевлар язып биргән стратегия буенча барабыз чынлыкта.

**Р.Вәлиев:**

— Дамир әфәнде, мин сезнең белән тулаем килешәм. Ул стратегиянең проектын укып чыкканнан соң, минем чәчләрем үрә торды. Чыннан да, анда татар мәдәнияте, татар мәгарифе, гомумән, татар халкы турында сүз бик аз иде. Милли мәгариф, миллилек бары тик башлангыч мәктәп өлешендә генә бар иде. Мин шуннан соң Президентка хат язып җибәрдем, Татарстанда мондый программаны ничек кабул итәргә мөмкин, дип. Президент аны мәгариф һәм икътисад министрларына җибәрде, шуннан соң гына милли мәгариф турында өстәмә бүлек барлыкка килде. Әлеге стратегияне гамәлгә ашыру программасын эшләгәндә активрак катнашырга иде безгә.

**Р.Юныс:**

*— Бер бик тә саллы сорау бар әле безнең: татарны тулаем милләт итеп берләштерү җәһәтеннәнниләр эшләнде һәм ниләр эшләнмәде? Кытайдан кайткан Зифа Табиева сүзләре һич истән чыкмый: «Менә без, Голҗадагы татарлар, чит илдә яшәсәк тә, шулай тату, халкыбызны, туган телебезне яратып, бердәмлек аңы белән тырышып-тырмашып яшәгән, һаман алга омтылган идек... Казанга кайтырга кирәк, үз җиребездә үзебез булып яшик дип Казанга кайттык. Тик монда үз телендә сөйләшкән, үз тарихы белән якыннан кызыксынган, халкының киләчәген төптән уйлап кайгырткан яшьләрне эзләп табарга кирәк икән әле! Әллә татар булып калыр өчен чит илдә яшәргә кирәк микән ул?» 1998-2008 елларда Кытайда татарларның дәүләт депутаты булган Әдибә Исхакова да миңа нәкъ менә шундый сүз әйтте. Тагын бер мисал өстим моңа. Берничә ел элек радиода турыдан-туры элемтә барганда, бер тыңлаучы Татарстан прокуратурасының зур бер түрәсенә, Татар бистәсендә өйләрне сүтәләр, бистә тарала, квартирларны бер йорттан булса да бирергә иде, диде. Шунда теге түрә татарларның шәһәрдә бергә яшәвен... кыргыйлык дип атады. Татар патша Россиясендә шулай бергә яшәгән — яраган, Татарстан дигән республикада исә бу кыргыйлык икән!*

**Д.Исхаков:**

— Нью-Йоркта кытайлар яшәгән җир өч-дүрт чакрымга сузыла. Чайна-таун дигән кытай шәһәрчеге бу. Йөреп чыктым, кибетләре, рестораннары, үзләренә кирәкле бөтен нәрсәләре бар монда.

**Р.Юныс:**

*—Түрәләрнең бер өлешенә татарларның татар булып татарча яшәү омтылышына, ягъни гап-гади һәм тап-табигый эш-гамәлләренә җинаять чигендәге нәрсә яки хәтта җинаять дип карау хас.*

**Р.Вәлиев:**

— Кыргыйлык дигәннән искә төште. Түбән Кама ГЭСы төзелгәннән соң, ул яктагы күп авыллар су астында калды. Шул вакытта партиянең Чаллы шәһәр комитетының беренче секретаре Рәис Беляев бик тә «кыргый» гамәл кылды. Күчерелгән һәр авылга бер йорт бирде. Алар гомер буе күршеләр булып бергә яшәгәннәр, хәзер дә бергә яшәсеннәр, дип. Мәсәлән, 120 йорт икән авылда, бөтенесен 120 фатирлы бер йортка кертеп урнаштырды.

**Р.Юныс:**

*— Бу җәһәттән Мансур Вәлиев 1989 елны үткәреп, «Казан утлары»нда басылган әңгәмәдән Нәкый ага Исәнбәт сүзләрен дә китерим әле. «Шәһәр җирендә фатир биргәндә, бер йортка бер милләт кешеләрен урнаштыру әйбәт. Балтыйк буе республикаларында ул әнә шулай эшләнә».*

*Рәсәй күләмендә милли-мәдәни автономиябез бар иде. Исәнме ул хәзер, тәэсире нигә сизелми? Бөтендөнья Татар Лигабыз да бар иде. 1991-1997 елларда аңа Гали Акыш җитәкчелек итте. Хәзер бармы бу Лига? Йә ярар, болары үзләре аерым бер сөйләшү сорый...*

*Президент сайлау мәсьәләсенә килик. Гади мәсьәләме бу? Әллә берәр хикмәте бармы?*

**Д.Исхаков:**

— Моның ике ягы бар. Беренче чиратта, без мона дәүләт атрибуты буларак карарга тиешбез. Әлеге институтны саклап калу бик мөһим. Рөстәм Нургалиевич әле тегендә, әле монда бара — бик еш йөри инде ул. Аның белән йөргәләгән бер кеше: «Миннеханов, төбәкләргә чыгып, татар белән очрашканда, гомумтатар Президенты була», — диде. Чыннан да, шулай бу. Димәк, моның дәүләтчелек өчен дә, милли яктан да әһәмияте бар. Мәскәүдә акыллырак шәхесләр күбрәк булса, бәлки, бу институтны бетермәсләр әле. Чөнки, телисеңме, теләмисеңме, татарның Россия эчендә аерым урыны бар. Шул урынны билгеләгән институт бу.

**Р.Юныс:**

*— Татарстан референдумы, аңа таянып эшләнгән Татарстан Конституциясе, хәтта Рәсәйнең үз Конституциясе дә, Президент итеп Татарстан халкы сайлап куюда Рәсәй җитәкчелегенә берни түгел инде, алайса? Шулай телибез, бетте-китте, вәссәлам!*

**Р.Вәлиев:**

— Урыста бик әйбәт әйтем бар бит: «Как назовёшь корабль, он так и поплывёт». Корабка нинди исем кушсаң, шулай йөзеп китә, ди урыс. «Президент, булды ни дә «Башлык», «Ил башы» булды ни, барыбер түгелмени, диләр. Барыбер түгел. Искиткеч зур мәгънәгә ия булган нәрсә бу. Мин ышанам: безнең парламент та бу исемне, бу атаманы калдыру өчен барысын да эшләячәк. Һәм Россия җитәкчеләре дә монда уйланырга тиеш. Әмма теге элекке сүземне әйтәм: мәҗбүр итмичә алар моны беркайчан да эшләргә җыенмаячак.

**Ф.Сафиуллин:**

— Россия Конституциясендә вәкаләтләр өч өлешкә бүленгән: федераль дәүләт вәкаләтләре, уртак вәкаләтләр һәм субъектларныкы. «Президент» атамасы субъектларның үзләренең карамагында. Федераль карамакка кергән вәкаләтләрдә ул юк, уртакларында ул юк, ә Конституциянең 73нче маддәсендә менә бу беренчесенә, икенчесенә кермәгән вәкаләтләр барысы да субъектларныкы, диелгән. Димәк, ул — безнеке. Аннан соң, Татарстан ул дәүләт дип игълан ителгән. Тегеләр исә — республикалар, ә дәүләтнең, Россия Конституциясендә язылганча, үз Конституциясе була. Анда болай диелгән (74, 76нчы маддәләр): «Россия Федерациясенең субъекты үзенең вәкаләтләренә генә кагылышлы мәсьәләләр буенча закон кабул иткәндә, ул закон федераль закон белән

тәнгәл булмаса, субъектның законы үз көчендә кала». Менә бу — безнең хокукый нигезебез. Тагын бер үтә мөһим нәрсә: Россия Конституциясенең 15нче маддәсендә: «Конституция Российской Федерации — основной закон прямого действия», — диелгән, ягъни ул турыдан-туры кулланыла. Аңа башка төрле арадаш законнар кирәкми.

**Р.Юныс:**

*— Безнең журналистлар, ни гаҗәп, менә мондый темаларга кермичә яши алалар! Референдум вакытында да шулай булган иде. Бер ай буе барды матбугат көрәше. «Вечерняя Казань» һәм Мәскәү гәҗитләре суверенитетка каршы берсеннән-берсе усалрак мәкаләләр чыгарып торды. Татар матбугатыннан ике-өч кеше тырышты инде шунда. Шөкер, язучылар, юристлар, галимнәр үз сүзен әйтте. Революциягә кадәр һәм аннан соң ничәдер ел булган ул чын татар матбугаты. Аннары инде «орган гәҗитләр», кушканны гына үтәүче журналистлар китте. Мөстәкыйль фикерләү юк, кыюлык юк. Онытмыйк: гадел сүздән курыккан журналист иблискә хезмәт итә. Хөр фикерле кешеләр, чын милли зыялылар тәрбияләргә кирәк.*

**Р.Вәлиев:**

— Дөрес әйтәсең, Рәфикъ. Милли тәрбия кирәк. Гаиләдән башлап. Балалар бакчасында, мәктәптә, югары уку йортында, бөтен мәдәният оешмаларында. Әгәр дә без халыкка милли тәрбия бирүне көчәйтмәсәк, тик торганда гына әллә каян күктән безгә милли проблемаларны белгән милли гамьле журналистлар төшермәячәкләр. Язучылары була әле аның. Милләтнең үз бәгыреннән сыгып чыгарган кисәкчеге кебек бит инде ул язучы халкы. Язучының төп темасы милләт язмышы булырга тиеш дип Туфан абый юкка гына әйтми иде. Ә инде халыкта милли рух тәрбияләр өчен, бүген аның институтларын булдырырга кирәк. Балалар бакчаларында беркадәр башланды әлеге эш. Бу темага хәтта минем үз гаиләмдә дә кайчак бәхәс купкалый. Нигә сез урысларны, башка милләтләрне татарча укытып тилмертәсез? Күпме экономия булыр иде, шул акчаны нигә татар мәктәпләрен ныгытырга гына бирмисез, диләр. Аларда барыбер татарга нәфрәт кенә уяна, нәрсәгә кирәк сезгә аларның татарча белүләре, татарларга шәпләп өйрәтегез татар телен, татар мәктәпләрен ныгытыгыз, татарларның шулай алга киткәнен күреп, алар да үзләреннән-үзләре килер, диләр. Болай фикерләүдә дә күпмедер хаклык бар шикелле.

**Ф.Сафиуллин:**

— Мәгариф турында мин дә әйтим әле. Без ничек кенә тырышсак та, балаларыгызны татар мәктәбенә бирегез дип үгетләсәк тә, иң зур тормоз монда — Россиянең бер законы. Бердәм дәүләт имтиханының нормасы уртак бит, ягъни рус телен татар да, чуваш та, мари да рус белән тигез, үз ана теле кебек белергә тиеш булып чыга. Шулай булгач, бу рус түгелләрнең ана теленә хокукын бетерү инде. Совет заманындагы кебек булса да, ничектер җиңеләйтелгән имтихан кертмичә, рус телендә генә булган бердәм дәүдәт имтиханын үзгәртмичә һич ярамый.

**Р.Вәлиев:**

— Әйе, татарның иң зур дошманы бүген — милли мәгарифтә рус телендә генә бирелә торган бердәм дәүләт имтиханы. Әле ул моңа хәтле икәү иде: рус теле һәм математикадан. Россия Дәүләт Думасыннан яңа закон проекты килде. Ул проект узса, БДИ дүрткә әйләнә: Россия тарихы белән рус әдәбияты да өстәлә. Бу ике фәнгә, димәк, өстәмә сәгатьләр бирелә, ә аларны каян алачаклар? Тагын татар телен, татар теле дәресләрен кыскарталар, димәк!

**Ф.Сафиуллин:**

— Шуның өчен БДИгә каршы көрәш БДИне татарча бирергә рөхсәт итегез дип түгел, «Татар халкын үз ана теленнән баш тартырга мәҗбүр итмәгез!» дигән оран белән барырга тиештер дип уйлыйм мин.

**Р.Юныс:**

*— Татар мәгарифе совет чорында ару гына яшәде әле ул. Хрущёвка кадәр. Коммунизм төзергә җыенган Хрущёв кына җимерә башлады аны — коммунизмда бер генә тел булырга тиеш дип.*

**Р.Вәлиев:**

— Бездә нигә элеккечә милли хәрәкәт, дәүләтчелекне ныгыту, мәйданнарга чыгу, көрәш юк, диләр. Еллар буе мәйданда ач утырып булмый бит инде. Һәр заманның үз ысуллары була. Элегрәк шундый ысул белән көрәшелде. Бүген исә — бүтәнчә. Бүген без менә «Казан утлары»нда утырабыз икән, «Казан утлары» журналы, димәк, бу эш белән үзенчә шөгыльләнә. Һәрбер оешма хәзер гамәли эш алып барырга тиеш. Үзе буллыра алганча. Менә Рафаэль, Дамир әфәнделәр һәм башкалар бу хәрәкәтнең теориясен, тактикасын эшләделәр, юлын сызып күрсәттеләр, хәзер шушы юлдан барырга кирәк. Әгәр без шушы сөйләшү белән генә чикләнеп калсак, бернинди алга китү дә булмаячак.

**Д.Исхаков:**

— Шунысы начар бу вазгыятьтә: әлеге эшләрне координацияләүче үзәк юк. Ул дәүләтнеке дә булырга мөмкин, ләкин көчле булырга тиеш. Янсә көчле шәхесләр утырган урын булырга тиеш.

**Ф.Сафиуллин:**

— Дәүләт бит кирәкле сүзне Татар конгрессы аша әйттерә ала. Иң уңайлы вариант бу.

**Р.Вәлиев:**

— Бу сүзем бүтән нәрсә хакында. Чын татар Татарстаннан читтә генә яши дигән фикер әйтелде. Татарстаннан читтә генә милләт турында күп уйлыйлар, татар анда гына сакланып кала, диделәр. Бу фикердә беркадәр хаклык та бар, ләкин бу чит илгә күчкән беренче буын, икенче буын, өченче буынга карата дөрес, ә хәзер, дүртенче буында, инде ул да сүнеп бара. Финляндиягә бардым, анда да инде татар яшьләре күбрәк финчә сөйләшәләр, Америкага бардым — инглизчә сөйләшәләр, Канадада инглизчә сөйләшәләр. Кытайдагылар уйгырча, казакъча сөйләшәләр, татарчалары такы-токы гына. Шуна күрә моны байрак итеп күтәреп йөреп булмый, аларда да проблема бар.

**Р.Юныс:**

*— Юк, бу бит һич тә байрак итеп күтәрелми, татар тормышы бөтен яклап чәчәк атарга, дөнья татарларына таяныч булырга тиешле Казанда хәлнең шундый булуына ут йотып әйтелә.*

**Р.Вәлиев:**

— Аларга рәхмәт, йөз ел буена татарлыкны саклап килгәннәре өчен.

**Ф.Сафиуллин:**

— Көчле университетыбыз булса, гуманитар юнәлештә, алар бездә укып кайтырлар иде.

**Д.Исхаков:**

— Наив караш инде бу. Көчле университет булсын өчен, көчле профессорлар кирәк. Безнең Тарих институты эчендә азрак реформалар үткәрелде бит инде. Анда борынгы төрки чорны өйрәнүче бүлек төзеделәр. Башына Альберт Борһановны куйдылар. Ул исә борынгы төркиләр белән шөгыльләнүче бер генә кеше дә юк, ди. Университеттагы өлкән яшьтәге профессорлар бөтенесе дә «отставка»га киттеләр.

**Р.Юныс:**

*— Киттеделәр, җибәрелделәр. Юкса мәгарифтән, мәдәнияттән, матбугаттан булдыклы татар кадрларын пенсия яшенә җиткәч тә җибәрергә ашыкмаска кирәктер. Булганны бетерергә түгел, булмаганны бар итәргә кирәк бит татар өчен утә авыр бу заманда. Авыл хуҗалыгы академиясе, Архитектура-төзелеш университеты, Техник университет, Технология университеты галимнәре (исемнәре «Татар гаме» дигән китабымда аталды — 443 биттә) татарча терминологияне эшләп, сүзлекләр әзерләп, дәреслекләр язып, бу уку йортларында гомер булмаганны татар группалары ачуны тәэмин иттеләр әнә!*

**Ф.Сафиуллин:**

— Аннан, кызганычка каршы, бер начар юлдан кереп киттек. Мәдәният хәзер — күңел ачу чарасы гына. Халыкның аңын, культурасын үстерү чарасы түгел. Нинди зур мәҗлесләрдә, банкетларда татарның атаклы артистларын җырлатып, ашап-эчеп утырабыз.

**Р.Вәлиев:**

— Анысы — мәҗлесләрдә, менә безнең радиода, телевидениедә татарның классик музыкасын ишеткәнегез бармы?

**Р.Хәким:**

— Тагын бер телевидение каналы кирәк татар телендә. 24 сәгать фәкать татарча сөйләсен. Кинәшче чагымда Шәймиевкә әйткән идем, дөрес, диде.

**Р.Юныс:**

*— Әйе, бик тә, бик тә кирәк мондый канал! «Яңа Гасыр»га килсәк, кимчелекләр күп анда. Алып баручыларның кайберләренә әдәби телне, татарча әйтелешне белү, зәвык җитеп бетми. Әйе, шырды-бырды җырларны да күп тыңлаттылар — шаукымга бирелеп. Бу канал өчен һич тә кирәкмәгән очраклы тапшырулар да күптин-күп. Ләкин, шөкер, халкыбыз өчен витамин кебек тапшырулар да бар бит. Бу — «Без тарихта эзлебез», «Мәдәният дөньясында», «Халкым минем», «Кучтәнәч», «Переведи! Татарча өйрәнәбез», «Поём и учим татарский язык», «Яшьләр on-line» һ.б. «Татарлар» тапшыруының төп хәбәрчесе Ләйсәнә Садретдиновага тырышлыгы өчен мин хәтта орден да бирер идем әле... Бу каналдан йөз чөермәскә, аны арулandырырга һәм көчәйтергә генә кирәк.*

**Ф.Сафиуллин:**

— Дәүләт Советы беркетмәләрендә Суверенлык декларациясенә, Референдумга, Татарстан Конституциясенә, Татарстанның һәм татар халкынын язмышына кагылышлы күп-күп чыгышлар һәм карарлар теркәлеп калды. Бу стенограммаларны китап итеп бастырып чыгарасы иде бит. Алар исән чакта, без исән чакта...

**Р.Вәлиев:**

— Мондый сөйләшүләр кирәк. «Казан утлары»нда да, ТНВда, радиода да. Матбугат, Тукай әйткәнчә, кыю, Тукайча туры сүзле булсын! Иң мөһиме: һәрберебез үз эшебездә җаваплы булырга тиеш.

* * *

*Әңгәмә тәгәлләнеп, ак кәгазьгә кучкәннән соң да шактый көннәр үтте. Ләкин күңелдә яңадан-яңа сораулар туа торды. Сорауларның үзәге гел шул инде: кая барабыз?*

*Борчылырга сәбәпләр күп иде. Шуларның берсе — туксанынчы еллар башын "онытуыбыз". Әйтерсең, ул чорда берни дә булмаган. Хәтта Суверенитет турындагы декларация белән Референдумның ун, унбиш, егерме еллык юбилейлары да берничек тә билгеләп үтелмәде. Онытырмаска, онытылса, шәп итеп искә төшерергә тиешле матбугат та, күп кенә зыялыларыбыз да күрмәгәнгә салышты аларны. Мондый "акыллы" гамьсезлек милләтебезне тромб үлеменә китерергә мөмкин ләбаса! Ләкин соңгы елда, шөкер, хәтернең, иҗтимагый-сәяси үзаңның кабат уяна башлавы сизелде. Башкалабызда, бөтен татар дөньясында Декларация игълан ителүнең 25 еллыгы да олылап бәйрәм ителде. Рөстәм Миңнеханов үткән юлдагы кебек Президент итеп Мәскәү тарафыннан билгеләп куелмады, 94,4 процент тавыш биреп, халык үзе сайлап куйды аны. Мөстәкыйльлек юлында булдырылган президентлык институтын саклап калу да бит бу! Президент Миңнехановның инаугурациядәге ант текстында үтә кирәкле менә мондый сүзләр дә бар: "Татарстан Республикасының Дәүләт суверенитетын тәэмин итәргә". Болар хакимият һәм халыкны якынайтуга, бергә һәм бердәм булуга күп яңа мөмкинлекләр ача.*

*Бу авыр чорда бердәмлек бик тә, бик тә кирәк! Четерекле хәлләр, сынаулар алда да күп көтәдер әле безне. 2017 елда Рәсәй белән икенче Шартнамәнең дә вакыты чыга әнә. Өченчесе нинди булыр, һәм булырмы әле ул? Булыр, шәт. Шәбе булыр! Тоташтан шулай чигенмәбез, һич тә җиңелмәбез — моңа хакыбыз юк!*

*Матбугат өчен* **Рәфикъ ЮНЫС** *әзерләде.*

# ГАШЫЙК КҮҢЕЛ ТИБРӘНЕШЕ...

ЖӘҮДӘТ ДӘРЗАМАНОВКА 70 ЯШЬ



Фәнзаман Баттал үзенең бер язмасында Жәүдәт Дәрзаманов иҗаты турында: «Әдипнең кайсы гына әсәрен укысаң да, милләтенә, халкының теленә, туган иленә гашыйклыгын тоясың. Гашыйк икәнсең, димәк, барысын да изге итеп саклый беләсең. Саклый да, кадерли дә белә Жәүдәт», — дип язган иде.

Чыннан да, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклес», Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге әдәби премиясе лауреаты Ж.Дәрзаманның иҗатында мәхәббәт тулы йөрәген тоясың: иҗат гадилеге, садәлеге белән күңел кылларын тибрәтерлек. Һәм бу иҗат, әлбәттә, турыдан-туры аның тормыш юлы борылышлары белән дә тыгыз үрелгән.

Жәүдәт Харис улы Дәрзаманов 1945 елның 13 октябрендә Татарстан Республикасының Лениногорск районы Сугышлы авылында туа. Иске Шөгер урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Шуннан соңгы тормышы һәм иҗаты Татарстан радиокомитетының балалар тапшырулары редакциясе, «Ялкын» журналы, «Татарстан яшьләре» газетасы, «Татарстан» дәүләт теле-радио тапшырулар компаниясенең әдәбият-сәнгать һәм музыкаль тапшырулар дирекциясе белән бәйләнә.

Ж.Дәрзаман әдәби иҗат белән мәктәп елларыннан ук мавыга башлый. Баштарак шигырьләре район газетасында, бераздан республика көндәлек матбугатында да күренә. Әдәбият тарихында балалар язучысы буларак танылган Ж.Дәрзаман бу өлкәгә 70нче елларда, дәүләтнең әдәбиятка, бигрәк тә балалар әдәбиятына игътибары кочәйгән бер чорда килә. Аның «Ирбатыр» (1975), «Солдат булдым» (1977), «Төнге мажара» (1980), «Гөлназ мәктәпкә бара» (1983), «Безнең әлифба» (1985), «Илләр гизә Илгизәр» (1989) кебек китапларында бүгенге укучы өчен дә кызыклы гына ачышлар бар.

Өлкән сыйныф укучыларына адресланган «Җир авазы», «Җиләкле көннәр», «Бизмән йолдызлыгы», «Ник керәсез төшләремә?», «Чорлар кайтавазы» кебек җыентыклары, җырчы Гөлсем Сөләймановага багышланган «Моңнар фәрештәсе» (1999) поэмасы, шулай ук, әдәбият сөючеләргә яхшы таныш.

Ж.Дәрзаман — җыр текстлары авторы да. Аның шигырьләренә («Синең өчен», «Мәхәббәтең, егет, каршыла» һ.б.) Р.Еникеев, Ф.Әхмәтов, М.Имашев, Т.Вәлиев кебек талантлар көй язды.

Ж.Дәрзаман иҗат иткән төп өлкә — балалар әдәбияты турында фикер йөрткәндә, без еш кына темасы, күтәрелгән проблемалары әһәмиятле, дип кабатларга яратабыз. Әмма, мәгълүм ки, темалар, проблемаларның әһәмияте генә, әгәр дә яңалык булмаса, әдәбиятка берни дә алып килми. Ж.Дәрзаман иҗаты исә үзенчәлекле ачышларга бай.

Дөрес, төрле жанрларда (шигырь, әкият, кыска хикәяләр, повесть) иҗат иткән Ж.Дәрзаман балалар шигъриятендә үзен тирәнрәк ача алды кебек. Балаларча гади тел, ачык төсләр, хисләрнең сюжетка бәйләп ачылуы, балаларча тасвир... Әлбәттә,

балалар язучысы булу өчен болар гына житми. Биредә тагын бер, ин әһәмиятле момент – автор әйдәп барган, бала ирешергә тиешле идея, поэтик фикернең ачыклыгы. Ж.Дәрзаман һәр әсәрендә аерым бер максат куя һәм аны акрынлап, ана гына хас булган сурәтләү чаралары аша, бер шигырьдән икенчесенә күчереп, балага яшәешнең искиткеч киңлекләрен ача, алай гына да түгел, аны да кичерергә, борчылырга һәм шатланырга өйрәтә. Тормыш матур булса да, анда һәрдаим яхшылык һәм начарлык төшенчәләре бергә йөри. Аерым әсәрләрнең драматик төс алуы да бу хакыйкатьне балаларга житкерү максатыннан башкарыла.

Поэзиядә Ж.Дәрзаманны, барыннан да бигрәк, баланың үз тормышы – ясле, бакча, мәктәп, ял вакытлары, үз-үзләрен тотышы кызыксындыра. Эш-хәрәкәт, нигездә, Гөлназ яки лирик герой («мин») исеменнән алып барыла, шигырьләрдә төенләнеш һәм чишелеш, әхлакый нәтиҗә-йомгак бар. Мисалга «Уенчыкларым» циклына кертелгән «Кирәк» шигыре. Биредә әдәбиятта инде дистә еллар дәвамында кабатланган «эштән соң аш бигрәк тәмле» фикере үткәрелә. Әлбәттә, беренче карашка биредә яңалык юк дәрәжәсендә. Әмма автор ике юл белән генә шигырьгә ата образын кертә:

*Әти киңрәк күри –*
*Аннан зурлар йөри.*

Шигырьдәге беркадәр табыш та нәкъ менә шушы юллар белән бәйләнгән. Алга таба «Тылсымлы чүкеч», «Солдат булдым» шигырьләрендә шушы ук фикер – ата белән бала мөнәсәбәте тагын да тирәнрәк ачыла. Мәгълүм ки, бүгенге чорда үрнәк алырдай ата образының әдәбиятта яктыртылуы – уңышлы алым. Чөнки бала, бигрәк тә ир бала, тирә-юньдәге кешеләрнең үз-үзләрен тотышыннан, кылган гамәлләреннән үрнәк алып үсә.

*Әти сукса, нык суга,*
*Кадактан да ут чыга.*
*Каян килә мондый көч,*
*Тылсымлыдыр бу чүкеч.*
(«Тылсымлы чүкеч»)

Чүкечнең тылсымы, әлбәттә, көчле куллар белән бәйләнә. Бу юлларда баланың әтисе белән горурлануы да, аны яратуы да чагылган. Шагыйрь балаларда хезмәткә хөрмәт, мәхәббәт хисләрен нәкъ менә ата образы, аны үрнәк итеп кую аша тәрбияләргә омтыла.

Күпчелеккә мәгълүм «Солдат булдым» шигырендә дә хезмәткә мәхәббәт, патриотик рух, атага булган хөрмәт һәм аның бала тормышындагы роле аерылгысыз рәвештә тасвир ителә:

*Иңемә мылтык астым,*
*Әти каршына бастым,*
*– Килдем, иптәш командир,*
*Әйдә, бирәр фәрман бир.*

Әти кеше, төрле эшләр кушып, баланы авырлыкларны җиңәргә өйрәтә. Нәтиҗәсе бала өчен дә куанычлы:

*Солдат булу шулай ул,*
*Өйрәнгәч бик уңай ул!*

Шигырьләрдә тәрбия мәсьәләсендә акыл сату юк. Идея юнәлеше уен, аерым очракларда теләк-хыял ярдәмендә алып барыла. Бала сөйләме төгәл, ачык, сүзләр бары тик туры мәгънәсендә генә кулланыла. Бу хәл исә, үз чиратында, баланың теле, сөйләме формалашуда да зур роль уйный.

Өлкәннәр һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтне тасвирлау – балалар шигъриятендә иң киң таралган тема. Әмма гаиләдә нәни бала туугa багышланган әһәмиятле вакыйганы, ни өчендер, күпчелек язучылар иҗатларында читләтеп үтә. Бу юнәлештә Ж.Дәрзаманның «Өйдә», «Сенелкәш», «Нәрсә булыр?», «Исем таптым!», «Өйрән әле», «Өйрәнү җинел түгел», «Мин дә нәни бит әле» кебек шигырьләре үзе бер циклны тәшкил итә. Мондый шигырьләрдә өлкән бала психологиясендә барлыкка килгән үзгәрешләр кызыклы. Бер яктан, өлкән бала – Гөлназ үзен инде зур итеп тоя, икенче яктан, яналык аның тормышына үзгәреш, проблемалар да алып килә. Әле бит аның да:

*Бик килә сөеләсе,*
*Һавага чөеләсе...*

Әмма игътибар өлкән балага карата беркадәр кимегән. Өлкәннәр күбрәк нәни баланы яратып «бииләр тирәсендә». Бала түзми:

*Үчти-үчти ит әле,*
*Мин дә нәни бит әле! –*

дип әтисенә әйтергә мәҗбүр («Мин дә нәни бит әле»).

Шулай итеп, кечкенә бала кайткач, гаиләдә туган атмосфераны шагыйрь, бала роленә кереп, «рольле герой»да, уңышлы поэтик чаралар ярдәмендә гади, садә итеп сурәтли алган. Өлкән баланың җитдилеге яки җитди булырга теләве, рухи дөньясы, кичерешләре дә оста тотып алынган детальләр аша бирелгән: «бер уйласаң, кирәк инде ул сеңел дигәне дә» яки «үсә-үсә кимер әле эше дә» дигән фикерләре елмайта. Алар балаларча риясыз, беркатлы. Шигырьдәге төп идея-фикер исә әле соңгы юлларда гына ачыла: «туган кирәк кешегә!»

Нәтиҗә уңышлы, уйландырырлык. Субъектның лирик кичерешләре артында өлкән шәхес – автор үзе һәм аның әлеге юнәлештә торган мәсләге дә ачык кына тоемлана. Бу җөмләләрнең үзенчәлекле төзелешендә, өлкәннәр фикерен үзенеке итеп кабатларга сәләтле булса да, сүзләр һәм сүзтезмәләрнең бала сөйләменнән беркадәр аерылып торуында чагыла.

Ж.Дәрзаман шигырьләрендә эш, уен, уку – барысы бергә, аерылгысыз. Мәктәп, уку процессы белән бәйле шигырьләр үзләре тулы бер бүлекне тәшкил итә. Гөлназ образы белән бәйле «Гөлназ мәктәпкә бара» циклында инде шигъри форма беркадәр катлауланa, эчтәлек авырая. Автор төп героиняны эшчән, олы җанлы итеп ачу аша беркадәр мәктәп тормышын да җанландырып тасвирларга омтыла. Мисалга «Эш беткәч» шигыре.

*Бөтен шартын китерде,*
*Гөлназ эшен бетерде, –*

дип башланган шигырь укучы күз алдында шактый җанлы тормыш картинасын тудыра. Гөлназның дәрес әзерләгән арада үзен сагынып беткән курчаклары янына килеп, аларны яратуы, зурлар, әниләр кебек сөйләшергә тырышуы үзенчәлекле, кызыклы:

*Үсеп җиткәч, бергәләп*
*Мәктәпләргә китәрсез.*
*Сез дә кайтырсыз арып,*
*«Дүртле», «бишле»ләр алып...*

Ж.Дәрзаманның кечкенәләр өчен язылган шигырьләре, нигездә, лирик миниатюраларны – мона кадәр үк инде татар балалар әдәбиятында калыплашкан форманы хәтерләтә. Аларда Г.Тукай, Б.Рәхмәт, Ш.Галиев һ.б. иҗатыннан килгән темалар яңа яклары белән ачыла, яңа проблемалар күтәрелә.

Авторның «Карурман кунаклары», «Мотаһир коесы», «Канатлы каһарман», «Айбулат» әкият-поэмалары фольклор белән тыгыз бәйләнгән. Анда халык авыз иҗатына хас матур детальләрне һәм чагыштыруларны, балалар фольклорына гына хас уеннарны күрергә мөмкин. Ж.Дәрзаманның мондый әсәрләре милли поэтикага һәм фольклор кебек үк зур тәрбияви көчкә ия. Мисал итеп, «Карурман кунаклары» әкият-поэмасын китерергә мөмкин.

Әкият-поэма халык әкиятләренә хас традицион башлам белән ачыла:

*Борын заманнарда түгел,*
*Әле бу заманнарда*
*Карт бүреләр атына, ди,*
*Өр-яңа таганнарда.*

Күренә ки, балалар дөньясы чагылган әсәрләр бала яшәгән законнарга, алар логикасына буйсындырыла. Моның шулай икәнен татар балалар әдәбиятында үз урынын алган миниатюралар да дәлилли. Аларда кош-корт, хайваннарның аерым сыйфатлары турында иркен рәвештә сөйләнелә, җанлы һәм җансыз предметлар бөтен барлыгында ачыла.

Гомумән, Ж.Дәрзаман иҗатында төп урын герой күңелендә һәм тормышта кайнап торган хис-хәрәкәткә бирелә. Кешеләр, кошлар, үсемлекләр һәрвакыт нәрсә беләндер мәшгуль: ашыгалар, эшлиләр, проблемаларны хәл итәләр, юлга кузгалалар һ.б. Нәтиҗәдә, яшәеш һәм герой хәрәкәте физик һәм акыл хезмәтен күзалларга ярдәм итә, бербөтен тормыш картинасын тудыра. Һәм бу хәл, язучы иҗатын тирәнрәк төшенү, аның геройлары белән бер үк хисләр кичерү мөмкинлекләрен ача.

Ж.Дәрзаман иҗади осталыгын һәрдаим арттыру юнәлешендә омтылыш белән яши. Р.Миннуллин: «Аны балалар белә, ярата. ... Алар (әсәрләр) табигый булулары белән үзләренә җәлеп итә. Кыландырмый, мөгез чыгармый, баланың башын бутамый шагыйрь. Үзе белгәнне генә яза. Балалар белән балаларча сөйләшә дә белә», − дип әлеге иҗатка зур бәя биргән иде.

**Ләйлә МИНҺАҖЕВА,**
*филология фәннәре докторы*

***Хата төзәтү***

*9 нчы санның 5 нче битендәге «Шайтан турында» шигыренә бирелгән эпиграфның авторын Гәрәй Рәхим дип укырга.*

# АНЫҢ ҖЫРЛАРЫ ОЗЫН ГОМЕРЛЕ

МАНСУР ШИҺАПОВКА 75 ЯШЬ



Ул сәхнәгә чыгып басса, ихтыярсыздан башлар күтәрелә, авызлар ерыла. Нык бәдәнле, мәһабәт кыяфәтле бу ир-егет карап торышка кеше күлдерә торган түгел, шаян сүз остасы буларак та даны таралмаган югыйсә. Ә менә йөзеннән, күзләреннән шундый бер жылылык, яктылык бөркелә ки, аны күргәч, күңел күге аязып киткәндәй була.

Ул, мөгаен, туганда ук елмаеп тугандыр. Һәрхәлдә миңа шулай тоела. Чөнки хәтта авыр чакларында да аның күз карашын томан каплаганын, йөзе каралып чыкканын күргәнем булмады.

Балык Бистәсе районының Яңшык авылында ишле гаиләдә дөньяга килгән Мансур Шиһапов яшьтән артист булырга хыялланган, 1957-1961 елларда В.Качалов исемендәге Зур драма театры каршындагы студиядә укыган, шул чорда Татар дәүләт академия театрында артист булып эшләгән. Соңрак Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлаган.

Минем ул уйнаган спектакльләрне караганым булмады, артист буларак аның хакында фикер әйтә алмыйм. Тискәре образларны бик үк уңышлы башкарып чыга алмагандыр дип уйлыйм. Йөзендә уйнаган яктылыкны сүрелдерә белмидер кебек. Ләкин сәхнәгә берегеп калмавының төп сәбәбе монда түгелдер, мөгаен. Мансур, режиссёрның күзенә генә карап торып, аның роль биргәнен көтеп, кушканын үтәп, гомумән, кемгәдер бәйле рәвештә яши алмый, минемчә. Үзе житәкче булып, яңа эшләр башлап жибәрү һәм аларны башкарып чыгу өчен яратылган шәхес ул. Житмешенче еллар башында Язучылар берлегендә матур әдәбиятны пропагандалау бюросында эшләде, каләм ияләрен төркем-төркем оештырып, бик күп авылларны урап чыкты. Бу бик тә мөһим эш белән безнең оешманы бөтен Рәсәйгә танытты, һәрхәлдә ил күләмендә беренче урынны яулап, Мәскәүдән Кызыл Байрак алып кайтканнары хәтергә сеңеп калган.

Аның житәкчелегендә, яшь язучы буларак, миңа да кайбер авылларда булырга туры килде. Гәрчә аннан өлкәнрәк булсам да, ул бар жирдә мин үземне бертуган абыем янындагы кебек хис итәм. Шулкадәр кайгыртучан, сак, ихтирамлы, игътибарлы аның мөнәсәбәте.

Туксанынчы еллар башында Бөтентатар Кызыл Ай жәмгыяте оештырылып, аның президенты булып сайлангач, киңәш һәм ярдәм өмет итеп, аның каршына барып бастым. Анарчы инде ул шактый урау юллар үтеп, эшләгән урыннарында матур эзләр калдырып өлгергән иде: Камал театрының баш администраторы, Курчак һәм Күчмә театрларның директоры булган, Күчмә театрны драма һәм комедия театры итеп үзгәртүгә ирешкән. Бер ел буе безгә, Язучылар берлеге рәисенең урынбасарлары булып, кулга-кул тотынышып эшләргә дә туры килде.

Кызыл Ай жәмгыятенә иң зур ярдәм күрсәткән кешеләрнең берсе дә ул булды:

җәмгыятьне куышлы итте, киңәшләрен биреп торды. Соңрак, ул инде Зур концерт залының директоры булып эшләгән чагында да, аның янына эзне суытмадым. Авыр чорда теләктәшлеге, хезмәттәшлеге мең нәрчә мохтажларга ярдәм күрсәтергә мөмкинлек бирде.

Оештыру, житәкчелек эшенә хирыс кешеләр, гадәттә, корырак, кырысрак була. Мансур исә үзенә бер: ул бик нечкә күнелле шагыйрь дә. Дәрәҗәле урында эшләүчеләрнең шактые каләм тибрәтә, китаплар бастырып чыгара, танылырга омтыла. Әмма күбесе бу теләгенә ирешә алмый.

Мансур Шиһапов шагыйрь буларак та исем казанды. Аның сүзләренә язылган җырлар дистә еллар буе яңгыраудан туктамый.

*Яшьлегемә кире кайтыр идем,*
*Кабатланмас булса ялгышлар.*
*Башкаларны йөрәк кабул итми,*
*Күз алдымнан буй-сыннарың китми,*
*Күңелемдә әрну, сагышлар.*

«Туй күлмәге» дигән бу җырны җырламаган моң сөюче татар юктыр. Шулай ук «Яшьлегем эзләре»н ишетмәгән-белмәгән кеше бармы икән?

*Бирелеп хыялга, уйларга,*
*Тыңлыйм мин агышын чишмәнең.*
*Чишмәләр җырлыйлар моң итеп,*
*Җырлыйлар яшьлегем хисләрен.*
*Мәңгегә сакласын авылым*
*Давыллы яшьлегем эзләрен.*

Шагыйрьнең 1997 елда басылып чыккан «Туй күлмәге» исемле китабына 33 җыр кергән. Һәркайсы йөрәк түреннән ургылып чыккан, һәркайсы халык җырлары дәрәҗәсендә камил язылган. Үзем дә әни кеше буларак, «Мин әнкәйнең бер бөртеге идем» исемле җырдан юллар китерми кала алмыйм:

*Мин әнкәйнең бер керфеге идем,*
*Алсулыгы бер як битенең.*
*Кадерлесе идем, күз алмасы,*
*Бердәнбере идем җиденең.*

Һәр шигырьнең язылу тарихы бар. «Васыять» исемлесе турында Мансур миңа болай дип сөйләгән иде: «Башкортстанда әдәбият-сәнгать көннәре үткәреп йөри идек. Зурлап каршы алдылар, мул кунак итәләр, ә атаклы җырчыбыз Хәйдәр Бигичевның күзләре нилектәндер сагышлы. Бер кичне ул миңа болай диде: «Беркем дә бу җиргә мәңгелеккә килмәгән, кайчан да булса безнең дә сәгать сугар. Шул хакта җыр яз әле». Аның сүзләре күнелемне кузгатты, тиз арада мин шигырьне язып та куйдым».

Көен Риф Гатауллин иҗат иткән бу җырны тетрәнмичә тыңлый алмыйм:

*Чишмәлектә язын бик тә моңсу,*
*Тирәклектә сайрый таң кошы.*
*Сагынып еларсыңмы су алганда,*
*Чагылып китсә гәүдәм балкышы?..*
*Язгы тауда сулар сибәрсеңме,*
*Тишелеп чыкса җаным гөл булып?*

Хәйдәрнең бу җырын концертларда халык тынсыз калып тыңлый иде. Кызганычка каршы, сөекле җырчыбызның гомере кыска булды.

Ә җыры калды. Ул озак-озак яшәр әле. Мансур Шиһаповның башка җырлары

кебек үк озын гомерле булыр. Клара ханым белән тату гаиләдә үстергән ике кызының яшьтәшләре дә, оныкларының чордашлары да жырлар аларны.

Мансур Шиһаповның иҗаты җырлар белән генә чикләнми. 2010 елда аның «Язгы ташкын булып» дип исемләнгән шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Бу китабы белән ул үзенең шагыйрь икәнлеген тагын бер кат раслады.

Сүземне аның «Серле өннәр» исемле шигыреннән юллар белән тәмамлыйсым килә.

*Йолдыз салкын. Әмма минем җаным*
*Алар яктысыннан җылына.*
*Йолдызлардан килгән серле өннәр*
*Күңелемә кереп сыена.*
*Һәм ачалар миңа үз серләрен:*
*Матурлыклар килә галәмнән.*
*Гүзәллекне саклау, аны яклау —*
*Шул сорала җирдә адәмнән.*

Бу юлларны язганда, шагыйрь үзенең каләмен минем дә уй-кичерешләремә мангандыр кебек тоела.

**Мәдинә МАЛИКОВА**

---

## Әтидән калган гадәт

Кадерле «Казан утлары» журналы редакциясе!

Мин — Сезнең даими укучыгыз. «Казан утлары» журналын һәр елны алдырам. Быел да язылдым. Әти дә, урыны җәннәттә булсын, журналыгыздан бер дә аерылмады. Хәер, бу басмага мәхәббәт миңа аннан күчкәндер. Аның журналны дөньясын онытып, йотылып укып утырулары һаман күз алдында. 200 йортлы татар авылында «Казан утлары»н үзем генә алдырган еллар да булды. Нишлисең, 200 каналлы телевидение, интернет үз эшен эшли. Тышлыгы ялтырап торган, үзе белән типография буявы исләрен иярткән журналны кулга тотып укуга ни җитә?!

**Х.КАЮМОВ.**
*Башкортстан Республикасы Миякә районы*
*Шатмантамак авылы*

# МИЛЛИ КИТАПХАНӘ: ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ, КИЛӘЧӘГЕ

РЕСПУБЛИКА МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНӘ 150 ЕЛ

Әүвәл Сүз барлыкка килгән, диләр. Кайбер борынгы китапларда Каләм дип тә әйтелә. Сүз һәм Каләм – бербөтен. Сүзләрнең сихрилеген Каләм җанландырса, Каләмнән сибелгән Сүзләр Каләмнең көчен, куәтен күрсәтә. Тиккә генәме халыкта: «Каләм белән язганны балта белән дә юна алмассың», дигән гыйбарә барлыкка килгән! Кешелек җәмгыяте үсеп, камилләшкән саен, сүзләрне теркәп куеп, аларны мәңгеләштерү ихтыяҗы да туа, арта. Тарихтан мәгълүм: тире кисәкләренә, каен тузларына язылган сүзләр акрынлап, фән-техника үсеш алгач, төрле формадагы китапчыкларга әйләнгәннәр.

Әйе, тамырлары ерак гасырларга барып тоташучы халкыбызның бәһаләп бетергесез шанлы үткәне, мәдәни җәүһәрләре, әдәбияты – мәдәни мирасы бар. Вакытлар-еллар узу белән, сәнгать әсәреме ул, тарихи китапмы – кыйммәте арта барып, мәдәни мираска әйләнә. Әнә шул мирасны туплап яшәтер өчен китапханәләр кирәк.

Милли китапханә – архитектура төзелеше буенча җөмһүриятебезнең йөзен билгеләүче, башкалабыздагы үзәк урамнарыбызның берсен бизәп торучы бина булса, эчке мәгънәсе ягыннан халкыбызның укымышлылыгын, зыялылыгын исбатлаучы тарихи үзәк. Бирегә килеп керүгә, үзеңне ниндидер бер мәгарәгә эләккәндәй тоясың, күңел шәһәр ыгы-зыгысыннан арынып, салмак дулкынга көйләнә, тавыш басынкылана, акыл-зиһен өстәлеп, диварларына борынгылык рухын сеңдергән залларында утырганда, ничәмә йөз мең кешенең кулы аша үткән китапларны актарганда, үзеңне олуг галим, акыл иясе кебек тә, шул ук вакытта әле берни белмәгән сабый итеп тә хис итәсең.

Билгеле, 150 еллык тарих турында сүз алып барганда, аның башлангычына күз салмый калу мөмкин түгел.

Татарстан Милли китапханәсенең башлангыч чоры 1865 елга карый. Танылган галим, археолог һәм этнограф Николай Второв әтисе, библиофил һәм төбәк тарихы белгече Иван Второвның 903 исемдәге 1908 томлык китап һәм вакытлы матбугат җыелмасын 1844 елда, Петербургка китәр алдыннан, шәһәргә бүләк итә. Иван Второвның шәхси китапханәсе искиткеч бай булуына карамастан, әле күп еллар үзләренең лаеклы урынын таба алмыйча «онытылып» ята. Дистә еллар үткәч кенә, шәһәр башлыгы П.А.Прибытков Н.И.Второвка җәмәгать китапханәсе ачылачагы турында хәбәр итә. Югыйсә, бу турыдагы карар 1830 елда ук кабул ителгән була. Ниһаять, 1865 елның 10 (24) гыйнварында китапханә ачыла. Бу шәһәр халкы өчен зур вакыйгага әверелә, беренче атнасында ук йөздән артык укучыны үзенә җәлеп итә. Алар – зыялылар, университет студентлары, гимназия укучылары, кыскасы, төрле катлам кешеләре. Ул чорда йортларында шәхси китапханә туплаган зыялылар шактый була, китапханә ачылгач, алар да китаплар тапшыралар. Җәмәгать китапханәсенең көннән-көн үсә, укучыларының арта баруын «Казан губерна хәбәрләре» газетасы яктыртып, укучыларны китапханәгә тартып тора. Китапханәдәге китаплардан файдалану тәртибе турында шәһәр думасы 1905 елда карар кабул итә. Шул ук вакытта китапларны өйгә бирү-бирмәү мәсьәләсе дә бәхәс уята. Бер төркем кешеләр өйгә бирү – китапларның таушалуына, югалуына китерә дип белдерәләр. Тагын шунысын да искәртеп үтәргә кирәк: китапханәгә теләсә нинди китап тапшырып та, алып та булмый. Николай I нең махсус күрсәтмәсе нигезендә, каталог тикшерелеп торыла. Шулай ук Эчке эшләр министрлыгының «тыелган китаплар» исемлеге дә төзелә, бу хәл 1905 елгы революциядән соң тагы да көчәя.

Татар-мөселман зыялылары милли мөселман китапханәсе ачу кирәклеге турында күп тапкырлар талпынып карыйлар һәм, ниһаять, мәшһүр галим Әхмәтһади Максуди тырышлыгы белән, 1906 елның 2 гыйнварында «Көтепханәи Исламия» – мөселманнар өчен филиал ачыла. Әлеге филиал чын мәгънәсендә татар мәгърифәтчеләре үзәгенә әверелә. Бирегә, мөселман кануннары буенча, бары тик ир-атлар гына йөрергә хокуклы дип табыла, даими йөрүчеләр ул заманның күренекле шәхесләре – Г.Тукай,

Ф.Әмирхан, Ф.Бурнаш, Н.Исәнбәт, Б.Урманче һ.б. була.

Татар мәгърифәтчелек хәрәкәтеннән мөселман хатын-кызлары да читтә калмый. 1913 елның 25 ноябреннән башлап, алар ял көннәрендә китапханәнең филиалына йөрергә рөхсәт алалар.

1917 елгы революция китапханә тарихына да үзгәрешләр кертә: ул «Үзәк губерна китапханәсе» дип йөртелә башлый, 1923 елда исә «Үзәк шәһәр китапханәсе» дип үзгәртелә, 1920 елда аңа В.И.Ленин исеме бирелә. Мөселманнар өчен ачылган филиал 1919 елда «5 нче шәһәр китапханәсе» исемен ала, 1922 елда «М.Вахитов исемендәге Үзәк шәрык китапханәсе» дип атала башлый. Китапханә эше бирелә Мирхәйдәр Фәйзи эшли башлагач тагын да тулылана, җанланып китә. Татар халкы арасында аң-белем тарату эшләре, төрле китап күргәзмәләре, әдәби-музыкаль кичәләр еш оештырыла. 1929 елда ул Үзәк шәһәр китапханәсе белән берләштерелә.



*Республика китапханәчеләре Татарстан Дәүләт Советында Ф.Х.Мөхәммәтшин белән очрашуда. 2011 ел.*

Китапханәләр эшенә хөкүмәтнең зур игътибар бирүен Казанда Беренче китапханәчеләр съезды (1919, июль), Идел буе китапханәчеләренең 3 нче съезды (1925) үтүендә дә күрергә була.

1965 елда Республика китапханәсенең Яңа Уставы кабул ителә һәм ул «Республика фәнни китапханәсе» дип атала. 1962-1986 елларда китапханә белән Маһирә Харис кызы Делешова җитәкчелек итә. Илдә үзгәртеп кору җилләре исә башлагач, 1991 елда, китапханә директоры, милләтпәрвәр шәхес Разил Вәлиевнең тәкъдиме белән «Милли китапханә» исемен ала. Ни өчен нәкъ менә «Милли китапханә?» Бу сорауга җавапны китапханәнең 1986-2000 еллардагы директоры, аның янарышы, үсеше өчен күп көч куйган Разил Вәлиевнең чыгышыннан таба алырбыз.

«Милли китапханә» нинди булырга тиеш? «Милли китапханә» башка илләрдә, нигездә, дәүләт китапханәсе дигәнне аңлата. Ул шушы җөмһүрияттә, шушы республикада яшәгән халыкның, андагы гыйльми оешмаларның, дәүләт органнарының рухи һәм мәгълүмати ихтыяҗларын кайгыртса торган һәм аларга кирәкле мәгълүматны туплый, җиткерә торган фәнни-мәдәни үзәк булырга тиеш. Без моны үзебезгә өлге итеп алдык. Әмма безнең республикада Милли китапханәнең милли төсмере булырга тиеш дип санадык. Ул дәүләтнең төп китапханәсе булу белән бергә, шушы дәүләткә, республикага исем биргән милләтнең дә төп китапханәсе ролен үтәсен. Ә безнең милләттәшләребез Татарстанда гына түгел, бөтен дөньяда сибелеп яши... Димәк, безнең Милли китапханәбез республикадагы һәммә халыкның һәм бөтен татар халкының баш китапханәсе булырга тиеш»[1].

Заман белән бергә исем-статус үзгәрү һәр чорда да китапханәнең җисеменә – бүлекләр саны арту, заманча эш юнәлешләрен камилләштерү-үстерүгә дә яңа таләпләр куя. Бүгенге көндә биредә ике дистәдән артык бүлек бар. Алар – «Укучыларга хезмәт күрсәтү», «Китап туплау», «Мәгълүмат-библиография», «Чит телләрдәге әдәбият», «Фәнни-методик», «Күргәзмәләр һәм мәдәни программалар», «Автоматлаштыру-компьютерлаштыру» һ.б. бүлекләр – мәдәният һәм тарих, китапханә-укучы өчен кыйммәтле хәзинә урыны.

Разил Вәлиевтән соң җитәкчелек эше (2000-2015) Наил Әкрам улы Камбиевка тапшырыла.

Сүз дә юк, китапханәдәге бүлекләрнең безгә иң якыннары – беренчесе татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеге булса, икенчесе – кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. Бүлек 1992 елда китапханә директоры Р.Вәлиев, галимнәр М.Госманов,

[1] Вәлиев Р. Дөнья гаме. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Б.49-50.

Р.Мəрданов, Ж.Миннуллин тырышлыгы белəн ачыла. Бирелə 2700 кулъязма бар, иң борынгысы XIV гасырга карый. Бүлекне бүгенге көндə Айрат Зəһидуллин житəкли. Инде вакыт тузаннары каплап, уалырга торган кəгазь битлəреннəн кирəкле мəгълүматлар таба алу, ай-һай, жинел эшлəрдəн булырмы? Бүлек хезмəткəрлəреннəн, борынгы татар, гарəп, фарсы язмаларын танып белү өстенə, сабырлык, үҗəтлек, түземлек кебек асыл сыйфатлар да сорала. Үз эшен, миллəтен чын-чынлап зурлый белгəннəр генə эшли ала торгандыр биредə. Заманча талəплəргə туры китереп, əлеге кулъязмаларның электрон вариантлары (күчерелмəлəре) да булдырыла.

Татар əдəбияты һəм туган якны өйрəнү бүлегендə татар язучыларының китаплары, татарлар һəм Татарстан турындагы документлар гына тупланып калмыйча, тарихыбыз өчен əһəмиятле милли библиография төзү эшлəре дə алып барыла.

Җəмгыятькə компьютер, электрон мəгълүмат чаралары үтеп кергəн бер чорда, матур əдəбиятка күлəгəдə калу куркынычы янаганын тоеп, Милли китапханə 1986 елда «Ел китабы» республика конкурсы оештыра башлый һəм əдəбият-сəнгать əһеллəре катнашындагы бу бəйге ел саен дəвам иттерелеп килə, татар əдəбиятын, татар язучысын укучыларга танытуда бер алым булып тора.

Татарстан Милли китапханəсе татар əдəбиятын үстерү, тарату буенча башка өлкəлəр белəн дə тыгыз бəйлəнештə, 1995 елда ук инде биредə маркетинг, халыкара һəм төбəкара китап алмашу бүлеклəре ачыла. 1996 елда китапханə үзенең «Милли китап» дип аталган нəшриятын оештыра. Биредə укучылар өчен кирəк булган библиографик кулланмалар, төрле белешмəлəр, социологик тикшеренү материаллары һ.б. нəшер итəлə. 1996 елдан татар һəм рус теллəрендə «Китапханə хəбəрлəре» дип аталган фəнни-гамəли журнал елга ике тапкыр дөнья күрə. Район китапханəлəре белəн эшчəнлеге дə тиешле дəрəҗəдə.

Китапханəдə 238 хезмəткəр эшли, елына якынча 35 мең укучыга хезмəт күрсəтелə, 1 млн. 450 мең китап бирелə. Китапханə тулысы белəн компьютер челтəренə тоташтырылган, «Татарстан Республикасының электрон китапханə каталогы» эшлəп килə. Милли китапханə, халыкара танылу алып, Россия китапханəлəр ассоциациясенең тулы хокуклы əгъзасы булып тора, чит иллəр белəн китап алмашу системасы заман талəп иткəнчə оештырылган. Китапханəлəр 1998 елда кабул ителгəн «Китапханəлəр һəм китапханə эше турында»гы Татарстан Республикасы Законы нигезендə дəүлəт тарафыннан яклана һəм саклана.

Милли китапханəнең 150 еллыгы, Россиядə əдəбият елы уңаеннан, «Əдəби Казан», «Паркларлагы китапханə», «Əдəби ишегаллары», «Əдəби кафе» һ.б. проектлар гамəлгə ашырыла. Укучыларны бигрəк тə «Парклардагы китапханə» үзенə тарта: укыган яки инде өендə артык саналган китабың булса, рəхим итеп, ял итү урыннарында махсус куелган киштəлəргə калдырып, үзенə ошаганын алып китə аласың. Китапханəнең бүгенге көндəге девизы да – «Укы. Уйла. Сөйлə». Шунысы куанычлы: алдагы еллар белəн чагыштырып караганда, укучылар даирəсе яшəрə бара.

Кайберəүлəр, бəлки, китапханəлəр казнага табыш китерə торган өлкə түгел, дип ялгышадыр, шуңа күрə кайчакта аларга дəүлəт тарафыннан игътибар җитеп бетми торгандыр. Мəсəлəн, Милли китапханəнең мəйданы, китаплар саны (3 млн. 300 мең!) белəн чагыштырып караганда, хəзерге көндə нормативлардан сигез тапкырга кимрəк. Бу дəүлəт күлəмендə хəл ителергə тиешле иң зур мəсьəлəлəрнең берсе булып кала бирə. Үзенең хезмəт юлын əлеге китапханəдə гади китапханəче булып башлап, китапханəнең эшен-яшəешен бөтен тулылыгы белəн аңлап эшлəүче директор Сөембикə Җиһаншинаның да килəчəккə өмет-хыяллары зурдан. «Вазифам буенча чит ил китапханəлəрендə еш булырга туры килгəнлектəн, заманча эш алымнары, яңа бина – бүгенге көннең төп талəбе икəнен яхшы белəбез. Кешелəрнең, гаилəлəре белəн килеп, китапханəдə китап укып утырып, фикер алышып, ял итеп, аралашып яшəүлəрен күрəсем килə», – ди ул.

Яңа заман... Яңа буын укучысы... Яңа заман язучысы... Китапханəлəребезнең яшəеше, беренче чиратта, язучыларыбызга да бəйле. Күңеленə заман шакыганын ишетеп, тоеп иҗат иткəндə, əдəби һəм мəдəни мирасыбызны баету, саклауны һəрберебезнең намус эше итеп караганда гына, китапханəлəребезнең əнə шундый олуг бəйрəмнəрен татар мəдəнияте бəйрəме югарылыгында зурлап билгели алачакбыз.

**Гөлзадə БƏЙРƏМОВА**

# БАЯЗИТОВ «НУР» ГӘЗИТЕН НИЧЕК ЯЗЫП ӨЛГЕРТӘ?

### «НУР» ГАЗЕТАСЫ ЧЫГА БАШЛАУГА 110 ЕЛ

*Жанкай, сачең бер көлтә, җиккән атны әркетә;*
*Баязидов «Нур» гәзитен ничек язып өлгертә?*

Габдулла Тукайның 1908 елда «Авыл җырлары» мотивына язган мондый такмазасына элекке елларда аның томнарын төзүчеләр: «Петербург ахуны Гатаулла Баязидов үзе чыгарган газетаны патша хөкүмәте карарлары, татар либераль буржуа идеологларының һәм үзенең бик озын дини-реакцион мәкаләләре белән тутыра. Тукай шуннан көлә», — дигән аңлатма бирәләр иде. Дөрес, 1916 елда ук, «Нур»ның 10 еллыгы уңаеннан, аның «шималь татарлары телендә беренче гәзитә» булуын шик астына алырга маташучылар килеп чыга: янәсе, мәсләге (тоткан юлы) ачык түгел, имештер, халык арасында киң таралмый. 1926 елда журналист-тарихчы Исмәгыйль Рәми үз «альбом»ында: «Исеме «Нур» булса да, эчке һәм тышкы күренешләре белән бик нурсыз, ямьсез, укырга күңелсез гәзит иде... Моның бердәнбер яхшы ягы булса, яхшы кәгазьдә бастырылуы иде», — дип бәяләргә ашыга. Сүзлекнең киң мәгълүматлы, милли җанлы Рәис ага Даутов әзерләп чыгарган 2001 елдагы яңа басмасында да әлеге тискәре фикер кабатлана. Узган гасырның 90нчы елларында татар әдәбиятының онытылган исемнәрен кайтаруда зур хезмәт куйган күренекле галим Мөхәммәт ага Гайнуллин шулай ук моннан ерак китә алмады. Ә бит, үз заманында татар телендә көндәлек матбугат булмаганлыктан, язганнарын кайда бастырырга белмәгән Тукай үзе «патша шәһәре»ндә «Нур» газетасының нәшер ителә башлавына чиксез шатлана һәм шунда ук аны тәбрик итеп, махсус котлау шигырен язып җибәрә (ул 1905 елның 6 декабрь санында басылып чыга):

*Шималь яктан чыгып бәркъ, орды бер нур,*
*Зыясыннан әһали улды пәрнур.*
(Төньяктан яшьнәп яшен, бер нур атылды,
Яктысыннан халыкның күзе чагылды).
*Мотабикъдыр мөсәммасына исме,*
*Мөнәсыйбдыр дәһи исменә җисме.*
(Исеме бик урынлы,
исеменә җисеме дә туры килә).
*Җәридә – бер фәридә, намы «Нур»дыр,*
*Татара якты көн һәм сөрурдыр.*
(Газета – тиңдәшсез нәрсә, исеме – «Нур»,
Татарга ул – якты көн һәм куанычтыр).

Г.Баязитов Тукайның теге чәнечкеле икеюллыгына үпкәләми, 1909 елның гает санында «Нур» иң күренекле урында «Г.Тукаев диванынннан» дигән баш астында аның «Бәйрәм бүген» шигырен бирә, 1912 елда «Милли шагыйрьләремездән мөхтәрәм Габдулла әфәнде Тукаев җәнапларының агыр хәстә улып Казаннан китү хәбәрен тәәссеф (көенеч) илә ишеттек», дип белдерә, 1913 елда исә шагыйрьнең үлемен милли фаҗига буларак хәбәр итә, бу вакыйгага зур урын багышлый һәм вафатына бер ел тулгач та аның бөеклеген искәртеп-билгеләп үтә.

«Ак патша»ның 300 еллык хакимиятенә һәм «мәҗрух указ»ына мадхия җырлаган, соңрак Җекта «Уклар» журналы, Казанда «Тавыш» газетасы чыга һәм тарала башлавын, гомумән, татар милли матбагасының аякка басуын хуплап (аның да шул мохиттә хезмәт итүен онытмыйк), «бишенче елны таң белән уянган» һәм «карангылыкта нур нәшр әйләдек без» дип куанып язган шагыйрьнең холкы белән «керпе» булуы мәгълүм. Аның, үзе эшли торган матбугат басмаларын яклап, бүтән газета-журналларга карата әче

такмаклар язуы бик табигый. Ә, тулаем алганда, шагыйрь әлеге икеюллыкта Гатаулла Баязитовтан көлми, наширнең осталыгына, өлгерлегенә генә ишарә ясый.

Каюм Насыйридан башлап, Габдрахман Ильяси, Заһир Бигиев, Закир Рәми, Шиһабетдин Әхмәрев һ.б.га кадәр татар зыялыларының газета яки журнал чыгарырга рөхсәт сорап язуы патша хөкүмәте тарафыннан еллар буе кире кагыла килә. Монархы Русия халыкларының 75 телендә көндәлек басма нәшер ителүгә карамастан, татарлар гына үз телендә матбугат бастыру мөмкинлегеннән мәхрүм була. Патша хөкүмәте 1809 елда ук татарча газета чыгаруга рөхсәт биргән кебек кыланса да, гасыр дәвамында диярлек төрле дәрәҗәдәге түрәләр бу эшкә үзләренчә каршылык тудыралар. Кыргыз яки кырым-татар телендәге газета-журналлар татарга аңлашылмый диярлек, әмма 1891 елдан башлап, хәтта В.К. фон Плевье кебек дәрәҗәле түрәләр, Казан зыялылары һәм эшмәкәрләре яклавына карамастан, Баязитов та хөкүмәт һәм цензура күзәтүе астында чыгачак русча-татарча «Һәфтә (Атна)», аннары «Чишмә» исемле газетага рөхсәт сорап язган гозернамәләренә карагруһ цензор В.Смирнов кебекләрдән гел тискәре җавап ала: имештер, «халыкта рус-татар газетасына ихтыяҗ аз», ә чынлыкта, шул заман документларында (игътибар итегез: бүген генә язылган кебек!), бу газетаны чыгару «надолго устранит необходимость изучения татарами государственного языка и... будет способствовать скорее национальному сепаратизму, чем культурному слиянию татар с русским населением» икәнлеге әйтелә. Фәкать 1905 ел инкыйлабы гына кара болытларны беркадәр таратып, якты нурга юл ача — татарны матбугатлы итә. Әле 1905 елның уртасында язган бер хатында танылган мәгърифәтче, әдип, журналист Шакир Мөхәммәдев, мәсәлән, татарча газета чыгу ихтималын «дөнья асты-өстенә килмәенчә торса, йөз елдан соң» булыр дигән төшенке фараз белән бәяли.

Беренче милли газетабыз 1905 елның 2 (15) сентябрендә, ягъни моннан 110 ел элек мәгърифәтче (фәлсәфә һәм мантыйк укыткан, төрки телләр мөдәррисе), әдип, галим (ислам динен яклап, рус телендә җитди тикшеренүләр язып бастырган, ул китаплар аннары француз һәм төрек телләренә дә тәрҗемәдә нәшер ителә), дин әһеле (25 яшеннән Петербургка мәхәллә имамы итеп чакырыла, ә бераздан Император гвардиясендә кырым-татар гарнизоны һәм император конвоеның ахуны итеп тә билгеләнә), дәүләт эшлеклесе (колледжский секретарь, Чит илләр министрлыгында тылмач, Русиянең зур бүләкләренә лаек булган зат) Гатаулла Баязитов тырышлыгы аркасында гына гамәлгә куела. Бу шәхеснең исеме үзе исән чагында ук (1905 елда) Брокгауз һәм Ефронның энциклопедик сүзлегенә, шулай ук ул замандагы бүтән белешмәлекләргә дә кертелгән.

«Нур» газетасының нәшер ителә башлавын хуплап, күп кенә татар зыялылары (Фатих Кәрими, Камил Мотыйгый, алда әйткәнебезчә, Г.Тукай һ.б.) хәбәр җибәрәләр. Камил Мотыйгый, мәсәлән: «Тәрҗеман» да егерме сәнәләрдән бире (елдан бирле) безә (безгә) нур иде... «Нур» исә милләтемезнең җәһаләт (наданлык)-караңгылыкларына изалә әйләсен (бетерсен)», – дип яза. Гатаулла Баязитов газета хәбәрчеләренә «үзе сөйләдеге нотык вә сүзләрендә... гайреләргә биргән нәсыйхәт сүзләренчә гамәл кылып, үзен дә яхшы тоткан кеше булса, шулвакыт, шөбһә юктыр ки, аның сүзе дәһа дә әсәрлерәк булып, икенчеләрнең колагына керә», — дигән фикерен ирештерә.

«Нур» газетасы, Г.Баязитовның үз сүзләре белән әйткәндә, «бер мәхәббәтле юлдаш» буларак, баштарак аена алты тапкыр гына чыкса, тора-бара аның нәшер ителү ешлыгы арта. 1905-1917 елларда Русиянең 17 шәһәрендә – Мәскәү, Уфа, Оренбург, Самарада һ.б. калаларда – татар телендә йөздән артык газета-журнал гамәлгә куела (аларның һәркайсын «Нур» алкышлап каршылый, мәсәлән, үзеннән соң «Казан мөхбире»нең икенче булып дөнья күрүенә «самимил-кальб (чын йөрәктән) тәбрик идәмез!.. Юлларымыз төрле булса да, мәтлаб (омтылыш), максат-морадлар һәммәбездә бердер» дип сөенү хисен белдерә). «Казан мөхбире», «Фикер», «Әлгасрел-җәдид», «Әл-ислах», гомумән, «Йолдыз»дан «Кояш»ка кадәр басмалар кабынгач, әлбәттә, каләм әһеленә эш-иҗат мәйданы киңәя. Шулай да Гатаулла агай исән чагында «Казан татар» телендә ул нәшер иткән газетаның абруе кимеми. Башта кырым татары Ильяс морза Бораганлы (Бураганский) вә ширкәте басмаханәсендә, аннары Баязитовларның шәхси типографиясендә басылган «Нур»ның 1914 елга кадәр 310 саны чыгып өлгерә.

Илдәге вазгыятьне һәм цензура басымын истә тотып, басманың мәсләге Г.Баязитов гыйльми һәм әдәби мәсьәләләрне бергәләшеп («бәхәс вә моназарә тәрәккыендә»)

тикшерү, ә сәяси кыйбласын «конституцияле падишаһлык» юлын сайлаган партия-фиркя белән «берлектә бармак», ягъни җәдитчеләр һәм монархистлар арасындагы «алтын» урталыкта булу дип билгели. Бередә, чыннан да, «падишаһ әгъзам император хәзрәтләре»нең фәрманнары, хөкүмәт карарлары һәм аларга мөнәсәбәтне (гел унай гына түгел!) чагылдырган мәкаләләр белән янәшә сәяси һ.б. көнүзәк мәсьәләләрне, милли һәм дини тормышны тасвирлаучы, Русия мөселманнарының дөнья күләмендә алып барган рухи, иҗтимагый, мәгърифәтчелек эшчәнлеген яктыртучы хәбәрләр дә урнаштырыла, ягъни «дахили» (эчке, илдәге) һәм «хариҗи» (тышкы, чит мәмләкәтләрдәге) хәлләргә укучыларның игътибары даими җәлеп ителә. Аларга Шәриф Камалның беренче санда ук чыккан «Әфгалә милләтә бер имган» (Милләт эшләренә бер караш) дигән мәкаләсе юнәлеш биргәндәр кебек. Мәсәлән, газета сәхифәләрендә Тукай тәбрикләп язган манифесттагы сәяси хокукларны тулысынча файдаланырга чакыру яңгырый. Бишенче елгы инкыйлаб чорында, гомумән, Русия сәяси тормышында мөселманнарның катнашуларын аклау-яклау эзлекле рәвештә чагылыш таба (ул заманда да ислам фанатизмы белән куркыту шактый көчле була бит), әйтик, Оренбург Диния нәзарәтен таркатуга каршы хатлар басыла. Мөхәррирнең җиңел кулы белән татар җәмәгатьчелеге өстенә көчле бер мәгълүмат ташкыны ишелә. Гомумән, Г.Баязитовның шул заман өчен төрле мөһим мәсьәләләрне күтәргән, милләт мәнфәгатьләрен кайгыртып язган мәкаләләреннән башка күз алдына китерүе мөмкин түгел. Алар үзара аңлашуга, бердәмлеккә, алгарышка өнди. Аерым очракларда, Тукай язганча, «сүзлә түгел, басмада» аңласыннар өчен, газетада кайбер текстлар (мәсәлән, муллаларны хәрби хезмәттән азат итү турында түрәләргә мөрәҗәгать яки «Несколько слов по поводу съезда миссионеров в городе Казани» дигән язма) рус телендә дә бирелә. Берничә санда Ризаэддин Фәхреддиннең «Манчжурия мәктүбләре», Г.Баязитовның «Ханкирмән» әсәре басылып килә. Газетада даими рәвештә милли сәнгатькә кагылышлы материаллар, «Социализмга фәлсәфи бер нәзар», «Анархизм-коммунизм» кебек фәнни-популяр һәм полемик мәкаләләр чыгып тора. Аның белән язышкан мәшһүр шәхесләр сафында Фатих Кәрими, Гаяз Исхакый, Камил Мотыйгый, Кәбир Бәкер, Сәгыйть Сүнчәләй кебек каләм ияләре, Һади Максуди һ.б. абруйлы галимнәр, Дәүләт Думасында мөселман бүлекчәсен әйдәп баручы Садри Максуди, Гайсә Еникиев, Котлыгъмөхәммәт Тәфкилевләр, мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов шикелле күренекле дин әһелләре дә бар. Петербургта Җәмигъ мәчет салдыруның башлап йөрүчесе булганлыктан, Гатаулла ахун әледән-әле шул теманы күзгата, Русия мөселманнарының игътибарын бу саваплы эшкә тартып тора, иганәчеләрнең исемләгән саннан-санга игълан итеп килә (ул мәчетне салганда, Рәмиевләр, Дебердиевләр һәм башка татар байлары, Бохара әмире дә зур матди ярдәм күрсәтә).

Беренче саннарыннан ук, халкыбызның мәдәни үсеше турында кайгыртып, «Шура» журналы үрнәгендә, «Нур» да тел моназарәсе (бәхәсе) башлап җибәрә. Ана «Татарча мөхәррирдән берничә сүз» дигән мәкаләсе белән Гатаулла Баязитов үзе этәргеч бирә. Бу эшне ул «зур педагогический һәм тарихи мәсьәлә» дип, төрек теленең язма әдәбиятта өстенлек алып торуына (күргәнебезчә, Тукайның «Нур»га котлау шигыре дә шундый корама тел белән язылган) борчылып: «Вакыт килде, милләт эшләренең беренчесе — телләр, буны сөйләргә һәм кырык кат тукырга кирәктер», — дип искәртә. Әлеге бәхәскә Һади Максуди кебек күренекле шәхесләр кушыла. Мөхәррирнең «Нишләек, кайсы телдә язаек — ягъни яна әдәби тел (төрек госманлы теле) яки үземезнең борынгы, халкымыз сөйли торган иске татар телемездәме язамыз?» дигән соравына тәүгеләрдән булып җавап биргән Гаяз Исхакый шулай ук, госманлы төрек шивәсенә йөз тоткан «әдәби тел» була алмый, ул халык сөйләшкән җанлы сөйләмгә нигезләнергә тиеш, ди: әдәби тел «ни хакында язылганлыгы һәр укый белә торган кешегә тәмам аңлатырдай булу берлән буладыр. ...Үземез сөйли торган телдә язарга тиеш димен һәм язамын». Тел бәхәсен йомгаклаган мәкаләсендә Г.Баязитов: «Иске аркадашымыз «Тәрҗеман» шивәсендә язуны мәгъкуль күрәдер. Без исә... «Нур» яза торган тел — татар-төрек шивәсендә язмакны хуш күрәмез... Казан халкының сөйләшә торган телдә булуны артыграк күргәне ачыкланадыр» (татар-төрек дигәнендә татар-төрки төшенчәсе күздә тотылган булса кирәк). Гомумән, Гатаулла хәзрәт чыгарган «Казан телендәге» газета безнең горурлыгыбыз санала ала, ул үз вакытында халкыбызны дини-рухи тәрбияләүдә, мәгърифәткә, милли бердәмлеккә өндәүдә, аның иҗтимагый аңын уятуда зур роль уйный.

Рәзән губернасының Төмәнсу авылында Касыйм мишәрләреннән чыккан рухани гаиләсендә туып, заманында Арчаның атаклы Кышкар мәдрәсәсендә белем алган Атаулла (Гатаулла) Баязит улы 1911 елның 21 апрелендә фани дөньядан бакыйлыкка күчә. Аны дәфен иткән көндә, җәмәгать һәм мөселман эшлеклесе буларак зур хөрмәт йөзеннән, шәһәр башлыгы әмере белән, биш минутка ил башкаласында шәһәр транспорты хәрәкәтен туктатып торалар, завод торбалары Петербургка матәм авазы тарата (хәзер мондый хәл булырга мөмкинме?!). Бу унайдан Ризаэддин Фәхреддин «Шура» журналында: «Милләтемезнең олуг адәмнәреннән улан бу кемсәнең фәүте (үлеме) зыягы газыйм (зур югалту) саналырга тиешледер», – дип язып чыга. Гатаулла хәзрәтнең «Нур» газетасындагы соңгы сүзләре аның рухи васыяте сыман яңгырый: «Без, Русия татарлары өчен, үзара улан ихтиляфларны (ызгышуларны) ташлап, тәрәккый вә тәмәдден (мәдәният) эшләре илә мәшгуль улырга кирәк. Безем кеби артта калмыш, тәрбиясез вә мәгарифсез татар милләте өчен шуннан башка юл тотарга ярамый».

Г.Баязитовның эшен улы – атасыннан башлангыч белем алган, башкаладагы атаклы Гуревич гимназиясен һәм аннары Петербург университетының француз-төрек бүлеген тәмамлаган, этисе кебек үк, Чит илләр министрлыгында тәрҗемәче вазифасын башкаручы Мөхәммәтсафа дәвам итә. Тукай Петербургка килгәч, аларның очрашып сөйләшүе мәгълүм. Ул хәйрия һәм җәмәгать эшләре белән дә шөгыльләнә (мәсәлән, генерал Шәех-Али белән бергә, кызганыч ки, рус карагруһ оешмаларына якынрак булган Русия мөселманнарының «Сыйрател-мөстәкыйм» җәмгыятен төзи). Октябрь (И.Рәми белән Р.Даутов ни өчендер Февраль дип язалар) инкыйлабына кадәр Уфада мөфти һәм Оренбург мөселман җыенының башлыгы булып тора. Бер яктан, карагруһларга якынаюы газетаның дәрәҗәсен төшерсә, Уфага китүе аның газетага игътибарын нык киметә, шуна күрә, гәрчә кайбер чыганакларда 1917 елда большевиклар яба дип расланса да, «Нур» 1914 елда ук чыгудан туктый. Мөхәммәтсафаның тормышы, күпчелек Сталин тоткыннарыныкы кебек, фаҗигале рәвештә тәгалләнә.

1990 елның 19 февралендә, Русиянең икенче башкаласындагы милләт җанлы затлар тырышлыгы белән, «төньяктагы балкыш», иҗтимагый-сәяси һәм мәгърифәт таратучы газета буларак, янадан кабынды. Ул, әлбәттә, Кыям Корманаев, Җәмил Гыйниятуллин, Рафис Гыйззәтуллин кебек шундагы химаячеләр ярдәмендә яши. (Кызганыч, мәгълүм сәбәпләр аркасында, хәзер инде ул ешрак рус телендә генә чыга, әмма төп мәсләге барыбер милләтебезгә хезмәт итү – гореф-гадәтләребезне, тарихыбызны искә төшереп тору, онытылган исемнәрне янарту, уртак мәдәни мәйданга берләштерү, туган телне өйрәнүгә чакыру булып кала.) Петербургта яшәүче кардәшләребезнең мәдәни елъязмасы булган басманы Татарстан да онытып бетерми. Г.Баязитовның истәлегенә Русиянең борынгы башкаласындагы Зур проспектта («Нур»ның беренче саны дөнья күргән йортта) мемориаль такта куелды (авторы – Петербург скульпторы Әхнәф Зыякаев). Шул чорларда Мөхәммәтсафаның хәзер Иерусалимда яшәүче оныгы Ялкын белән дә элемтә урнаштырылды.

Газетаның татар матбугаты башлангычы буларак 100 еллыгын искә төшергән көннәрдә аның хакында галимнәр Равил Әмирхан, Мөнҗия Мәрдиева, журналистлар Илсөяр Хәйруллина, Хөсәен Вәлиәхмәтов, хәзерге замандагы баш редакторлары – Баязитовның нәсел дәвамчыларыннан берсе (әнисе Аиданың әбисе Гатаулла агайның кызы Заһидә оныгына исемне дә әтисе белән бергә тыңлаган итальян операсыннан алып куша) журналист һәм мәгърифәтче, халыкара бүләкләргә лаек булган Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әлфинур Гафурова, заманында Оренбург якларында хәйрия эше белән данлыклы Галикәев байлар токымыннан килүче, бүген үзе дә эшмәкәр Ринат Мәһдиев һ.б. язып чыкты. Әлфинур ханым башлап йөргәнлектән, газета тарихына багышланган фәнни конференцияләр оештырылды, ул шулай ук Г.Баязитовның шәхесе һәм тормышы турында монографик хезмәт язып нәшер итте.

Моннан 110 ел элек чыга башлаган «Нур» газетасы бүгенге татар көндәлек матбугатына да лаеклы үрнәк булып тора.

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ**



*Фирая Зыятдинова (1945-2006) — хис-кичерешләргә бай лирик шагыйрә. Шигырьләрендә яшьлек, мәхәббәт, күңел матурлыгы, яшәү кадере, бәхеткә омтылу кебек мәңгелек темалар өстенлек итә. «Бәхет өчен күп кирәкми», «Мин сине шундый сагындым», «Китмим әле яшьлегемнән» һ.б. күңелгә үтеп керә торган җырлары танылган җырчылар тарафыннан әле бүген дә яратып җырлана. «Матур буласым килә», «Язгы ярсу», «Мин Кояшка елмаям» һ б. исемдәге дистәләгән китап авторы. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек була.*

Фирая
Зыятдинова

# ТИК ЯРАТЫП КИТИК ДӨНЬЯДАН

## Ышаныгыз!

Хаталардан һичкем хали түгел,
Ялгышты, дип, ялгыз итмәгез.
Бураннарда калып, юлдан язсам,
Аерылды, дип, ташлап китмәгез.

Гөнаһларым булса, шелтәләгез,
Юлларыма борылып карармын.
Сүнә төшсәм, жан өрегез миңа —
Ялкынланып тагын янармын.

Үпкәләшкән чаклар булмас, димим,
Болгана да сулар, тона да...
Һәр йөрәктә хаклык уты яна,
Мин ышанам менә шунарга.

Юк-бар үпкәләүләр онытылыр,
Хыянәтне генә кичермәм.
Соңгы сулышкача мин сезнеке,
Ышаныгыз миңа, кешеләр!

* * *

«Жырларың ник моңлы?» — дип сорыйлар.
Мин — авылда үскән баламын.
Моннарны мин, сызылып таң атканда,
Кошлар сайравыннан аламын.

Көз сулышы, диләр, жырларыңда,
Күбрәк язны жырла син, диләр.
Көзләр миңа язны якынайткан
Жырлар алып килә — белмиләр.

Сулар бездә салмак, уйчан ага,
Уйчанлыгым, бәлки, шуннандыр?
Чишмә жыры, моңлы бер көй булып,
Күнелемә кереп тулгандыр.

## Тик яратып...

Без һәрвакыт яратырга тиеш,
Яратмау ул — Жирдән юк булу.
Ә ярату — йөрәк тулы әрнү,
Ярату ул — тоташ ут булу.

Утлар бит ул жылытып кына калмый,
Яндыра да көлгә калдыра.
Жаннарыңа сөю бик еш кына
Сары сагыш булып сарыла.

Котылу юк Жирдә сагышлардан,
Котылу юк вакыт-еллардан...
Янсак яныйк, көлгә калыйк, әйдә,
Тик яратып китик дөньядан.

## Ни диярләр икән?

Ни мәңгелек икән жир йөзендә? —
Бар да бетә, бар да югала...
Кеше килә, яши. Китеп бара,
Ни кала соң аннан, ни кала?

Дан, дәрәжә, байлык, югары пост —
Вакытлылар бар да дөньяда.
Мәңге китмәскә күк килгәннәрдән
Ни кала соң Жирдә, ни кала?

Йолдыз кебек атылып үтә гомер,
Жир өстенә түгелеп моң кала.
Әйткән сүзләр, кылган эшләр кала
Хатирәләр булып дөньяга.

Тормыш күкләрендә эз калдырып,
Йолдыз кебек атылып бер үткәч,
Нәрсә калыр бездән кешеләргә?
Ни диярләр икән без киткәч?!

## Гаҗәп түгел

Мин елмая идем бар дөньяга,
Мин елмая идем гөлләргә.
Язмыш әллә жәза бирде микән
Кайгы килгәндә дә көлгәнгә?

Хәзер инде шатлык килгәндә дә
Моңлы булып туа жырларым.
Сизеп торам, еллар узган саен
Нечкәргәнен күңлем кыллары.

Нечкәрсә дә гажәп түгел инде,
Өзелер дә әле беркөнне,
Көйли-көйли жирдә ин аһәнле,
Ин сагышлы, моңлы бер көйне.

Беләм ич мин жирдә сагышларның
Шатлыклардан күбрәк булганын.
Минем күңел, ахры, сыйдыргандыр
Зар-моңнарын бөтен дөньяның...

Мина язган бугай тибрәтергә
Ин-иң нечкә күңел кылларын.
Шуңа, бәлки, тормыш талларына
Моңлы былбыл булып кунганмын.

## Бик ямансу булыр әле безгә...

Кар-бураннар мәңге дулый алмас,
Тагын килер язлар әйләнеп.
Бик ямансу булыр әле сина
Якты язлар кергән мәлләрне.

Төшләренә кереп йөдәтермен,
Жәйге таңнар сызылып атканда.
Шәфәкъләргә карап моңланырсың,
Алсуланып кояш батканда.

Бик ямансу булыр әле сиңа
Алтын көзләр кергән мәлләрне.
Төшенерсен агачыннан кубып,
Жиргә төшкән яфрак хәлләрен.

Карлар сыман, керфегенә кунып,
Күзләренә синең багармын.
Сагыш-моңга түзә алмам мин дә,
Күз яшьләре булып тамармын...

Бик ямансу булыр әле безгә...

# ЯР ЧАЛЛЫ ТҮГЕЛ, ЧАЛЛЫ!

Чаллы шәһәре җөмһүриятебез тормышында үзенә игътибарны күбрәк җәлеп иткән саен, аның тарихы һәм атамасы белән кызыксыну да көчәя. Бу турыда матбугатта «Нигә Яр Чаллы?» яисә «Чаллы шәһәренең тарихы» һәм шуңа охшаш башка язмалар урын алды. Артык «хислеләр» Чаллы атамасының борынгылыгын инкарь итеп, аны соңгы чор белән билгеләргә тырыша башлады. Шулай да, ярый әле, «соң булса да, уң булсын дигәндәй», инкыйразга ук килеп җитмәдек. Алайга калса, Чаллының (Н.Челны) атамасы чынлап та урыс җырларында җырланган «Выезжали расписные Стенки Разина челны» сүзенә кайтып каласы иде. Иң яхшы очракта да Чаллы атамасы «Челны — көймә» мәгънәсендә, Себерне яулап алучы Ермак белән бәйләнәчәк иде. (Шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер: бу көймә, ялган тарихка ияреп, Чаллы шәһәре гербында үз урынын алып өлгерде инде.) Татарның тарихи атамасына урысның «Набережные»сы ябышып, «Яр» кушымтасы да өстәлде.

* * *

Ә чынбарлык нидән гыйбарәт соң? Тарихка күз салыйк. Чаллы шәһәре дигәч тә, хәзер үзенең «КамАЗ»лары белән дөньяга танылган «Яр» Чаллы шәһәре күз алдына килә. Әмма Чаллы атамасының тарихына бәйле рәвештә, безгә башка Чаллы шәһәре турында сүз алып барырга кирәк. Ул — Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш, Тәберде Чаллысы авыллары янында урнашкан борынгы Чаллы шәһәре (1183-1556). Тарих кабатлана, диләр. Мәшһүр Биләр-Болгар калалары, Яна һәм Иске (Эчке) Казан шәһәрләре кебек, хәзерге Чаллының да тулы хокуклы тарихы — Борынгы Чаллысы бар.

Чаллы атамасы беренче тапкыр 1184 (1183) елгы вакыйгаларга бәйле Ипатьев елъязмасында[1] искә алына. Анда Бөек Болгар дәүләтенә 1184 елда Владимир-Суздаль кенәзе тарафыннан оештырылган һөҗүмнәр уңаеннан мондый юллар бар: «Иделнең Болгардан астарак өлешендә урнашкан Исады утравында, урыс көймәләре тупланып, шуннан Олуг шәһәргә (Биләргә) һөҗүм ясадылар. Бу сугышлар вакытында Исады утравына, көймәләр белән Саба-Күлләр, Челматлар һәм дә алар белән бергә Тәмте болгарлары — барлыгы 5 мең кеше килеп һөҗүм итте». Әлеге бәрелешләрдә кенәз Изославның үтерелүе һәм шулай ук болгарларның Торск шәһәреннән атлы гаскәрнең ярдәмгә килүе дә искә алына.

Әйтеп үтелгән вакыйгалар һәм язма безнең тарихыбызга караганга күрә, сорау туа: бу исемнәрне йөрткән кайсы болгар кабиләләре соң болар, кайда яшәгәннәр һәм бүгенге көндә аларның варислары кемнәр һәм ничек яшиләр? Кемнәр соң алар Саба-Күл, Тәмте, Челмат кабиләләре? (Соңрак чорга караган елъязмаларда Сабакүл, Челмат шәһәрләре дип тә языла[2].)

Бу сорауны үзләренә күпләр куйган. Мәгълүм тарихчы В.Татищев балымар, биләр кабиләләре кебек Челматларны да болгарлар дип саный. Ул бу аталышның XVII гасырга чаклы кулланышта булуын күрсәтә. С.Ремезов картасында да хәзерге Алабуганы «Шайтан каласы» Челматлар дип укыйбыз. Ә инде Н.А.Спасский үзенең тикшеренүләрендә Лаеш, Кашан, Котлы Бөкәш, Тәберде Чаллысы, Кирмәнчек, Мамадыш (Алабуга) шәһәрләрен барысын да Челмат (Чаллы) кабиләләренеке дип искәртеп уза[3].

[1] ПСРЛ. Т.II. Ипатьевская летопись. — М., 1962. — С. 626.

[2] ПСРЛ. Т. I. Лаврентьевская летопись и Суздальская летопись по Академическому списку. — М., 1962. — С. 390; ПСРЛ. Т. IX. Патриаршая или Никоновская летопись. — М., 1965. — С. 10; ПСРЛ. Т. XV. Летописный сборник, именуемый Тверской летописью. — М., 1965. — С. 269.

[3] Спасский Н.А. Очерки по родиноведению Казанской губернии. — 2-е изд. — 1912.

Бөек Болгар дәүләтенең бер өлешен хасил иткән бу болгар кабиләләренең тиз арада үзләренең башкаласы Олуг Биләргә ярдәмгә килүләре дә игътибарга лаек. Алар турындагы мәгълүматларның 1184 елда ук искә алынуы Чулман буендагы болгарларның тормышын күзалларга мөмкинлек бирә. Беренчедән, аларның дошман килүе турында тиз арада хәбәрдар булуы болгарларның бердәмлеген белгертсә, икенчедән, кыска вакыт эчендә 5 меңлек гаскәр куя алулары, көймәләрдә һөҗүм ясау мөмкинлекләре игътибарга лаек.



*Борынгы Чаллы шәһәренең капкасы. Казу эшләре нәтиҗәләре буенча архитекторлар тарафыннан эшләнгән.*

Бу чорларда 20-30 сугышчы бирә алырлык авылларны да зур авыллар исәбенә кертергә була. XII гасыр ахырында алар күбесенчә Идел-Чулман буйларында яши. Хәзерге чорда без атап узган җирләр тирәсендә XII гасырга караган дистәгә якын шәһәр (Алабуга, Кашан 1, Кашан 2, «Керпе угы» шәһәрчеге (XII-XIV), Ташкирмән, Имән Кискә) һәм күп кенә борынгы авылчыклар һәм каберлекләр билгеле. Ә инде соңрак чорга караган тарихи һәйкәлләрнең саны күп тапкырга арта һәм аларның урнашу җирләре дә күпкә киңәя.

Челмат атамасына киңрәк тукталасым килә. Челматлар алар — Челман яисә Чулман кешеләре. Чулман — хәзерге Кама елгасының шул чордагы аталышы. Чулман атамасы үзе дә төрле гасырларга караган елъязмалар һәм китапларда төрлечә язылa. Мәмлүкләр чоры географы Әл-Омари (XIV гасыр) аны Чулыман, икенче бер гарәп авторы Ибн Халдун (1332-1406) Җалыман дип атап уза. Шулай ук Елыман, Чалыман һәм башка исемнәр дә билгеле. Кыска гына тарихи экскурсия ясаганда, Чулман атамасының төрләнү тарихы һәм географиясе шундый.

* * *

Ә Чаллы атамасының мәгънәсе нәрсәгә кайтып кала соң? Шунысы кызык: бу аңлатмада да һәркем үзенчә ачыш ясый. Аның беренчесе «Чаллы — ташлы» мәгънәсендә аңлатыла. Андагы «Чал-таш», имеш, чуваш теленнән алынган. Ләкин без элекке чорда Чаллы тирәсендә бер генә чуваш авылын да таба алмыйбыз. Аннан соң «таш» ул — төрки сүз һәм «таш» сүзен без инде «таш билге» язуында Болгар-Алтын Урда чоры кабер ташларыннан ук укып беләбез. Акташ, Ташкичү, Ташкент һәм башка «таш» сүзенә бәйле борынгы атамаларда «чал» сүзе күренми дә. Икенче бер аңлатмада Чаллы атамасы шул исемдәге болгар кабиләләре булу мөмкинлегенә ишарә ясый. Җитмәсә, «чал» сүзе Дунай болгарларында да очрый. Шулай да бу турыда борынгы язмаларда еш искә алынмый.

Ниһаять, тагын бер аңлатмада «чал» сүзе борынгылыкны белдерә һәм ул күпкә киңрәк мәгънәгә ия (чаллы, борынгы). Күптәнге, иске әйберләр, вакыты җиткәч, агачлар да саргаялар, соры төскә керәләр. Күп кенә яр буйлары да, тау башлары да аксыл соры ташлар, кипкән үләннәр белән каплана. Олыгайган саен, чәчләргә дә чал керә. Гомер-гомердән милләтебезгә тереклек суы биргән Иделне олылаганда да, «Чал Идел», дибез бит.

«Чал» — борынгы төрки сүз. Төркиләрдән ул күп кенә башка халыклар теленә дә күчкән. Урыс халкы да «чал» — «чалый» сүзен күп кенә аңлатмаларда куллана. Мәсәлән, чалый — серый, чалый — седой, чалый конь, чалая погодка, чалая могила һәм башкалар. Кыргыз телендә «чал баш аска» — «седоголовая скала» мәгънәсендә кулланыла. Ә шул ук искә алып узган Дунай болгарларындагы «чал» сүзе кар белән капланган тау башларын аңлата. Чал чәчләрне генә капламый, халык кабул иткән мәгънәдә тау башларын да, елга буйларын да, хәтта җәнлекләр, кешеләрне дә чал баса. Бигрәк тә аларның төсләре аксыл-соры булса.



*Борынгы Чаллы шәһәрендә табылган Шәһәр гербы, талисман. XII гасыр.*

Чаллы атамасының таралышына игътибар итик. Хәзерге чорда җөмһүриятебездә булган 20дән артык Чаллы атамасындагы авылларның 75-80 проценты Чулман буйларыннан 15-20 чакрым ераклыкта урнашкан. Чулманның үзенә үк биш Чаллы елгасы кушыла. Ә соңрак чорга карасак, Казан губернасы җирләрендә Чаллы атамасында барлыгы 33 авыл санап үтелә. Ә Чел, Чул атамалары белән алар — 40ка, авыллардан тыш атамалар белән 60ка җитә. Аларның урнашуы да борынгы Чулман буйларында. Мәсәлән, шул чордагы Лаешта — 11, элекке Алабуга, Малмыж, Минзәлә өязләрендә 7 Чаллы атамасындагы авыл була. Челмат-Чаллыларның шул чордагы яшәү җирләре хәзерге Саба Күл, Тәмтеләрдән көнчыгыштарак, Чулман һәм Чулманга коя торган Чаллы елгалары тирәсендә урнашкан була.

Кызганычка каршы, хәзерге вакытта бу авылларның бер өлеше күчерелгән, исемнәре үзгәртелгән һәм юкка чыккан авыллар исәбенә кимеде. Мәсәлән, әйтеп узылган җирләр тирәсендә 1619 елгы язма китапларда искә алынган Югары Чаллы хәзер — Керәшен Казаклары, Яңа Чаллы — Олы Кадрәк, Түбән Чаллы Мәмле Казаклары исемнәрендә билгеле.

* * *

Чаллы атамаларының таралуы яисә кимүе, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, татар авылларының шәһәрләрдән — 30-40, ә зур елгалардан 15-20 чакрым ераклыкка куылуы сәбәпле дә. Инде Чаллы төбәген күзаллап, аның үзегенә күчсәк, шул тирә-яктагы Чаллы авыллары уртасында безне борынгы Чаллы шәһәрлегенең әлегәчә сакланган ныгытма урыннары, саклану чокырлары, шул чордагы кабер ташлы зират урыннары каршылар.

Бу шәһәрне татар язмаларында еш кына Чаллы (Кала тау), Корым Чаллы, ә урыс язмаларында Чаллин, Чалым, Чаллым һәм Чалмат исемнәрендә күрергә була. Казан шәһәре яулап алынганнан соң да, борынгы Чаллы шәһәренең атамасы әле тарихтан бөтенләй үк төшеп калмый. Казан шәһәре урыслар тарафыннан җимерелгәч, тирә-яктагы халык милли азатлык өчен көрәшкә күтәрелә. Шул чорга караган язмаларда 1556 елда баш күтәрүчеләрнең Чаллым шәһәрен торгызулары искә алына[4]. Чаллым-Чаллы шәһәрен кабат торгызып, аның җирлегендә вакытлыча Казан ханлыгы һәм аның башкаласы торгызыла. Чаллылар ханлыкка Сөембикәнең энесе Гали Әкрамны чакыралар[5]. Гали аларның ярдәм сорауларын кире какмый. Әтисе Йосыф мирзадан да, Әстерхан ханлыгыннан да булышырга вәгъдә алгач, ул үзенең коралланган 300 кешесе белән Мәмеш Бирде җитәкчелегендәге баш күтәрүчеләр тарафыннан күптән түгел генә кабат торгызылган Чаллы каласына хан булып килеп урнаша. Алар кул астында берләшкән баш күтәрүчеләр, тигезсез сугышларда батырларча көрәшеп, Мәскәү якларыннан берсе артыннан берсе килеп торган князь Н.Мстиславский, Юрьев, бояр Морозов һ.б. җитәкләгән, баштанаяк коралланган басып алучыларга каршы әледән-әле каршылык күрсәтеп, аларның хәрәкәтләрен тыеп торалар. Әмма тигезсез сугышлар нәтиҗәсендә баш күтәрүчеләрнең көчләре кимегәннән кими. 1556 елда Казан ханлыгының соңгы форпосты Чаллы шәһәре дә алына.

* * *

Тарихи һәм сәяси вакыйгаларга бәйле, Казан ханлыгы чорыннан калган археологик һәйкәлләр бик аз өйрәнелгән. Без бу чорны күбесенчә урыс тарихы, аның тарихчылары күзлегеннән генә күреп беләбез, өйрәнәбез. Алары да бары өзек-төтек юллар белән Тау ягы, Казан, Арча тирәләре турында гына. 1552 елда Казанның алынуы әле Казан ханлыгының тулысынча җимерелүен күрсәтми. Илбасарларга каршы сугыш дәвамлы була. Бу чорда Казан шәһәре Казан ханлыгында төп рольне үз кулына алса да, аның әле Казан белән бергә элекке кечкенә ханлыкларының

[4] ПСРЛ. Т. XIX. История о Казанском царстве (Казанский летописец). — СПб., 1903. — VII-XVI. — 530 с.
[5] Трепавлов В.В. История Ногайской Орды / В.В.Трепавлов; отв. ред. М.А.Усманов. — М.: Изд. фирма «Восточная литература» РАН, 2002. — С. 257-258.

(билек, әмирлекләренен) үзәген тәшкил иткән башка төбәкләре дә була. Әлеге аерым төбәкләргә Казан тирәсеннән тыш Арча төбәген, Мишә елгасының югары һәм урта агымы буйларын, Мишәнең аскы өлешеннән алып Нократ буйларыннан ары сузылган элекке Чаллы ханлыгы җирләрен, Тау ягын, аннан төньяктагы Ашыт буйларын һәм башкаларны кертергә була.

Бу элекке билек җирләренең үзәкләрен тәшкил иткән шәһәрләрне дә без Казан белән бергә Казан ханлыгы шәһәрләре исәбенә кертә алабыз. Алар: Арча, Чаллы, Өтернәс, Алат, Иске Җөри, Иске Казан, Алабуга һәм башкалар. «Казан елъязмасы»нда алар нигытылган кечкенә шәһәрчекләр белән бергә утызга якын дип әйтелә[6].

* * *

Сәяси яктан йомшаклык җилләре искәндә, тарихчыларга археологик яктан азмы-күпме өйрәнү мөмкинлеге булып алды. Хәзерге Чаллы шәһәре биләмәсенә кергән Элеватор тавында да, аз булса да, археологик яктан тикшерү уздырылды. (Бу урында шәхси йортлар тыгыз урнашкан, көрәк тыгарга урын табуы җиңел түгел.) Чаллы елгасының тамагында утырган урында (бу тирә Элеватор тавы атамасында билгеле), тикшерү нәтиҗәләренә таянып, археологлар хәрби ныгытма урнашкан[7] дип фараз кыла. Шунда ук инде урыны билгеләнгән һәм вакыты Алтын Урда чоры белән тәңгәлләштерелгән борынгы авыл урыны (Е.П.Казаков аны «Чаллы тамагы авыллыгы» буларак тамгалый) да табылды. Керамик материал да бу урында бик борынгы чорларда ук болгар-татар халкы яшәгәнлеген дәлилли.

* * *

Янә Чаллы шәһәре һәм аның тирә-ягын күзаллап, тарихын барлап, әйтәсе килгәнем шул: моннан 810 еллар элек искә алынган, биредә яшәгән Саба Күл, Тәмте һәм Чаллы кешеләре — безнең болгар бабаларыбыз. Алар бердәм булып, үзара аралашып, ярдәмләшеп яшәгән, кайгы-шатлыклары да уртак булган. Бу чорларга караган бизәкле кабер ташлары аларның үз әби-бабаларына ихтирамлы булуларын белгертә. Хәзерге Чаллы шәһәре дә — үткән чорлар мирасы. Аның исеме дә Яр Чаллы түгел, Чаллы! Без шулай барына да ризалашабыз һәм читләргә ярашабыз икән, тиздән ата-баба җирендә тамырсыз, тарихсыз калуыбыз да бик ихтимал.

Менә шундый чагыштыру, язмыш һәм чынбарлык!

Язмамны тәмамлап, тагын шуны да әйтәсем килә: тарихыбызны барлап, өйрәнеп, үткәннәр белән бүгенгебезне чагыштырып, бик яхшы сабак аласы бар безгә. Бу эшләрне озакка сузмаска, тарихыбызны битарафлыкта, үз тузанында ук күмеп калдырмаска иде!

* * *

Чаллыны күтәрү, дөньяга танытуда аның тарихына игътибарны юнәлтү бик тә мөһим. Монда борынгы Чаллының «КамАЗ» юлыннан бары 3-4 чакрым ераклыкта, Казан белән хәзерге Чаллының нәкъ уртасында урнашуы да күп уңайлыклар тудыра.

Борынгы Чаллының Кремль диварлары, аның эчендәге Хан йорты һәм мәчете торгызылып, тирә-яктагы изге чишмәләре чистартылса, янындагы искиткеч табигате тагын да матураеп, туристларда да онытылмас хисләр калдырыр иде.

Хәзерге вакытта тормышка ашырыла башлаган «Көмеш ай» проекты да киләчәктә Җукәтаудан соң Түбән Кама — Чаллы — Алабуга — Кирмән — Борынгы Чаллы — Кашан — Казан тукталышлары белән түгәрәкләнер. Борынгы Чаллы тирәсендәге авылларның халкы да гаҗәеп эшчән, игелекле булулары белән икътисади, рухи һәм мәдәни проблемаларны хәл итәргә булышыр иде.

**Нурулла ГАРИФ**

[6] ПСРЛ, XIX, 1903. — С. 126; ПСРЛ, XIII, 1965. — С. 225.

[7] Отчёт об археологическом исследовании в Набережных Челнах / Багавиева А.А., Нигамаев А.З., Хузин Ф.Ш. — Елабуга, 1999. — С.30.

Миңнеруй
Гайфуллина

# ЙӨРӘГЕМ ЯНА

ХИКӘЯ

— Яшьлектә адәм баласы бигрәк самими була инде, сеңел, бигрәк наив! Һәр әйткән сүзгә ышану дисеңме. Аннан-моннан каләм тырнаштыру чын журналист булдың дигән сүз түгел икән әле ул. Син дә наив булма, сеңлем, наив булма. Сине Министрлар Кабинеты газитенә язгалыйсың дип ишеттем. Борын чөяргә ашыкма, сеңел, сак бул. Акылга утыртучылар табыла ул, сеңел, мине дә төп башына «утырткаладылар», — дип мишәрчәләп бик тиз башлады үзенең сүзен, карт корреспондент. Ул да яшьлегендә «Социалистик Татарстан»га мәкаләләр язгалап торган икән. Каләм тотып, көн кадагына суккан кыю мәкаләләр генә язуыма инанып йөргән чорым, — дип, иркенләп сөйләп китте олыгайган каләм иясе. — Очраганда «дөрес язгансың, маладис», дип мактап җибәрүчеләр дә ешайды. Мин табигатем белән бик тиз ышанучан, наив кеше: шулай куанып, рәхәтләнеп язам да язам. Минем язганнарны яратмаган кеше юк дип ышану да наивлык икән ул. Шул наивлыкны берәү тәки «лечить» итте бит, сеңел. Шулай, йомышым төшеп, бер зур түрә янына кердем. Керсәм, анда кем генә юк! Районның бөтен «каймагы» бергә җыелып, мыдыр-мыдыр, әкрен генә ни турындадыр киңәш-табыш итеп утыралар. Миңа керергә ничек рөхсәт иткәннәрдер — монысын әле һаман да аңламыйм. «Моңардан барыбер котылып булмас» дип уйлаулары булгандырмы. Но керттеләр. Түрәләрнең тыныч сөйләшүләрен, гармонияле мөнәсәбәтләрен боздым да куйдым бит, сеңел, бераз утыра торгач. Хәер, гаеп миндә түгел: бик дәрәҗәле түрә белән бер фикергә килеп булмады, бәхәскә керергә туры килде. Нәрсә турында бәхәсләшкәнне әйтеп тормыйм, һәркем үзен хаклы саный инде, әлбәттә. «Дөрес»ләр күп инде ул, ләкин шул дөреслекне әйтүче телләләр бәхетсез, сеңел. Андый телне кис тә ат икән инде син аны. Тыныч яшәтми икән ул андый телле булу. Зур түрә белән бәхәсләшәбез, бәхәснең иң кайнар җирендә монын урынбасары (бик йомшак йөрәкле кеше икән, бәгърем, тыңлап утырган, күрәсең, рәхмәт төшкере) кинәт сикереп торды да, ядрә кебек атылып, затлы шкафка кулы белән тыгылып, «Социалистик Татарстан»ны тартып та чыгарды. Әһә, мин әйтәм, бу мине яклап чыга, ахры. Урынбасар иң элек шунда утыручы эреле-вaклы түрәләрне шаккатырып кап-кара затлы өстәлнең уртасына, үтә дә кискен житезлек белән, шап иттереп, газитне китереп тә салды. Бу шапылдаудан утырыштагы халык сискәнеп өнсез калды: тып-тын. Шулвакыт яклаучым хәтәр крута хәрәкәтләнеп, миңа таба борылды, җыелышкан бар түрә дә гипнозланган кебек аның артыннан мина төбәлде. Һәм ул, бармаклары белән «Социалистик Татарстан» битендәге нindидер рәсемгә каты итеп төртә-төртә: «Менә минем моңарга йөрәгем әрни!» — дип кычкырып җибәрмәсенме? Мин башта сискәнеп киттем, курыктым. Аннан, газиттәге рәсемнең мин җибәргән җимерек күпер фотосурәте икәнен абайлагач, эчемә үземә дә сәер тоелган ниндидер сөенеч тарала башлады. «Социалистик Татарстан»ның иң беренче битендә бит, сеңел, шундый да «крупный план» белән куелган, искитмәле инде. Ояла белгән кеше күрсә, бүген тотып күпер сала, валлаһи. Фотодагы күпер сымак нәрсәнең ян-ягыннан чыгып, тырпаеп торган торбалары

ялтырап кара өстәлгә таралып төшкәндәй булды шулчак. Урынбасарның өстәлдәге газиткә каты-каты барып төшкән бармакларының буыннары күнеләндәге көчле тойгыдан бөгелеп-бөгелеп килә. Бармак буыннары бөгелгән вакытта башта агарып, аннан (киеренкелектәндер инде, Ходайның рәхмәте) кызарып-кызарып китәләр. «Ертылмагае гәзит» дип уйлап та куйдым. Ә минем, сенлем, халыкның «маладис!» сүзенә ихлас ышанган наив күнелем урынбасар гәзиткә көчлерәк суккан саен күбрәк тантана итә. Әйтеп бетермәслек шатлык бит бу! Шатланмаслыкмыни: мин жибәргән фото, минем районның сәләмә күперләре турында язган мәкаләм белән жибәрелгән фото лабаса! Менә бит, дим эчемнән, галел язсаң, бөтен кешегә дә ошыйсың. Су эчәсе килгән кеше шикелле авызымны ачып, мактау сүзләрен тагын да күбрәк кабул итәргә әзерләнеп торып ук бастым. Иркен сулап, маңгаемдагы тиремне дә сөртәсе иттем. «Әнә бит нинди зур түрәнен күнелен кузгатырлык мәкалә язганмын. Димәк, авыл халкының күперсезлегенә аның да йөрәге авырта! Түрәнен йөрәге янса, көт тә тор, авыллар күперле булачак бит, һичшиксез, булачак! Мин, сенелкәш, ул минутларда үземне районның иң кадерле кешесе итеп тойдым. Еш сулаудан жилкәләремнең сикереп-сикереп менеп төшкәненнән бераз оялып, шуны сизмәсеннәр дип, игътибарларын йөземә юнәлтәсе иттем: олы кульяулыгымны алып, борынны сөрткәндәй булдым. Мактанмыйм, янәсе аллә ни язмаганмын ич инде дигән хәрәкәт иде бу үземчә. Ә урынбасар, шул арада гәзитне күтәреп алды да аркасына пропельлер беркетелгән Карлсон кебек бүлмә буйлап, дөресрәге, мин бәхәскә кергән зур түрә тирәли чабып әйләнә башлады. Үзе гажәеп тизлек белән әйләнә, үзе тишәрдәй итеп бармаклары белән гәзитне төя, үзе такмаклый: «Менә минем мона йөрәгем яна, йөрәгем яна!» — ди ул, йөрәк турысына кулы белән кагылып ала-ала. Әлбәттә, бу сүзләрдән соң, һичшиксез, мине мактау башланачак! Бернәрсә аңламаган халык кәнәфиләреннән кузгалгандай итеп, йөрәге янучыга таба бөтен булмыш гәүдәләре белән борылды. Урынбасарның кулы йөрәк турына таба шуышкан саен, утыручылар да ирексездән, үзләре дә сизмичә, ана ияреп, бахырларым, күкрәк турларын кашыштыргалап алдылар. Урынбасарның хәрәкәтенә күзләре генә иярү житмәгән, тора-бара башлары да иярде. Өстәлдәге сулы графин янына урындыклары туры килгән аеруча да шәфкатьле йөрәклеләре, үзләре дә сизмәстән, куллары белән стаканга үрелү кебегрәк хәрәкәт ясый башладылар. Янган йөрәкне стакандагы су белән булса да сүндерергә иде, ахры, исәпләре. Ә минем, сенлем, әйтәм ич, шатлыгым эчемә сыймый: тәки халыкны күперле итәм бит яза-яза. Районга да ярдәм киләчәк! Мин, кычкырып, күкләргә чөеп мактар секундларны тагын да тизрәк житкерәсем килеп, түрәләр алдындагы абруемның кинәт тагын да күбрәк күтәреләсен сизеп, сөенечтән, күкрәккә сыймаган сулышымны көчкә тыеп, ана сорау бирәсе иттем: «Ник яна соң?» — дигән булдым, иелә төшеп. Әйе, әйе, бөгелеп сорадым. Әйтерсен лә, хәзер өстемә, кем әйтмешли, «шквал бәхет явачак» та, ул «шквал»ны баш белән генә күтәреп бетерә алмаячакмын. Сорау, сенел, астрологлар әйтмешли, «роковой» булып чыкты. «Син, — диде урынбасар сикерергә жыенган әтәч кебек, — «Социалистик Татарстан»га специально, иң хәерче күпернен фотосын жибәргәнсен. Мәкаләндә ике авыл күпере турында язгансын, ә үзен районны черните итәр өчен иң жимерегенен фотосын жибәргәнсен!

...Тораташтай катып калганымны хәтерлим, сенел. Менә нәрсәгә яна икән ләбаса аның йөрәге! Күпме басып торганмын, кем мине кабинеттан чыгарган кайчан, ничек — берни хәтерләмим, сенел. Шул хәлдән соң минем наивлык бетте. Язганым бөтен кешегә дә ошап бетмәскә мөмкин икәнлекне аңладым. Син дә шуны онытма, сенел, шуны онытма. Минем мәкаләмне президент укый торган гәзиттә бастыралар дип, борын күтәрергә ашыкма.

Ә күпер фотоларына килгәндә, ике авылныкын да жибәргән идем, сенел, «Социалистик Татарстан» үзе белгәндер инде кайсы фотоны куярга, — диде ул, серле елмаеп.

# СОҢГЫ БАЛКЫШ

ХИКӘЯ

Чиләкләрен күтәреп, сөт тапшырырга чыккан хатыннар аптырашта калды: шактый көтсәләр дә, тыкрык башыннан атын әкрен генә юырттырып килүче Җирән Әхмәт күренмәде. Ни булды икән, нишләп аларның гел вакытында килә торган сөт җыючылары бүген юк соң әле?

— Гөнаһ шомлыгы, бер дә болай булмый торганые... — дип, Хәмдүнә җиңги сораулы карашын әле бер күршесенә, әле икенчесенә күчерде, әйтерсең, алар анардан күбрәк беләләр...

Шулвакыт тыкрыктан Җирән Әхмәт үзе күренде, күзләре әлҗе-мөлҗе генә күрүче Рәхиләттәйгә кадәр аны танып алды, чөнки Әхмәт абзыйның чәчләре, бала-чага үртәп ирештергәнчә, «рыжий, рыжий, рып-рыжий», ә бите тулы эре-эре сап-сары сипкел... Кояштан туса да бу кадәр үк булмас, билләһи-валлаһи. Чосрак бичәләр тел яшереп тормыйлар, үзенә үк Җирән Әхмәт дип дәшәләр. Хәер, ул моны шулай тиеш дип кабул итә, тамчы да рәнҗеми. Бөтен авылга берәү бит ул.

Тик бүген хатыннарның бер генә дә шаяртасылары килмәде. Әхмәтнең житди, борчулы йөзе һәм атсыз гына килүе сәбәп булды моңа. Гел шат күңелле, көләч йөзле Әхмәтне алыштырып куйганнар диярсең. Хәтта җирән чәчләре, мыегы да каралып киткәндәй тоела.

— Кешедән дә акыллы иде бит атым, күзгә генә карап торадырые. Андый ат бөтен мирда булмас...

Әхмәт куллары белән башын учлап тотып, эскәмиягә барып утырды. Хатыннар да пошаманга төште, аны кызганудан ни әйтергә дә белмичә тора бирделәр. Ниһаять, ат асраган Миңлебай бабайның карчыгы Сабирәттәй сүз катасы итте.

— Алай да бик бетеренмә әле, кем, Әхмәт, хайван бит ул, бәйләп-нитеп куймагач, сызгандыр арт яклап кына басуга. Кайтыр, кайтыр, югалмас, Алла боерса, ат энә түгел... Әнә безнең Бөркет...

Карчыгының сөйләп беткәнен көтәргә тәкате калмаган Миңлебай бабай үзе сүзгә кушылды.

— Бу заманда ышанып булмый, кем, Әхмәт туган, куркытып әйтүем түгел, хәзер шашлыкка дип этләргә кадәр алып китәләр. Төнгелеккә ябарга кирәк иде, кем инде шулай бәйләми-нитми атын әллә кая, җәһәннәмгә куя... Рәҗе шулай ярый?..

Үз гомерендә кешенең сынар әйберен дә алмаган Әхмәтнең Миңлебай бабай белән килешәсе килмәде. Күңеленә шик корты кертергә теләмичә:

— Кит әле, булмас, Миңлебай бабай, ат хәтле ат урларга кемнең кулы барсын? — дип башын чайкады.

— Төнлә тавыш-мазар дә ишетелмәдемени соң, Ходаем? — дип сорыйсы итте Хәмдүнәттәй.

— Кичәгенәк бәрәңге бакчасында Галимә җиңгәгез белән теге төртенгере жукларны чүпләп жык булдык, оҗмахка киткәндәй жоклаганбыз.

— Соң, болай борлыгып утырып булмый бит инде, эзләргә, су буйларын, басу, тау тирәләрен караштырырга кирәк, — диеште һаман күбәя барган урам халкы.

— И, апакайларым, жан кисәккәйләрем, мин бөтен якын-тирәне айкап чыктым бит инде, жук малкаем, жук, суга төшкәндәй жук булды...

Жирән Әхмәтнең аты югалгач, авыл бигрәк күңелсезләнеп калды. Бичәләр дә, иртән сыерларын капкадан гына чыгарып жибәрәләр дә, кереп киту ягын карыйлар. Шулай да жиз башлы Әхмәт үзе йә аты Йолдыз күренмәсме дип, тыкрык ягына күз салмыйча калмыйлар.

* * *

Ай яктысы якты, йолдызлар жем-жем килә, чалт аяз төн. Су сөлеге кебек житез ике егеткә абзар артындагы туры лапаста печән чемченүче Йолдызны алып китүе бер дә кыен булмады. Әхмәт абзыйсының атына ипи каптыруын күргәне бар иде Раилнең, шуңа ул үзе дә, ахирие Рузил дә кесәләренә ипи кисәкләре тутырдылар. Ипигә алданды Йолдыз: кешеләр якынлашуын тоеп, сискәнеп, колакларын торгызды, әмма шулчак борынына тәмле ипи исе килеп бәрелде.

— Мә, Йолдыз, мә.

Күрше егете Раил тавышы иде бу. Ат тынычланды, пошкырып куйды да йомшак иреннәре белән икмәккә үрелде. Ул да булмады, Рузил циркачлар житезлеге белән ат муенына йөгән кидереп тә куйды.

Ипи кисәкләре каптыра-каптыра, алар, атны йөгәненнән житәкләп, бакча сукмагы буйлап су буена төштеләр. Ә анда кечкенә инешне аркылы чыгасы да ике йөз метрлап ара үтәсе, аннары урман — күп нәрсәләрне, әләм балаларының күп хилафлыкларын яшергән урман башлана.

Урманга барып житкәнче артык тавыш чыгармаска, сөйләшмәскә тырыштылар.

Шактый ара үткәч, үзләренә жан керде тагы.

— Карале, Раил, гел мач килеп тора, малай, беркем сизмәде, беркем күрмәде.

— Шулаен шулай да, ашыктык, парин, ашыктык, синең сүзеңә карап... Башта атны сатып алучы табарга иде, ә болай без аны кая куябыз?!

— Нәрсә котың ботыңа төште, сатып алучы табылмый димени шундый атка, эһ тә итми табабыз аны, бер уникe меңгә сатып жибәрсәк, алтышар мең. Ния, әчне тишәмени?

— Башта сат әле, аннан шапырынырсың, жарпач...

Раил белән Рузил шулай сөйләшә-сөйләшә, шактый ара уздылар. Күндәм ат та ризасызлык күрсәтмичә атлавын белде.

Раил белән Рузил һөнәрчелек училищесында укый башлагач дусланштылар. Акчалы егет ул Рузил, кызларны сыра белән сыйларга да, модалы киенергә дә мөмкинлеге бар: кыйммәтле джинсы чалбар, күн куртка... Югыйсә ул да авыл малае, тик икенче районнан. Ә Раилнең... Кая инде ана житәргә.

Көннәрдән беркөнне Рузил Раилга сүз катты, күрәсең, читтән генә үзен гел күзәтеп йөргәнен сизгәндер:

— Акча эшләргә өйрәтимме, парин?

Раил «ничек?» дигәнен сизми дә калды.

— Сезнең авылда төнлә кешеләрнең каз-үрдәкләре, күркәләре, сарыклары югаламы?

— Каян белим мин, тикшереп йөрергә ментмы әллә?

Шуннан соң гына нәрсәдер аңына барып житте:

— Нәрсә, кош-корт урларга котырткычы буласыңмы, юк инде, бур исеме күтәреп йөрисем килми әле, аннары, каз урлап кем баеган? Ат дисәң, бер хәл инде.

— Кызык кеше син, Раил, кем сине мәжбүр итә, не хочешь — не надо. Вообще-то шәп идея әйттең бит әле — ат. — Ул, шәп дигәнне аңлатып, баш бармагын тырпайтып күрсәтте. — Элек бит атаклы ат караклары булган, без дә

шулар кебек, төнлә урлап алып китәбез дә сатабыз. Менә сиңа акча. Шитыкрыты, беркем бернәрсә белми.

Рузил бәхет кошы тоткандай, йотлыгып, дәртләнеп сөйләде дә сөйләде. Бур исемен күтәрәсе килмәгән Раилнең да башына уй төште. Аның бит унсигез яшенә житеп, жүнле акча тотып караганы да юк, ә монда... меңәрләп?!

— Ә мин каян ат алырга икәнен беләм, — дип кычкырып жибәрде ул. — Безнең күрше Әхмәт абзыйларның Йолдызы абзар артында гына, лапасларында төн чыга, атым саф һавада ял итсен, кыш көне абзарга керергә өлгерер әле, ди Әхмәт абзый...

Күрше авылда практика үтүче «механизатор» егетләрнең төнлә Раиллар авылына килеп Йолдызны алып китүен беркем дә сизмәде дә, күрмәде дә.

* * *

Таң атканчы, иртәнге савымга хатын-кызлар уянгалаганчы егетләргә кайтып житәргә кирәк, алар басуга барырга тиеш. Шуңа атка атланып барырга булдылар.

— Рузил, ә без Йолдызны хәзер кая куябыз соң? Әле бит сатып алучы юк?..

— Әйе шул, аны авылга алып кайта алмыйбыз, шунда ук, нинди ат бу дип, тенкәгә тиячәкләр...

— Нишлибез соң? — Раил чын-чынлап шүрли калды.

— Ә-һә, уйлап таптым! Ну баш үземдә, баш түгел, Министрлар советы! Әйдә, урман эченәрәк керәбез дә берәр агачка бәйлибез дә куябыз, сатып алучы тапкач та килеп алырбыз...

— Давай, шулай эшлибез.

Ике авыл арасы жиде-сигез чакрым булыр, үзләре практика үткән авылга житмәс борын, алар атны урман читендәге юлдан эчкә бордылар да, тагы да эчкәрәк, куерак жиргә керергә теләп, Йолдызны куалауларын белделәр. Ат сыртыннан төшәргә туры килде үзләренә.

— Рузил, житәр булмаса, әле жәяү кайтасы да бар бит.

— Ярар, акчаны шулай эшләп алалар аны, нибуч кайтырбыз, берни дә булмас. Якын калдырсаң, кеше-мазар күрүе бар, атны дим, аннан акча тү-тү...

— Ансы шулай инде.

Егетләр тагы да эчкәрәк керделәр.

— Хәзер печән әзерләп бетерделәр, кеше бик йөрмәс... Рузил, кара әле нинди каен агачы, әйдә шуңа йөгәненнән бәйләп куйыйк. Торсын әлегә шунда.

Кара төн уртасында ике егет атны, ычкынып китмәсен тагы дип, йөгәненнән урый-урый агачка бәйләп куйдылар да, фатир хужабикәсе сыер саварга торганчы, авыл ягына ашыктылар.

Егетләр ах-ух килеп фатирларына кайтып кергәндә, офыкта таң беленә иде инде. Хужабикә: «Йөрисез дә инде, төн убырлары», — дип сукранып алды, аны ишетүче дә, жавап кайтаручы да булмады. Төн убырлары бер-ике сәгатькә булса да юрган астына чумдылар.

* * *

Колхозда урып-жыю эшләре кызганнан-кыза барды, практикант егетләргә дә трай тибеп йөрү мөмкинлеге булмады — рәис каты, урак чорында һәр минут кадерле дип тукып кына тора. Житмәсә, Раил белән Рузил хәзер икесе ике басуда. Атны кайчан барып алырга, кая, кемгә сатарга дип, аерым-аерым баш ваталар. Раил Рузилнең котыртуына бирелүенә үкенә дә башлады. Үкенерсең дә шул. Кичә эштән соң, арыган булса да, атны карап кайтмакчы булды ул. Кем белә, монда тиздән кулга акча керәчәк дип, хыялланып, ымсынып йөрерсең,

ә анда атыңны алып киткән булырлар. Калырсың аннан әппәр итеп, калды муен серәеп дип.

Әнә шундый уйлар белән урманга китте Раил. Монда да, үз авылларындагы шикелле, ерак та түгел каенлык башлана, ул эчкәрәк кергән саен куерганнан-куера бара. Раил урманга бик тиз барып житте һәм... аптырап калды: кай тирәдән кереп, атны кая бәйләделәр соң әле? Бу урманны бөтенләй белми бит ул...

Егет исәңгерәп торды: каян, ничек табарга бу Йолдызны?!. Берничә урыннан эчкәрәк кереп-чыгып, тагын кереп карады. Әмма ат түгел, тояк эзләре дә күренмәде...

Ул, коты алынып, фатирына кайтты һәм изрәп йоклап яткан Рузилне җилтерәтергә тотынды:

— Рузил дим, тор, мужыт синең исенә төшәр, мин атны кая бәйләп калдырганыбызны белмим. Тор дим, йокы тәпәне, мин барып эзләп карадым, тапмадым...

— Кит әле моннан, торып берне манганчы... Күрше авылыгыз урманын син белмәгәнне мин каян белим?!

* * *

Менә өч көн, өч төн инде Йолдыз каенга бәйләнгән килеш тора. Агач тирәли саргаеп-кибеп барган үләннәр дә калмады. Хайванкайның үтереп ашыйсы, эчәсе килә. Йолдыз сабыр, акыллы ат, башта тыныч кына хуҗасын көтте, менә килер, менә күренер дип ышанды, тик көн саен иртән икмәк һәм иркә сүзләр белән сыйлаучы хуҗасы һаман күренмәде. Жәй белән хушлашырга җыенган урман шомлы һәм тын, төннәр караңгы һәм салкын, өстәвенә, ямьсез итеп җил улый...

Йолдыз тилмереп хуҗасын көтә: кешеләр, нигә мине болай бәйләп тотасыз, минем сезгә нинди начарлыгым тиде дигән сүзләрне теле белән әйтә генә алмый. Ә яшьле күзләрендә газап, рәнҗү, аптыраш һәм сагыш.

Дүртенче, бишенче көннәр дә әнә шулай газап, әрнү белән үтте. Аны килеп бәйдән чишүче дә, авылына алып кайтучы да булмады. Йолдызның матур, шома итеп таралган ялы киезләнеп катты, эче эчкә батты, койрыгында тигәнәк, өстендә тигәнәк... Сыртлары ялтырап торган, иртәләрен, шатланганын белдереп, кешнәп хуҗасын каршылаган җирән Йолдыз белән биш көн буе бәйдә торган, күзләрендә өметсезлек, үзен хәлсезлек биләп алган мескен ат арасында охшашлык табуы кыен, җир белән күк арасы кебек иде.

...Йолдыз шулай хуҗасын зар-интизар булып көтте, ул аның килеренә жаны-тәне белән ышанды, шушы коллык тоткыныннан коткарыр дип өметләнде. Хайванкайны кызганып, аклан тирәли тезелеп үскән каен кызлары һәм каен егетләре өнсез генә үксеп елады... Йолдызның әле кайчан гына йолдыздай очкынланып янган күзләре, яшәүдән ваз кичкән бичара адәмнекє төсле, өметсезлек, бушлык белән тулды.

* * *

Әхмәт абзыйның көне көн, ашавы ашау түгел. Онытылып китеп, иртәләрен Йолдызына дип сырмасының кесәсенә ипи сыныклары салып чыга да, абзар артында ятимсерәп торган арбага барып бәрелә. Шуннан гына аңына килеп, уянып киткәндәй була.

Тирә-якны айкый торгач, аяклары калмады инде, әмма бушка. Йолдыз суга төшкәндәй юк булды.

Бүген калага барырга җыенды, атының югалуы турында гәҗиткә белдерү биреп карарга иде нияте. Авылдашлары шундый киңәш бирде аңа.

— Нигә шулкадәр бетеренәсең, дубырга төшеп икенче ат ал да, сөт җыярга чык, — диде колхоз рәисе.

— Йолдызымны тапмый торып, сөт җыярга чыга алмыйм мин, — дип кырт кисте Әхмәт.

...Гәҗиттә өч көннән генә чыгачак белдерүне күтәргә Әхмәт абзыйның тәкате калмады. Өстән яңгыр явып торуына да карамастан, күрше авылга барып кайтырга булды. Юлдан гына барасы итмәде, күрше авылны чолгап алган урманнарны да караштырырга булды. Туры юлдан Сәлим кордашына кунакка баруы бик җайлы була иде дә... Әле менә күпме бара, арып бетте, әмма авыл күренми. Үз авылы урманнарын биш бармагы кебек белсә дә, бу урманнарда бик йөргәне юк шул аның... Юлга чыгам дип, торган саен эчкәрәк кергән Әхмәт абзый адашуын абайламый да калды.

Җәй дә түгел, көз дә түгел бер ара иде, яфраклар саргая башлаган, яшеллекләрен җуйган гаярь имәннәр мәңгелек уйга чумганнар, рәт-рәт тезелгән наратлар бар да бертөсле, игезәкләр кебек; каеннар лебер-лебер әкрен искән җил белән серләшә; бөтен дөнья юеш, ара-тирә серәеп калган ак чәчкәләр очрый. Кошлар тавышы күптән тынган. Күптин-күп төрле серләр, могҗизалар, табышмаклар яшергән урман тын калган, көз якынлашуын тоеп, моңсу сагышка чумган.

Йолдызы белән үз урманнарында вакытында күп, бик күп йөрде инде, ул чакта ничек рәхәт, бар нәрсә якын, үз, кадерле иде. Бу урман да үзләренекеннән әллә ни аерылмый, тик менә барыбер чит-ят икәнен белдереп, җанын өйкәп тора.

Һи-и, үз урманнарында, Бүре кулы булсынмы ул, Саклау, Тукуҗа, Кутырлы комган яклары, Салкын чишмә... аннан ул, ник төн уртасы, дөм караңгы булмый, туп-туры авылына кайтып җитә, йөгәнен Йолдызының үз иркенә куя да... Ә монда?.. Йөри торгач, Әхмәт абзыйның ашыйсы килүе исенә төште, кулы сырма кесәсенә салып куйган ипи кисәген сыпырып куйды. Юк, юк, ачтан үлсә үләр, әмма Йолдызына дигән икмәген капмас. Менә алар бер-берсен табыштылар ди, Йолдызының, күз нурының, йолдыз сыман балкып торган күзләренә ничек карар?..

Нинди дә булса берәр сукмакка килеп чыкмаммы дип, Әхмәт абзый озак йөрде. Башта шабыр тиргә баткан иде, инде менә өши башлады. Карчыгы бәйләгән оекбашларын да киясе итмәде шул, җылы тоелды. Кем белгән соң урманда адашып калырын? Кайда егылырыңны белсәң, шунда салам түшәр идең дә бит... Әхмәт абзыйны дерелдәвек алды, караңгы да төшеп килә иде. Берәр каен төбенә утырып ял итәргә, хәл җыярга кирәк...

Аһ!.. Әхмәт абзый өстенә аннан-моннан ботак-сатак каплап куелган алагаем тирән чокырга барып төшкәнен сизми дә калды.

* * *

Ай-яй-я-а-а-ай!!!

Хәлсез Йолдыз колакларын шомрайтты, күзләрен ачты, йөрәге ярсып тибәргә тотынды. Кеше тавышы?! Җитмәсә, хуҗасыныкына охшаган!.. Йолдыз сагаеп тыңлый. Тик нигә тавыш кабат ишетелми? Бәлки, Йолдыз саташадыр, ялгыш ишетәдер?.. Менә ул җан ачуы белән, бәйдән ычкынырга теләп, тырмашырга, тартылырга тотынды. Алай да ычкына алмагач, йөгәнен чәйни башлады. Нindидер серле бер көч аңа куәт биреп торды шикелле. Ниһаять, алты көн буе үзен коллыкта тоткан каешның өзелүен тойган Йолдыз арт аякларына басып... кешнәп җибәрде. Йолдыз иректә! Ирек! Нинди тылсымлы, бөек сүз! Кешегә үзен кеше, атка-ат итеп тояр, һаваны һава, суны су, шатлыкны шатлык итеп кабул итәр өчен ирек, ирек кирәк! Йолдыз хәзер үләнен дә табар, авылын да... Тик анарда үлән кайгысы юк, аны баягы тавыш борчый. Кайдадыр, якында гына кемгәдер хәвеф яный, хәвеф! Йолдыз аякларын чак сөйрәп, күңеле әйдәгән якка атлады.

Коштай очып кына барыр иде — хәле юк... Их, бер генә кисәк ипи катысы кетердәтеп аласы иде!.. Йолдыз ниндидер сиземләү белән, сагаеп, чокыр янында туктап калды. Күрүдән бигрәк, монда кеше ятканын жаны белән тойды ул.

...Чокыр төбендә исәнгерәп күпме ятканын, кайчан аңына килгәнен дә Әхмәт абзый белми. Әле ул шундый матур төш күрә: имеш, ул түбәндә, ә Йолдыз күктә, йолдызлар янында. Үзе шундый матур, хан кызларын бер читтә торсын: озын ялы кызлар ак муеннарына салган нәфис яулыктай жилдә жилферди. Әхмәтнең чәчләре төсле жип-жирән тиресе елык-елык килә, ә үзе, ипи катысы бирәсеңме инде дигән сыман, пошкырып-пошкырып ала. И рәхәтлек! Йолдызының йөгәне генә нишләптер ямьсезләнеп, пычранып беткән. Житмәсә өзелгән... Таныды Әхмәт абзыегыз, бу йөгәнне ул күрше егетенә, Раилга үзе ясап биргән иде, көзгә ат аласыз икән, кирәге булыр дип шатландырган иде.

Чокыр читендә пошкырып басып торган Йолдызның чокырга асылынып төшкән йөгәнен кулларына алган Әхмәт абзый күз яшьләре аша һаман бер сүзне кабатлый:

Төш бит чын булмый...

Төш бит чын булмый...

* * *

Йолдызның чокыр читендә басып торуы төш түгел иде. Әхмәт абзый сул як кулбашының авыртуына түзәлмичә, ыңгыраша-ыңгыраша, йөгәнгә чат ябышты һәм үрмәли-үрмәли, шуыша-шуыша чокырдан чыкты, хәле бетеп, Йолдызының аяк астына ауды. Күпме яткандыр, һушына килгәндә жан дусты йомшак борынын хужасының яңагына терәгән дә сабыр гына тора бирә. Әхмәт абзый, күз яшьләрен тыя алмыйча, атының башыннан кочаклап алды, ат та... елый иде.

— Әйдә, бахбаем, кайтыйк, мин сине тәрбияләрмен, сыйлармын, — дип пышылдый Әхмәт абзый, ә Йолдызы, аңлагандай, башын чайкап-чайкап ала...

Кулбашының авыртуы көчәйгәннән-көчәя барган Әхмәт абзый торып басмакчы булды, тик хәлсез аяклары аны тыңламады, ул тагын жиргә ауды. Каһәр генә төшсен! Ничек кузгалырга, ничек кайтырга? Ул бит бер адым да атлый алмый!

Йолдызы, аның уйларын аңлагандай, әйдә, мина атлан дигән шикелле, дерелдәп торган гәүдәсен ниндидер серле бер көчкә буйсындырып, хужасы утыра алырлык итеп жиргә сузылып ятты. Аякларына басу мең газап булса да, хайван бу кыенлыкны да жиңде, ул бит хәзер ялгыз түгел.

Ат муеныннан кочаклап, аңын әле югалтып, әле һушына килеп, Жирән Әхмәт үз авылларына якынлашканда, таң беленә иде инде. Ул да булмады, шалтыр-шолтыр капкалар ачылды, урамнар халык белән тулды.

— Йолдыз табылган! Йолдыз! — диеште кешеләр.

— Ну бу Әхмәт маладис та инде, тәки тапкан бит атын, — дип баш чайкады, сокланды халык.

Йолдыз чак сөйрәлеп, соңгы көче белән хужасының тар капкасыннан эчкә узды. Өлгерде ул. Соңгы сулышын алып, гөрселдәп жиргә авуын Йолдызның беркемгә дә күрсәтәсе килми иде. Аның ачык күзләрендә соңгы балкыш булып соңгы шатлык нурлары биеште...

**Зәйфә САЛИХОВА.**
*Башкортстан, Бәләбәй*

# ӘХЛАК САГЫНДАГЫ ШАГЫЙРӘ

## ЙОЛДЫЗ ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Укытучы хезмәте белем бирү белән бергә балаларга әхлакый кыйммәтләрне аңлату, үстерү һәм тәрбияләүдән гыйбарәт. Шуна күрә дә балаларга әхлак тәрбиясе бирү көн кадагындагы мәсьәлә булып тора. Ансыз җәмгыятьнең киләчәге юк. Без — укытучылар, балаларда әхлак тәрбиясен матур әдәбиятка мәхәббәт уяту аша тәрбияләргә тиешбез.

Без — XX гасыр балалары, бөек Тукайдан алып Шәүкәт Галиевка кадәр шагыйрьләрнең шигырьләрен укып үстек. Балаларга атап шигырьләр язу хәзер дә дәвам итә. Замана үзгәрә, дөнья үзгәрә, балалар да. Балаларга ияреп балалар шигърияте дә үзгәрә.

Балалар өчен язучы шагыйрьләр бүгенгә көндә дә шактый. Алар заман сулышын тоеп яшиләр һәм иҗат итәләр. Шундыйларның берсе — Йолдыз Шәрапова. Аның иҗатына тукталуыма иң элек шагыйрәнең шигырьләре һәм алып барган тормыш рәвеше сәбәп булды. Үз гаиләсенә (4 бала) ятимә кызны сыендыруы белән шагыйрә генә түгел, ә чын мәгънәсендә Бөек Ана исеменә лаек батыр йөрәкле хатын кыз булуы да! Шундый затлар гына үсеп килүче яшь буында әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләрдәй шигырьләр иҗат итә аладыр, андыйларга ышану җинел, аларның сүзе хикмәтле!..

Ислам динендә әхлак мәсьәләләре мөселманны характерлаучы төп сыйфатларның берсе булып тора. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрлек вазифаларын үти башлагач, кешеләргә әйткән: «Мин сезгә әхлагыгызны камиллеккә ирештерү өчен җибәрелдем», — дип. Йолдыз иҗатында балаларны Ислам дине аша әхлаклы итеп тәрбияләүгә әһәмиятле урын бирелә. Ул үзенең «Икәүләшеп укыйбыз» шигырендә бала белән әбинең дөньяви һәм дини белемнәр үзләштерүен уен формасында шаяртып һәм бик тә үтемле итеп сурәтли. Шул ук вакытта гыйлемнең кайсы яшьтә дә кирәкле булуына төшендерә. «Рамазан аенда» шигырендә әбисе оныгына ураза тоту, моның өчен никадәр ихтыяр көче һәм тырышлык таләп ителү әхлак тәрбиясе бирә. Гомумән, Йолдыз, балаларда үзенең иҗатына кызыксыну уятыр өчен, бик үтемле алымнар куллана белә. Шигырьләренең исемнәрен уку белән үк, бала аның шигырьләренә тартыла, эчтәлеге белән кызыксына (мәсәлән, «Антенналы бәрәнге», «Шигырьле чәй», «Җавапсыз сорау» һ.б.).

Йолдыз Шәрапова иҗатында әти-әнигә карата хөрмәт, гаделлек, тырышлык, хезмәткә мәхәббәт кебек әхлакый сыйфатлар кызыл җеп булып сузылган. Күркәм холык, югары әхлакның кеше тормышындагы әһәмиятен тойган хәлдә, шагыйрә балаларны кызыклы мавыктыргыч итеп төшендерә ала. Мәсәлән, «Бур буран» шигырендә әниләр сүзен тыңламауның начар бетүен; «Көйсез көн» шигырендә көйсез баланың көйсез көнгә тиңлеген; «Калган эшкә кар ява» шигырендә ялкаулыкны кар гына күмә алмаганлыгын үз укучысына җиткерә. «Тылсымлы сүзләр» шигырендә никадәр тәрбияви мәгънә бар: гаиләдәге дустанә мөнәсәбәт, татулык, җылылыкның кирәклеге «Хәерле» сүзе аша аңлатыла.

Барыбыз да балалар кебек үк хәерле көннәргә, хәерле гамәлләргә, хәерле мөнәсәбәтләргә мохтаҗбыз. Шагыйрә шигырьләрендә шаярту стиле җитдилеккә борыла һәм укучысын уйландыруга этәрә. «Алдау уены» шигырендә, уен барышында уйламыйча әйтелгән сүзнең ятим бала йөрәген никадәр телгәләвен күрәбез. Туган җирнең якынлыгы, изгелеге Йолдызның «Адашкан песи» шигырендә, шәһәрдә авылын сагынып, тилмереп яшәүче песи образы аша чагылдырыла.

Шагыйрәнең «Васыять» шигыре балаларга тормыш девизы кебек язылган. Сугышта һәлак булган бабайның хәләл җефетенә юллаган кульязмасында балаларын кайгыртып язылган васыяте аша ул үз укучысына түбәндәгеләрне җиткерә: «Аяклары исән булсын, Җирдә калсын эзләре». Ач-ялангач чорда балаларны ачлыктан

һәм өшетми сакларга», дигән васыятен кулланып, шагыйрә матур яшәүнең төп кыйммәтен әйтеп бирә. Яхшы гамәлләрең белән җирдә эз калдырырдай Кеше булу — яшәешебезнең асылы, мәгънәсе! Әлеге омтылышка ирешүдә Йолдыз Шәрапова иҗатының үз өлеше, үз урыны бар. Шагыйрәнең язу үзенчәлеге: шигырьләренең мавыктыргыч һәм җайлы укылышлы булуы бала күңелен шигърияткә тарта. Төрле образлар аша баланы эш сөяргә, матурлыкка омтылырга, күркәм холыклы, юмарт һәм кешелекле булырга чакыра ул. Шагыйрә, заман сулышын күз уңында тотып, балаларны уйланырга мәҗбүр итә — кирәгеннән артык телевизор, компьютер каршында утыру һәм башка тискәре күренешләр йогынтысыннан саклану юлларын күрсәтә. «Үзебез компьютер тычканын тотып, әхлагыбызны песи хөкеменә калдырмасак иде!» — дип кисәтә кебек ул һәммәбезне!

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: Йолдыз Шәрапова балалар әдәбиятында нык урынын булдырды, аның шигырьләрен балалар яратып укый. Шигырьгә, әдәбиятка тартылган баланың киләчәктә дә тәрбияле, иманлы булуына өмет бар.

**Зөлфия ГЫЙБАДУЛЛИНА,**
*Актаныш районы Такталачык коррекция интернат-мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

---

# МӘКАЛЬ ӨМӘСЕ

*XXI гасыр мәкальләрен – авторлы мәкальләрне җыю дәвам итә. Шәпләрен китап итеп бастырып чыгарачакбыз.*

- Язын кар астына ут керер, итәкләр астына кот керер.
- Тәтенсез ут йөрәк янганда гына була.
- Көчек олы бурзайга караганда күбрәк өрә.
- Татар барда хәтәр юк, хәтәр барда татар бар.
- Йөгәнсез теләк богауга илтә.
- Нигезенә хәзинә күмелгән йорт бәхетсез булыр.
- Сыраханәдән сырхауханәгә бер адым.
- Жирнең чуаны — вулкан.
- Пычак та кайрый белмәгән ир ни пычагыма!
- Азат булыйм дисәң, сүзеңнең колы бул.
- Бүрелеген җуйган бүре бүрек булыр.
- Чөгендер суы кан түгел, тәхетсез хан хан түгел.
- Ач бүре айны каргап улый.
- Күке әлимент түләми.

**Рабит БАТУЛЛА**

- Карга каркылдаганнан гына күк күкрәмәс!
- Нигезең нык булмаса, түбәң кыек булыр!

**Флёра МӘРДАНОВА,**
*Тукай районының Кузкәй авылы*

- Ирексезнең ирегә — иҗат...
- Сарылганнан сагай.

**Светлана ГАЗИЗОВА**

# ИЛГӘ ТАРИХ ЯЗГАНДА

Илнең әллә кай төбәкләреннән нефть чыгарырга дип килгән төрле милләт кешеләре арасында җырга, шигърияткә гашыйклар да табыла. Алар көндезләрен «кара алтын» чыгару промыселларында, төрле цехларда, мәктәпләр, балалар бакчаларында, төзелешләрдә эшлиләр, ә кичләрен ярсу йөрәкләренә рухи дәва табу максаты белән кулларына каләм алалар. Язучысы булса, иярүчесе табыла. Әдәби берләшмә төзү турында күптәннән хыялланып йөргән Илдус Мәрдәншин көннәрдән бер көнне тәвәккәлләп, үз янына азмы-күпме каләм тибрәткән кешеләрне чакыра. Бу — 1980 еллар башы. Шигырьләрен иң беренче булып берләшмә утырышына килүчеләр арасында Николай Сидоров, Гафифә Гаффарова, Гөлнур Мәхмүтова, Кадрия Сөләйманова, Венера Булатова, Илгиз Фәрхетдинов, Әсфия Мәхмүтова була. Ә берләшмә эшен башлап җибәрүгә фатиханы Әлмәт Язучылар оешмасы рәисе Әдип Маликов бирә. «Җәлил чаткылары» (Сарман) исемен алып, берләшмә алга таба өметле каләмле яшьләр исәбенә тулылана бара. Әдәби-иҗат төркеме әгъзалары, посёлок, район күләмендә үткәрелгән бер мәдәни чарадан да калмыйлар, һәркайсында актив катнашып, үзләренең каләмнәре аша тормыш, яшәү, хезмәт көндәлеген халыкка житкерә баралар. «Җәлил чаткылары»на йөрүчеләр арасында төрле яшьтәге каләм ияләрен күрергә мөмкин. Тынгысыз житәкче Илдус Мәрдәншин балалар бакчаларында, мәктәпләрдә еш була, әз генә илһам чаткысы, сәләте сизелгән һәр баланы берләшмәгә тартырга тырыша. Аның тырышлыгы белән күп кенә альманахлар дөнья күрә, аерым каләм тибрәтүчеләр үз китапларын чыгара. «Җәлил чаткылары» зур хөрмәт, соклану хисләре белән халык теленә менгән икән, монда, әлбәттә, анын дистә еллар буе житәкчесе, күп китаплар автор Илдус Мәрдәншинның роле зур. Бүгенге көндә 34 еллык иҗат гомере булган берләшмәгә 30 га якын кеше йөри. Әле безгә яңа килеп кушылган «Илһам чишмәләре» дә бар. Алар — Гафифә Гаффарова, Расиха Гыйльфанова, Әнисә Минһажева, Булат Әюпов, Рухия Ахунжановаларның юлларын дәвам итеп иҗат итәләр, язганнары район матбугаты, посёлокта чыгып килә торган «Нефтяник Джалиля» газеталарында басыла. Ландыш Шәйдуллина, Флүзә Григорьева, Лилия Големова, Нәвия Гатиятуллина, Әлфия Ногманова, Гөлсинә Әхсәнова, Әнәс Ибәтуллин, Халисә Шәйдуллина, Раил Арсланов елдан-ел осталыкларын арттыралар. Шунысы куанычлы: берләшмә үз эшен китапханә, мәктәпләр, музей белән тыгыз элемтәдә алып бара, алар белән берлектә уздырылган мәдәни чараларда башлап йөри. «Җәлилнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе, посёлок житәкчелеге ярдәме дә әйтеп бетергесез. Идарә, посёлокның оешкан, төзелгән еллары, 500 миллион тонна «кара алтын» чыгару кебек тарихи даталарга багышлап чыгарылган китапларны, альманахларны нәшер итүдә күрсәткән ярдәмнәре өчен без барлык иҗатчылар исеменнән аларга зур рәхмәтләребезне житкерәбез. Берләшмә әгъзалары нефтьчеләргә кушылып, илгә-көнгә тарих язалар, үзләре яшәгән, иҗат иткән җирне каләмнәре аша рухи биеклекләргә күтәрәләр.

**Рәис КӘЛИМУЛЛИН,**
*«Җәлил чаткылары»*
*әдәби-иҗат берләшмәсе җитәкчесе*

## Өч йолдыз – туган җирем

Туган җирем, сихри балачагым,
Иң кадерлем минем – Азнакай.
Ә Җәлилем – ул бит тормыш юлым,
Гомер күгемдәге якты ай.

Газиз анам ярып җанын биргән,
Азнакаем – белем һәм канат.
Ә Җәлилем – хезмәт юлымдагы
Иярләнгән ярсу, тугры ат.

Иярләнгән атым, туган җирем –
Безнен өчен ул бит – Татарстан.
Ә йөрәге аның – мәркәзебез,
Тукаебыз сөйгән хәр Казан.

Шушы өч йолдызым – Туган җирем,
Газиз анам белән тиң алар.
Аналар да , без дә бер сүнәрбез,
Бу йолдызлар мәңге янарлар.

**Булат ӘЮПОВ**

## Бергә чигик

«Бисмилләһи» – диеп, сүзем башлап,
Олы келәм килә җәясем.
Шул келәмне җир өстенә салып,
Дога белән килә чигәсем.

Җир өстенә матур келәм кирәк,
Чигәр идем алтын төсләрдән.
Бизәк куеп көмеш укалардан –
Күнелләге якты хисләрдән.

Келәм уртасында дога булсын,
Бергәләшеп чигә башларга.
Тузмаслык та, унмаслык та итеп,
Җәелгәндә дә кыя-ташларга.

Ай-кояшның барын искә алып,
Йолдызларны сипсәк һәр читкә,
Шул келәмгә баскан берәүнен дә
Күнеле булмас иде ширектә.

Зөһрә кызны көянтәсе белән
Чигәр идем төсле җепләрдән.
Чигү сапламнарын алыр идем
Хур кызлары эрләр сүсләрдән.

Сонламыйча, эшне башлыйм әле,
Хәерлегә булсын бу эшем.
Җир-Анага кадер-хөрмәт булып
Керсен иде бераз өлешем.

**Расиха ГЫЙЛЬФАНОВА**

## Күрәсезме?

Әй сез, шаян җилләр, әй бураннар,
Бу якларга каян килдегез?
Дөньяларда нинди яналык бар,
Юлыгызда ниләр күрдегез?

Очрагандыр матур зур калалар,
Мәрмәр таштан горур биналар.
Йөзәр катлы искитмәле йортлар,
Чит илләрдә бар ди бит алар!

Әй шаян җил, күрденме соң әле
Авыл кадәр генә бистәмне?
Йортлары да бик куп түгел аның,
Булса да шул ничә дистәдер...

Ә шулай да матур урамнары
Сокландыра күпләр күңелен.
Тезеп-тезеп куйган якты йортлар
Тәрәзендә кояш түгелме?

Тырыш халкы белән дан тота ул,
Нефтьчеләр безнең – чын батыр!
Күнел биреп эшли алар эшне,
Еллары да уза бик матур.

Нинди генә эшкә тотынса да,
Җәлилләр – алгы сафларда.
Шаулап-гөрләп, бик күнелле уза
Бәйрәмнәр дә безнең якларда.

Горур яши халкым, чөнки бистә –
Герой исемен йөртә торган җир.
Аны искә алып, сәлам булып,
Йөрәкләрдән агыла шигъри җыр...

Күрәсезме, җилләр, әй бураннар,
Нинди күркәм минем Җәлилем.
Кечкенә ул, ләкин төш кенә ул –
Мина илһам биргән үз илем.

**Флүзә ГРИГОРЬЕВА**

## Яшәү мәгънәсе

Яшәүнең мәгънәсе нидә?
Шул сорау борчый һаман.
Йокысыз үткән төннәрнең
Шәмнәре булып янам.

Берәү әйткән: күрәштә, дип,
Бардык аның артыннан.
Офыкларның аръягында
Гөлбакчалар бар сыман.

Берәү әйткән: тормышта, дип,
Яши халык төрлечә.
Кемнәр йөзә балда-майда,
Кемдә кайгы бер мичкә.

Яшәү мәгънәсе шундадыр,
Тынгы белми һич йөрәк.
Яшәү мәгънәсе — мәгънәсен
Эзләүдә булса кирәк.

**Лилия ГОЛЕМОВА**

## Гомер

Чәчкәләрнең гомере кыска, диләр,
Кыска ул тик кеше гомере.
Чәчкәләрдәй сокландыра белә
Кешеләрнең йөздән тик бере.

Чәчкә гомерләре кыска, диләр,
Яшәп кала алар, ичмасам.
Кеше гомере чып-чын гомер була,
Жиде кабат ямау ямасаң.

Көн эчендә шиңгән чәчкәләр дә
Өлгерәдер нурын чәчәргә.
Кайчагында гомерләр дә житми
Чын кешечә итеп яшәргә.

**Эльвира ИХСАНОВА**

## Шундый бер төш күрдем

Гажәп тә соң инде, гажәп тә соң,
Ниләр генә керми бу төшкә.
Бер бабайны күрдем бүген төштә,
Шундый ябык, шундый бетәшкән.

Аягында тишек кирза итек,
Иске шинель кигән өстенә.
Күренеп тора, тормыш дигәннәре
Аямаган аны һич кенә.

«Исәнмесез, бабай, ни хәлең бар?
Ярдәм кирәкмиме миннән? — дим, —
Шәфкатьлелек һәм дә игелекләр
Ташып тора, бабай, синнән», — дим.

Ә ул мина текәп карап торды,
Күз карашы жанны актарды.
«Төсең таныш, олан, син кем улы?» —
диеп бабай жавап кайтарды.

«Әнискеке, Иске Минзәләбаш
Кәлимуллин Әнис улы мин.
Әни — Римма, Сафин Нәгыйм кызы...»
Үзем никтер авыр сулыймын.

Бабай шактый сүзсез калып торды,
Сизеп торам, елый башлады.
«Күз ышанмый, белдем, син бит, олан,
Оныгым», — дип әйтеп ташлады.

«Зарифулла — исемем, бабаң булам,
Сөйләгәндер сина Әнисем.
Олан, хәзер үзем күргәннәрне
Килде бераз сиңа сөйлисем.

Мең тугыз йөз кырык икенчедә
Сугышка, дип, мине алдылар.
Килеп каптым шунда Суслонгерга,
Чын тәмугка илтеп салдылар.

«Сугыш» дигән уен уйнаттылар,
Агач мылтык белән «ут ачтык».
Ялангачлык, ачлык жиңде безне —
Якты дөнья белән хушлаштык.

Каберем юк, олан, безнең башлар
Чокыр, канауларда ятадыр.
Безнең жаннар гына туган якка
Монсу кошлар булып кайтадыр.

Рухыбыз бит дога өмет итә,
Тойсын шуны безне белгәннәр.
Сөйләшсеннәр безне искә алып,
Рәнжемәсен читтә үлгәннәр».

Гаҗәп тә соң инде, монсу да соң,
Менә шундый бер төш күрдем мин.
Бабам белән төштә күрешкәнне,
Түкми-чәчми сөйләп бирдем мин.

Рәис КӘЛИМУЛЛИН

## Боз күңел

Боз сөңгеләренә кояш
Елмая, күзен кысып.
Шуңа да эри инде боз
Һәм җиргә тама тып-тып.

Бозның да күнеле — йомшак,
Шаккатып карап торам.
Кояшның елмаюыннан
Тамам-тамам, дип тора.

Күнеле — каты, йөрәге — боз,
диләр бит синең хакта.
Яратып бер карыйм әле,
Янымa килгән чакта.

Сине бер елмайта алсам,
Күнелләрем булмасмы?
Боздай салкын йөрәгенә
Сөю кереп тулмасмы?

Әнисә МИНҺАҖЕВА

## Бер сүз җитә

Бер сүз житә жанны яраларга,
Ярсып-ярсып үксеп еларга.
Бер сүз житә жанны дәваларга,
Кайгылардан сине араларга.

Күзләреңдә синең нур балкыса,
Бу дөньяда рәхәт яшәргә.

Өметеннең соңгы шәме сүнсә,
Ярдәм сорап, кемгә дәшәргә?

Яшәү-үлем — күз-каш арасы,
Мәнге яшәү? Юк шул чарасы.
Сүзләрнең дә жанга якыннарын
Кирәк икән әйтеп каласы...

Әлфия НОГМАНОВА

## Сагыну

Шәһәрдә бик рәхәт яшәсәм дә,
Йөрәк калган икән авылда.
Гомер узган саен дәшеп тора,
Төшкә кереп, Суыр тавы да.

Ак кышларда яуган мамык карлар,
Инешемнең текә ярлары,
Яшел келәм җәйгән борма юллар,
Челтәр шәлле көяз таллары.

Оясына куныл, канат кагып,
Сыерчыкларымның сайравы,
Урманнарга гүя ямь өстәгән
Тукраннарның томшык кайравы.

Таш тавының челтер чишмәләре,
Чирәм чүпләп йөргән казлары.
Төшкә кереп чакыргандай тоела
Авылымның шаулы язлары.

Туган йортның газиз капкасы да,
Кайтып шакыр, диеп көтәдер.
Шәһәр кочагында яшәсәк тә,
Сезне сагынып гомер үтәдер.

Гөлсинә ӘКСӘНОВА



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Зариф БӘШИРИ**

## Авыр сүзне җиңеләйт

...Йосыф хәзрәт Фатих Әмирхан турында «Зариф мулланың күзлекле улы үзе студент, үзе социал-демократ икән!» дигән сүзләрне ишеткән дә аны үз күзе белән күрергә теләгән. Әнә шундый теләктә йөргән бер вакытта ул Фатих Әмирхан белән көтмәгәндә очраша. Кемдер берәү ана: «Зариф хәзрәтнең күзлекле улы шул була инде», — дип төртеп күрсәтә. Йосыф хәзрәт читтән күрү белән генә чикләнми, Фатихның алдына ук килеп баса: «Зариф хәзрәтнең күзлекле улы! Үзең судин, үзең «сасыган виноград» син буласыңмы инде ул?» — дип сорый. Татар өчен авыр әйтелешле «социал-демократ»ны шулай сасы виноградка әверелдерә.

— Йосыф хәзрәтнең кыңгыр аткан ташы туры килеп төшкән, — ди Тукай, моны ишеткәч. — Азмыни бездә биленә ат аркалыгы бәйләп, кызыл авызланып йөргән «сасыган виноградлар»!

Бу атама шулай ук яшьләр арасында тиз таралып китте. Берәрсе белер-белмәс сәясәттә гәп орып кызыл авызлана башласа, аңа: «Житәр инде, сасыган виноградланып торма!» — дип туктаталар иде.

**Хәсән ТУФАН**

## Тел язмышы

Тукай абый туган телне
«Әнкәм теле», дисә дә,
Безнең өйдә ул телдә шул
Әби генә сөйләшә.

Менә сиңа тамаша!
Заман ничек алмаша:
Ана теле безнең өйдә
Әби теле ләбаса.

**Салих БАТТАЛ**

## Көндәлекләрдән

Аэродромнан Муса Җәлилгә (1934, 23 октябрь) шылтыраттым:
— Кил, кинога билет бар.
— Нинди картина?

— Яшәртү турында. Фәнни картина.
— Һи, алайса картлар гына карарлык икән.
— Шунын өчен сина шылтыратуым да, — дидем мин, — «сакалым сабынлы мунчала кебек» дип шигырь язгансын ич милиционер кыз турында...

Барып керәсен – Муса бүлмәсенен (Столешников тыкрыгында) ишеге һәрвакыт ачык, үзе күп вакытта өйдә булмый. Берчакны төнге унбергәчә көтеп утырдык. Кайтты. Театрда булган. Фәтхи Бурнаш белән икәүләп. Бурнаш Казаннан килгәндә, юлда арыган, күрәсен, йоклап утырган.

— «Дедушкин сон»ны карарга барып, Бурнаш йокысын карап кайттым, — ди Муса.

Икенче барганда да өйдә юк иде. Ул кайтканчы башкалар да жыелды. Муса аптекадан теш даруы алып кайткан. Әхмәт Фәйзи дару шешәсен алып карады да:
— Бу теш даруы түгел, — диде.

Әхмәт Фәйзинен хатыны югары белемле медичка булганга, бу мәсьәләдә авторитет санала. Анын белән сүз көрәштереп булмый. Медицинасыннан бигрәк үткен сүзләре хәтәр.

Шуна Муса, башын иеп кенә:
— Нинди дару сон бу? — дип сорады.
— Моны эч авырткannan эчәләр.
— Алай булса тешемнен эче авырта торгандыр, — дип куйды Муса.

Мәскәүдәге татар язучылары арасында еш кына шундый сүз ярышы килеп чыга һәм анын әле теге, әле бу жинүчесе була иде. Беркөнне Мусага Мәхмүд Максуд белән бергә ике Әхмәт – Фәйзи һәм Ерикәй килеп керделәр. Мәхмүд, ярышны башлап:
— Ягез әле, кайсы Әхмәт жинәр? — дигәч үк, Ерикәйнен:
— Әлбәттә, мин! — дип жавап бирүе үк жинеш саналды. Чөнки жину шартларынын берсе — озак көттерми, тиз жавап бирү иде.

Экспромт остасы Әхмәт Фәйзи, минем акрынлыкны тәнкыйть итеп, эпиграмма язып бирде:

*Сөйли бит Баттал явыз, ә!*
*Сүзе саен биш минут паузә.*

Басылганмы, юкмы — хәтеремдә юк, «Чаян» журналына кагылган эпиграммасы хәтеремдә:

*«Чаян» мине һич тә көлдерә алмый,*
*Кытыкламый хәтта тешләве;*
*Ләкин үләм көлеп, исемә төшсә,*
*Ф.Хөснинең шунда эшләве!*

**Илдар ЮЗЕЕВ**

## Автограф

Язучы булып өлгергән һәм нәшриятта бер-бер артлы китаплар чыгара башлаган Туфан Миннуллиннын тәкъдиме мина ошады.

— Әйдә, иң кыска язылган автографка икебез өчен генә конкурс игълан итәбез, — диде ул.

Һәм үрнәк тә күрсәтте. «Кеше бул!» исемле яна гына чыккан китабына автограф язып бирде. Титул битендә «Илдар, мә!» дип язылган иде.

Минем дә китап чыкты. Мин дә аңа автограф чәпәдем: «Туфан, тот китабымны!» Озынрак килеп чыкты, кәнишне. Туфан жинде. Мин рәхәтләнеп жинелдем.

**Фәнзаман БАТТАЛ**

## Тугандаш шагыйрьләр

Уфага баргач, Илдар Юзеевне башкорт шагыйре Гайнан Әмири белән телевидениедән чыгыш ясарга чакыралар. Максат: ике тугандаш халык шагыйрьләренең дуслыгын күрсәтү икән.

Беренче булып сүз алган Гайнан Әмири, Казан кунагына таба борылып, җөмләне башлап җибәрә:

— Менә без, Илдар дустым, икебез ике халыкның шагыйрьләре. Башкорт әдәбияты үссә, татар әдәбияты да үсә. Без икебез ике халыкның уллары булсак та, бер-беребезнең телен яхшы аңлыйбыз. Мин синең иҗатыңны яхшы беләм. Син дә мине беләсеңдер, дисәм, ялгышмамдыр...

Шулчак Илдар Юзеев үзе дә сизмәстән:

— Һи, ничек белмәскә инде, Гайнан абый, икебез дә бер татар авылында туып үстек ич! — дигән.

**Шәүкәт ГАЛИЕВ**

## Фикерләр сандыгыннан

***

Мәйданда азаябыз, торган саен сирәкләнәбез. Сирәкләнгән саен... сыешмыйбыз! Ин соңгы ике тәкә дә сөзешер микән?..

***

Ире белән кычкырыша торгач, хатыны, тәрәзәне ватып, икенче каттан сикергән. Халык җыелган. Берни булмаган. Ә ире үрсәләнә:

— Үзем гаепле, үзем җүләр! — дип ачыргалана. — Күпме кыстадылар — бишенче каттан аласы булган фатирны!

***

Аумакайлыгы ишәя-ишәя, кеше дә ишәгәя.

***

Күнегүләрне туктатса, балерина юаная башлый. Кеше рухы да шулай: уйлары биеми башласа, фикер буыннары ката башлый.

***

Кабыгын салдырган бүрәнә кулдан шуып чыга. Искә төште яшь чаклар: шулай кочактан чая гына шумак була иде кайбер кызлар...

***

Төшемдә күз кабагымны күтәрә алмый азапланам – шундый авыр, имеш. Уянып китсәм, күзгә кояш төшкән. Кояш нуры җиңел түгел икән.

***

Йорт әйберләре күтәреп ир белән хатын кайта. Арыганнар. Бик арыганнар бер-берсеннән. Яңа әйбер сатып алып ял итмәкчеләр.

***

Җир-Ана... Алайса, Галәм-Әби? Әбиенә сәлам әйт, кунакка барырбыз.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу — безнең сәхифә!

# РӨСТӘМ МАҖАРАЛАРЫ

## Сихерле чәчәкләр

Ул уянганда, кич якынлашкан иде инде. Уяну белән, тәнендә ниндидер бер татлы рәхәтлек сизде. Кулларын-аякларын сузып, тәмләп киерелгән иде — дөп итеп җиргә төште. Имгәнү-фәлән булмады, шулай да бераз җайсыз төште булса кирәк, чишмә янына чатанлап барды. Салкын су йокыны таратты. Ашыйсы килеп китте. Аз-азлап кимерә-кимерә, актык сохарилар да юкка чыктылар.

«Урман акрынлап караңгылыкка чумды. Бу вакыт Рөстәм абагалар янында иде инде. Әбисе аңа абага җиде төн уртасында чәчәк ата дигән иде. Яз көне, төннәр кыска чакта, җиде төн уртасы кайвакыт була икән? Теләсә кайчан булсын — барыбер түгелмени. Бу төнне Рөстәм йоклау түгел, күзен дә йоммаячак.

Шулай уйланып утырганда, тәнгә салкынча җил бәрде. Кайдадыр күктә каргалар чарылдады. Каты итеп күк күкрәде. Яшен яшьнәп, кара урман аша яп-якты тасма сызылып үтте. Ояларына ашыккан җәнлекләр чинавы ишетелде. Төнге янгын вакытында була торгандай ал яктылык җәелде.

Рөстәмне курку алды. Әмма аның куркуы кызыксыну, хәйран калу белән катнаш иде. Шуңа күрә урманнан качу, кая булса да югалып тору Рөстәмнең башына да кермәде. Моңарчы һичкайда күрмәгән, ишетмәгән дәһшәтле гүзәллекне татудан туган хис иде бу. Агач яфраклары һәм үсемлекләр, алтынга манчылгандай, ялтырап яна башладылар. Бөтен әйләнә-тирә иснәп туйгысыз хуш ис белән тулды. Бер сүнеп, бер кабынып торган яшен яктысы күзләрне чагылдырды. Рөстәмнең күзләре дүрт булды: ул берничә абагада нәфис бриллиант кашларыдай җем-җем итеп торган чәчәкләр күрде. Күз ачып йомганчы, алар шундый үстеләр, чәчәктән яуган нурлар яктылыгында үлән арасына төшкән кечкенә генә инәне дә табарга мөмкин иде. Рөстәм бу тылсымлы чәчәкләрне ашыга-ашыга өзәргә тотынды. Аңарда комсызлык туды: тел астына гына кыстыру түгел, ул аларны учлап-учлап авызына тутырды һәм чәйнәми-нитми йота барды. Хәер, чәйнәргә кирәк тә түгел иде, чәчәкләр авызга эләгү белән, пешеп өлгергән җиләктәй, эределәр һәм үзләреннән-үзләре югала бардылар.

Шуннан соң нәрсә булганын Рөстәм хәтерләми. Аның башы әйләнде: ул, хәлдән таеп, җиргә егылды.

## Кем сорый?

Абага чәчәкләрен ашаганнан соң, Рөстәм белән ул үзе дә аңлый алмаган хәл булды. Һәрбер үсемлекнең, һәрбер гөлчәчәкнең кеше әле өйрәнеп җитмәгән хосусияте бар. Әгәр дә фән, гыйлем табигать биргән барлык әйберләрнең дә серләренә төшенсә иде, электр утлары, радио аша рәсемнәр тапшырулар, диңгез асларында карабларда йөзүләр генә түгел, хәзерге хыял җитмәслек могҗизалар туар иде. Шундый заман килер, зуп-зур шәһәрне ел

*Дәвамы. Башы 5,6нчы саннарда.*

буена жылытырга бер каен агачындагы көч җитәчәк, хәзергә фән күзе төшмәгән нинди дә булса гап-гади үлән кешене картлык үлеменнән коткарачак, кешене үлемгә алып барган ютәл авыруыннан азат итәчәк...

Рөстәм белми калды: төн буе яңгыр яуды. Ләкин яңгырның да, яшен яшьнәүләрнең дә һичбер бәйләнешләре юк иде. Абага чәчәкләренең тәэсире ашказаны аша Рөстәмнең бөтен тәненә таралды, яшь тәнгә үзгәреш кертеп, аны изрәтте, йокыга талдырды. Рөстәм бер тәүлектән артыграк йоклады. Уяну белән, ул үзен шундый рәхәт, шундый җиңеләеп киткәндәй хис итте ки, урманнан ничек чыкканын да сизми калды. Ләкин күтәренке кәеф озакка бармады. Инде өйгә ничек кайтып керергә? Тамак ач, өс-баш чыланган. Шул абага артыннан җенләнеп йөреп, нихәтле дәрес калдырылды. Укытучы абыйларга нәрсә әйтергә? Пионер була торып ялганларгамы? Әбиләр әкиятен тыңлап, могҗиза эзләргә урманга бардым, урманда яшәдем диярлгәме? Шуны сөйләп кеше көлдерергәме? «Б» классындагы Өтер Вәли бигрәк тә рәхәтләнер инде: «Ышанмагыз, малайлар, шуның сүзенә! Вечно мактана ул! Урманда кундым, дип ялганлый. Әбисе кочагында чикләвек ашап яткан ул!» — дип көләр. Хурлыгы ни тора! «Чынлап та, үзең абага чәчәкләрен ашадым дисең, ә үзең күренәсең... Ничек инде ул алай?» — дип, бүтән малайлар да теңкәгә тиеп бетәрләр. «Эх, әби, әби, сине тыңлап җүләргә калдым!» Бу сүзләрне Рөстәм чын-чынлап әрнеп әйтте. Өйгә кайтып кергәч тә, ул иң элек әбине күрер, җен-пәриләреңне күрмәдем, абага чәчәгеңне учлап-учлап ашадым... ашасам да үзгәрмәдем: күрәм дә, күренәм дә дип ачынып сөйләр.

Бу вакыт ул трамвайлар туктала торган урынга килеп җиткән иде инде. Җәяү байтак килende, килә-килә өс-башы да кибәргә өлгерде. Почмакта портфельле бер иптәш басып тора иде. Рөстәм аның янына килде һәм:

— Абый, сәгать ничә? — дип сорады.

Рөстәмнең соравы портфельле иптәшне сискәндереп җибәрде. Ул як-якка борылып карады, күзләрен уды, кул сәгатенә күз салды һәм сөйләнә-сөйләнә китеп барды:

— Сәгать сигез... Ә кем сорый — белмим... Колагыма шулай чагылды, күрәсең...

Рөстәм шатлыгыннан нишләргә белмәде. Сикерәсе, биисе килде. Димәк, әби ялганламаган, хыял чынга әйләнде. Димәк, Рөстәм чынлап та күзгә күренмәс кеше булды. Мөгаен, шулай микән, теге иптәш сукыр түгел идеме дип, Рөстәм трамвай вагонына асылынган ике малай янына йөгереп барып, дәүрәк күренгәненең борынына чиертте. Чиертү яхшы ук каты булды, күрәсең, малай:

— Нишләп син, Кылый, тик торганда борынга чиертәсең? Кутырым барын оныттыңмыни? — дип, юлдашына акырды һәм чалт иттереп аның яңагына сукты. Рөстәмгә бу кызык тоелды. Башланган кыйнашта ул әтәчләнгән шук малайны җиңәргә булышты. Борын эчендәге кутырны шакшылыктан күреп, янә бер тапкыр авырткан борынга чиертте.

Димәк, дөрес! Малайлар да аның күренмәс кеше булуын растадылар. Ул өйгә кайтырга ашыкты. Ләкин өй эчтән бикле иде. Тәрәзәдән карап, әбисен күрде. Рөстәм башта тәрәзә чиертергә дә, «әби, ач» дип кычкырырга да уйлаган иде, ләкин бу фикереннән тиз кайтты, ашыйсы бик килсә дә, ишек ачылганны көтәргә булды. Озак торып та көтә алмагач, ишек дөбердәтте.

— Кем бар?

Рөстәм тиз таныды: әби тавышы иде бу. Инде кем дип җавап кайтарырга? Ул аптырап калды. Бераз дәшми торганнан соң, тавышын үзгәртеп эндәште:

— Бу мин... мәктәптән килгән идем... Рөстәм кайтмадымы?

— Юк, бәбкәм, юк. Кайтмады. Кем буласың? Атың ничек? Әби ишек ачты. Шул арада Рөстәм өйгә кереп китте.

— Ай Алла, — диде әби, — кай арада күздән югалды?.. Ишек ачып та сораучыны күрмәгәнгә гаҗәпләнеп сөйләнә-сөйләнә, әби Рөстәм басып торган бүлмәгә әйләнеп керде. Нәрсәдер карады да яңадан чыкты, тагын керде. Ул йомышын — эшлисе эшен онытты. Рөстәм, әби чыгып китүгә, шкаф тирәсендә актарына башлады. Икмәккә май япканда, кулыннан пычагы зыңгылдап идәнгә төшеп китте. Тавышка әби керде һәм идәндә яткан пычакны алып куйды.

— Күселәр иләшә башлады, ахрысы. Мәче алып кайтырга кирәк.

Рөстәм әбинең бу сүзләреннән чак кына кычкырып көлеп җибәрмәде. Мин ашаган майны да күсегә сылтарлар микән, дип, ул туйганчы ашады. Кухняга чыгып, әбинең күз алдында йотлыга-йотлыга су эчте. Чүмечне куйганда, янә тавыш чыгарды. Әби табагач алды һәм өстәл астына иелде:

— Ышыт-ышыт, нәләт суккырлары!

Рөстәм, кычкырып көлмәс өчен, телен тешләде. Өстәл артына утырып, әлеге мәгълүм язуны язды. Аны китап эченә салды да дәресләрен карарга кереште.

Гайшә апа кайтып кергәндә, букча өстәлдә ята иде. Ул шуңа ташланды. Рөстәм утырган урыныннан сикереп торды, әнкәсенең муенына сарылырга, йөгереп барып әнкәсен кочарга, күп-күп итеп үбәргә теләде. Ләкин аяклар тыңламадылар. Ул баскан урынында катып калды. Рөстәм үзенең нинди авыр хәлдә калуын хәзер генә аңлады: димәк, әнисе аны күрми һәм күрмәячәк. Рөстәм аның кайгы-хәсрәтен тыңлар, аның елап утыруын күрер, ул йоклаган чакта аның янына барыр, үбәр дә, бәлки. Әтисе белән дә, әбисе белән дә шул ук хәл булыр. Ә алар Рөстәмне юк дип йөрерләр...

Гайшә апа ишегалдына чыгып, улым, улым, дип, Рөстәмне эзләп йөргән чакта, Рөстәм үзенчә бер карарга килде: китәргә булды. Өйдә калса, аңарда әти-әнисен кызгану хисе өстенлек алачак. Аны фронт көтә, башлары киселми калган фашистларның башларын кисәргә кирәк. Ул букчасын алды һәм ишеккә таба атлады. Нәкъ шул чакта әнисе кайтып керде, букчага дип, өстәлгә кулын сузды. Мәгълүм ки, букча озак табылмый торды. Рөстәм, ата-ананың тирән хәсрәтләренә түзә алмыйча, букчаны өстәлгә китереп куйды. Баягы язу килеп чыккач, Рөстәм аны ник язганына үкенде. Аны букчада онытып калдыруына ачуланды. Инде эзләү башланачак, кирәкмәгәнгә йөрүләр китәчәк, бик ихтимал; Рөстәмгә дә комачаулык ясарлар. Ә эзләүдән ни файда? Барыбер таба алмаячаклар ич... Тапсалар ни? Менә бит ул, аларның яннарында басып тора. Күрмиләр генә! Әйе, ата-ана өчен, бүтәннәр өчен хәзер ул бар да, юк та.

Бу хәл Рөстәмне кинәт олыландырып җибәрде, болай да акыллы иде ул, зурлар сүзенә колак салырга ярата торган иде. Хәзер исә тагы да үсте, җитдиләнде, искиткеч вакыйга аның үзенең дә искиткеч булуын таләп итте. Рөстәм үз язмышын үзе хәл итәргә тиеш икәнлекне аңлады һәм зурларча акыл йөртә башлады.

## Нишләргә?

Рөстәм дә әтисе белән бергә милиция идарәсенә барды. Ул анда Һашим абый белән өлкән начальникның сөйләшүен тыңлады. Башта болар да аңа кызык тоелды, аның шаярасы, кешеләрне шаккатырган әкәмәтләр ясыйсы килде. Ләкин ул, өлкән начальник кабинетында тыңлап утырганда, табигать алдында кешенең никадәр көчсез җан икәнлегенә гаҗәпләнде. Ул менә үсмер бала гына әле, әмма табигатьнең юмартлыгы нинди көчле итте аны. Инде нишләргә? Хәзер үк эшкә керешергәме? Рөстәм бит гитлерчылар тарафыннан җәберләнгән Ватаны турында, таш диварларга бәрелеп үтерелгән балалар турында уйлап йөреп, шушындый зур көчкә ия булды. Димәк, китәргә, кичекмәстән фронтка китәргә кирәк. Аның бурычы хәзер — дошман тылына күчү, әләккән бер фашистны кисү, үтерү, кыру. Шулай эш иткәндә, көн саен

ничә фашист солдатын үтереп була икән? Йөзне, ике йөзне... Ә аның болай күренми йөрүе озаккамы барыр? Бәлки, ул иртәгә үк элекке хәленә кайтыр? Фронтка да барып җитәр, күренә дә башлар, дошман аны бер минут эчендә юк итеп ташлар һәм ул, Рөстәм, үч ала алмыйча калыр. Сөйләшәсе иде, берәр галим белән киңәш итешәсе иде. Ләкин ул галимне кайдан табарга?

Әтисе белән Рөстәм дә өлкән начальник яныннан чыкты. Инде кая барырга? Өйгә кайтса, ата-анага карап торып эч пошачак. Кызгану аның көчен, дәртен басачак, ә аңа хәзер нык ихтыярлы, батыр булырга кирәк.

Шулай уйланып кайтканда, ул әтисеннән бераз артта калды. Унике-унөч яшьләр чамасындагы ике малайның чатта тәмәке тартып басып торуларын күрде. Рөстәм якынлашканда, алар нәрсә турындадыр бик әшәке сүзләр кушып сөйләшәләр иде. Ике малайның берсе Рөстәмгә таныш Өтер Вәли, бозыклыгы белән укытучыларның теңкәләренә тигән гаять хәйләкәр, хулиган Вәли иде. Аны күргә, Рөстәмнең ачуы килде. Ул, як-ягына каранып, бүтәннәрне күрмәгәч, Өтер Вәлинең авызыннан тәмәкесен алып ташлады һәм: «Тәмәке тартма! Тартма... Сүгенмә! Сүгенмә!» — дип, чалт та чолт итеп яңаклады. Малай абына-сөртенә качты, бу, аның артыннан куып җитеп, тагын өстәде.

Ул, үзендә бераз канәгатьләнү сизгәч, Ленин бакчасына кереп утырды. Мәктәбен, иптәшләрен, укытучыларын сагынды. Аларны күрәсе килү тойгысы шулхәтле көчле булды ки, ул, караңгы булуга да карамастан, мәктәпкә барып чыкты. Аннан өенә кайтты. Һашим абый ишек янында күрше карчык белән сөйләшеп тора иде. Рөстәмгә бу бик уңай булды — ул өйгә керде.

Әнисе һәм әбисе йокларга ятканнар иде инде. Әтисе кергәнче, Рөстәм ашап алды, диванга күз салды, шунда ятып йокларга булды. Һашим абый ишекләрне бикләде, кулын юды һәм өстәлдә ачык яткан китапны укырга тотынды. Рөстәм аңа сагынып карап торды. Түзмәде — янына ук килеп басты. Әтисе аңа бик җитди укыган булып күренде, ләкин ни өчендер хәрәкәтсез ята, күзләр менә ярты сәгать инде һаман бер биткә текәлгәннәр. Димәк, атаның үе китапта түгел. Нәрсә турында уйлый икән ул? Рөстәм, кагылыр-кагылмас кына, әтисенең чәченнән сыйпады. Һашим абый башын күтәрде, артка борылып карады. Рөстәм яшен тизлегендә читкә ташланды. Әтисенең нидер эзләгән сыман пошынып йөрүен күзәтте. «Юк, болай ярамый, — дип уйлады Рөстәм, — адым саен саклык кирәк».

Иртәгесен Рөстәм бөтенесеннән дә элек уянды. Ләкин ишек ачып чыгып китәргә, бит юарга уңайсызланды. Нәрсә эшләсә дә, ишетелер кебек тоелды, әбисен күселәр куудан азат итәсе килде. Озакламады, бүтәннәр дә уянды. Әйтелгәнчә, сәгать сигездә өлкән начальник күренде. Өйдәгеләр Рөстәм турында сөйләшәләр, начальник та сүзгә катнашты. Үзе турында мактау сүзләре ишетүгә, Рөстәм куанды да, борчылды да.

Әбисе дә аны мактады:

— Әкиятләр тыңларга бик ярата иде, — диде.

Начальник моны эләктереп алды:

— Әкиятләр? Нинди әкиятләр?

Рөстәм әбигә карады. Абага хакында әйтеп ташлар дип курыкты. Ул хәтта әбисе янына ук килеп басты, әйтә башласа, ничек булса да сүзен бүлмәкче иде. Ләкин әби әйтмәде. Рус телен ватып-сындырып, «рудной сказка» дию белән генә канәгатьләнде.

Начальник Рөстәмнең өстәлен, китапларын карады һәм:

— Букчасы кайда? — дип сорады.

Букча Рөстәмнең кулында иде, шуңа аны күрми тордылар. Тагын ары сугылып, бире кагылып, букча эзләү китте. Рөстәмдә балалык шуклыгы кузгалды, шаярып аласы килде. Әмма бу теләген ул тиз басты, чөнки аңлый иде инде: аның юк кына шаяруы да хәзер могҗиза булып тоелачак. Букчаны начальник алдына өстәлгә китереп куйды.

— Менә шушы мәллә? — дип, начальник аны кулына алды һәм серле итеп:
— Әйе! — диде. Әйе диюе аның: «Нишләп соң мин күрми тордым», — диюе иде.

Тагын ярты сәгать чамасы сөйләшеп утырганнан соң, начальник кайтып китәргә җыенды һәм Һашим абыйны үзен озата чыгарга үтенде. Рөстәм дә алар белән бергә чыкты.

— Улыгызның югалу вакыйгасы мине бик кызыксындырды, — дип, начальник сүз башлады. — Монда без аңлап җитмәгән нindидер бер хикмәт бар. Беләсезме, нинди нәтиҗәгә килдем мин?

— Юк, белмим, — диде Һашим абый.

Рөстәм, ишетми калмыйм дип, адымын кызулатты.

— Улыгыз монда, Казанда, кечә ул өйдә булган.

Һашим абый шатлану катыш гаҗәпләнде. Шатлыгыннан начальникны култыклап алды, гаҗәпләнүеннән аңа сорау бирде:

— Кем булса күргән мәллә?

— Бөтен бәла дә шунда шул: күрүче юк. Теге хикмәтле язуны ул кичә язган һәм өйдә язган. Ә букча... — начальник сүзен әйтеп бетермәде, туктады. Әйтим микән, әйтмим микән дигән сыман, аз гына уйланып торды һәм дәвам итте:
— Бер югала, бер килеп чыга торган букча сер пәрдәсен ача ачуын, ләкин... хәер, соңыннан... без кабат очрашырбыз әле. Менә нәрсә: ул букчаны мин язу өстәле янындагы кадакка элеп калдырдым. Әйтегез, аңа берәү дә кагылмасын. Ара-тирә күзәтсеннәр генә. Сезнең йорт тирәсенә мин үземнең бер кешемне куйдым. Улыгыз сез күрмәгәндә өйгә кайта һәм букча белән нидер эшли. Хатын-кызга бу турыда сөйләми торырга мөмкин.

— Аңлыйм, аңлыйм, — диде Һашим абый. Начальник Һашим абыйның кулын кысты.

— Хәзергә хушыгыз. Кирәк булсам, телефон номерларымны язып алыгыз: 0-35-46.

— 0-35-46. Рәхмәт!

**Гадел КУТУЙ**

*Дәвамы киләсе саннарда.*

---

## Халык әйтсә, хак әйтә

- Матурлык көлмәк белән сәләптә түгел, оят белән әдәптә.
- Матурлыкны ягымлы узган.
- Һавага карап өең як, анасына карап кызын бак.
- Гыйшык тоткан кыз баланы
  Йокы алмый түшәктә.
  Яр сөймәгән егетләрне
  Китап саный ишәккә.
- Ярсыз егет — парсыз мунча.

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

## Бер тамчы су

**«Там, там, там, тамуыңны яратам», — яңгыр астында шулай дип җырлап барганда, ул... уянып китте. Кайдадыр чалкан ята икән бит, ә аның өстенә ниндидер кыз иелгән. Теге җылы тамчылар шуның күзеннән тама икән ул!**

Егет уянганын сиздермәде. Күзенең керфекләре арасыннан гына карады. Әллә кайда түгел икән. Үзе менә ничәмә еллар казыган кое төбендә ята лабаса. Егетнең зиһене яшен тизлегендә эшли башлады. Башында әллә ничә төрле сорау туды.

Елый. Нигә елый? Күзеннән яшь ага, шулай булгач, кызның тәнендә су җитәрлек микъдарда. Ә суны кайдан алган соң ул? Әллә бу күрше кызы аның кара көнгә дип саклап торкан суын табып эчкәнме? Ошбу уй егетне бөтенләй айнытып җибәрде. Һәм ул үзенең өстенә иелеп яшь коеп утырган кызны тупас кына этәреп, яткан урыныннан торды. Егетнең тупаслыгына игътибар да итмичә тегесе:

— Исән, исән икәнсең! Мин сине әллә берәр төрле газдан исереп үлгәнсеңме дип торам, — диде.

Егет дәшмәде, кырында яткан ташны шудырып, таш артындагы куышка кулын тыкты. Сулы банка үз урынында иде. Ул җиңел сулап куйды. Чөнки суга кытлык инде менә ничәмә еллар дәвам итә. Кыз исә тагы сөйләргә тотынды.

— Сиңа шатлыклы хәбәр әйтергә төштем. Кичә яңгыр яуды. Килеп тикшереп киттеләр. Эчәргә яраклы дип таптылар. Түләргә акча булмау сәбәпле, суның яртысын алып та киттеләр. Аннан да бигрәк Коры елга буенда полиэтилен япма җәеп, эти хәтсез генә су запасы җыя алды. Аны яшереп куйдык. Һавада очкан күзәтче самолёт та, космоста очкан спутниклар да сизмәделәр шикелле. Югыйсә таң белән килеп анысына да налог салып китәрләр иде. Менә сиңа атналык азык та төшердем, — диде.

Егет бу юлы да дәшмәде. Гомумән, ул бик сөйләшә торганнардан түгел. Кыз өскә менеп китте. Ә егет коены казуын белде. Казылган таш-балчыкларны өскә бүтәннәр тартып менгезә. Аның эше бары тик казу һәм чыккан бөтен нәрсәне чиләкләргә тутыру. Менә ун ел инде ул шушы коены тирәнәйтә. Әтисе әйтеп үлде: 80 метрлар чамасы аста су бар, диде: Моны беркем дә белми. Нефть разведкасында эшләгәндә, әтисе, беркемгә дә әйтмичә, үз белдеге белән бораулаган булган. Бакча артындагы скважинада су шулкадәр дә көчле булып, хәтта ки буровой торбаларын кәкрәйткән. Әтисе, тизрәк скважинаны ябып, бригадасы белән башка урынга күчә.

Тирә-якта су беткәнгә дә бик күп еллар үтте хәзер. Су бөтенләй бетеп үк җитмәде ул, нефть чыгару аркасында калганының да шактый өлеше пычранып, эчәргә яраксызга әйләнде. Су булмагач, урманнар да корыды. Урманда Америка чаганыннан башка агач та калмады. Чиста сулы санаулы чишмәләрне байлар үз кулларына алып, су сатып яталар. Эш хакын да су һәм азык белән түли торган заманалар җитте!

Егет, әтисенең васыятен исенә төшереп, тагы да үҗәтләнеп, алмаз очлы боравы белән гранит ташны тишәргә тотынды. Бу эшне алар качып-посып кына эшләделәр. Югыйсә, кое казыганнарын белсәләр, үзләре белән бергә коены да шартлатып күмеп китәргә мөмкиннәр.

Егет электр уты яктысында атнага якын эшләде. Атна азагында аны икенче дус егете алыштырырга тиеш. Гранитны тишә торгач, бер урында кварц комы да килеп чыкты. Егет белә иде: андый комда алтын-көмеш тә була. Тик бу турыда беркемгә дә әйтмәделәр. Алтын-көмештән дә кыйммәтрәк иде алар өчен эчәр су!

Бүген ул ниндидер икеләтә күтәренке кәеф белән эшләде. Атна азагы бит. Иртәгәдән өстә эшләячәк. Ни дисәң дә, тузаны юк. Һавасы да саф. Ул эшен төгәлләп, коралларын җыештыра башлады. Әле генә боравын суырып алган тишеккә нишләптер яңадан күзе төште. Аннан чыккан ком дымлы иде. Ул яңадан дәртләнеп тагы берәр сәгать тишекне тирәнәйтте. Ниһаять, таш тишегеннән күз яше кебек кенә су тамчысы күренде. Егет теле белән ялап карады — су төче иде! Тәүге тамчы артыннан тагы берсе тәгәрәп төште. Егет шатлыгыннан җырлап җибәрде. Үз алдына:

— Аллаһы боерса, яшибез әле. Яшибез! — дип куйды.

Шуннан ул, хыялга бирелеп, болай булгач күршегә яучы җибәрергә дә була, дип уйлап куйды...

**Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ.**
*Башкортстанның Эстәрлебаш районы*
*Түрмай авылы*

## Никахлар күктә укылмаса...

**Мин аны йөрәгемнән мәңгегә алып атарга, ә баламны саклап калырга ант иттем.**

**Язның ярсулы бер көне иде ул...** Без Зөфәр белән әти-әнием янына кайтып, зурдан купмый гына никах укытып килдек. Егетем әтисе белән генә яши иде. Әнисе ике ел элек авырып вафат булган. Әтисе, Зөлфәт абый, туйны эш-көшләр беткәч дип, Сабан туена тәгаенләде. Мин туйга чаклы дус кызым Алсу белән яшәвемне дәвам иттем. Авылда зур кызулык белән язгы кыр эшләренә әзерлек башланды. Зөфәр район үзәгенә йөреп, авыл хуҗалыгы идарәсендә белгеч булып эшли иде. Ул иртә таңнан китә, соң кайта башлады. Кайбер көннәрдә кунгалап та калгалый. Ике-өч көн бөтенләй хәбәре булмагач, әтисе минем яныма кагылып чыкты. Берәр хәбәр ишетмәмме дип керүе икән. Минем дә берни белмәвемне аңлагач, сагая калды. Иртәгә үк район үзәгенә барып, эш урынына сугылып кайтырга ниятләвен әйтте.

Шул көннән Зөфәр суга төшкәндәй юк булды. Ул эшеннән, гариза язып, бөтенләй киткән булып чыкты. Минем тормышым чәлпәрәмә килде.

Көннәр үтә торды. Билгесезлектә яшәү җанны кимерде. Мин хәлсезләнеп, ашау-эчүдән калдым. Беркөнне эштән чыгышлый башым әйләнеп китеп, чак кына егылмый калдым. Коймага сөялеп хәл алдым да кеше-кара күргәнче дип өйгә атладым. Болай яшәп булмый дип, икенче көнне район поликлиникасына тикшеренергә киттем. Мин үзебезнең үзәк китапханәдән урап килгәнче анализлар әзер иде инде. Шәфкать туташы елмаеп каршы алды:

— Анализларыгыз бик яхшы. Әни буласыгызны белә идегезме, – диде ул. Тагын әле: — Хатын-кызлар консультациясенә дә кереп чыгарга туры килер, — дип тә искәртеп куйды.

Мин әллә ишеттем, әллә юк, берни әйтмичә чыгып киттем. Кая барасымны, ни эшлисемне белмәс халәттә урам буйлап атладым да атладым...

Өйгә кайтып кергәндә, бик соң иде инде. Ярый әле берүзем генә. Алсу язгы каникулда ике-өч көнгә авылларына, әнисе янына кайтып киткән иде. Өстемне дә алмаштырмыйча диванга аудым. Елый-елый төрле уйларга чумып ята торгач, тәмам арып, иртәнгә авышкач кына йоклап киткәнмен. Иртән бөтенләй башка кеше булып уяндым. Җәһәт кенә сикереп торып юындым да, көзге каршысына килеп басып:

— Йә, Гөлия, күтәр башыңны, җебеп төшмә! Син кемнән ким соң әле?! Буйсының, төс-битең сөбханалла. Белемең, эшең бар. Әлегә торыр җирең дә ярап тора. Сер бирмә! – дип, үз-үземә каты гына итеп кисәтү ясадым. Мин хәтта балам булуына сөенеп, аның өчен яшәргә кирәк дип шатланып та куйдым.

Баланың никахлы атасы булуы да миңа ниндидер ышаныч, көч биргән төсле тоелды.

Чираттагы ялымны алдым да, күз күрмәгән, колак ишетмәгән якка чыгып китеп урнашырга кирәк дигән уйга килеп, җыена ук башладым. Дөрес эшлимме мин, юкмы? Зөфәр акылына килеп, мине эзләмәсме, дигән уйлар да бөтерелде башымда. Тик, бу ниятемнән берәү дә туктата алмаслык хәлдә идем инде мин әлеге минутларда.

**Энже РАЗОВА.**
*Актаныш.*

## Горур Алия

**Ул аны йөрәгеннән мәңгегә алып атарга, ә баланы саклап калырга ант итте.**

**Язның ярсулы бер көне иде бу...**

Тәкъдирендә шулай язылгандыр инде — Алия бер ай эчендә Аны да, карынындагы тумаган баласын да җуйды. ...Өйдән эшкә барып, эштән өйгә кайтып, ундүрт җәй үтеп китте. Ә бер көнне... йокысыннан елмаеп уянды ул. Аяклары да сызламый сыман, йөрәге дә сикерми кебек. Кичә өенендә күргән Әмир бүген кызның төшенә кергән иде.

Алия айга бер тапкыр хастаханәгә йөри. Кичә аның капкасы төбендә төз буйлы ак халатлы докторны күргәч, күзенә ышанмады. Ничек инде, бу доктор — Әмирме?

— Әмир Рафаэлевич, исәнмесез! — дип, бер төркем яшьләр аның белән исәнләшкәч кенә ул табибның чыннан да Әмир икәненә төшенде.

Алиягә кинәт рәхәт булып китте, аның янына барасы килде, әмма аяклары аны тыңламадылар. Тораташтай басып торды да, врачына да кереп тормыйча, өенә кайтып китте ул.

«Әмир монда эшли икән... Ә нигә каушадым соң әле мин?» Йөрәге, сулык-сулык килеп, типми башлагандай тоелды, аякларының хәле китте... Ниһаять, кайтып җитте, акрын гына диванга барып егылды. Кино кадрларыдай, күз алдыннан Әмир белән бәйле вакыйгалар уза башлады. Аларны бит әлеге дә баягы шул хастаханә очраштырды, таныштырды, дуслаштырды. Күпме еллар үтсә дә, Алия, бөтен ваклыкларына кадәр, авыруы белән көрәшеп уздырган ул ямьсез, соры көннәр эчендәге матур хатирәләрне күңел түрендә саклый...

Кыз район хастаханәсенә эләкте. Бөерендә һәм йөрәгендә чир таптылар врачлар. Унбиш яшьлек үсмер кыз исә монда үзенә яңа дуслар тапканына бик сөенде. Чуваш кызы Надядан чуваш телен өйрәнде, шәфкать туташы Фәридә белән уртак серләрен пышылдаштылар. Үзе кебек авырып ятучы Әмир белән дуслыгы шашка, шахмат уеннары аша, бигрәк тә әдәбият, шигырьләр турында гәпләшкәндә ныгыды. Кечкенәдән китаплар, шигырьләр укырга яраткан Алия Әмир язган шигырьләрнең беренче тыңлаучысы булды. Дәваланып чыккач та ике арада дуслык, сагыну, юксыну хисләре белән тулган, җаннарны көйдерердәй утлы, шигырьле хатлар йөри башлады. Ничек әле?

— Җәйләремдә шундый салкын миңа,
Җаннарымда зәһәр салкынлык.
Кеше ташкыныннан сине эзлим,
Тоймыйм ләкин көткән якынлык...

Ике арадагы шигъри хатлар аларны бик якынайтты. Алия дә мәктәпне бетерде, институтка укырга керде, инде тулай торакка урнашырга вакыт җиткәч, туган авылына кайтырга дип автовокзалга килде һәм... Әмирне күрде...

Яшьләр көне буе бергә булдылар. Сөйләшеп сүзләре бетмәде, бер-берсенә

карашып күзләре талмады. Күктән аларны кышның ягымлы кояшы назлады. Әмир исә Алияне көне буе кулларында күтәреп йөрергә риза иде. Ике гашыйк уртак төнне теләделәр... Ә аннары? Аннары Әмирне ерак районга эшкә җибәрделәр, хатлары да, шалтыратулары да сирәгәйгәннән сирәгәйде һәм бөтенләй тукталды. Шулай ай арты ай уза торды, Алия исә сөйгәнен көтүдән туктамады.

Көннәрдән бер көнне Алиянең ишеген кактылар. Бусагада Әмир иде. Ул үзгәргән, ир булган, чөнки гаилә корган, әмма инде аерылышырга да өлгергән булып чыкты. Аның сүзләреннән Алия шуны аңлады: имеш, Әмир теләмәсә дә, туасы баласы хакына өйләнергә мәҗбүр булган. Бераздан боларның барысы да кызның уйдырмасы гына булуы ачыкланган. Берниндә дә бала тумаган. Шуннан соң Әмир нишләгән? Билгеле, аерылган.

Алия аны тыңлап та бетермәде. Очрашулардан качты. Әмирнең аңа булган хисләренә тамчы да ышанмады. Йөрәгендәге чәчкә булып атып утырган мәхәббәт гөлләрен дә төбе-тамыры белән йолкып атты! Дөрес, Әмирне җүйганга карап дөнья үзгәрмәде дә, бетмәде дә. Алия үзе генә үзгәрде. Егетләр тарафына күз дә салмады, сүзләрендә ышаныч тоймады...

Ялгыз калуында Алия беркемне дә гаепләми, киресенчә, беренче һәм соңгы мәхәббәтенә тугры булуы белән горурлана иде ул. Инде хәзер нишләргә менә? Доктор Әмир Рафаэлевичка приёмга барып караса инде әгәр?..

**Надия ВӘЛИЕВА.**
*Казан.*

---

## Яза аласыз!

«Хикәя яза аласызмы?» – үткән елгы 12нче санда шул исемдәге иҗади бәйгебезнен чираттагы турын игълан иткән идек. Инде аңа да йомгак ясалды.

Хикәячекләр бик күп килде. Шуларның 31е журналда басылып чыкты. Казандагы 4нче татар гимназиясе житәкчелегенә рәхмәт. Алар гимназиядә хикәя өмәсе игълан итеп, үзләре дә язып, инде чираттагы санга ук 11 хикәячек өлгерттеләр!

Иң шәп 7 хикәя авторын «Казан утлары»ның «Яңа базар» дигән сатирик әсәрләр җыентыгы белән бүләкләрбез дигән идек тә, авторлар, шәп язып, вәгъдәне боздырдылар: 7 түгел, 10 китап бирәсе була!

Менә алар, җиңүчеләр (исемлек алфавит буенча бирелә): **Әлфия Арсланова.** «Мин ялгызым түгел хәзер» (№4). Башкортстан, Кушнаренко районы, Карача Елга авылы; **Илфат Әхмәдуллин.** «Гомерлек үкенеч» (№6). Кукмара районының Ядегәр мәктәбе; **Рәзинә Әхмәдуллина.** «Мәңгелек сер» (№6). Кукмара районының Янил мәктәбе; **Илхания Вахитова.** «Сагындым, бәгърем, сине!» (№1). Казан, 4нче гимназия; **Надия Вәлиева.** «Көндәлегем битләреннән» (№2). Казан. 162нче балалар бакчасы; **Гөлфия Габдрахманова.** «Артык чибәр иде шул» (№1). Казан, 4нче гимназия; **Динәрә Гыйльфанова.** «Төзәтә алмаслык хата» (№6). Кукмара районының Янил мәктәбе; **Хисаметдин Исмәгыйлев.** «Урман юлында» (№2). Башкортстанның Эстәрлебаш районы Турмай авылы; **Флёра Мәрданова.** «Ак ефәк» (№3). Чаллы; **Гүзәлия Тарханова.** «Жыр» (№3). Казан, 96нчы гимназия.

Хикәя язу өчен ун башлам бирелгән иде (№12, №1). Авторларны иң җәлеп иткәне «Там-там-там...» дип башланганы булды. Инде яңа башламнар кирәк, чөнки тиз арада бәйгенең яңа турын башлап җибәрәчәкбез. Башлам – хикәянең төше, орлыгы. Бу берничә җөмләгә тылсымлы көч сала белергә кирәк. Монарчы башламнарны редакция хезмәткәрләре әзерләсә, бу юлы төп бәйгене кече бәйге белән башлап җибәрәбез: авторларыбыз һәм укучыларыбыздан әнә шундый хикмәтле җөмләләр көтәбез! Алар 22 октябрьгә кадәр килеп житсеннәр иде.

## Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ИНАУГУРАЦИЯ

Казанда, Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында тарихи вакыйга — инаугурация тантанасы булды, Рөстәм Миннеханов рәсми рәвештә Татарстан Республикасы Президенты вазифасына кереште.

ТР Президентын сайлауда Рөстәм Миннеханов өчен 2 миллион 306 мең 844 кеше тавыш бирде. Бу — сайлаучыларның 94,4 проценты (калган кандидатлардан Рушания Билгилдеева — 1,68, Хафиз Миргалимов — 2,56, Руслан Йосыфов 0,81 процент тавыш җыйды) дигән сүз. ТР Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Әгъзәм Гобәйдуллин Рөстәм Миннехановка 2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Президенты булып сайлануы турында таныклык тапшырды.

Инаугурация тантанасын ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ачты. Залга Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Дәүләт Флаглары, Татарстан Республикасы Президенты штандарты кертелде. Сәхнәдәге президиумга — РФ Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Михаил Бабич, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Төркия Республикасының икътисад министры Нихат Зәйбекчи, Казакъстан Республикасы Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дарига Назарбаева, РФ элемтә һәм гаммәви коммуникацияләр министры Николай Никифоров күтәрелде. Залга көчле алкышлар астында Рөстәм Миннеханов керде. Ул ТР халкына тугрылыклы хезмәт итү, ТР гражданнарының ирек һәм хокукларын тәэмин итү, РФ Конституциясен, ТР Конституциясен һәм ТР законнарын үтәү, үзенә тапшырылган ТР Президенты вазифаларын намус белән башкару турында ант итте. Михаил Бабич Рөстәм Миннехановка РФ Президенты Владимир Путинның котлавын ирештерде. Казакъстан Республикасы Президенты Нурсолтан Назарбаев исеменнән — Дарига Назарбаева, Төркия Республикасы Президенты Рәҗәп Эрдоган исеменнән Нихат Зәйбекчи да котлау текстларын укыдылар. Минтимер Шәймиев Рөстәм Миннехановның беренче сроктагы эшчәнлегенә бәя биреп, бу елларның гаять көчле социаль-икътисади үсеш чоры булуын әйтте. Тантанада чыгыш ясаган ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев сүзләренә караганда, халык Президентны сайлаган икән, ул киләчәктә дә Президент булып калырга тиеш.

Инаугурация тантанасында Казан шәһәре мэры Илсур Метшин, «Татнефть» ААҖнең генераль директоры Наил Маганов, КФУ аспиранты Анастасия Ануфриева һ.б. чыгыш ясады.

### ТР МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ ЯҢА СОСТАВЫ

ТР Дәүләт Советының унынчы утырышында каралган төп мәсьәләләрнең берсе — ТР Премьер-министрын, вице-премьерларны раслау, шулай ук Министрлар Кабинетының яңа составын формалаштыру. ТР хөкүмәте җитәкчесе вазифасына ТР Конституциясенең 75нче маддәсе нигезендә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов тәкъдим иткән Илдар Халиков тәгаенләнде. Премьер-министр урынбасарлары да үз урыннарында калдылар.

### ПРЕЗИДЕНТ ЮЛЛАМАСЫ

ТР Дәүләт Советының унберенче утырышында ТР Президенты Рөстәм Миннеханов парламентка еллык юллама белән чыгыш ясады. Утырышта Дәүләт Советы депутатларыннан тыш дәүләт хакимияте органнары һәм киң җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты. Президент үзенең юлламасында кризис шартларында республикабыз социаль-икътисади үсешенең төп юнәлешләрен билгеләде, халыкның тормыш-көнкүрешен тагын да яхшырту, заманча инфраструктуралар булдыру, телне, мәдәниятне саклау һәм үстерү бурычын куйды.

### ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕ

Ун ел төзекләндерүдән соң, Мәскәүдә Җәмигъ мәчете ачылды. Аны ачу тантанасында Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин, Төркия һәм Палестина лидерлары Рәҗәп Эрдоган белән Мәхмүд Аббас, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов катнашты.

### ИТАЛИЯДӘ ТАТАР МОҢНАРЫ

Дөнья буйлап сибелгән милләттәшләребезне барлау, алар белән элемтәләр урнаштыру, хезмәттәшлек итү, мәдәни бағланышларны ныгыту максаты Россиянең төрле шәһәрләреннән дистәдән артык эшмәкәрне һәм Татарстаннан сәнгать

осталарын мәңгелек шәһәр Римгә алып килде. Алар Римнен шоколад, моцарелла сырлары житештерүче предприятиеләре белән таныштылар, Рус фәнни һәм мәдәни үзәгендә үткәрелгән «түгәрәк өстәл»ләрдә катнаштылар. Әлеге үзәкнен зур залында һәм шәһәр үзәгендәге «Шустер» паркында, Изге Павел соборы янындагы мәйданда Татарстанның халык артисты Хәмдүнә Тимергалиева, жырчы Илһам Шәймәрданов, «Казан утлары» журналынын баш мөхәррире Илфак Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирза) катнашында зур концерт күрсәтелде. Бу — әлеге чараларны оештыручылар, Рим шәһәрендә яшәүче аналы-кызлы Зөһрә һәм Венера Мәжитоваларнын әлегә шундый зур масштабтагы беренче эшләре. Шулай булуга карамастан, алар инде Италиянен берничә шәһәрендә, күрше илләр — Бельгия, Франциядә яшәүче милләттәшләребез белән эшлекле элемтәләр урнаштырганнар. Италиядә узган чараларда ТРда кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле Сәрия Сабурская, Россиянен Италиядәге илчелеге сәркатибе, милләттәшебез Данис Бәширов та катнашты.

## МӨСЕЛМАН КИНОСЫ ФЕСТИВАЛЕ

Казанда XI халыкара мөселман киносы фестивале булды. Быел анда 53 илдән 150 кинофильм күрсәтелде. Шунын 7се — Татарстаннан. Фильмнарга танылган актёр, режиссёр Владимир Меньшов житәкчелегендәге дәрәжәле жюри бәя бирде.

Режиссёр Садык Шер-Нияз төшергән «Курманжан Датка» (Кыргызстан) фильмы фестивальнен баш бүләген алды. Режиссёр Салават Юзеевнын «Ишекне шапылдатып ябып чыгып китте» фильмы «Ин яхшы кыска метражлы фильм» һәм «Ин яхшы ир-ат роле» (Илдус Габдрахманов) номинацияләрендә жинеп, берьюлы ике бүләккә лаек булды. «Рудольф Нуриев. Рудик» фильмы (режиссёры Фәрит Дәүләтшин, сценарий авторы Рабит Батулла) «ТЮРКСОЙ»нын махсус призы белән билгеләп үтелде. Казан шәһәре мэры призы Софья Гобәйдуллина турындагы фильм өчен режиссёр Степан Беловка тапшырылды. Габдрахман Әпсәләмов әсәре буенча эшләнгән «Ак чәчәкләр» фильмы (режиссёры Ренат Әюпов, генераль продюсер Миләүшә Айтуганова) «Татар әдәбиятын экранлаштыруга өлеш керткән өчен» дигән призга ия булды.

## МӨСЛИМДӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

Мөслимдә татар әдәбияты көннәре үткәрелде. Язучылар районның янартылган үзәк китапханәсендә, лицейдә, гимназиядә һәм авыл мәктәпләрендә чыгыш ясадылар.

Кичен Мөслим Мәдәният йортында «әкиятче бабай» Зариф Мөэминовнын (1893-1966) «Мажара» исемле китабын тәкъдим итү кичәсе булды. Китапны Мөслим туфрагында туып үскән язучылар Мөжәһит Әхмәтжанов белән Факил Сафин гарәпчә имлядан тәржемә итеп чыгарган.

Әлеге сәфәр Казанда ук Мөслимнән чыккан шагыйрь Зөлфәтнен Яна Бистәдәге зиратына чәчәкләр салу белән башланган иде. Язучылар туган якларында жирләнгән Харрас Әюпов, Наис Гамбәров, Флүс Латыйфи һәм Зариф Мөэминов каберләрен дә зиярәт кылды. Искә алу мәрасимендә мәрхүм әдипләрнен авылдашлары да катнашты. Татар әдәбияты көннәрендә катнашучы Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов житәкчелегендәге зур делегацияне (анын составында ТРнын халык шагыйрьләре Разил Вәлиев, Рәдиф Гаташ, ТРнын халык язучысы Фоат Садриев, шулай ук журналыбызнын бүлек мөхәррире Камил Кәримов та бар иде) Мөслим муниципаль районы башлыгы Рамил Муллин озатып йөрде.

## ЯҢАРТЫЛГАН ТУКАЙ КЛУБЫ

Казаннын Бауман урамында, элеккеге Матбугат йортындагы (хәзерге «Нугай» кунакханәсе) Тукай клубы реконструкциядән сон янадан ачылды. Аны ачуга багышланган әдәби мәжлестә төп чыгышны «Татмедиа» акционерлык жәмгыяте генераль директоры кинәшчесе, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин ясады. Үзләренен әлеге клуб белән бәйле истәлек-хатирәләрен Татарстанның халык язучылары Гәрәй Рәхим, Марсель Галиев, шагыйрь Әхмәт Рәшитов, «Татмедиа» акционерлык жәмгыяте генераль директоры кинәшчесе, публицист Римзил Вәлиев һ.б. уртаклашты. Әдәби мәжлесне «Татмедиа» акционерлык жәмгыяте генераль директоры урынбасары Сөмбел Таишева алып барды. Соныннан Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов турында Арча телерадио компаниясе «Казан арты» тарих-этнография музее белән бергә төшергән фильм күрсәтелде. Әлеге фильм турында фикер алышуда әдәбият галиме Фоат Галимуллин, «Мәдәни жомга» газетасы баш мөхәррире Вахит Имамов, Арча әдәбият һәм сәнгать музее директоры Шәфигулла Гарипов, Гариф Ахуновнын кызы, шагыйрә Наилә Ахунова һ.б. катнашты.

## ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Республиканын халыкара абруен ныгытудагы аеруча зур казанышлары, Татарстанның тарихи-мәдәни һәм рухи мирасын саклап калуга, торгызуга һәм популярлаштыруга әһәмиятле өлеш кертүе, актив жәмәгать эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе ШАЙМИЕВ Минтимер Шәрип улы «Дуслык» ордены белән бүләкләнде.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: роман Р.КАРАМИ «Куда бежишь, скакун моей жизни?»; исторический роман В.ИМАМОВА «Сулейман султан»; стихи А.СУФИЯНОВА, Р.ДЖАМАЛА, Ф.ЗИЯТДИНОВА, Ф.ЗИЯТДИНОВОЙ; рассказы А.ЮНУСОВОЙ.
«Конкурс на повесть малого формата»: Г.АДГАМ. «Один из тысячи».
«100-я страница»: Р.БАТУЛЛА. «Не дадим маху!»
«Литература народов России»: стихи В.ХЛЕБНИКОВА с предисловием Р.ХАРИСА.
«25 лет новой государственности Республики Татарстан»: «Круглый стол» с участием Р.ХАКИМА, Р.ВАЛИЕВА, Ф.САФИУЛЛИНА, Д.ИСХАКОВА, Р.ЮНУСА.
«Наши юбиляры»: статья Л.МИНГАЗОВОЙ к 70-летию Дж. ДАРЗАМАНА; статья М.МАЛИКОВОЙ к 75-летию М.ШИГАПОВА; статья Г.БАЙРАМОВОЙ, посвящённая 150-летию национальной библиотеке РТ; статья М.ВАЛИЕВА, посвящённая к 110-летию со дня издания газеты «Нур».
«История»: Н.ГАРИФ. «Город называется «Чаллы»!
«Рассказы из жизни»: рассказ М.ГАЙФУЛЛИНОЙ.
«Творчество читателей»: рассказ З.САЛИХОВОЙ.
«Слово педагога»: статья З.ГИБАДУЛЛИНОЙ, посвящённая творчеству Йолдыз ШАРАПОВОЙ.
«В литературных объединениях»: стихи Б.АЮПОВА, Р.ГИЛЬФАНОВОЙ, Ф.ГРИГОРЬЕВОЙ, Л.ГОЛЕМОВОЙ, Э.ИХСАНОВОЙ, Р.КАЛИМУЛЛИНА, Э.МИНГАЗОВОЙ, А.НУГМАНОВОЙ, Г.АКСАНОВОЙ с предисловием Р.КАЛИМУЛЛИНА.
«Белый парус»: Г.КУТУЙ. Повесть «Приключения Рустема» (прод.); рассказы Х.ИСМАГИЛОВА, Э.РАЗОВОЙ, Н.ВАЛИЕВОЙ.
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Казанская царица Сююмбике в плену у Ивана Грозного. *Работа Ильяса Файзуллина*; Новый фонтан в Лядском саду. *Фото Евгении Павловой*.

# IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novel by R.KARAMI «Where are you running, the horse of my life?»; historical novel by V.IMAMOV «Suleiman Sultan»; poems by A.SUFIANOV, R.JAMAL, F.ZIYATDINOV F.ZIATDINOVA; stories by A.YUNUSOVA.
«Competition for a small format story»: G.ADGAM. «One of thousands».
«100th page»: R.BATULLA. «Don't let the fluff!»
«Literature of peoples in Russia»: poems by V.KHLEBNIKOV with Foreword by R.HARRIS.
«25 years of new statehood of the Republic of Tatarstan»: «Round table» with participation of R.HAKIM, R.VALIEV, F.SAFIULLIN, D.ISKHAKOV, R.YUNUS.
«Our heroes of the anniversary»: article by L.MINGAZOVA to 70th anniversary of J.DARZAMAN; article by M.MALIKOVA to 75th anniversary of M.SHIGAPOV; article by G.BAYRAMOVA devoted to the 150th anniversary of the National library of the Tatarstan Republic; article by M.VALIEV devoted to the 110th anniversary from the date of the edition of the «Nur» newspaper.
«History»: N.GARIF. «The city is called «Chally»!
«Stories from life»: story by M.GAYFULLINA.
«Creativity of readers»: story by Z.SALIKHOVA.
«Teacher's word»: article by Z.GIBADULLINA devoted to creativity by Yoldyz SHARAPOVA.
«In literary associations»: poems by B.AYUPOV, R.GILFANOVA, F.GRIGORYEVA, L.GOLEMOVA, E.IKHSANOVA, R.KALIMULLIN, E.MINGAZOVA, A.NUGMANOVA, G.AKSANOVA with Foreword by R.KALIMULLIN.
«White sail»: G.KUTUY. Story «Rustem's Adventures» (cont.); stories by H.ISMAGILOVA, E.RAZOVA, N.VALIYEVA.
«Pages of humour»: section is conducted by M.GALIEV.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Kazan Queen Syuyumbike in captivity at Ivan the Terrible. Work by Ilyas Fayzulin; New fountain in the Lyadsky garden. Photo by Evgenia Pavlova.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Иван Грозныйнын Казан патшабикәсе Сөембикәне әсирлеккә алуы. *Ильяс Фәйзуллин эше.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Лядской бакчасындагы яңа фонтан. *Евгения Павлова фотосы.*

# Яңа китаплар




**Әнәс Хәсәнов.**
**БӘХЕТ КАЙДА ОЯ КОРА.**
*Роман, хикәяләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. — 319 б. Тиражы — 2000 данә.*

Язучы Әнәс Хәсәновның бу романында яшь замандашларыбызның җәмгыятьтә тирән иҗтимагый үзгәрешләр чорында – XX гасыр ахыры – XXI йөз башында – Россиядә яңадан аякка басып килүче кыргый капитализм шартларында бәхеткә омтылулары, эзләнү, хаталары, югалту-табышлары аша тормышта үз урыннарын табулары тасвирлана.
Язучының геройлары – ихлас күңелдән яратып сурәтләнгән олылар, гомерләрендә күпне күргән хезмәтчәннәр, тормышны сөеп яшәүче милләттәшләребез.




**Госман Гомәр.**
**ДАҺИЛАР МӨНБӘРЕ.**
*Истәлек-хатирәләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. — 303 б. Тиражы — 2000 данә.*

Китапка узган гасыр башыннан алып бүгенгәчә, йөз елдан артык вакыт эчендә яшәп, иҗтимагый, сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышыбызда тирән эз калдырган, күбесен автор үзе яхшы белгән, бергә эшләгән, якыннан аралашкан шәхесләр турында истәлек-хатирәләр туплап бирелгән.

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2015
Парклар һәм
Скверлар елы



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)